# Казан утлары

2

ФЕВРАЛЬ

1969



ФАТИХ КӘРИМ

[1909—1945]

М. РӘХИМОВ рәсеме

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**2**

ФЕВРАЛЬ
1969

## Бу санда

ПОЭМА, РОМАН, ШИГЫРЬЛӘР.

С. ХӘКИМ. Дуга. Поэма. . . . . . . . . . . 3
А. РАСИХ. Каһарманнар юлы. Роман. . . . . . 10
Ә. ДАВЫДОВ. Йокысыз төннән соң. Роман-симфония . . . . . . . . . . . . . . 55
Г. ГАЛИЕВ. Бөтенесе дә бергә. Хикәя. . . . . . 66
Г. АФЗАЛ. Нишләдең син, Пушкин; Фәлсәфәне ничек кенә боргалама; Мең төрле; Тукай турында уйлангада; Рәхәт булып; Суык җилләр; Якты уйларымның. Шигырьләр. . . . . . . 73
Р. ГӘРӘЙ. Кайгырма дилләр дуслар; Урман аша уза поездлар; Чишмәләрдә тәңкә чыңы; Ап-ак бәхет булып; Зиратына килдем; Әй, кайда син, яшьлек; Истәлеккә калган каурыйлар. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . 75
М. ХӨСӘЕН. Сонетлар. . . . . . . . . . . . 77
М. ШАБАЕВ. Кашкарыйлар сары; Ра-ра-о-ом; Соңлый язган тәүбә; Чыршы урыны — урманда. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 79
М. САДЫЙКОВ. Балыкчы карт; Көн буе...; Юлда; Юлдагы уйланулар. Шигырьләр. . . . . . . 81
Н. МАДЪЯРОВ. Аерылабыз...; Ялгыз гына...; Балкый офык...; Язгы ташкын...; Җитсен, дидем... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 83

ИСТӘЛЕКЛӘР, ХАТЛАР, ЯЗМАЛАР

Фронтка да, фронттан да . . . . . . . . . . 84
А. ФАДЕЕВ. Полк командиры. . . . . . . . 87
М. НОВИГАТСКИЙ. Кутуй Катуков танкистлары арасында . . . . . . . . . . . . . . . 91
М. КУТУЕВА. Кутуйны сагынам. . . . . . . . . 95

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МОСТАФИН. Бәхәс дәвам итә. . . . . . . . 96

БАТЫРЛАР КИТАБЫНА

И. ЗӘБИРОВ. Җәлил көрәштәшләре. . . . . . . 110
Әхмәт Симаев — Җәлил дусты. . . . . . . . 118
Ш. РӘКЫЙПОВ. Егерме икенең берсе. . . . . . 123
А. МАРЧЕНКО. Дуслык кичтә утлы юлларны. . . 130

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Ф. ДУНАЙ. Бәхетле син, Бәхетгәрәй. . . . . . 136

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ә. НӘҖИП. «Котадгу белег» әсәренә 900 ел. . . 142

ХАЛЫК ИҖАТЫ

З. НУРИ. Партизан уклары. . . . . . . . . . . 148

ФРОНТ МАТБУГАТЫННАН

М. САДРИ. Фронт газетасында басылган сатирик шигырьләр . . . . . . . . . . . . 151

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

И. ИЛЯЛОВА. Исеме — Ринат аның. . . . . . . 154

ТӨРЛЕСЕННӘН

Ә. ИСХАК. Г. ИШМӨХӘММӘТОВ. Күңелсез кимчелекләр. . . . . . . . . . . . . . . . 160

ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Л. ГАДИЛОВ. Дипломат. . . . . . . . . . . 167
Безнең сафка. . . . . . . . . . . . . . . 179

БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

П. ЧЕРНОВ. Халык мәхәббәте — иң зур бүләк. . 181

СЕЗНЕҢ КИТАП КИШТӘГЕЗГӘ

ЗӨЛФӘТ. Минем елмаю. . . . . . . . . . . 184
С. ХӘКИМҖАНОВ. «Ике аккош» турында. . . . 185

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

Ш. ГАЛИЕВ. Аптырагач; Үзең нинди. Шигырьләр. 187
З. НУРИ. «Үзтәнкыйтьче»; Уң кул белән сул аяк; Кино сөюче сүзе. Шигырьләр. . . . . . . 188
Ш. МАДРИШ. Эзе бар. Шигырь . . . . . . . 188
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . . 189

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники,Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафинъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 13/XII-1968 ел. Басарга кул куелды 27/I-1969 ел. ПФ 09078.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84246 экз.
Заказ Д-2050. Бәясе 50 тиен

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1969 ел.

## Сибгат Хәким

# ДУГА

*Бу әсәрем минем — истәлек-биография. Бөек Ватан сугышында мин гел бер дивизиядә — 375 нче (соңыннан Харьков исемендәге) дивизиядә хезмәт иттем. Бу дивизия 30 нчы армия составында башта Калинин фронтында озак сугышты, аннан 1943 елның мартында аны Елец аша Белгород юнәлешенә күчерделәр. Бу — Воронеж фронты. Безнең дивизия Белгородка 12 километр кала Ерик авылы участогында оборонага урнашты, шунда торды, немецларның бишенче июльдәге һөҗүмен шунда каршылады.*

*Воронеж фронты... Соңыннан ул Дала фронтына әйләнде. Дала фронты тора-бара Икенче Украина фронты дип йөртелә башлады. Исемнәре үзгәрсә дә, фронт фронт булып калды... Юлым шул фронтлар буйлап үтте.*

*Дуга сугышлары Сталинградтан кала иң зур сугышлардан санала. Мин аның бары бер участогында гына булдым, мин бит бары взвод командиры гына, взводның биләгән урыны тар, кечкенә. Күргәннәрем күбрәк Ерик белән бәйле. Әсәрдә шул участоктан читкә чыгарга батырчылык итмәдем...*

*Дуга сугышлары... Дуга турында иптәшләргә күп сөйләдем. Язмавым өчен алар тиргәделәр. Бөтенләй язмадым түгел, яздым, «Курск дугасы» исемле йөз юллык әсәрем бар...*

*Дугада оборонада алып барган язмаларымны һөҗүм вакытында югалттым. Шуннан соң күңел төште, күңел сүрелде. Тагын бер психологик сәбәп: уттан бер чыкканнан соң икенче тапкыр керәсе килми. Әсәргә алыну минем өчен утка яңадан керү белән бер. «Урләр аша» поэмасында да Дуганы читләтеп үттем. Кыскасы, «Дуга» егерме биш ел буена кырыйда калып килде. Язучы өчен, бәлки, кайвакыт шулай ара калдыру да кирәктер. Вакыт үзү белән вакыйгалар ачыграк күренә төшә.*

*Ләкин зур вакыйгаларны язучының онытуы мөмкин түгел. 1968 елның апрелендә мин, үз теләгем белән, хисләремнең кушуы буенча, үзем сугышкан урыннарга барып чыктым. Халыкта: исенә төшсә исе китә, дигән сүз бар. Мин дә, хисләрем бер кузгалса, шулай, берничек тә туктатырмын димә... Ерикка барып чыктым. Үземне тагын бер кат тикшердем: чыннан да мин шунда сугышып йөрдемме соң? Чирек гасыр узгач күңелдә шундый сәер хис туа икән. Дөрес икән, чын икән. Уйларны-истәлекләрне яңарттым. Куаклыклар арасындагы траншеяларның саргаеп эзләре генә беленеп тора. Күптән язылган хаттагы юллар кебек, сагышлы, моңсу... Авыр булса да яшьлек шунда узган, миңа ул чакта 32 яшь иде...*

*Башта проза белән язарга исәп бар иде, материал күп, зур. Бөтенесен дә әйтеп бетерәсе килә. Язарга утыргач, прозаны шигырь җиңде. Ә шигырь җентекләп язуны яратмый. Ни булса да, мин, хисләрем артыннан ияреп, шигъри әсәремә кереп киттем.*

*Дугада узган җиде көн, чирек гасырдан соң шигырьнең Дугада җиде көн эчендә туган кичерешләре, солдат кичерешләре, Ерик кечкенә, ләкин аның да ташыган чагы булды...*

**АВТОР**

## Дугада беренче көн

Минем кебек бәхетлеләр сирәк,
Дуслар монда кабат аз кайткан...
Карап иске ориентирларыма,
Машинадан төшеп, асфальттан
Киттем кереп Дуга кырларына.
Теге чакта ятып инешкә
Бит юасы килгән иде, хәзер
Хозурланма шуңа иреш тә.
Күңел түзми... Ерик авылы ничек?

Нәрсә калды икән искедән,
Үзгәргәнме, юкмы? Һәр адымда
Кызыксынган сәер хис белән
Киттем кереп Дуга кырларына...
Ә сугышы? Алда — ул хакта.
Йөр син монда чирек гасырдан соң
Тездән батып кара туфракка.
Йөр син җирнең дымсыл исен иснәп...
Сугылырсың кайчан син кабат?
Миналардан күпме тазартылган,
Сугыштан соң күпме сукалап,
Чәчелгән җир, сугыш шомы һаман
Ята өстә, сеңгән эңгергә,
Әйберләргә сеңгән, сугыш төсе
Китмәс төсле җирдән гомергә.
Ничек итеп сыйдыра аладыр ул
Борчуларның эчке, тышкысын
Җыйган күңелем, ирек бирәм аңа,
Бар дөньяга, әйдә, кычкырсын.
Шатлыгымны кычкырсын ул минем,
Якты хыял әле күп миндә,
Тимер-җиргә, шул магнитлы җиргә,
Зур бәхетләр теләп Губкинга [1],
Киттем кереп Дуга кырларына.
Сөргән җирләр буйлап атлыйм да
Ышанмыйча торам, мин Дугада —
Чирек гасыр узгач, апрельдә.
Торам кырда, яшьлегемне көтәм,
Үр артында аваз: тиз кайтыр...
Торам уйлап, элек мине монда
Чүкеп алыр иде снайпер.
Ерик колхозының бакчалары
Артындагы тирән казылма
Ята шулай, танкларга каршы,
Кырык өченең авыр язында
Без казыган идек төннәр буе...
Ул кыен яз — барыбер минем яз,
Кай төшләрдән борылып йөрде икән
Минем яшьлек? Кайда блиндаж?
Блиндажның нәкъ өстендә һәйкәл —
Автоматлы солдат... Без уттан
Чыктык, таралыштык, ә ул тора
Бөтенесе өчен взводтан.
Траншеялар өстендә таш мәктәп
(Күзләремдә шатлык, яшь бүген),
Аскы катта минем буын, өске
Катларында аның яшь буын.
Кайный яшьлек, кайный тормыш, тормыш
Үз дигәнчә йөри эш итеп,
Сугышларның өсләренә таштан
Сарайларын сала үч итеп...
Теге чакта, теге чакта мин шул
Устав кушкан белән чикләндем.

---

[1] Белгород өлкәсендәге яңа шәһәр.

Гел күзәтеп торган чиркәүнең
Бер күрәсе килгән иде эчен,
Әз генә дә хәзер шүрләмим,
Күңел кушты, һәм менәргә булдым
Серле чиркәү торган үргә мин.
Таныш чиркәү, шыксыз соры чиркәү,
Әгәр чиркәү кинәт еласа,
Гаҗәпләнмәм, снарядлар яуды
Таш юл аша, тимер юл аша.
Үрдә кемдер, күрәм, көтә мине,
Шикләнгән һәм бераз сагайган
Бер кыяфәт белән кузгалмыйча
Көтә мине, чыгып сарайдан.
Шик тудырмас өчен мин дә читкә
Борылмадым, туры сарайга
Бара бирдем, белсен, нигә монда
Йөргәнемне әйтеп сал аңа.
Чиркәү кебек ялгыз, чиркәү кебек
Ят тоелды миңа башта ул,
Әйтерсең лә, сугыш бетү белән
Шушы үргә менеп баскан ул,
Көткән гүя чирек гасыр буе,
Тузан гына, йөзе бәләү күк,
Ул ашадан аша күрә мине,
Ул ашадан аша белә күк.
Кырлардагы һәр калкуда күзе...
Тора кеше... сөргән, чәчкән ул.
Сабыр гына: — Без бер частьтан,— диде,
Мин дә әчтән: «Безнең частьтан ул».
Үзем уйлыйм: тукта, минем белән,
Минем белән кайда булды ул?
Сыный гүя, сугышып үлгәннәрдән
Вәкил сыман пәйда булды ул.
— Карт солдатсың икән, ориентирга
Төртеп күрсәт, карап син торма,
Без сугышкан урынны син күрсәт,
Утыр, әйдә, мотоциклга...
Алда безнең зур иманлек иде.
«Солдатларың санап ал кабат!..»
Иманнарнең бер төркеме кырда
Баскан чыгып бераз алгарак.
Иманнарне ул тикшереп торган,
Кистермәгән, махсус санаткан.
Карт иманнар... Дуга кырларыннан
Җыелганнар кебек солдатлар...
Хат алгандай кайсы бик шат, кайсы
Җырлый кебек, сагыш кайсында,
Һәркайсында кемендә йөз яра,
Баһадирлар тора каршымда.
Кыргыз, диде, башкорт, диде кайсын,
Кыенсынды исемен атарга,
Батырлар бар төштә — татарлар бар,
Кимендә бер урын татарга.
Кешеләрне исемлектән түгел,
Вакыйгалар буйлап ул таба.

Бусы — Низам... Җиләндерел аны
Карт иманнәр алган уртага.
Кызык нәрсә сөйли көбек Низам,
Сүз кыстырма читтән Низамга,
Дуга кырын яңгыратыр төсле
Бер кычкырса басып ызанга.
Ә үзе кем? Ул Степан Бурмак.
Табыштыгыз ничек? диярләр.
Һич башкача түгел, нәкъ язганча,
Тормыш реаль, бар да реальләр...
Шулай башлап, шулай тәмамладым
Мин беренче көнен Дуганың.
Чирек гасыр узгач, бер иркенләп
Дугадагы өйдә кунамын.
Уйлап ятам: ник ашкындым монда?
Күңелемдә сорау туа да
Җавап эзлим, нәрсә соң мин эзлим
Тигезләнгәч бар да Дугада?
Син безгә тиеш идең уттан,
Син үлемнән үттең, эзләрең
Суынмады, кире кайта-кайта
Нигә эзлим утның үзәген?
Сугышкансың, азат итешкәнсең,
Илең җиңгәч, бөек алкышка
Кушылгансың, инде хәзер яшең
Якынлашкан чакта алтмышка
Нәрсә калган Дуга кырларында?
Шуннан артык нидер дауларга
Кемнең ни хакы бар? Туктый-туктый
Күтәреләм ник ак тауларга?
Уйлап ятам... Шагыйрь түгел, солдат
Булганына күңел куана,
Сагаласын иске үлемем, барыбер
Барган булыр идем Дугага...

## Дугада икенче көн

Яңа салган йортта кундым үзем,
(Аякларым, билем языла),
Төшләр ләкин кайтардылар мине
Тагын иске блиндажыма.
Күнегелгән икән блиндажга,
Оныт, имеш, аны, без аннан,
Блиндажда Бурмак Степаннар,
Каекбайлар белән Низамнар.
Язмышларны бер урынга җыеп,
Миңа хәзер бер җеп төйнәсе,
Үткәннәрем кабатлана төштә,
Гел газаплый Ржев тирәсе.
Еллар буе кабатлана алар,
Газаплары җанның бетмәде,
Шул Калинин фронтының кышы,
Чаналарга җиккән этләре
Керә төшкә, дулый бураннары,

Сыкрый нарат, сыкрый чыршылар,
Буран бары зәһәрләнә төсле
Ынгырашу белән шыңшудан.
Күз алдымда һаман бураннары,
Яралары туңган солдатлар...
Этләр генә белә кебек җирдә
Кар астында күпме санбат бар.
Кайчак Низам үзе җигелеп тартты,
Чокырларны күрсә — урады,
Хәлдән таеп кайчак, ятып карга
Этләр белән бергә улады.
Туплар улый, этләр улый — барысы
Әйләнә бер шомлы улауга...
Яралылар ыңгыраша — сигнал,
Кузгалалар тагын, ул — алда.
Буран тынса, ашыктырды Низам,
Көне-төне чапты Сарбайлар,
Сарбайлары җылы ояларын,
Йорт-җирләрен уйлап саргайган.
Чапты алар яшь чакларын уйлап,
Ялбырдады җилдә йоннары,
Низам эчтән әкрен генә итеп
Яралылар өчен җырлады...
Ачуланса, этләренә түгел,
Дошман ягына карап акырды,
Ул куркыныч кырлар уртасында
Юлларымны бик еш аркылды...
Язга чыккач, тагын күрдем аны,
Мина ташып йөрде атта ул.
Ни өчендер мин ярата идем
Ат янынннан аның атлавын.
Ышанычлы, эре, салмак адым...
Әйткән сүзе: утта, алда сез...
Үзе ничек котылгандыр, белмим,
Калды беркөн атсыз, арбасыз.
Очрашканда атын мактый иде,
Машинаның көче көч түгел...
Эттән — атка, аттан — утка, шулай
Тора-бара безгә күчте ул...

Ржев яны, Ржев сугышлары...
Адымыңны санап уз алга.
Немецларның казык какканы да
Ишетелеп торды Низамга.
Шомлы өннәр, төнге өннәр, төннәр...
Өлгермисең төнне чыгып та,
Яңа һөҗүм, ыргыласың алга
Шинель ташлап тимер чыбыкка.
Яңадан төн. Казык каккан тавыш...
Уздыруы кыен бер төнен.
Кеше төсле үксеп, куаклыкта
Балалары җылый төлкенең.
Низамның да балалары җылый,
Иң кечесе башлый, уртанчы
Кушыла сыман, посттан бушагач та
Йокламады Низам бер тамчы

Йокламады, шул җылаган тавыш
Торды һаман колак төбендә.
Тапты Низам: төлке балалары
Ята аунап куак төбендә.
Куаклыклар арасында йөреп
Юешләнгән аның өс-башы...
Тапты Низам: төлке балалары
Эссе көндә балта остасы
Читкә аткан бияләйләр кебек,
Ята җирдә, кеше булып та
Караганнар җылап... Юк, аларның
Хәл ителгән эше минутта.
Актарылып калган куак төбе,
Тормыш беткән анда, ямь беткән.
Кеше булып җылаганга күрә
Җәзаланган гүя җәнлекләр.
Өең төсле, йортың төсле синең,
Куак төбе калган тын булып,
Үткән ашыгып немец разведкасы
Гранаталар анда тондырып...

Төрле хәлләр, төрле чаклар булды,
Кайгырган һәм бергә көлешкән...
Бу әрнүләр — әрнүмени алар,
Әрнүләргә бары керешләр...
Без әрнедек... Өйдә, өсне салып,
Өч-дүрт сәгать тоташ йокларга
Хыялландык, хуҗаларын җуйган,
Моң урнашкан тын, таш йортларда
Дошман утыра түрдә, төпләрендә
Амбразура ясый ул ватып,
Бернечә кат тимер чыбык белән
Бакчаларны безнең уратып
Алган да ул утыра, шул йортларга
Тупларыннан үзең бәр элек.
Ятып кырда яңгыр асларында,
Без Ржевка карап әрнедек.
Җимерелер, кабат торгызырбыз,
Без эшләми аны, кем эшләр?
Бу әрнүләр... Болары да әле
Әрнүләргә бары керешләр.
Без әрнедек... Без оныттык күптән
Бакчаларның таңгы чыкларын,
Сугышып йөреп сизмисең дә икән
Комсомолдан яшең чыкканын.
Мәхәббәттә, иҗатында, эштә
Гомерең буе тынма, ут эзлә,
Утлар кайчак оныттыра икән
Житкәнеңне хәтта утызга.
Иҗатыңда синең озак янган
Утлар кими төшсә, кем өстәр?
Бу әрнүләр... Болары да, әйе,
Әрнүләргә бары керешләр.

Син үлмәссең, күршең үләр, сине
Читләп үтәр төсле һәр үлем.

Күптән инде мин сөйләргә телим
Бөеклеген сезгә әрнүнең.
Өйгә кайту — төштә. Сугышларның
Очы ерак, бетү кайда ул.
Бөек була ала икән әрнү
Күтәрелсә эчтән кайнап ул.
Ржев чите, керәк төртсәң, җирдән
Су чәчрәп чыга — су урыны.
Житте көзе кырык икенең дә,
Сталинград көчне суырды.
Әйләнә дә ул бомбага тота,
Болыт тимер кебек кызарган.
Траншеялар тып-тын, күккә төртеп,
Ымлап кына яши Низамнар.
Өстә һәркөн тузан баганасы,
Безнекеләр ник аз, күр әваз
Ник ишетелми күктә? Безнең күктә?
Кешеләр аз бездә, корал аз.
Канатлары белән өскә дошман
Тора басып, юк ял бирәсе.
Бетте дисең, бар да бетте, дисең,
Ник күренсен бер җан иясе.
Ә бераздан җир кыймылдап куя,
Әле һаман исән, бел, абзаң
Дигән кебек тузаннарын кагып,
Каекбайлар калка бераздан,
Калка җирдән Бурмак Степаннар,
Мылтыкларын кулда чак тоткан.
Шул үлемсез Низамилар калка,
Күзләрдән яшь тама шатлыктан.
Бер зур хисне ачык татыдым мин,
Ашарга ал юлга өч көнлек,
Кимендә мең еллык булсын икән
Дошманыңнан рухи өстенлек.
Төшләр борчый: иске блиндажга
Солдатларым кереп тула да
Шаулый шулар, шулар арасында
Икенче көн үтте Дугада.

*Ахыры киләсе санда.*

**Атилла Расих**

# КАҺАРМАН-НАР ЮЛЫ

РОМАН

## I

Латиф, чемодан янына чүгәләгән килеш серле генә елмаеп, хатыны белән улын күздән кичерде, аннары чемодан капкачын ачып җибәрде. Гөлбикә белән Маратның йөзләре бердән яктырып китте. Чемодан эче җылы як җимешләре белән тулган: эре, аксыл-яшел виноградлар, итләч, баллы грушалар, кызыл яңаклы, сары хәтфә кабыклы шафталулар, кызгылт-сары әфлисуннар, мандариннар. Бүлмә эченә шунда ук тәмле ис таралды. Марат, никадәр үзен үскән егет дип исәпләмәсен, шатлыгыннан нәни балаларча сикергәләп сөенергә тотынды. Ә Гөлбикә исә күзләрен очкынландырып елмайган хәлдә:

— Кара! Ни юл килеп бер бозылмаган! — дип куйды.

— Бозылмый,— диде Латиф,— самолет бит ул! — Аннары малаена мөрәҗәгать итте: — Улым, сайлап ал әле үзең теләгәнне генә!

— Ярар инде, әлек бушатыйк,— диде Гөлбикә.

— Алсын, алсын!

— Я, сайлап ал алайса, улым, тик юып ашарсың,— диде әнисе.

Марат бер мәл кулларын уып, күзләрен елтыратып карап торды, аннан: «Вот это да-а!» дип, йодрык зурлыгындагы грушаны алды.

— Хәзер инде син,— диде Латиф, хатынына карап.

— Ходаем, миңа дамыни әле? Бәлки мин сайламыйча гына барысын да алырмын?

Гөлбикә бүлмәне яңгыратып көлеп җибәрде.

— Юк, юк,— диде Латиф, житдилеген саклап.— Алып аша бүлгач, аша! Мин бит сине беләм, Гөлкәй, юкса син аларны безгә генә ашатып бетерәчәксең.

Хатыны бер шафталуны алып, юарга дип, кухня якка чыгып киткәч, Латиф:

— Мин дә,— дип, бер виноград тәлгәшен сабагыннан өзеп алды.

Бераздан алар өчәүләшеп кухня якта җылы як җимешләре белән сыйлана башладылар. Өчесенең дә әледән-әле карашлары очраша, һәм күзләрендә татулык, иминлек, бәхет чагыла иде.

— Әллә, картым, исән-сау кайтып житсәм, ишектән керү белән үзләрен сыйлармын дип нәзер әйткән идеңме? — дип елмайды Гөлбикә.

Латиф ни өчендер бу шаяртып әйтелгән сүзләргә келмәде дә, елмаймады да. Киресенчә, минем андый кеше булмаганлыгымны беләсен бит, дигәндәй, башын кыйшайтып, авыр кара кашларын гына хәрәкәтләндереп алды.

— Әти, ә теге әйберне оныттың штоли? — дип сорады кинәт Марат.

Латиф тәнбиһле елмаю белән имән бармагын өскә күтәрде.

— Менә җен малай, бөтен эффектыны боздың!

— Юк, юк, мин бер сүз дә әйтмәдем, әйтмәдем, әти,— диде Марат, чиксез куанып.

— Юк, болай булмады инде,— диде Латиф, күнелсезләнә төшеп,— мин сюрприз ясарга җыенган идем, ә син онытмагансың икән, шельма.

Улы куанычыннан шыркылдап көлгән арада Латиф караңгы коридорга чыгып китте. Бераздан ул Маратка дип алган су асты мылтыгы күтәреп керде. Маратка аквалангистлык шаукымы кагылган иде. Яз башыннан бирле инде ул, мылтык алып бир дип, Латифның колак итен ашады. Хәзер мылтыкны күргәч, егет, шатлыгыннан ни эшләргә белмичә, әтисенең битләреннән үбәргә кереште.

— И-и, менә бит әтиең сине ничек ярата! — диде Гөлбикә.— Моның өчен нишләргә кирәк инде?

Марат кулындагы хикмәтле мылтыкны тикшерә башлады. Ләкин әнисен дә җавапсыз калдырмады, чөнки аңардан нәрсә көткәннәрен тоя иде.

— Тагы — әйбәт итеп укырга да,— дип куйды ул, кыюсыз гына.

— Менә шул шул, улым,— диде әнисе,— менә хәзер үк безгә сүз бир. Быел син бары дүрткә и бишкә генә укырга тиеш. Булдымы?

— Булды,— диде Марат.

— Син әйбәтләп әйт, дүрткә и бишкә генә укыйм, диген.

— Ну әйттем ич инде,— диде Марат, рәнҗүле күзләрен тутырып.

Латиф әле генә Кара диңгез буеннан курорттан кайтып төшкән иде. Ләкин никадәр генә ул яклар купшы, назлы булмасын, Латиф үз өенә кайтып кергәч кенә бәхеткә тарганын җаны-тәне белән тойды. Ул бары әле генә ял тәмен татыгандай булды.

Менә аның яши торган җире шушы инде. Әле быел гына ремонт ясалган өч бүлмәле квартира.

Латиф, үзе дә тоймастан, нидер эзләгәндәй, бүлмә ишекләрен ачып, карап йөрергә керешге. Сәер, бик сәер иде. Гади генә ванна бүлмәсе дә, стеналардагы сыек яшел фонга йөгерткән алтын накат та, ялтыр телен тыныч кына хәрәкәтләндереп торган зур сәгать тә, диваннар, секретерлар, шторалар — барысы-барысы ана тынычлык бирәләр, үз итеп, якын итеп аны каршылыйлар иде. Латиф үз бүлмәсенә кереп өстәл янына утырды. Ул үзган бер ай чамасы вакыт эчендә өен дә, хезмәтен дә, семьясын да, бергә эшләгән иптәшләрен дә, хәтта, артык өнәмәсә дә, трест управляющие Габделмөэминевне дә сагынган иде. Менә шушы җыйнак, елкылдап торган язу өстәлен дә, шушы затлы агач караватны да сагынды ул.

Әлбәттә, әгәр ул яшь булса, утрак тормыш алып бармаган булса, болай булмас иде. Тик аның бер ритмдагы тормышка ияләшүе хәзер тәмам табигатенә сеңгән иде инде.

Ул һәр көнне сәгать җидедә уянып китә, яткан җиреннән генә үрелеп радионы тоташтыра. «Правда» газетасына күзәтү тыңлый. Тапшыру беткәч, урыныннан тора, иртәнге туалетын башкарып, гантельләр белән физзарядка ясый башлый. Бу эш тәгәлләнер-тәгәлләнмәс, аны хатыны чәй эчәргә кухня якка чакыра. Димәк, Гөлбикә табын әзерләп куйган инде, бары уналты яшьлек улы Марат кына үз бүлмәсендә изрәп йоклый әле. Әйдә йоклый бирсен! Аның укуы икенче сменада әле, шуңа күрә егетне борчып уятмыйк.

Латиф иртәнге якта күп ашамый. Сыек кына пешерелгән ике йомырка, я бер котлет, я инде, булса, берәр кисәк җиңел сеңешле ит. Инде аннан соң май ягылган, сыр куелган бутерброд белән бер стакан куе чәй эчә ул. Иртәнге аштан соң җылы су белән авызын чайкый, аннары үз бүлмәсендә электробритва белән сакал-мыегын кыра, кагыйдә буларак, күлмәк алыштыра. Өстенә костюмын кигәч, Гөлбикә аңа киемен щеткаларга булыша. Башыннан аягына кадәр киемнәрен күздән кичерә. Ниһаять, Латиф ашыкмыйча гына эшкә китә. Ул якты, иркен, биек таш йортлар тезелеп киткән урам буйлап трестка юнәлә. Җәяү генә бара. Бу сәламәтлек өчен бик файдалы.

Әйе, бу шулай бер кагыйдә булып көн тәртибенә әйләнгән. Барысы да: Латифның эшкә саф һава сулап җәяү генә баруы да, хәтта билгеле бер тизлектә атлавы да. Үзенең эш бүлмәсенә кереп утыргач, иң беренче булып язу әсбапларын тәртипкә китерүе дә, үзенә эш белән килгән кешеләрне барысын бер юлы киләмле, гөлле, иркен кабинетына кертүе дә, клиентлар белән алай артык онытылмыйча, ләкин шулай да шактый ягымлы, эшлекле бер тонда сөйләшүе дә — барысы да какшамас бер кагыйдә.

Әлбәттә, эштә һәр көнне бер үк мәсьәләләр чишеп утырмый ул. Төрлесе була. Ләкин андагы эшләрне өстәнрәк карасаң, шул ук бер төркем билгеле мәсьәләләр икәнен күрүе авыр түгел. Аларның берсе дә Латифны яңалык буларак каушатмый. Һәрхәлдә, аңа ул мәсьәләләрнең барысы белән дә, кичә булмаса, өченче көн дигәндәй, очрашырга туры килгәне бар. Аңа тагы әледән-әле шәһәрдәге һәм районнагы предприятиеләрдә булырга туры килә, кайчак ул бүлек башлыклары белән озын-озак киңәшмәләр уздыра. Ләкин болары да яңалык түгел, ул моңа да күнеккән. Аның күңеле һәр даим көр, ул беркайчан да төшенкелеккә бирелми. Аның алдында беркайчан да аптырап, югалып калырлык мәсьәлә туганы юк әле. Менә шулай көннәр хезмәт һәм күнегелгән мәшәкатьләр белән үрелеп уза да уза. Билгеле бер көйгә салынган рәвештә тыныч һәм рәхәт уза. Латиф моны үзенең авыр көрәшләр һәм ызгышлар эчендә узган яшьлеге өчен мәкафәт дип саный.

Латиф курорттан кайтуының икенче көнендә үк эшенә китте; тиз арада барысы да нәкъ моннан бер ай элек булган элекке эзгә төште. Управляющий урынбасары ялдан соң була торган күтәренкелек белән эшен башлап җибәрде. Хәер, беренче көнне үзе якын күргән коллегалары белән ул ял истәлекләрен уртаклашып ләчтит тә сатып алды. Ләкин бу тиешенчә генә микъдар вакыт алды. Ул беренче көнне үк башаягы белән эшкә чумды. Беренче көнне үк өенә соңгарыбрак кайтты. Гөлбикә ишек ачарга чыккан иде. Латиф хатынын җиңелчә кочаклап йомшак иреннәреннән үпте, ярым ачык ишектә күренгән улына көлемсерәп:

— Эшләр гөрлиме, улым? — диде. Ул пальтосын салып иркен коридордагы кием элгеченә таба юнәлгәндә, хатыны аңа:

— Бик соңладың, карткаем, нигә беренче көннән шул кадәр үк җигелергә! — диде.

— Зарар юк, эш бит. Үзе юкның күзе юк, өелгән,— диде Латиф, якты чырай белән.— Капкаларга берәр нәрсәң бармы, Гөлкәй?

— Бары да әзер!

Гөлбикә Латиф өчен табын әзерләгәндә әйтеп куйды:

— Сиңаниндидер сәер хат килде әле.

Гадәттә Латиф ашап-эчкәннән соң гына, ятар алдыннан гына, көндәлек почтаны актара һәм яткач, караватта гына аларны күзеннән кичерә иде. Хатлар мәсьәләсенә килгәндә, аңа алар башлыча эшләгән җиренә килә. Аңа хатны эш кешесе буларак, күбрәк эш турында язалар. Ә инде өйгә, үзенә адресланган хатны аның бик күптәннән алганы юк.

Хәер, моннан берничә ел элек институтта бергә укыган дус-ишләреннән, шарикләреннән хатлар килгәли иде әле. Ләкин соңгы елларда үзе дә җавап яза алмады, дуслары да муеннан эшкә чумдылар, ахры — хатлар килми башлады. Һәрхәлдә, ким дигәндә, менә ике ел инде Латифның хас үзенә атап язган хат алганы юк иде. Шуңа күрә Гөлбикәнең сәерсенүе, әлбәттә, табигый. Латиф эченнән: «Авылдаш, я кардәш-ыругдандыр. Ярдәм-фәлән сорап язгандыр берәрсе»,— дип уйланды. Ул өстен алыштыру өчен гадәтенчә үзенең бүлмәсенә керде. Күзләренә өстәлдә, газеталар өемендә, яткан конверт чалынды. Ул, чыннан да, Гөлбикә әйтмешли, «сәер» иде. Латиф аңа игътибарын юнәлтү белән хатның күз күнекмәгән ят бер конвертта икәнлеген абайлады. Кабаланып кулына алды, кәнәфигә утырды. Бер мәл конвертны ачарга базмыйча аптырап карап торды. Гаҗәпләнмәү һич мөмкин түгел иде. Чөнки хат чит илдән, чит дигәндә дә әле, тегеннән-моннан түгел, Көнбатыш Германиядән, Мюнхеннан җибәрелгән иде.

Латифның уй-фикерләре чуалып китте. Булмас ла, каян килеп, ди ул. Кемнән булсын мондый хат? Монда ниндидер ялгышлык бардыр бәлки. Бу миңа булмаска тиеш, дип уйланды ул. Мюнхен кадәр Мюнхенда кеме калган аның, кем аңа шуннан хат язсын, ул конвертка текәлеп бик озак карап торды, зиһенен тупларга тырышты. Ләкин конвертның тышына эре хәрефләр белән бик ачык итеп Латифның адресы, исеме, фамилиясе язылган иде. Бәлки бу берәр провокациядер? Бик мөмкин, дип уйланды Латиф, нинди хәлләр булмас! Ни әйтсәң дә, ул күренекле генә кеше. Нигә, булмыймыни андый хәлләр? Бик булуы мөмкин. Алай дисәң, Мюнхен дигән немец шәһәрендә дошманнар гына яшәргә тиеш дигән кагыйдә дә юк бит әле. Сугышның тыл азабын шактый татыса да, Ватан сугышында булуын булмады ул, ләкин командировкага Германиягә барып кайткалады. Билгеле, ул Демократик Республикада булды. Берлинның көнбатыш ягына ике аягының берсен атламады. Ләкин немец инженерлары, немец эшлекләре белән очрашмады түгел. Кем белә, бәлки араларында Федератив Республикадан килгәннәре дә, я булмаса соңыннан шунда качып киткәннәре дә булгандыр. Хәер, алай дисәң, хатны ни өчен өй адресы белән язарга тиеш соң алар?

Латиф хатны кулына тоткан килеш шундый юраулы уйлар эченә кереп батты. Бәлки конвертны ачып та тормастан, тиешле оешмага илтеп тапшырыргадыр? — дип уйланды ул. Бүлмәгә хатыны килеп керде. Ул иренең иңенә кулын салды да хатка текәлеп калды.

— Кемнән ул, нинди хат? — диде Гөлбикә бераздан серлерәк тавыш белән.

Бу сүзләр Латифны уятып җибәргәндәй булды. Юк, юк, диде ул эчтән генә, бу кадәр үк хөрлектән ваз кичкән куркак кеше булырга ярамый. Ни пычагыма миңа әллә кая барып йөрергә? Ул кыюланып, тәвәккәл рәвештә конвертны ертты да аның эченнән хатны тартып чыгарды.

— Хәзер белербез без аның кемнән, кайдан икәнлеген,— диде ул, бер дә исе китмәгәндәй.

Латиф, хатның гарәп хәрефләре белән язылганлыгын абайлап, өстәлдә яткан күзлеген алып киде. Аптырап җилкәләрен җыерды. Кинәт ниндидер, күңелгә нык сеңгән таныш бернәрсәгә орынгандай булды ул. Әле хатны бөтенләй укымас борын ук бу язуның үзенә ни өчендер таныш икәнлеген тойды. Бу күрәзәлек кебек соң дәрәҗәдә сәер бер хис иде. Шундый бер кичереш иде ки бу, әйтерсең лә, Латиф узгандагы ниндидер җылы һәм якын нәрсәгә орынды. Ул артык тыела алмыйча, ашыгып, каушап һәм хаттагы һәрбер ачылган яңа сүзгә тетрәнеп, кыекмыек хәрефләр тезелгән юллардан күзләрен йөгертә башлады.

— Кем, нәрсә яза? — дип пышылдады Гөлбикә.

— Ашыкма, укыйм әле, танып җиткермим,— диде Латиф. Бераздан, ул хат белән мавыгып, бөтен дөньясын, хәтта янында үзен көтеп торган Гөлбикәсен дә онытты. Йөзе ачылганнан-ачыла, күзләре нурлана, олыгаюдан бушәнләнә башлаган йөзе алсулана барды. Гөлбикә хатның әйбәт, борчусыз хат икәнлеген аңлап иркен сулап куйды.

— Миңа да әйтерсең, яме,— диде ул, тәмам тынычланып. Һәм ашыгып бүлмәдән чыгып китте.

Күп тә үтмәде, Латиф чиксез куанып урыныннан сикереп торды. Ул ишек яңагына бәрелгәнен дә тоймыйча хатыны артыннан йөгерде.

— Гөлкәй, беләсеңме бу хат кемнән?! — диде ул, бөтен кухня эчен яңгыратып. Гөлбикә хатның бик кадерле, бик якын кешедән булуын бая ук сизенгән иде инде. Әле ни әйтергә дә белмичә иренең шатлыктан ачылган көләч йөзенә сорау белән текәлде. Латиф тезеп китте:

— Хат әтидән! Минем әтидән! Әти исән! Аңлыйсыңмы, Гөлкәй, минем әти исән, исән!!!

Гөлбикә Латифның әтисе юклыгын, күптән, гражданнар сугышы елларында ук, кызыллар ягында сугышып йөреп үлеп калганлыгын яхшы белә. Хәзер каенатасының исән булуын ишетү аның өчен дә һич көтелмәгән зур яңалык иде.

— Мә, укы,— диде Латиф, хатны Гөлбикәгә сузып. Хатын, каушаудан кинәт югала төшеп, кәгазьне кулына алды. Алар икесе дә хатка текәлгән хәлдә бер утыргычка чүктеләр.

— Ходаем,— дип куйды Гөлбикә,— мин бит аны бары әнекиең сөйләве буенча гына беләм.

Гөлбикә хат укыган арада Латиф үзләрендә торып, әле моннан биш ел элек кенә вафат булган әнисен хәтерләде. Нинди зур шатлыклы вакыйганы күрми китте бит бичара ана. Яшьли ирдән калып, күп газаплар кичерде, гомере буена ирен көтте. Үлеп калды, диделәр, ышанмады. Үзебез күрдек, диделәр, аңа да ышанмады. Сизенгән икән бичара! Мәхәббәте күңел сизгерлеген көчәйткән.

Латиф үзеннән ике яшькә кече энесе Яхъяны да хәтерләде. Ул әтиләре фронтта чакны туган, әтисен күреп тә белми иде. Ләкин шулай да абыйсыннан ким шатланыр идемени ул! Әйе, аның сугыш бетә дигәндә генә шул ук герман җирендә үлеп калуы бик үкенечле булды шул...

Латиф әтисенең төсен-сынын хәтерләргә тырышты. Ләкин, кызганычка каршы, ул аны үзе дә юньләп белми иде. Аның күз алдында бары әнисе сөйләгән истәлекләр генә җанланды. Күп тапкырлар кабатланганга күрә, ахры, Латиф аларны тәмам үзләштергән иде. Һәм хәзер аерып та булмый, әллә әнисе сөйләгән, әллә үзе кичергән хәл. Алар барысы да еллар узу белән буталып беткән. Шулай да Латиф әтисен күз алдына китереп бастырды. Менә ул, кырпусыз бүрек кигән, сызылып киткән мыеклы, кара кашлы, буйчан бер авыл егете. Хәер, әнисе Латифка, әтиенә охшагансың, дия торган иде. Бәлки шуңа күрәдер. Бәлки ул үзенең яшь чагындагы кыяфәтен күз алдына бастырып ул кешегә мыек сызган, шуны авылча киендергәндер. Ләкин Латиф кинәт шул кадәресен аңлады, әлбәттә, аның кайчандыр яшь булган әтисе хәзер картайган бер кеше бит инде! Ул исәпләп утырды: әтигә хәзер кимендә алтмыш тирәсе дигән фикергә килде. Латиф шушы урында әтисенең исән булып чыгу куанычыннан туган шатлыкның сүрәнләнә башлавына игътибар итте. Үзе теләмәсә дә, күңеленә ниндидер чатак уй-шөбһәләр үрмәли башлады. Тукта, ничек соң инде ул, аның әтисе, гражданнар сугышында, ак бандитлар белән көрәштә һәлак булган кеше бит? Ничек инде ул исән? Тукта, ничек инде ул? Ул, димәк, үлмәгән һәм моңарчы дәшми-тынмый кайдадыр яшәгән. Тукта, ничек була

инде ул? Мюнхен шәһәреннән яза бит? Латифның монарчы шатлыктан балкыган йөзенә кинәт элекке сүрәнлеге кайтты. Ул куркынып Гөлбикәгә карады. Гөлбикә исә, хатны укып чыккан, хәзер хатка кулларын куйган килеш уйланып утыра иде, күрәсең, ул да нәкъ ире кебек үк үз-үзенә бер-бер артлы сораулар биреп азаплана иде. Ниһаять, ул сөрмәле яшькелт күзләрен тутырып Латифка текәлде.

— Бу дөрес микән соң?

— Әллә,— диде Латиф.— Просто башым җитми.

Ишектән уллары Марат күренде. Бу тал чыбыгыдай нәзек, озын буйлы үсмер малай, күрәсең, кухнядагы шау-шулы сөйләшүне ишетеп, эшеннән аерылган иде. Әнисе, аны күрү белән, хатны тиз генә итәгенә төшерде.

— Нәрсә булды? — диде малай, муенын сузып.

— Юк, болай гына, улым, әтиең эшендәге хәлләрне сөйли.

Барысы да тынып калдылар. Марат, бераз ышанычсыз карап торганнан соң, ишекне ябып, үз бүлмәсенә китеп барды.

— Бир әле,— диде Латиф, җәһәт кенә хатка үрелеп,— тагы бер укып чыгыйм әле.

— Берәрсенең әтлеге булмаса ярый инде,— дип куйды хатыны.

Латиф хатны кулына алды да, житди төстә:

— Алай булырга тиеш түгел,— диде.— Синең үзеңнән дә әтиең өйгә язган хатларын күргәнең бар ич. Язуы нәкъ шуныкы.

Гөлбикә бер сүз дә дәшмәде. Ирен озак кына күзәтеп торганнан соң сорамый булдыра алмады:

— Ә ни өчен ул анда барып чыккан икән соң?

Латиф, аптыравын белдереп, кулларын гына җәеп җибәрде, хатны укуын дәвам иттерде.

— Кычкырып укы әле, мин кайбер сүзләрен аңламадым,— диде Гөлбикә.

Латиф яна баштан кычкырып, шулай да күрше бүлмәдәге улына ишетелмәслек итеп, укый башлады.

«Газиз улым Латифҗан!

Бу хатны сиңа ерак җирләрдән сәлам күндереп язучы кеше синең бәхетсез әтиең булыр. Ничәмә еллардан бирле без бер-беребез илә хәбәрләшмичә сак илә сөктай дөньяның төрле якларында яшәдек. Тик язмыш бер рәхим-шәфкатен кылды. Картайган көнемдә булса да синең исән-аман икәнлегеңне белдем. Әниең дөньядан күчкән икән. Мәгәр исән калганнарыбызга ходай гомерләрен матур кичерергә язсын. Дәхи дә бу хатымны шуның өчен язам, бәгъзе хәбәрләргә караганда, мәгълүм булганча, сезнең якларга, үзебезнең ата-бабалар яшәгән, гомер сөргән якларга бездәйләргә дә барып чыгарга рөхсәт булган икән. Бу безнең кебек чит мәмләкәтләрдә каңгырып илен сагынып йөрүчеләр өчен шулай ук зур бәхет. Инде гомеремнең азагында бер илгә кайтып, туган туфракка аяк басып торсам вә сине күрсәм, миңа артык берни дә кирәкми. Син, газиз улым, минем баштан кичкәннәр белән бик кызыксынасыңдыр. Без хәбәрләшмичә торган арада күп сулар акты, күп җилләр исте. Инде мин башлардан узганны яза калсам, ул бер китап кына булмас. Шуңа күрә боларын калдырып, мин эшнең асылына күчәргә кирәк табам. Бу хатны язудан максат, улым, беренчеләй, сиңа үземнең дөньяда яшәвемне, әле исән-сәламәт икәнлегемне җиткерү булса, икенчеләй, үземнең турист сыйфатында гына булса да үзебезнең якларга барып чыгарга теләгәнемне әйтү. Мәгълүм булсын, әтиең һәр даим сез газизләремне уйлап яшәде. Күп еллардан бирле сезнең турыда берни дә белә алмаенча зар-интизар кылды. Инде, бәхеткә каршы, синең дөньяда икәнлегеңне, бик абруйлы, мөгътәбәр кеше булып Казан кала-

сында яшәвенне анык белдем вә шушы мәктүбемне, зур өметләр баглап, сезнең тарафларга күндерәм. Исән-сау булып, аяк-куллар сәламәт булса, бер күрешми калмабыз. Шунда мин сиңа, газиз углым, барысын да түкмәенчә-чәчмәенчә сөйләп бирермен. Нишләмәк кирәк, язмыштан узмыш юктыр, тәкъдирдә ни язылган булса, шуны күрербез, углым. Инде минем тормышларыма килсәк, мин аллага шөкердән башкасын шулай ук очрашып бер кара-каршы утырып сөйләшкәндә хәбәр кылырмын. Синең җәмәгать, бала-чагаларың да бардыр, углым. Алар мине ишетеп кенә белә торганнардыр. Мәгәр шулай да син аларга миннән күп-күп сәламнәр күндер. Бу хатыма җавап итеп хат язмый калма, мин шуннан чыгып, үземнең калган тормыш юлымны хәл кылырмын. Белмәссең, аллаһы боерса, әллә бәлкем туган-үскән якларда әниең каберләре янында миңа да урын табылыр. Анысын алдан юрап булмый, углым. Тик барлык җаным вә тәнем илә туган илгә ашкынам, ичмаса, картайган көннәремдә шул изге якларга бер зиярәт кылып үлим дип телим. Нишләмәк кирәк, дөнья вафасыз. Хуш, бердәнбер, газиз углым. Синнән түземсезлек белән хат көтеп калам. Әтиең Ибраһим».

Хат укылып беткәч, Латиф белән Гөлбикә бер-берсенә сүзсез генә карашып тордылар. Икесенең дә башларында бер үк уй иде. Ни дигән сүз бу? Бу нинди хәл? Шатлыкмы бу, яисә, киресенчә, башка төшкән зур бер хәсрәтме? Кем соң бу әти? Кирәкле кешеме ул, я бөтенләй кирәксезме? Дусмы ул, әллә дошманмы?

Күптән үлгән дип исәпләнгән әтисенең табылу шатлыгы хәзер бик ераклашкан диңгез карабы кебек кенә булып калды. Ул һаман ераклашты, кечерәйгәннән-кечерәя барды. Ә шомлы уйлар дулкыны көчәйгәннән-көчәя, һаман дәһшәтен арттыра биреп, бер-бер артлы күңелне чыбыркылый башлады. Көтелмәгән, уйланмаган, сәер, үтә сәер бер хәл иде бу. Бер хат кисәге еллар буена корылган бинаның көлен күккә очырган бомба кебек булды. Әтисенең гражданнар сугышында каһарманнарча үлүе, совет власте өчен корбан булуы Латифның күңеленә бала чактан ук якты эз салган, хәтта аңа билгеле бер юнәлеш биргән иде. Латиф әченнән һәр вакыт әтисе өчен горурлык хисе кичереп яшәде. Барысы да, барысы да, илнең барлык казанышлары иң беренче чиратта аныкы. Чөнки Латифның әтисе менә шушы якты замана килсен өчен актык тамчы канынача үзен аямыйча сугышкан, ә Латиф аның эшен дәвам иткән.

— Минемчә, Латиф, бу хат астында әллә ниләр ятадыр әле. Син язуы аныкына охшаган дисең дә...— дип куйды Гөлбикә.

— Я, шуннан? — диде Латиф, кинәт ачуы килеп. Ул җәрәхәтләнгән күңелендә хатынының казынуын һич теләми иде.

— Тикшертергә кирәк. Хәзер үк органнарга хәбәр итәргә,— диде хатын, кашларын җыерып.

Латифның ачуы тагы да көчәя төште. Ничектер бу Гөлбикә күңелдәге изге бер нәрсәгә абайсыз, дорфа рәвештә кагыла иде. Бу мәсьәләне ул бары үзе генә, ялгызы гына хәл итәчәк.

— Туктале, туктале зинһар,— диде ул, кул селкеп,— аларын миңа калдыр инде. Кая соң синең ашың? Ашарга бармы, юкмы? дим. Мин бүген көне буе диярлек кайнар нәрсә капмадым.

— Менә аша инде, алдыңда ич,— диде Гөлбикә, мондый кискен үзгәрешкә аптырый төшеп.

— Аша инде ди, суынып беткән ич!

— Соң үзең хатлар укып сөйләшеп утыргач, мин гаеплемени?! Китер, жылытыйм.

— Ярар инде, әйдә. Җүнләп ашыйсы да килми икән. Бая җыләрләнеп утырыш вакытында бер стакан фруктовый су эчкән булган идем, ашказанын тагы авырттырдым, ахры.

Латиф алдына куелган итле бәрәңгене бер-ике капкалады да:

— Кая, чәең юкмы? Ясап бирче,— диде.

Ул, онытылып, стакандагы шикәрле чәен бик озак вакыт болгатып утырды. Бөтен өй эче тынып калды. Әле күптән түгел генә үзен күкләргә күтәргән шатлык, төсен җуеп, авыр бер кичерешкә әйләнергә тора иде.

Ләкин бу бит һич башка сыймаслык нәрсә! Латифның әтисе, югалган әтисе, табылган. Бу үзе генә дә зур шатлык түгелмени? Ул, барысын да, барлык шартлылыкларны читкә атып бәреп, үзенең шушы якты дөньяда йөрүенә сәбәпче булган кешенең — әтисенең исән булуына шатланырга булды. Әлбәттә, шулай! Чит ил, я булмаса Мюнхен дип әле, аның нинди сәбәпләр аркасында барып эләгүен анык̧ламыйн торып, һич хөкем чыгарырга ярамый. Нинди хәлләр булмас дөньяда! Бәлки ул анда да революцион хәрәкәткә актив катнашкан бер кешедер. Тик шунысы: ничек барып эләккән ул анда? Аннан соң, язуына караганда, бер дә алай алдынгы кешегә дә охшамый шул. Берәр сәүдәгәр кисәге, я бәләкәй фабрикант булмагае! Ай-ай-ай!

Латиф сыкранып башын тотты. Гөлбикә сискәнеп иренә текәлде.

— Ярар, Латиф, чәеңне эч, башыңны катырма, иркәм.

— Бетте,— диде Латиф, үзен кулга алып,— тик син, зинһар, бу турыда берәүгә дә әйтмә.

— Соң, шулай инде,— диде Гөлбикә, барын да аңлап.

— Юк, мин хәзергә дим. Әлбәттә, мондый нәрсәне яшерү мөмкин эш түгел. Мин аны үзем дә ачыктан-ачык трестта сөйләячәкмен. Тик әле хәзергә дәшми торыйк. Кайбер нәрсәләрне ачыклап булмасмы.

Ул хатынына нинди әйберләрне ачыкларга теләве турында берни дә әйтмәде. Ярты стакан чәен эчте дә:

— Булмаса, мин ятыйм әле,— диде.

Хатыны дәшмәде, борчылып иренең бүлмәдән чыгып китүен күзәтте.

Латиф исә үз бүлмәсенә кереп чишенә башлады. Хатны мендәр астына кыстырды. Бүген килгән газета-журналларны караваты янындагы тумбочкадан алып, берәм-берәм күздән кичерде. Гаҗәп хәл, мендәр астындагы хат аңа һич тынычлык бирми иде. Ниһаять, хат Латифның күңелен бөтенләй билэп алды. Газетадагы хәбәр хәзер укылу белән онытыла бара иде. Латиф түзмәде, мендәр астына кулын кертте, үзенә җан тынычлыгы табарга теләгәндәй, хатны яңадан кулына алды. Ул бу юлы инде аның һәрбер сүзенә игътибар итеп, озаклап туктала-туктала укыды. Латиф андагы һәр сүзне, һәр хәрефне күңелдән белә иде инде. Ләкин шулай да укуын дәвам иттерде әле. Хәзер үк нидер ачылыр кебек, нидер аңлашылыр һәм барысы да хәл кылыныр кебек иде. Тик җиңеллек һаман килмәде. Ахырда ул, үзенең авыр кичерешләреннән котылырга теләгәндәй, гасабиланып, хатны идәнгә атып бәрде, утны сүндерим дип торшер кнопкасына үрелде.

## II

Төн ялыктырып бетерде, йокы бик сай, саплам-саплам булды. Бары көн яктыра башлагач кына Латиф тәмам алҗып, төпсез тирән бер йокыга талды. Бераздан Гөлбикә ире янына керде. Латиф ишек ачылу тавышына уянып күзләрен ачканда көн яктырган, өй эче әбиләр чуагы иртәсенең нурларында коена иде.

Латиф быел әле беренче тапкыр үзен эшкә алып бару өчен гараждан автомобиль сораттьі. Эштә көне буе хат турында уйланды. Ләкин

үзе генә кичерде, үзенең борчуын кемгә булса да әйтергә, кемгә булса да чишәргә батырчылык итмәде. Башта үзем булдырырдай кайбер нәрсәләрне анынкларга кирәк, аннан күз күрер, дип уйлады ул. Латиф бүген үк мәрхүмә әнисенең әйберләре арасыннан әтисеннән килгән хатларны табып укырга булды.

Латиф эштән соң өенә кайтып өс-башын алыштыру белән подвалга төшеп китте. Әнисеннән калган, тузып беткән, дым тартып күгәргән иске яулыклардагы төенчекләрне актарырга кереште. Өметен ахыргача өзмичә, андагы әйберләрнең барын да бөрәмтекләп карап чыкты. Бәхеткә каршы, ниндидер язулар, хатлар шулай да сакланган иде. Латиф подвалдан, тузанга манчылып, пәрәвез җепләре иңртеп, бер пачка хат алып менде. Билгеле, бу хатларның күбесе кирәксез булып чыкса да, икесе әтисенең фронттан язган хатлары иде. Латиф бүлмәсенә кереп бикләнде дә, барлык игътибарын җигеп, шул хатларны укырга утырды. Алар язылганга кырык еллап гомер үткән бит инде. Аларның төсе уңган, кәгазе урыны-урыны белән череп тишелгән, ахры, су тигәндер. Ләкин төп сорауга җавап бирерлек иде әле алар. Ә ул сорау мәгълүм. Бу кырык ел элек язылган хатлар белән кичәге хат арасында бәйләнеш бармы, юкмы? Почерк дигән нәрсә гаҗәп бит ул. Ул бер калыпланганнан соң аз үзгәрә. Латиф байтак вакыт хатларны хәрефләп чагыштырып утырды һәм, куркынып, болар бит бер кул белән язылган дигән нәтиҗәгә килде. Латифның күңеле дәһшәттән өшеп үк китте. Ләкин ул чигенмәде, шашып калмады, түземлек белән һаман хатлардан аерылмады. Инде шул хатлардан әтисенең теге якка ничек эләгүен белеп булмас микән дигән теләк көйри башлады аңарда. Ул саргаеп, тетелеп беткән хатларның хәзер эчтәлеген аңларга, әтисенең фәлсәфәсен төшенергә тырышты. Ләкин монысы алай ансат эш түгел иде. Монда зурайтып күрсәтә торган пыяла да ярдәм итә алмый иде. Шулай да Латиф, тырыша торгач, бер хатны укып аңлады. Анда әтисе, әнисенә бик күп һәм, Латифча, һич кирәксез булган, «күптин күп, чуктыйн чук» сәламнәрдән соң, үзенең Казаннан фронтка китүен яза, хәер-догадан аермауларын, исән-сау әйләнеп кайтсын дип теләүләрен үтенә. Ахырда дүрт юллык кына, Латифча, артык беркатлы җыр да язып куя. Ләкин бу хаттан Латиф дөрләп торган дәрт тә, революция идеалларына бирелгәнлек тә тапмады. Күренеп тора, бер авыл малаен тотканнар да армиягә алганнар һәм ул, язмышына буйсынып, фронтка китеп барган. Хатның читенә генә әтисе «мин үзебезнең татар бригадасына эләктем, авылдашлардан минем белән бер взводта Заһир Гайнулласы, аннан Алты бармак Закирының малае Шәмс...» дип куйган. Хатның шушы урыны ертык. Кем ул «Шәмс»? Шәмсетдинме, Шәмсулламы, әллә башка исемме? Аннан гомумән әти нинди караштагы кеше булган? Армиягә ничек алганнар аны? Үзе теләп киткәнме, чакырткан-нармы? Латиф әнисенең хәзер янында булмавына ачынып куйды. Эх, сорарлык берәр кешең булса иде ичмаса! Житмәсә, ул үзенең авылдашларын да юньләп белми бит. Авылдан яшьли чыгып китте шул. Колхозлашу дәвере, искене вату-сындыру, «уңышлардан баш әйләнү» чоры иде. Тормыш артык авырлашты, ашарга икмәк, бәрәңге бетте. Шуннан алар таралыштылар. Латиф балалар йортына барып эләкте, соныннан рабфакка керде. Ул да булмады, рабфакны тәмамлагач, сынаусыз-нисез дигәндәй, институтка да кереп китте. Сонынннан инде инженер-механик булып эшләгән елларында әнисен үз янына алдырды, авыл белән бәйләнешне бөтенләйгә өзде.

Ләкин тукта, әтине белгән, күргән авылдашлары барысы да үлеп бетмәгәндер бит инде?! Әни әллә кемнәр турында еш-еш сөйли иде. Әллә кем абыйларың, фәлән-фәсмәтән дип. Шайтан белсен шунда!

Латиф никадәр генә баш ватмасын, ул кешеләрне һич хәтерли алмады. Ә инде авылдашлар турында Гөлбикәдән сорашу ничектер тоз-

сызлык кебек иде. Чөнки Гөлбикә башка яктан, чыкылдаган мишәр, Нижгар ягыныкы. Хәер, шунда да әнинең сөйләгәннәрен хәтерлидер әле бәлки, дип, Латиф хатыныннан сорарга булды. Гөлбикә үзенә булышырга килгәләп йөрүче дворник хатын белән керләр уа иде.

— Син хәтерләмисеңме,— диде Латиф, хатынын үз бүлмәсенә чакырып,— әни безнең Казанда яшәүче ниндидер авылдашлар турында сөйли иде. Аның әле, хәтерем ялгышмаса, шул кешеләргә барганы да булды шикелле.

— Хәтерлим,— диде Гөлбикә, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә.— Сезнең бит биредә Гыйният абыйларыгыз яши. Алар, минемчә, сездән ике өй аша гына торганнар.

— Исемә төште,— диде Латиф, яктырып,— аларның Әмирхан исемле уллары да бар иде. Минем яшьтәш. Бергәләп печән чапканыбызны хәтерлим әле.

— Мин ул кадәресен белмим инде.

— Ә ул Гыйният абый исән микән соң, белмисеңдер?

— Нигә белмәскә,— диде Гөлбикә,— әнеки бит теге вакытны шуның җеназасына барды.

Латиф ояла төшеп үз алдына елмаеп куйды.

— Шулай икән. Мин ул Гыйният абыйлар белән бик якын аралаша алмадым шул. Аларны теге елларда раскулачивать итеп тә маташкач...

— У-у, аның раскулачиваниесе дә нахактан булган. Әнеки, ул кешеләрнең халыкка файдасыннан башка берние дә булмады дип, юкка рәнҗеттеләр дип, бик еш сөйли иде.

Латиф житдиләнеп китте.

— Как сказать...

— Башка сүзең юкмы? — диде Гөлбикә.

— Юк.

— Соң аны, авылдашлар кирәк булса, мин барып килим. Ул Гыйниятабыйның хатыны да үлде булса кирәк инде, тик бала-чагалары бар, ахры. Алар синең авылдашларны беләләрдер әле!

— Юк инде, кирәкми.

— Нигә кирәк булды соң әле ул сиңа?

— Юк инде, болай гына.

Гөлбикә иренә аның кызыксыну сәбәпләрен сизенеп, бераз вакыт сәерсенеп карап торды. Ләкин аны-моны әйтмәде, сак кына ишекне япты.

Латиф икенче хатны укырга керешге. Уртадан ук череп умырылып төшкән, ялгыш кагылсаң да уалырга торган хатның язуларын юньләп танырлык та түгел иде. Латиф кулына лупа алды. Берни дә аңлашылмый. Бары «Без Идел ярында палаткалар корып яшибез», икенче бер урында «балык шулпасы», «Самарадан Оренбургка җибәрмәгәйләре» һәм «Минем мена яңа иптәш Хәмзә...» дигән сүзләрне генә укырлык иде.

Латиф, бераз уйлангач, хатларда танылган сүзләрне күчереп язды, аннан хатлар белән вакыт уздыруны хәзергә куеп торырга кирәк дигән фикергә килде. Тәгаен, ул елларның документлары архивларда бардыр. Латиф шуларны соратып, я кемнәндер тикшертеп караса, яхшырак булмасмы? Әнә шул документларның берәрсендә әтисенең ни рәвештә әсир төшкәнлеге чагыла торгандыр әле.

Латифның хәзер барлык теләге әтисе турында ни булса да белү, аның кем, ниндирәк кеше икәнлеген ачыклау иде. Әйтерсең лә, хәзер барысы да, хәтта барлык яшәүнең мәгънәсе дә шуңа бәйләнгән. Ләкин бераздан аңарда архив материаллары белән танышу дәрте дә сүнде. Ул тарих фәненнән бик ерак торган хезмәттә иде шул, аның өстенә бу

эшләр белән шөгыльләнеп утырырга вакыты бармыни әле аның?! Ул барысына да кул селтәде дә кечкенә чәен эчәргә дип алгы бүлмәгә чыкты. Чәй эчә-эчә һаман бер нәрсә турында баш ватты. Менә сиңа әкәмәт! Юк, аның әтисе турында нидер белми торып, нидер анықламый торып, бер эшкә дә кулы бармый иде хәзер. Чөнки бу аның язмышы.

Ниһаять, Латиф иртәгә үк гражданнар сугышы тарихы буенча бераз белгеч табып шуның белән сөйләшеп карарга булды. Бардыр әле андый кеше. Латиф шуның белән бүгенге «эзләнүләренә» нокта куйды.

Иртәгесен ул, чыннан да, эшендә, бер буш ара табып, әдәбият, тарих, тел институтына шалтыратты. Аннан аңа, хас татар бригадасы тарихы белән шөгыльләнүче бездә юк, дип җавап бирделәр. Латиф өметен өзмичә университетның тарих факультетына шалтыратты. Ниндидер карыңкы тавышлы бер карт кеше аңа партия тарихы кафедрасына мөрәҗәгать итеп карарга кушты. Чыннан да, анда бригада тарихын өйрәнүче табылды.

Латиф шул кеше белән очрашу өчен көндезге икедә үзенә беркетелгән «Волга» машинасына утырды. Нәкъ ике минуттан соң машинадан төшеп, университетның колонналы ишегенә юнәлде. Латифка кирәк булган мөдир бүлмәсендә, икенче катта, ике кеше сөйләшеп утыра иде. Берсе аның, кара кучкыл йөзле, чал керә башлаган чәчле кеше, тәгаен, профессор үзе, ә икенчесе артык яшь чырайлы, бала сымак, күзлекле бер егет иде. Латиф белән алар икесе дә торып күрештеләр, профессор утырырга урын күрсәтте. Шунда Латифның исенә төште, бу профессорны Латиф белә иде бит, алар шәһәр күләмендә уздырыла торган җыелышларда бер генә тапкыр очрашмадылар ич. Шулай, шулай, ул аның хәтта бер тапкыр лекциясен дә тыңлаган иде. Ләкин менә бу яше кем соң? Шул теге мәсьәлә белән шөгыльләнүче түгел микән? Егет профессор каршына ук утырган һәм, әле генә сөйләнгән сүзләрнең тәэсиреннән булса кирәк, әледән-әле нервылы хәрәкәтләр ясап, кашларын җыергалап куя иде. Ул үзе ямьсез түгел иде: шактый киң һәм биек маңгай, килешле йөз, матур кашлар. Тик Латифка ул үзенең артык бала сымаклыгы аркасында гына ничектер ошамады. Ул арада профессор сүз башлады:

— Рәхим итегез, Латиф Ибраһимович, таныш булыгыз,— Альфред Яхич,— диде, егеткә күрсәтеп.— Ул нәкъ менә сезне кызыксындырган мәсьәләләр өстендә эшләп утыра.

Латиф та, Альфред та икесе бердән уңайсызланып киттеләр. Латифның эше профессор уйлаганча алай зурдан кубарлык түгел иде бит, ә Альфред исә, мин бу кеше өмет иткәнне канәгатьләндерә алмам, дип борчыла иде. Шулай да Латиф, олы кеше буларак, үзенең Альфред белән танышуына шатлык билгесен күрсәтергә тырышып, баш иде һәм сүз дә башлап җибәрде:

— Миңа, дөресен генә әйткәндә, бераз җайсыз да, чөнки мине бары хосусый кечкенә бер деталь генә кызыксындыра.

— Рәхим итегез, менә безнең Альфред Яхич сезне кызыксындырган темада иң компетенцияле кеше.

— Нинди күләмдә? — диде Латиф, чак кына шаярта төшеп.— Университет күләмендәме?

— Алай гына да түгел, тәгаен, бөтен республика күләмендәдер,— диде профессор, елмаеп.

Альфред исә сүз дәшмәстән, кызарынып, нидер эзләгәндәй, кесәләрен актара башлады.

— Сез биредә эшлисезме? — дип сорады Латиф егеттән.

Альфред урынына профессор үзе җавап бирде:

— Ул безнең университет кешесе түгел әлегә. Ләкин шулай да без-

нең кафедра кешесе. Бүген булмаса иртәгә безгә күчәчәк. Ассистент вакансиясенең раслануын гына көтеп ятабыз.

— Ах, шулай икән,— диде Латиф,— сез, мөгаен, профессор житәкчелегендә диссертацион эш алып барасыздыр әле?

— Белмим әле,— диде Альфред, бөтен йөзе белән елмаеп,— диссертация дигән исем астында эшләнә эшләнүен. Ләкин нәрсә булып чыгар, иң әһәмиятлесе ахыр чиктә эшне башкарып чыгу бит.

Альфред, шулай дөрес әйтәмме, дигәндәй, профессорга карап куйды.

— Тырышсагыз, булмый калмас,— диде профессор, егетне дәртләндереп.

— Хәзер сез шул бер эш белән генә шөгыльләнәсезмени? — дип сорады Латиф.

— Юк, андый эш мөмкин түгел. Безнең Альфред Яхич урта мәктәптә укыта. Укыту эшләре буенча урта мәктәптә мөдир булып эшли,— диде профессор.

Профессорның бу яшь егет турында артык кайгыртучанлык күрсәтүе, әлбәттә, Латифка тиешле тәэсирен ясамый калмады. Галимнең егетне яратканлыгы сизелеп тора иде. Башсыз булмас бу, дип уйланды Латиф. Профессор кинәт сәгатенә күз төшереп алды да аягүрә басты.

— Мин сезне таныштырдым, үземнең вазифамны үтәдем, хәзер үзегезне генә калдырырга рөхсәт итегез. Минем дәресем...

Профессор чыгып киткән арада Латиф, сүзне нидән генә башлыйсы икән? — дип уйланып утырды. Ул эчке тойгы белән егетнең үзенә бернинди дә анык җавап бирмәячәген сизенә башлаган иде инде. Чөнки кайдан белеп бетерсен ул барлык кешене? Бу хәл теге арба белән куян куу кебегрәк килеп чыгачак инде. Ләкин кем белә тагы! Латиф, очраклылыкка исәп тотып, шулай да сүзгә керешә:

— Менә эш ничек тора,— диде уйланып, һәр сүзен бизмәнгә салып,— сез мина, әлбәттә, төгәл җавап бирә алмассыз. Ләкин ул тема белән шөгыльләнгәч, һәрхәлдә, эзләнү юлларын күрсәтә алырсыз дип уйлыйм.— Ул ияген сыпырып, бераз вакыт тынып торды.— Мин әтиемнең язмышы белән кызыксынам. Минем әти, нәкъ менә сез өйрәнә торган татар бригадасында хезмәт иткән (Альфред күзләрен беткәнче ачып, башын кыйшайтты), һәм ул, егерменче елның башларында булса кирәк, үлеп калган. Билгеле, мин ул вакытны хәтерләмим инде, шуңа күрә анык кына итеп әйтә алмыйм. Кыскасы, рәсми белешмәләр аның үлүе турында өзеп берни дә әйтмиләр.

— Сез әтиегезнең каберен эзләп бик дөрес эшлисез,— диде Альфред, кинәт Латифны бүлдереп,— әгәр мин әтиемнең кырык беренче елны Мәскәү янында үлеп калганын белмәсәм, мин дә аны тапмый торып тынычланмас идем. Ничәнче полкта хезмәт иткән әтиегез?

— Менә, кызганычка каршы, мин анысын да сезгә әйтә алмыйм шул,— диде Латиф, уңайсызлана төшеп.

— Ә исем-фамилиясе ничек булган әтиегезнең, рядовой булганмы, командир-фәләнме?

— Билгеле, рядовой, каян килеп аңа командир булу! Ул гади авыл малае, русча бөтенләй белмәгән, элек армиядә дә булмаган, билгеле...

— Юк, алай димәгез. Бик кызык хәлләргә юлыгам мин бригаданың тарихын өйрәнә торгач. Анда ай-я-а-ай,— дип, башын чайкап куйды Альфред, хикмәтле хәлләрнең күплегенә исе китеп.

— Юк, юк, ул командир-фәлән булмаган,— диде Латиф.— Анысы билгеле.

— Исем-фамилиясен әйтегез әле,— диде Альфред, блокнотын ачып.

— Исеме Ибраһим инде аның, фамилиясе... Бездә бит, үзегез беләсез, элегрәк бигрәк тә, әтисенең исемен фамилия итеп ала торган бул-

ганнар, ә минем бабайның исеме Касыйм. Димәк, Ибраһим Касыймов була инде.

Альфред күрән тышлы бәләкәй блокнотына язып куйды.

— Мин сезгә хәзергә берниндн вәгъдә бирә алмыйм,— диде ул.— Ләкин алай-болай очрый калса, хәбәр итәрмен. Чөнки архив материалларында кайчак аерым исемнәр дә, исемлекләр дә килеп чыга. Аннан сез аерым кешеләрнең истәлекләренә дә игътибар итегез. Мин сезгә, әгәр кирәксә, бригада турындагы әдәбият исемлеген дә бирермен. Тик беләсезме, бөтен бәла шунда, беркем дә системалы рәвештә шул героик бригаданың юлын күзәтмәгән, гыйльми нигезгә салып, тулы тарихын язмаган, өзек-өзек кенә материаллар. Аннан инде,— Альфред бермәл икеләнеп тынып торды,— аннан инде аның билгеле башка сәбәпләре дә бар. Ә чынлабрак карасаң, безнең татар халкының уллары героик юл узганнар. Аның белән горурланырга була...

— Горурланмыйча гына кызыксыныгыз,— диде Латиф, көлемсерәп.

Альфред сәерсенеп, ни әйтергә дә белмичә, уң як иңбашын күтәреп куйды. Латиф дустанә рәвештә егетнең җилкәсенә кулын салды.

— Зинһар, игътибар итмәгез, Альфред туган, мин болай гына, шаяртып кына. Дөресен генә әйткәндә, минем үзем өчен сезнең татар бригадасы белән шөгыльләнүегез шәбрәк тә әле. Белмәссең, архив материаллары арасында, бәлки минем әтинең язмышы яшеренеп ятадыр.

— Мин сезгә менә нинди киңәш бирер идем,— диде Альфред, уңайсызлануыннан айнып төшеп,— мин сезгә Үзбәкстанның тарих институты белән бәйләнешкә керергә киңәш бирер идем.

— Ә нигә?

— Чөнки татар бригадасы формировка узганнан соң ук яңа оешкан Төркстан армиясе белән Урта Азияне азат итәргә бара. Нәкъ егерменче ел. Моны безнең үзбәк дуслар хөрмәт белән искә алалар. Өйрәнәләр дә булса кирәк...

— Кара, кызык бу! Мин моны белми идем әле.

— Шулай, шулай. Минем ул үземне дә бик кызыксындырды.

Альфред Идел буе аерым татар бригадасының командиры турында сөйли башлады. Аның Фрунзе белән бер шәһәрдә туып үскәнлеген һәм, бик ихтимал, балачактан ук бергә булганлыкларын сөйләде; ниһаять, ул татар бригадасының ничек барлыкка килүе турындагы тарихка күчте. Ләкин Латифка сөйләнгән кадәресе дә бик җиткән иде. Ул, егетнең хәтерен калдырмас өчен, мөмкин кадәр йомшаграк итеп, хәзер үзенең һич вакыты булмаганлыгын аңлатты. Әлбәттә, киләчәктә бәйләнеш тотачаклар алар. Ул, Альфредның вәгъдәсен алып, саубуллашып чыгып китте.

## III

Латиф киткәч, Альфред бераз вакыт булмәдә япа-ялгызы тик кенә утырды. Аның әле генә чыгып киткән танышына бераз ачуы килгән иде. Ләкин, күрәсең, мондый хәлләрне егетнең беренче тапкыр гына кичерүе түгел иде, ул, бераз вакыт күңелсезләнеп тәрәзә аша урам күзәткәннән соң, өстәлдә яткан кулъязманы алды да онытылып укырга тотынды. Йомышлар барысы да үтәлгән, бары профессор танышырга тәкъдим иткән кулъязманы гына укып чыгасы калган иде. Альфред мәкаләне бирелеп, кайбер урыннарын дәфтәренә күчереп укыды. Ярап куя ул, кайбер кирәкле бөртекләр бар ич!

Альфред эшен бетерде дә сәгатенә карап куйды. Биш минуттан соң профессор дәресен тәмамларга тиеш. Саубуллашмыйча китеп булмый, яхшы түгел. Тагы кайчан килеп була әле. Альфред почмакта яткан зур рюкзагы янына барды. Ана китап тутырылган иде. Ләкин

китаплар ничектер жайсыз тøялгøннøр. Поездддан тøшкøч, шактый арасы атлап узасы бар бит әле. Китап почмаклары, рәтләмәсәң, арканы житәрлек каезлар. Альфред китапларын бушатып, яңадан капчыгына берәм-берәм тутыра башлады. Ләкин ул эшен башкарган арада китапларын да караштыргаламый булдыра алмый иде. Кулына эләккән бер китапны яратып, хәтта сыпыргалап, сокланып күзеннән кичерде. Битләрен берәм-берәм ачып хәзер үк укый башлыйсы иде дә, тик вакыт юк. Әйдә, ярар инде, түзәрмен, калдырып торыйк. Инешлегә кайткач... исән булсак. Япа-ялгыз гына, рәхәтләнеп, тынычлыкта.

Ул китапларын рюкзагына жайлап тутырды да капчыкның авызын бәйләргә керешге. Шул чагында бүлмәгә профессор килеп керде. Альфред чүгәләгән жиреннән аягүрә басты.

— Сез китәргә жыенасызмы? — дип сорады профессор, креслосына утырып.

— Әйе, Рәфкать Сабирович. Вакыт. Юкса поездга соңга калырмын дип куркам.

— Материал житәрлек түгел шул,— дип куйды профессор, сүзне башкага күчереп.— Картинаны тулысынча күз алдына китереп бастыру өчен, бердәнбер юл — архив материалларыннан тыш, бригадада хезмәт иткән ветераннарны мөмкин кадәр күбрәк табу. Әлбәттә, истәлекләр белән генә дә чикләнергә ярамый. Истәлекнең тулылыгы авторның яза белү сәләтенә дә, хәтеренә дә, намусына да бәйләнгән. Шуңа күрә, эш уңышлы барсын дисәгез, сез аларның адресларын табып, һич иренмичә үзләрен күрегез.

— Рәхмәт. Минем ял көннәрем һәм каникулларым бары шул эшкә генә багышлана инде.

— Шайтан алгыры,— дип куйды Рәфкать Сабирович, пошынып,— килми бит раслау хәбәре. Сезгә хәзер башаягыгыз белән чумарга кирәк бу эшкә.

— Дәресләр башланып киткәч кенә мәктәптән китүе дә жиңел эш түгел шул...

— Анысын эшләр идек әле, министр жүнле кеше. Аңлар иде. Профессор, нидер әйтергә теләгәндәй, беравык уйланып утырды.

— Менә нәрсә,— диде, тагы сүзне башкага күчереп,— моннан биш ел элек мин музейда бер зур гаугалы вакыйганың шаһите булган идем.

— Татар бригадасы тарихы мәсьәләсендәме? Сез бит аны миңа сөйләдегез.

— Минем әйтергә теләгәнем шул, нәкъ шушы жанжалның үзәгендә торучыларның Ташкенттагысы әле күптән түгел генә Казанга кайткан.

Альфред плащына үрелгән жирдән тукталып калды.

— Кызык. Озакка дип кайтканмы?

— Ишетүемчә, бөтенләйгә, торырга дип кайткан. Ул моңа кадәр улында яшәгән икән. Хәзер Казанга кызы янына кайткан.

Альфредның күзләре бөтенләй очкынланып китте.

— Адресын бирегезче, зинһар, Рәфкать Сабирович.

— Адресын, кызганычка каршы, белмим шул әле.

Альфред яңадан чөйдәге плащына үрелде.

— Ах, алай икән,— диде күңелсезләнеп.— Берничек тә табып булмыймы?

— Мин аны табарга тырышырмын, Альфред. Сез икенче тапкыр килгәндә, бәлки ул өй кенәгәсенә язылган булыр, һәм без аны адрес бюросы аша ансат кына табарбыз.

Профессор хәйләкәр генә күз кысып куйды.

— Аны кем күргән соң? — диде Альфред.

— Ул музейда булган. Ләкин анда адресын язып калырга онытканнар.

— Менә әкәмәт төенчекләре,— дип куйды Альфред, ризасызлык белгертеп.

— Сез борчылмагыз, сезгә хәзергә житеп торыр әле. Әдәбият диюем.

Альфред башына кепкасын чәпәде дә профессор янына килде.

— Сау-сәламәт булыгыз, Рәфкать Сабирович, рәхмәт сезгә.

— Кайчан килә аласыз тагы?

— Җае туры килсә, киләсе атнадан да калмам. Тырышырмын.

— Хушыгыз. Берәр яңалык булса хәбәр итәрмен,— диде профессор.

Альфред рюкзагын җилкәсенә асты да, профессорның йомшак кулын кысканнан соң, ишеккә таба юнәлде.

Унбиш минуттан соң ул җирле поездлар вокзалында иде инде. Тиз генә билет алып, китәргә торган поездга утырды. Күп тә үтмәде, дизель поезд салмак кына, йомшак кына кузгалып та китте. Тәрәзә каршындагы вокзал биналары, шәһәр өйләре берәм-берәм артка шуыштылар. Альфред тәрәзәдән карап барды һәм тирә-якта таныш басулар, урманнар күренә башлагач, үзе дә тоймастан, уйларына, күңелендә туган күренешләргә чумды.

Хәл бик катлаулы иде әле. Беренчедән, университетка күчү мәсьәләсе һаман ачыкланмый, икенчедән, Луиза көйсезләнә. Имеш, авылга урнаштык, әйбәт кенә шунда тормыш корыйк инде. Ул гына да түгел, мәктәп директоры Әхмәдиев белән дә мөнәсәбәт киеренкеләнеп бара. Нигә дисәң, әлеге дә баягы, аныңча, Альфред мәктәп эшләре белән житәрлек кызыксына алмый. Имеш, әллә нитикән кирәксез гыйльми эшләр белән вакытын уздыра. Өйрәнгән ул директор Альфредка гына салынып.

«Чыннан да,— дип уйланды Альфред,— мин моннан ике ел элек завуч булып эшкә керешкән шәпне барысын да бер үзем сөйрәп бардым. Халит абыйга шул дәресләренә кереп чыгудан һәм башкарылган эшләр турында минем докладымны тыңлаудан башка эш тә калмый иде. Ләкин бит мин әле дә эшләмим түгел. Тик үз вазифамны гына үтим, ә аныкын үтәргә вакыт калмый».

Альфред тиз-тиз алмашынган тышкы күренешләргә тәрәзәдән караган хәлдә ачынып елмаеп куйды. Ерактa сузылып яткан көзге юллар, иркен яланнар ни өчендер аңа сугыш кырлары булып тоелдылар, ул да булмады, шул сугыш кырларына бәйләнештә аның күз алдына ни өчендер Беренче татар бригадасы төзүдә башлап йөрүче кеше килеп басты. Ул кеше бик яшьли интернациональ батальон комиссары булган. Соңыннан Беренче татар бригадасының комиссарына, аның ялкынлы политик житәкчесенә әверелгән, ә соңыннан ул инде, гражданнар сугышы беткәч, шул кеше танылган совет язучысы булып киткән. Ул Шамил Усманов. Менә бүген генә профессор белән шул каһарман турында сөйләшү булды. Хәзер инде хатларга таянып әйтергә була, Шамил Усманов бригада оештырырга рөхсәт сорап Ленинның үзе белән сөйләшкән. Альфредның йөзенә чак кына сизелерлек елмаю билгеләре чыкты. Ул моннан ярты гасыр диярлек элек булып узган хәлләрне күз алдына китерергә тырышты. Әйе, әйе, Альфредның күз алдына аерата китерергә тырышкан нәрсәсе Шамил Усмановның Ленин белән сөйләшүе иде. Бусы аеруча, аеруча кызык. Ничек, ничек булды икән ул сөйләшү? Шул хәлне бөтен ваклыгы белән белсәң иде. Ә бәлки ул болай булгандыр. Менә Шамил Усманов Кремльдә Ленин бүлмәсенең приемныенда. Башында якты уйлар, дәртле хисләр. Менә ул түземсезләнеп көткәннән соң Ленин белән очрашып, аңа үзенең теләген аңлата. Ул яшь, матур, өстендә үзенә килешле хәрби форма. Утырма якалы френч, күм-күк галифе чалбар, ялтыратып чистарткан күн итекләр, башында кызыл йолдызлы кара күн фуражка. Әйе, әйе, шулай, тәгаен, шулай, чөнки

Усмановның ул көннәрдә төшкән карточкасын күргәне бар Альфредның. Ә аннан соң ничек булган? Альфред җилкәләрен җыерып куйганын үзе дә сизмәде. Ә бәлки болай булгандыр. Ленинның секретаре, ул вакытны япь-яшь, чибәр Фотиева ишек янында тыныч кына көтеп утырган Шамилгә мөрәҗәгать итеп:

— Иптәш Усманов, Владимир Ильич янына рәхим итегез,— дигәндер.

Шамил дәррәү урыныннан сикереп тора, бил каешын тиз генә сыпырып куя һәм кыю адымнар белән эчкә керә. Ә кабинетта Ленин. Ул үзенең өстәле янында, шулай ук Альфредка мәгълүм нәзек камыштан үрелгән креслосында. Бәлки әле белмәссең, кулында «Правда» газетасы да булгандыр.

Күңел күзе барысын да төгәл итеп тикшерергә тели. Чөнки бер татар егетенең Ленин янына керүе, аның белән сөйләшүе соң дәрәҗәдә кызык иде. Альфред байтак вакыт кашларын җыергалап, тагы, үзе дә сизмәстән, булган хәлләрне күз алдына китерергә тырышты. Хәзер инде ул Ленин белән Шамил арасындагы әңгәмәне яңадан тудырырга тели иде.

«Тәгаен, Ленин Шамилдән: «Сез татармы?» — дип сорагандыр инде»,— дип уйланды ул. Чөнки, Альфредча, Ленин үзе дә Идел буенда туып үскән кеше булгач, андагы халыкларны бик яхшы белә, алар белән кызыксына. Нигә дисәң, аның Кокушкинода бер татар малае белән дуслашуы мәгълүм иң. Кем әле ул малайның исеме? Әйе, Баһаветдин.

Альфредча, Ленин Шамилнең шундый яшь чырайлы булуына да игътибар иткәндер. Ул, тәгаен, аның яшен сорагандыр. Альфредның колагына Шамилнең сүзләре ишетелгәндәй булды. «Миңа унсигезенче елның азагында егерме бер яшь тулды инде, Владимир Ильич».

Альфред күңелендә туган Ленин белән Шамил үзләренең әңгәмәләрен дәвам иттерә бирделәр. Ахырда Ленин, бөек Ленин үзе, Идел буе беренче аерым укчы татар бригадасы төзелергә тиеш икәнлеген кирәк дип таба. Белмәссең, бәлки әле даһи үзенең бик ерак-еракларданкүрә белүчәнлеген бу очракта да Шамилгә сиздереп, бу бригаданың революция өчен нинди зур һәм мактаулы эшләр башкарачагын, андагы егетләрнең дан белән күмеләчәген хәбәр иткәндер. Һәрхәлдә, шулай булуы, Альфредча, бик, бик мөмкин иде.

Ниһаять, бер мәсьәлә турында гына уйланып утыру Альфредны ялыктыра төште. Ул тәрәзәдән күренгән авыл өйләренә һәм андагы бәрәңге бакчаларына карап, өйдә хәзерге минутта үзен көтеп утырырга тиешле хатыны, аннан бәләкәй улы Шамил турында уйлап алды. (Кара инде син аны, нинди исемнәр туры килү! Юкса Альфред улына исем сайлаганда һич Шамил Усмановны күздә тотмаган иде.)

Бер зур авылның уртасындагы таш мәктәп бинасы күзенә чалынды. Ул Альфредка иртәгә буласы дәресләрен исенә төшерде. Ниһаять, узган кыш урталарыннан бирле аралары киеренкеләнгән мәктәп директоры күз алдына килеп басты. Элеккеге татлы уйларның эзе дә калмады, барысы да буталып, Альфред алдында кырыс, катлаулы чынбарлык кына калды. Ул авыр итеп бер көрсенде дә дәресләр расписаниесен карау өчен блокнотын эзләп кесәсенә тыгылды.

## IV

Альфред поезд туктау белән вак таш өеменә сикерде. Кечкенә разъездда ыгы-зыгы, шау-шу булып алды. Кемнәрнедер каршы алдылар, кемнәрнедер озатып җибәрделәр. Поезд кузгалганда Альфред агачлыкка таба юл буйлап бара иде инде. Ул борылып артына карады. Поезд шактый ераклашкан, нарат урманы эченә кереп бара иде.

Ә Альфредның тирә-юнендә ямь-яшел уҗым басулары һәм моңсу көзге тынлык. Һавада яңгыр тамчылары түгел, ә ниндидер су тузаны бөркелә. Альфред быкырдык юлдан, үзенең татлы уйларына чумып, еракта ялкынланып янган учаклар кебек балкыган кып-кызыл өрәңгеләргә таба китте. Ул яшәгән авыл тимер юлыннан биш километрлар чамасында иде. Поезддан төшкәндә шактый ишле күренгән халык иркен басуда төрле якка таралып ни арададыр юкка да чыкты. Хәер, Альфредның алай кем белән булса да юл кыскарту өчен сөйләшеп барырга теләге дә юк иде. Ул, үзе күптән түгел тапкан материал белән булашып, һаман онытылмас унтугызынчы ел турында, данлыклы татар укчы бригадасының мең газаплар һәм җиңү шатлыклары белән тулган озын-озак юлы турында уйланды. Ара-тирә ул үзе үткән колхоз басуларына күз ташлый һәм мәктәптәге, өйдәге эшләре турында да фикер йөртеп ала. Колхозга мәктәп балалары бәрәңге алышырга барачаклар, андагы эшне оештыруны мәктәп директоры Альфредка тапшырды. Аннары өйдә дә бәрәңге аласы бар. Ничә көннән бирле инде Луиза бер үзе казына... Эшләр җитәрлек анысы, уйланырга да мәсьәлә җитәрлек, ләкин баштан һаман теге тарихи вакыйгалар чыкмый. Ә бит һич уйламаганда-көтмәгәндә башланды мондый өстәмә эш. Әле узган елның язында гына ничектер Казанга бер баруында аны Рәфкать Сабирович очратты. «Карагыз әле, иптәш Хәйретдинов,— диде ул, Альфредның кайда эшләгәнлеген белгәннән соң,— сезгә мин гыйльми эш белән шөгыльләнергә тәкъдим итәр идем. Сез аны булдыра алырсыз, дип уйлыйм. Тик ятмагыз, эшләгез, гомер һич сизелмичә уза бит ул, ә иҗади эш белән бизәлсә, ләззәтле була»,— диде.

Альфред студент чагында ул доцент иде. Аны лекцияләрен оста сөйләве һәм гади булганы өчен студентлар аеруча хөрмәт итәләр иде. Ләкин Альфред белән аның мөнәсәбәте моның белән генә чикләнмәде. Хәтерендә, ул чакны ук Рәфкать Сабирович Альфредны гыйльми эшкә тартырга тырышты. Ләкин аспирант итеп калдыра алмады. Хәзер исә менә шул кеше профессор булган, хәтта кафедра мөдире булып киткән. Аның тәкъдиме Альфредның күңелендә болай да күптән көйрәгән учакка агач өстәү булды. Учакның дөрләп ялкынланып януын теләгән Альфред профессор янына бераздан үзе барды һәм гыйльми эшкә тема алып, баш-аягы белән шуңа чумды. Альфред өчен яңа тормыш башланды. Шул өстәмә эше аркасында ул кинәт яңа тойгылар һәм яңа кичерешләр дөньясына барып эләкте. Әлбәттә, ул элек тә татар бригадасын ишетеп белә иде. Ләкин ул аңа җитәрлек әһәмият бирмәгән икән. Профессордан тема алганнан соң, ул чынлап эшкә кереште, җәйге каникул вакытын бары шуңа багышлады, Мәскәүдә, Ленинградта йөреп кайтты, Казан архивларында казынып, бу көнгәчә шактый материал туплады...

Альфред авыл читенә җиткәндә көн караңгылана башлаган иде инде. Ул, кайтып җиткәч, әле ут алынмаган өй эчен күрергә тырышып, ян тәрәзәне чиертте. Ул юри шаяртып шулай эшли иде, хатынын тәрәзәгә килүен күргәч, тиз генә ике тәрәзә арасына качты һәм тавышын үзгәртеп, тамак төбе белән:

— Миңа Луиза Хәйретдинова кирәк иде, чыксын әле,— дип кычкырды.

Күрәсең, Альфредның хатыны өчен бу мәзәк яңалык булып чыкмады. Ул шунда ук ирен таныды да форточкага үрелеп:

— Әйдә, әйдә, якланма әле, пожалысты, барыбер таныдым,— дип кычкырды.

Альфред хатынының сүзләрен ишетү белән бу уеныннан туктады, чөнки Луизаның кәефе кырылган чак икәнлеге тавышыннан ук сизелеп тора иде.

Ул мышкылдап өйгә килеп керде һәм ишек янында ук авыр рюкзагын салып ташлады. Өй эче бәләкәй генә. Мич белән икегә бүленгән. Альфредларның тормышны әле яңа гына кора башлаулары өй җиһазларына карау белән үк аңлашыла иде.

Альфред өс киемнәрен салган арада түр яктан Луиза тусрый битле имчәк баласын күтәреп чыкты. Альфредның хатыны яшь, чибәр, аксыл чырайлы, түгәрәк йөзле, ләкин аның талчыкканлыгы йөзенә үк чыккан иде. Альфред, улын күргәч, рюкзагтан өстәлгә бушата башлаган китапларын ташлап, балага үрелде. Малай да этисен танып, тешсез авызын ера башлады. Мәгәр Луизаның хәтере житәрлек калган иде. Ул тыелырга теләмәстән ачуланып:

— Нишләп йөрүең инде бу синең? Дөньяңны шулкадәр онытмасаң булмыймыни? — диде.

Альфред аның саен баланы алмакчы булып кулларын сузды, Луиза яны белән борылып улын яшерде.

— Кулларың салкын, сузылма, пожалысты. Болай да башы авырудан чыкмый.— Луиза, баягы соравына җавап көтеп, кискен караш белән ирене текәлгән иде.

— Соң бит мин трай тибеп йөрмәдем,— диде Альфред, акланып,— гыйльми китапханәдә утырдым, профессорны күрдем...

— Шул кадәр озак. Таң белән өйдән чыгып киткән кеше. Неужели син үзеңнең бала атасы икәнлегеңне онытасың. Ярый инде, мине саңга сукма, ди, ичмаса, бала атасы икәнлегеңне онытмаска кирәк иде. Мин бит монда япа-ялгыз. Баланың кәефе юк, төне буе йокларга бирмәде. Кешеләрнең ирләре, ичмаса, буш вакытлары булса, җимерттереп бәрәңге казыйлар. Ә син иртә чыгып китәсең, кара төндә кайтып керәсең...

Әле кара төнгә ерак иде аңысы, ләкин Луизаның әйткәннәрендә дә дөреслек юк түгел иде. Чыннан да, ул быел язлыкта, башка укытучылар шулай итә диган булып, җуләрләнеп, бәрәңге утыртты. Билгеле, ул аның белә җәй буена бер генә тапкыр да кызыксынмады. Луиза үзе эшләде, я булмаса акча түләп, күрше-күләннән берничә тапкыр төбен өйдертте, утатты. Ләкин хәзер, гөнаһ шомлыгына каршы, котырып уңган нәгаләг бәрәңгене казымыйча булмый. Альфред бакчага чыккан саен бәрәңге казуга киткән кадерле вакытын кызганып, сукранып керә иде. Кемгә кирәк бу кадәрле бәрәңге, аз дигәндә моннан сиксән капчык чыгачак, ә безгә күп дигәндә өч капчык житкән! Ләкин Луиза аны-моны белми иде, утыртылган бәрәңге алынмый калырга тиеш түгел дип уйлый иде. Бер яктан караганда, әлбәттә, анда да хаклык бар иде... Ләкин шулай да Альфред тиз генә бирешергә уйламады.

— Син беләсең бит, Луиза,— диде ул,— мин эш белән йөрим. Беләсең бит, мин бөтен буш вакытымны гыйльми эшкә бирәм.

— Соң инде гыйльми эш дип, дөньясын кем оныткан! — диде Луиза.

— Нигә онытырга!? Киресенчә, мин дөнья, дөнья дип тырышам. Берәр китап чыгарып куйсам, үзеңнең дә исең китәр әле. Инде алай да булмый икән, газета-журналларда мәкаләләр бастырырмын. Син бит беләсең, нинди героик юл үткән ул безнең татар бригадасы! Син, Луиза, бер дә шуның белән горурланмыйсыңмыни? Ул бит безнең бабайларыбызның юлы.

— Кемгә кирәге бар соң синең тарихыңның? Вакыт, тазалык бетереп бер дә кирәкмәгәнгә. Ичмаса, түләүле булса икән эшең! Менә үзеңне җүләр дип сүгәрләр әле, шул.

— Кем сүгәр?

— Ах, аз иде ди андыйлар? Син белми идең ди аларны!

— Беркем бернәрсә әйтмәс. Рәхмәт әйтерләр. Мин бик кирәкле эш эшлим.

— Хаҗәте бар иде ди!

— Я нигә андый сүз сөйлисең инде син? Син бит мине просто рәнҗетәсең!

— Ну, кемгә кирәк ул, кемгә кирәк синең тарихың?..

— Юкны сөйләмә, ашарга бир әле булса, мин көндез дә ашамаган.

— Яле, нәнекәчем,— диде Луиза, малайны караватына бастырып. Ап-ак чәчле, сөттәй ак йөзле бала шунда ук авызына кабырчык балыгын кабып, кәефнең шәплеген аңлатырга теләгәндәй, сәер тавышлар чыгара башлады. Луиза плитәдән жылымса аш алды һәм ире алдына китереп куйды.

— Суынып киткән булса, керосинкада жылытырсың.

— Ярый, болай да бата. Жылытырлык тәкатем калмады, ачыгып үлә яздым.

Ул кызу-кызу ашады да урыныннан сикереп торды.

— Ачуны бик китердең, Луиза. Әйдә, үзең дә киен, Шамилне дә киендер. Бәрәңге казырга киттек!

— Юкны сөйләмә инде, ичмасам. Караңгы төшкәч, бәрәңге казып йөриләр иде ди.

Чыннан да, өйдә генә түгел, тышта да караңгы иде инде хәзер. Альфред олы яктагы электр лампочкасын кабызды да үзе алып кайткан китапларны язу өстәленә чыгарып салды. Ах, хәзер үк укый башлыйсы иде, тик бу эш мөмкин түгел шул, иртәгә дәресләр, ә план төзелмәгән әле. Кайчаннан бирле инде сигезенче классның сочинениесе каралып бетмәгән. Ә иртәгә отметкаларын әйтергә кирәк. Болай да әллә кайчаннан бирле сорыйлар. Яхшы түгел. Шулай да тәкатьсезләнтән Альфред китапларның кайберсен караштыргаламый түзмәде. Кызыклы гына мәгълүматлар вәгъдә итә иде бу китаплар, шайтан алгыры! Я, ярар, мәктәп эшләрен бетерик тә аннан иркенләп, рәхәтләнеп...

— Безнең Жәзилә апа кайчан кайта соң? — дип сорады ул, борчылып, эшенә керешер алдыннан. Луиза бала караватына сөялеп бер кулына китап тоткан килеш шулай ук үзенең иртәгә буласы дәресләренә әзерләнә иде. Ул китабын өстәлгә куйды да:

— Ул тиз генә кайтмас инде,— диде.

— Ничек алай?

— Авырып калган. Барган жирендә суык тидергән. Туганнарында ята.

— Ә Шамилне нишләтәбез соң?

— Белмим инде. Мин инде нишләргә дә белмим.

— Алайса мин күршеләргә кереп чыгыйм әле,— диде Альфред, урыныннан кубып,— бәлки берәрсе белән сөйләшермен. Юкса, баланы кемгә калдырырга соң!

Луиза каршы бер сүз дә әйтмәде. Альфред тиз генә киенеп чыгып китте. Ул әйләнеп кайтканда, бала йоклаган иде инде. Альфред урынында хатыны дәрес планнарын язып утыра иде.

— Яле, икәүләшеп утырыйк әле,— диде Альфред.

— Утыр, мин теге өстәлгә күчәм. Булдымы соң? Нишләтәбез баланы?

— Сөйләштем. Шамилне Хатип абзыйларда калдырып торырбыз. Нәгыймә апа риза булды. Бик әйбәт апа ул.

Луиза изрәп йоклаган баласына карап куйды:

— Жанкисәгем, мир көтүчесе кебек өйдән өйгә йөрергә калды инде үзеңә.

— Әле монысына шатлан. Әллә кемнәргә кереп беттем. Берсе алай ди, берсе болай ди. Беркем дә кешегә ярдәм итим әле дип атлыгып тормый.

Альфред хатыны белән янәшә утырды да, алар берелеп эшкә керештеләр.

Төнге уникенче яртыда Луиза, эшләрен тәмамлап, чишенә башлады. Ә Альфред әле яңа гына теге китапларны кулына алган иде.

Ул, хатыны йокларга яту белән, бөтен дөньясын онытып тарихи вакыйгалар дәрьясына чумды.

— Ятмыйсыңмыни әле син? — диде Луиза, ризасызлык күрсәтеп.

— Юк әле, юк, кая ул яту!

— Үзең дә таптың инде шунда, ни үзенә, ни миңа юк тынычлык.

Альфред каршы бер сүз дә әйтмәде. Рәхәтләнеп укуын дәвам иттерде.

— Утны каплап куй әле, пожалысты, күземә төшә,— диде Луиза, йөзен чытып.

Альфред, Луизага ут төшмәсен дип, газета кәгазе белән өстәл лампасын каплады да тагы берелеп укуына кереште.

Өченче яртыда Луиза уянып бер генә күзен ачты. Альфред һаман укып утыра иде әле.

— Син әле һаман йокламыйсыңмыни? — диде хатын.

— Юк әле,— диде Альфред.

— Җүләр,— диде Луиза.

## V

Иртәгесен авыл өстен күе авыр болытлар каплап алды. Алар шулкадәр түбән, хәтта якындагы тузып, череп беткән мәчет манарасының башы да күренми иде. Битләрне, кулларны чеметтереп салкын яңгыр яварга тотынды. Альфред Шамилне тотты. Луиза сумка һәм портфельләрне күтәрде. Яңгырга каршы йөзләрен яшерергә тырышып тая-шуа, алар авыл урамы буйлап мәктәп ягына таба киттеләр. Алар баланы урнаштырып, мәктәпкә килеп кергәндә җыештыручы апа, кулына кыңгырау тотып, коридор уртасында тора иде инде. Дәрескә дип булса кирәк, үз кабинетыннан чыгып килүче директор кин коридорны тутырган шау-шулы балаларны төксе бер караш белән күзләреннән кичерде дә Альфредны күреп үз янына чакырды. Луиза, бу корырак табигатьле, үзеннән күп олы директорны тыйнак кына сәламләп, сүз әйтмәгәе дигәндәй, ашыга төшеп, укытучылар бүлмәсенә кереп китте.

— Сиңа әйтәсе сүз бар,— диде директор, Альфредның кулын кысып,— әйдәле кереп сөйләшик.— Директор кабинет ишеген ача башлады.

— Тукта инде, Халит абый,— диде Альфред,— плащны гына салып куйыйм.

Кинәт колакларны тондырып звонок чыңы яңгырады. Халит нидер әйтте: күрәсең, тоткарланма дигәндер, Альфред, укытучылар бүлмәсенә кереп, укытучылар белән исәнләште дә кием элгеченә плащын элә башлады.

— Чәчләреңне бераз сыпырып идең,— диде Луиза, кайгыртучанлык күрсәтеп. Ул бер кочак дәфтәр тоткан хәлдә Альфред яныннан узып китте.

Альфред, галошларын салып, чәчләрен сыпыра-сыпыра, яңадан коридорга чыкты. Ашыгып директор бүлмәсенә керде. Чак кына да кауша-мыйча, Әхмәдиевнең каршысына ук утырды. Директор, гадәттәгечә сул күзен кыса төшеп, артык җитди кыяфәттә аңа карап торды.

— Менә нәрсә. Безне бит, малай, халык арасында аз буласыз, лекцияләр аз укыла, дип тагы куыра башладылар. Нишлибез?

— Мин аны үзем дә уйлаган идем,— диде Альфред, аякларын чалып, иплəбрәк утырып,— безнен бит барысы да стихия рәвешендә

бара, Халит абый. Ул эшкә, план төзеп, даими рәвештә керешергә кирәк. Көч житәрлек. Без коллектив белән тотынсак, теләсә нинди теманы күтәрә алабыз. Аристотельдән алып космик корабларга кадәр!

— Дингә каршы кирәк.

— Анысын да булдыра алабыз. Безнең физик Сәлимжан абый хәтта «могжизалар» да күрсәтә ала. Мин моның турында бүген уйланырмын. Иптәшләр белән сөйләшеп, бәлки, план сызмасын да ясап булыр әле.

— Бик кирәк, оештыр инде син, малай. Ләкин монда менә нәрсә...— Ул тукталып торды,— мин роного барганда кичә райкомга кереп чыккан идем, шунда мине бик кыса башлагач, мин, моның ахыры хәерле булып бетмәс дип, иртәгә үк безнең лекция булачак, дидем. Синдә әзер тема юкмы соң, син бит тарихчы? Юкса эш харап.— Ул, елмая төшеп, сораулы карашын Альфредка төбәде. Завуч, кашларын жыерып, гасабиланып уйлана башлады. Тагы шул икән инде, артын-алдын уйланмый, тота да вәгъдә бирә.

— Кемгә мөрәжәгать итәргә дә белмим шул, Халит абый,— диде Альфред.

— Бәлки үзеңдә берәр әзер тема бардыр? Син бит тарихчы. Бүген какраз кино күрсәтеләчәк икән. Сеанс алдыннан бер кырык биш минутка лекция борып жибәргәндә шәп булыр иде. Ничек?

— Әгәр эш миңа терәлеп калган икән, минем кызыклы бер темам бар. Мин аны бүген үк чыгып сөйли алам.

— Нинди тема?

— Менә мин материал жыя торган Татар бригадасы тарихы.

Директор кинәт йөзен жыерды.

— Татар бригадасы дисең инде син?

— Әйе. Безнең бабайларның гражданнар сугышындагы гүзәл бер сәхифәсе.

Директор, Альфредның йөзенә үк карап, тагы сул күзен кыса төште.

— Нигә, ярый ул,— диде, ниһаять.— Ул тарихта андый-мондый нәрсәләр юктыр бит?

— Аңламыйм мин сезне, Халит абый. Ничек инде? Сез ул бригаданың үткән юлы турында берни дә белмисезмени?

— Белмим, чөнки мин тарихчы түгел... Ләкин шуны әйтим. «Татар бригадасы» дип авызыңны тутырып әйтүең генә бераз...

Альфред тыела алмыйча кычкырып көлеп жибәрде.

— Әй, Халит абый, Халит абый!

Директор шундук үзенең кирәгеннән артык саклык күрсәтүен аңлады булса кирәк.

— Юк, ярар, болай гына ул,— диде.— Беләм мин синең ышанычлы егет икәнлегеңне.

Альфред, кесәсеннән блокнотын чыгарып, сөйләнәчәк лекциянең кыскача эчтәлеген аңлата башлады. Бу инде Халитны тәмам тынычландырды, аннары сүз көндәлек мәктәп эшләренә күчте.

Инде кирәкле әңгәмә беткән кебек иде. Ләкин күптән директорга үзе турында әйтергә теләгәннәре Альфредка китәргә ирек бирмәде. Күптән инде аның директор белән үзе турында ачыктан-ачык сөйләшәсе килеп йөри. Бүген исә, ничектер шушы эшне башкарырга вакыт житкән шикелле иде.

— Минем сезгә тагы бер сүзем бар иде, Халит абый,— дип башлады ул,— менә ни турыда.

Ул кыймагандай бераз уйланып торды.

— Я, я,— диде директор, нидер сизенгәндәй, сагая төшеп.

Альфред тәвәккәлләп:

— Менә нәрсә, Халит абый,— диде,— гыйльми эш белән шөгыльләнүем минем барлык булганымны йота башлады.

— Ничек инде ул?

— Ничек дип... Мин бөтен вакытымны гыйльми эшкә бирергә тиеш. Башкача мөмкин түгел. Мин моны сезгә генә әйтәм, Халит абый. Чөнки...

Альфред, сүзен әйтеп бетермәстән, тагы тукталып торды.

— Мин сине штоты аңламыйм,— диде Халит, елмаеп,— син нәрсә, әллә...

— Әйе, шул, «әллә»,— диде Альфред,— мин университетка китәм. Анда хәзер минем өчен штатный урын булдырырга тырышалар.

— Ничек инде ул алай? Мин син эшләгән мәктәпнең директоры... берни дә белмим.

Альфред жинелчә көлеп куйды.

— Менә белсен дип тырышам да инде, Халит абый.

— Аңламыйм. Мин сине үзем завуч итеп күтәрдем, сиңа авторитет тудырдым. Инде безнең уртак эшебезгә комачаулый торган һәвәскәрлекләреңә дә түздем. Инде ахыр чиктә уку елы башлангач, син безне ташлап китмәк буласыңмы?

— Мин бит бүген китәм димим, Халит абый. Без аның формаль-ный якларын тиешенчә эшләрбез. Һәрхәлдә, мин коллективның эшенә зарар китермичә генә китәрмен...

— Юк, туган, мин моңа категорически каршы, мин сине жибәрмәс өчен барын да эшләячәкмен, аны бел, үпкәләштән булмасын.

— Юк, сез аңларга тиеш, Халит абый, мин моңарчы барлык көчемне җигеп тырыштым. Миңа коллективтан аерылуы бик авыр. Ләкин сез аңларга тиеш. Бу эш, тарих — минем призванием. Менә мин бер ел эчендә дә, барлы-юклы вакыттан файдаланып кына да, дөнья кадәр нәрсә актарып ташладым. Һәрхәлдә, миңа университеттагы иптәшләр шулай диләр. Тарих минем өчен җан азыгы инде хәзер. Аннан соң, уйлап карагыз, кирәк тә бит ул! Сез аңларга тиеш, тарихыбыз, татар халкының тарихы, аның революцион һәм гражданский тарихы һич тиешенчә өйрәнелмәгән.

Альфредның йөзе кызарган, ул, кулларын селки-селки, үзенең хаклы икәнлеген аңлатырга тырыша иде.

Юк, юк, ул һич Әхмәдиевне болай кискен рәвештә каршы килер дип уйламаган иде. Ул, һич югында, уйлашырбыз, киңәшербез, күз күрер, дияргә тиеш иде кебек. Артык тырышып эшләүнең начар ягы да бар шул каһәр, менә шуның газабын кичерә инде хәзер Альфред.

Директор гадәттәгечә кулын күтәреп, үзенең баш икәнлеген исенә төшереп, аны сүзеннән бүлдерде.

— Шашма, житте, Альфред Яхич,— диде ул.— Син үзеңнең коммунист икәнлегеңне онытма. Бер мин генә түгел. Бездә райком бар әле, аннан районо ни әйтер. Аннан килеп, республиканың югары партия һәм совет оешмалары да бар. Шулардан узып...

— Анысы турында борчылмагыз, Халит абый, алар минемчә аңларлар.

— Беркая да китмәячәксең син!

Альфред, күзлек пыялаларын ялтыратып, соң дәрәҗәдә ачуы килгән хәлдә башын күгәрде.

— Ничек алай әйтергә хакыгыз бар сезнең? Мин бит крепостной түгел.

— Кирәкмәс сүзләр сөйләмә, Альфред Яхич, син бала да түгел.

— Сез халкыбызның тарихына житәрлек хөрмәт белән карамыйсыз. Менә шул, юкса бу урында теләсә кайсы иптәш эшли ала.

— Ә тарихчы булып университетта? — дип сорады Халит. Аның күзләрендә мыскыл, кимсетү утлары күренә иде. Бу исә Альфредны бөтенләй чыгырыннан чыгарды.

— Халит абый, сез аңларга тиеш, мин ул эшемне башка бернигә дә алыштыра алмыйм, мин менә дүрт ел укытканнан соң үземнең бары шул өлкәдә генә ни булса да бирә алачагымны тойдым.

— Нигә, син укытучы буларак та начар эшләмисең. Юкса мин сиңа «дүрт ягын кыйбла» димәс идеммени?!

— Юк, юк,— диде Альфред, башын чайкап.

— Менә алайса син башта безгә, безгә генә түгел, бөтен халыкка үзеңнең талантлы тарихчы икәнлегеңне күрсәт, аннан соң икенче төрле сөйләшербез.

Кинәт звонок чалтырады. Бусы тәнәфескә чыгу өчен иде. Яңадан биш минуттан Альфредның дәресе. Альфред аягүрә басты да, нишләргә белмәгәндәй, ачынып кул селтәде һәм директор бүлмәсеннән чыгып китте.

# VI

Иртәгесен иртүк аңа профессор шалтыратты. Рәфкать Сабирович теге үзе әйткән, Ташкенттан кайткан кешенең адресын тапкан икән, шуны хәбәр итте. Ләкин мәктәптә дә эш тулып ята иде әле. Альфред Казанга баруны якшәмбе көнгә калдырырга мәҗбүр булды.

Ул чагында да Луизаны, Шамил белән кул-аягын бәйләп, авылда калдырырга туры килә әле. Тагы бәрәңге казылып бетмәгән килеш ятачак. Ләкин бармыйча да ярамый, кем белә аны, ул бүген монда, ә иртәгә, белмәссең, үзенең Ташкентына китәр дә барыр. Кулга төшкән асыл кошны ычкындырырга ярамый.

Якшәмбе көнне Альфред караңгыдан ук торды да, сак кына юынып, киенә башлады. Луиза йоклый иде әле. Аның ап-ак йөзе алсуланып тора, кызыл иреннәре бүлтәйгән, ә керфекләре йоклаганда да матур озын, куе кара булып күренәләр. Альфред өстәлдә яткан күзлеген киеп алды һәм бераз вакыт хатынының матур йөзенә сокланып карап торды. Кинәт караватында йоклаган Шамил тынычсызланып ыңгырашып алды. Аның ап-ак йомры матур арты, нәни симез тәпиләре ачылып киткән иде. Альфред улының өстенә йомшак одеалын иплән япты. Тагы, төймәләрен каптыра-каптыра, Луизаның тыныч кына йоклавын күзәтте. Кинәт хатынның озын матур керфекләре тибрәнеп куйды, ул күзләрен ачмыйча гына, йокы аралаш сорады:

— Нишләп шулкадәр иртә?

— Казанга китәм, Люлю.

Альфред хатынына яратып шулай дип дәшә, Луиза да андый вакытларда ирен Альмам дип йөртә иде. Луиза зур коңгырт кара күзләрен ачып, үпкәләгән кыяфәт белән Альфредка карады. Авыр иде бу шелтәле карашны күтәрү. Ләкин Альфред әйтми булдыра алмады.

— Сиңа бит мин кичә аңлаттым инде, Люлю.

— Гомергә бер тапкыр гына булса да ялны бергә уздырабыз дип торам тагы мин!

— Соң бит ул кешенең китеп баруы мөмкин.

— Бар, бар, пожалысты. Китәсең дә шул Казанда олагасың. Әллә көне буе бала белән чиләнүләре бик күңелле дип уйлыйсыңмы?!

— Мин бу юлы озак тормам,— диде Альфред, плащын киеп,— мин көндезге поезд белән кайтып җитәрмен.

Ул хатынын үбәргә дә теләгән иде. Ләкин кыймады, мондый ачулы чагында алай итү Луизаны җенләндерә генә төшәр, дип уйлады.

— Мин бик озак дигәндә дә көндезгә кадәр генә,— диде ул, бик ярарга тырышып,— бәлки эле иртәрәк тә кайтып житәрмен... Менә күрерсең.

Луиза күзләрен йомган килеш хәрәкәтсез ятуында булды. Альфред бөтенләй күңелсезләнеп ишек алдына чыкты һәм арттан гына, бәрәңге бакчалары аша, станция сукмагына таба китте. Көн аяз, өй түбәләрендә, калкурак урыннарда сөт түгелгәндәй агарып кырау күренә иде.

Альфред тимер юл буендагы бәләкәй өйгә кереп билет алды, аннан чыгуы булды, пошкырып, гөрелдәп, дачный поезд да килеп житте. Альфредның башы хәзер иң кызыклы уйлар белән тулган иде. Ул эле күрәсе кешесенә зур өметләр баглый. Чөнки, ишетүенчә, ул карт үзләре үткән шанлы юлны истәлек итеп калдырырга жыена икән. Ә бу эш, Альфред фикеренчә, бик әйбәт. Алар кулга-кул тотынышып эшләрләр. Пенсионер кеше, вакыты күптер аның. Аннан соң бит ул үзе катнашкан, үзе сугышларда һәм походларда булган. Әйбәт булачак. Тик бу кешене юкка чыгарырга теләгән икенче бер пенсионер, Хәмзә ага Бакиров, белән булган хәл кебек кенә килеп чыкмасын... Көннәрдән бер көнне Альфред шул Хәмзә абзыйга барды. Әмма тегенең сөйләшәсе дә килмәде; башта китап язып бастырыйм, аннан соң материалдан файдаланырсыз, күз күрер, диде. Сәер кеше иде ул. Кем белә, бәлки бусы да шулай дияр Альфредка. Хәер, бераздан барысы да билгеле булыр, юкка баш катырмыйк...

Альфред поездга кереп утыру белән куен кесәсеннән блокнотын алып картның адресын укыды. Аннары икенче кесәсеннән буйга бөкләнгән юка дәфтәр чыгарды. Анда кайбер язмалары бар иде аның. Вакыт булуыннан файдаланып, Альфред газета өчен әзерләнеп ята торган шул мәкаләсен төзәтергә керешә.

Мәкаләдә болай язылган иде:

«Яшь совет республикасы өчен иң газаплы, иң михнәтле онытылмас мең тугыз йөз унтугызынчы ел иде. Илгә һәр яктан интервентлар һөжүм итә. Ул гына житмәгән, гражданнар сугышы бетмәс-төкәнмәс корбаннар сорый. Колчак, Кызыл Армиянең көнчыгыш фронтына үзенең канлы хәнжәрен кадап, урта Иделгә, Самарага омтыла. Шундый хәтәр көннәрдә эле күптән түгел генә Мәскәүдән Казанга күчерелгән Үзәк мөселман хәрби коллегиясе беренче аерым Идел буе татар бригадасы төзүгә керешә. Ул бригаданың беренче полкы Казанда оеша. Аның туган көне — 1919 нчы елның март ае. Бу полк башлыча татарлардан тора. Татар эшчеләреннән, татар крестьяннарыннан. Алар бу полкка сүнмәс дәрт белән, утлы корал тотып, бөек революциягә ярдәм күрсәтү теләге белән киләләр. Барлык эш ана теләндә бара. Чөнки кызылармеецлар үз телләрен генә әйбәт беләләр. Аларга ашыгыч рәвештә сугыш фәнен үзләштерергә туры килә, чөнки фронттагы хәлләр артык хәвефле. Безнең фронт ярдәмгә мохтаж. Ашыгырга кирәк. Шулай итеп безнең бабайлар ай ярым чамасы гына өйрәнәләр дә Колчакка каршы фронтка китеп баралар. Хуш, Казан, хушыгыз, туган-үскән яклар! Менә алар, безнең бабайлар, ике эшелон булып, төялешеп башта пароходта Самарага баралар, аннан юл поездда дәвам итә».

Альфред шул жирдә туктап уйланып утырды. Ничектер теләгәнчә жанлы, кызыксындырырлык булып чыкмый кебек иде. Ул, башын үзгәртергә кирәк, дигән карарга килде дә яңадан кулъязмага текәлде. «Менә ул безнең татар егетләре, аларның өсләрендә төрле-төрле кием, форма гаскәри дип әйтерлек тә түгел, ләкин күр син, ул арсланнарның йөрәк тибешен тыңла, игътибар ит күзләренең яктылыгына. Аларның күңелләрендә дәрт кайный, алар бөек ирек өчен, үзләренең тулы хокуклы кеше булулары өчен көрәшкә ашкыналар! Әнә алар, баш киемнәренә кызыл йолдыз, я булмаса кызыл тасма тагып, үзләренең кем өчен көрәшкәнлекләрен дөньяга фаш итеп баралар. Алар теплуш-

каның ачык ишекләренә бәйләнгәннәр. Кайберәүләр ишек аркылы күеләп киртәгә сөялгән, бер-берсен иннәреннән кочканнар. Жырлыйлар. Юк, маршларны белмиләр әле алар. Алар гади авыл көйләрен, мәхәббәт турындагы жырларны, үзләренең авылда, я эшче бистәләрендә калган хатыннары, җанкисәкләре, сөйгән кызлары турында жырлыйлар. Ә алда канлы, чәнечкеле тимер чыбыклы окопларда аларны зур сынаулар көтә. Алар көнчыгыш фронтның Фрунзе житәкчелегендәге көньяк группасының уң як канаты дип аталган Оренбург далаларына баралар».

Альфред дәфтәреннән аерылып тагын йөзен чытты. Юк, юк, бу әле каралама гына. Моны утырып ныклап эшкәртәсе бар.

Ул тагы дәфтәр битенә текәлде. «Анда чуалышлар, жирле бай казакларның фетнәләре бер-бер артлы булып тора. Безнең армиягә бик авыр, ул торгынлыкта, ә шул ук группаның төньяк канатында данлыклы егерме бишенче дивизия, анда — Василий Иванович Чапаев. Аның турында әле дивизия военкомы Дмитрий Фурманов вакыты житкәч роман язачак. Чапаев барлык киртәләрне җимереп алга бара. Уң канатта жиңү безнең якта, тик ана тагы да зуррак мөмкинлекләр тудырып Бәләбәйгә юл ачу өчен, көньяк канатны да хәрәкәткә китерергә кирәк. Егетләр шунда баралар. Татар егетләре. Безнең этиләр, бабалар. Шулай. Алар үнжиденче май көнне фронт линиясенә барып життеләр. Бер эшелон Оренбург юлындагы Сорочинская, икенчесе Ново-Сергеевка станциясендә бушана. Алар тиздән Михаил Васильевич Фрунзе куйган сугышчан бурычны үтәүгә керешәчәкләр. Бу уен түгел. Ныклап өйрәнмәгән, үзләре ачлы-туклы, кием-салымнары бөтен булмаган егетләр бары тирән ышаныч аркасында, бөек теләккә ашкыну дәрте белән янганга күрә бу эшкә баралар. Бер полк сиксән километрга сузылган фронтка сибелә, ул шуны тотачак. Алда тамаклары тук, өсләре бөтен, кызмача атлы казаклар. Жир утлы кисәүдәй көйрәп тора. Әйтерсең лә, тирә-юньдә, кая барып сугылма, ут төртелгән дары базлары. Башкача чагыштыру һич мөмкин түгел. Бары бөек азатлык көрәшенә булган ышаныч кына безнең егетләргә түземлек һәм гайрәт бирә. Замчаловка. Белогорка. Андагы канлы сугышлар! Менә, менә нәкъ шул көннәрдә инде беренче татар полкы егетләре үзләренең революция эшенә ни дәрәҗәдә бирелгәнлекләрен күрсәтәләр дә. Алар сан ягыннан һәм корал җәһәтеннән үзләреннән берничә тапкыр күбрәк һәм көчлерәк, гомер буе хәрби эштә булган атлы казакларны тар-мар итеп ташлыйлар. Беренче авыр имтиханны менә дигән итеп узалар. Ләкин әле алда күп авырлыклар бар, җәфа чигәселәре аз түгел. Ничәмә тапкыр полк сфинкстай көлгә әйләнеп яңадан туачак әле.

Онытылмас унтугызынчы июнь көне. Сул як канатта Чапай дивизиясе, дошманны тар-мар итеп, Уфа каласын азат итә. Колчак, җәрәхәтләнгән ерткыч кебек, юлында булдыра алган кабахәтлекләрнең барысын да эшләп, Урал тауларының көньягына таба чигенә. Ләкин ул әле исән, ул әле көчле. Нәкъ менә унтугызынчы июнь көнне группаның уң як канат очы булган тугызынчы ротага ак казаклар һөҗүм итә башлый. Бу Новая Белогорка дигән авыл янында героик тугызынчы рота егетләре соңгы тамчы каннарына кадәр чигенмичә сугышалар. Туктаусыз пуля сиптергән пулеметның көпшәсе уттай кыза. Атлы казаклар, күз күремендәге бөтен тирә-юньне тутырып, безнең окопларга таба һөҗүм итәләр. Тирә-якны тузан болыты, сөрем баскан, мылтык, туп тавышларыннан колаклар тона, бөтен даланы тутырып атлар кешни. Тугызынчы рота барлык көчен куеп сугыша. Егетләр берәм-берәм егылалар, тагы торып винтовкаларын кулларына алалар, үлгәнче сугышалар. Ләкин бәдбәхет дошман көчле. Ул ротаның башына житә. Аннары, шул уңыш белән дәртләнеп, ул өченче батальонның артына төшә. Батальон полкның төп көчләреннән аерылып кала. Дошман,

...енче батальонны камап, икенче батальонга ташлана. Шәйхетдинов Хөснияр. Икенче батальонның командиры, ул бераздан полк командиры булачак. Арслан йөрәкле оста командир. Ул каушап калмый. Һөҗүмне лаеклы рәвештә каршы ала. Ярдәмгә беренче батальон егетләре килә. Канлы көрәш кызганнан-кыза бара. Ләкин хәл бик авыр. Беренче батальон саклыгы астында икенче батальон егетләре чигенәләр. Матвеевкадагы полк штабы да чигенә. Матвеевка кулдан кулга күчә башлый. Ниһаять, безнең гаскәрләр Воробьевкага чигенәләр. Ләкин анда безнең егетләрне атлы казакларның эскадроны көтә. Күп корбаннар белән утлы боҗраны өзеп, ахырда камалыштан чыгалар. Шулай да алар Гамалеевка станциясенә урнашкан полк штабын дошман кулына бирмиләр.

Башларыбызны иеп, совет власте өчен һәлак булган якташларыбызны искә алыйк. Полк тар-мар ителә, ләкин рухи яктан ул шулай да үлми, киресенчә, исән калганнар үзләренең яшәргә, көрәшергә хаклы икәнлекләренә һәм җиңәчәкләренә ышанычларын арттыралар. Йөрәклэрдән утлы нәфрәт ялкыннары тышка ургыла. Туктагыз, сабыр итегез! Без әле сезгә үзебезнең кем икәнлегебезне күрсәтербез! Менә алар, хәл җыю, көч-куәт арттыру өчен, бригаданың башка полклары янына, Самарага юл тоталар. Аларга озакламый Казан губернасыннан килгән якташлар кушылачак, алар анда хәрби белемнәрен арттыралар. Көннәрдән бер көнне Михаил Васильевич Фрунзе парад кабул итәр. Ул бик риза булыр һәм полк яңадан, героик казанышларга һәм данга ашкынып, туплар канонадасы ишетелгән якларга сәфәр чыгар»...

Альфред, тәрәзәдән карап, әледән-әле кашларын җыерып, тагы уйлана башлады. Юк, юк, теләгәнчә барып чыкмый иде бу мәкалә. Ләкин нәрсә җитми? Ул шул сорауга җавап эзләп азапланды. Ә тәрәзәдән мәһабәт төз наратлар, җәен дә, кышын да үзенең гүзәллеген югалтмый торган ылыслы агачлар урманы күренә. «Туктале, дип уйланды Альфред, бу беренче полк вакыйгаларында нинди хыянәтле эшләр дә булган бит. Кем әле ул, казакларга сатылган хыянәтче прапорщик?» Альфред хәзер инде тарихи вакыйгаларга чумды һәм аңа тыштагы матур урман тагы күренмәс булды.

## VII

Альфред ишеккә язылган номерга күз атты да звонок төймәсенә басты. Коридор буйлап, тәгаен, бала кешенең җиңел генә йөгереп килгәне ишетелде. Чыннан да, ишекне ачучы өч-дүрт яшьләрдәге матур бер кыз бала иде. Альфредның кемгә килгәнлеген ишеткәч, ул, коридор очында күренгән ачык ишеккә карап, кыяр-кыймас кына кычкырды:

— Бабам, сиңа килгән. Бер абый.

— Кем соң ул, кызым? — дип сорады бераү.

— Ну, чык инде, килгәннәр дим ич,— диде кыз, куркынып һәм пошынып.

Бераздан, аягындагы киез башмакларын чыштырдатып, коридорга ир кеше килеп чыкты. Ул артык ябык, аксыл йөзле, буйчан бер кеше иде. Сакал-мыегы кырылган булса да, аның күптән пенсия яшендәге кеше икәнлеген күрү белән аңлау авыр түгел иде.

— Сез Хәбибрахман ага бит? — диде Альфред.

— Әйе, шулай.

— Әйдәгез исәнләшик. Исәнмесез.

— Исәнмесез.— Хәбибрахман уңайсызлана төшеп елмайды.— Тик мин сезне танымыйм.

— Зарар юк, Хәбибрахман ага,— диде Альфред,— хәзер мин барысын да аңлатырмын.— Ул үзенең исем-фамилиясен әйтте.

— Мине сезнең Беренче татар бригадасы турындагы истәлекләрегез кызыксындыра. Мөмкин булса, без бераз сөйләшеп утырыр идек.

— Рәхим итегез,— диде Хәбибрахман, Альфредка сынаулы караш ташлап,— нинди мәсьәлә кызыксындыра соң сезне?

Альфред өс-башын, галошларын үз өенә кайтып кергәндәгедәй кыю гына салып урнаштырды да карт артыннан эчке бүлмәгә узды. Хәбибрахман абзыйның өстендә җиңсез үзбәк чапаны иде. Эшләү өчен комачаулагангадыр, күрәсең, ул чапанның җиңнәрен сүтеп ташлаган иде. Моны Альфред якты бүлмәгә кергәч кенә абайлады һәм эченнән елмаеп куйды.

Алар өстәл янына кара-каршы куелган утыргычларга урнаштылар. Нәни кыз, күзләрен Альфредтан алмыйча, бабасының тезләре арасына кереп сыенды.

— Мин ике елга якын инде Беренче татар бригадасының тарихын өйрәнәм. Мин үзем тарихчы профессор Даутов кул астында эшлим,— дип сүз башлады Альфред.

Хәбибрахман абзыйның соргылт күзләре бердәм яктырып китте.

— Бик әйбәт. Бик кирәкле эш.

— Минем ишетүемчә, сез бригаданың үткән юлы турында китап язасыз икән?

— Гамәлгә ашырылмыйча калган эш,— дип куйды Хәбибрахман, эрнүле елмаеп...

— Сәбәп нәрсәдә соң? Сезгә кемнәрдер каршы төшкән булса кирәк?

— Шулай булды шул.

— Сез миңа аңлатыгыз әле, Хәбибрахман ага... Хәер, анысы кирәкми дә. Беләсезме, Хәбибрахман ага, миңа сезнең ярдәмегез кирәк иде. Тарих фәнендә истәлекләрнең дә әһәмияте зур. Әлбәттә, субъектив хаталарның булуы мөмкин. Чын дөреслекне документаль рәвештә генә исбатлап була. Ләкин шулай да, минемчә, ул истәлекләр бик кадерле чыганаклар...

— Соң үзең күргән, үз башыңнан узган нәрсә мөһим инде.

— Әйе, әйе. Менә нәрсә, Хәбибрахман ага. Сез үзегез ничәнче полкта хезмәт иттегез?

— Беренче полкта.

— Димәк, сез унтугызынчы елгы июнь сугышларында катнаштыгыз инде? Мин әле юлда, сезгә килгәндә, поездда шуның турында үземнең кайбер язмаларымны укып килдем.

Альфред үзенең Казаннан читтә, авылда, яшәгәнлеген әйтте.

— Ийе, катнашырга туры килде,— диде Хәбибрахман.— Мин аның тарихын әйбәт беләм.

— Гафу итегез, сез кем идегез, рядовой кызылармеецмы, отделенный-фәләнме?

— Мин анда соңыннан тугызынчы ротаның өченче взводында отделение командиры булдым. Башта гади кызылармеец идем...

— Шулай икән. Билгеле, бер утыруда гына барын да сорашып булмый инде. Зинһар, үзегез кызык дип тапканны сөйләгезче. Альфред, кесәсеннән зур блокнотын алып, язарга әзерләнде.— Сез бригада тарихын язарга җыенуыма каршы түгелсездер бит?

— Андый сүзне сөйләмәгез! Мин, киресенчә, бик-бик шат. Беренчедән, сез безнең тарихны киләчәк буыннарга калдырасыз, ә икенчедән, сез, минемчә, миңа союзник. Мин шулай булыр дип ышанам.

— Ничек инде, без бергә эшләрбезме? Сез шуны күздә тотасызмы?

— Әгәр теләсәгез, алай да була. Аннан, Альфред иптәш, тагы шунысын да әйтим, мине бер кеше тарихны бозуда гаепли бит.

— Ах, сез тагы әлеге җанҗаллы вакыйга турындамы?

— Ләкин бу эштә хата тегә якта, Альфред. Мәсьәләнең нечкәлекләренә керә калсагыз, аңларсыз...
— Сөйләгез әле, зинһар, барысын да,— дип үтенде Альфред.
— Сез беләсезме икән, мин бит культ заманының корбаны булган кеше.
— Шулаймы? Анысын белми идем.
— Мин утыз җиденче елны райком секретаре булып эшләдем. Үзегез беләсез, партия эше авыр, катлаулы, мәшәкатьле, ифрат күп вакыт таләп итә торган эш. Шуңа күрә, мин никадәр тырышсам да, бригада турындагы тарихны халыкка җиткерә алмадым. Ә минем моңа шактый гына мөмкинлекләрем бар иде, югыйсә.
— Нинди мөмкинлекләр?
— Нинди дип,— Хәбибрахман картлыктан төссезләнә башлаган соры күзләрен Альфредка таба төбәде.— Мин партия эшенә күчкәнче, үзем укытучы чагында ук...
— Ах, сез элек укытучы идегезмени?
— Әйе, мин укытучы идем. Аннан партия эшенә алдылар и шунда...— Бөтен әзләнүләрем бүленеп калды.
— Гафу итегез. Мин артык бүлдермәм,— диде Альфред.
— Ийе, болай... ни... Ә-э... ни... Ну менә шул укытучы чакны ук мин үзебезнең бригада турында материал җыя башлаган идем. Аның өстенә минем язулар да бар иде. Билгеле, миңа, авыл укытучысына, ул вакытны эшемнән аерылып, төрле архивларда казынырга мөмкинлек булмады. Тик мин шулай да үзем адресларын белгән иптәшләрнең барысына да хатлар язып, алардан истәлекләр, я булмаса шушы тарихка бәйләнешле документлар сорадым. Ни әйтсәгез дә, без бит бик олы юл уздык. Туры сызык белән сызганда да Казаннан Бохарага чаклы! Ничә километр ара? Алты мең километр! Ләкин бит ул шоссе юлы буйлап автомобильдә бару түгел, ул һәр адым саен явыз дошман белән көрәшеп, ачлыкны, суыкны, тифны җиңеп атлау... Кыскасы, мин йөздән артык иптәштән хат алдым: төрле истәлекләр, көндәлекләр һәм башка төрле документлар, рәсемнәр. Инде менә райком секретаре булып эшли башлагач та тик ятмадым, булдыра алганча каләм тибрәттем. Тик озак кинәндермәделәр мине. Утыз җиденче елның бер төнендә ябык машинага утыртып алып киттеләр дә Казан төрмәсенә яптылар. Хәтта шул кадәресен дә әйтә алам. Тикшерү вакытында шул хатлар алышуым минем башыма җитә язды. Аны улика итәргә тырыштылар.
— Ничек инде?
— Янәсе, мин нииндидер яшерен переписка алып барам. Совет властена каршы көрәшкә татарларны күтәрергә җыенам...
Альфред ачу аралаш көлеп куйды.
— Гафу итегез, сорамый булдыра алмыйм,— диде ул, тынычлангач.— Ул язуларның хәзер берсе дә исән түгелме?
— Кайберәве генә,— диде Хәбибрахман,— кайберәве генә исән. Мин илле алтынчы елны реабилитацияләнеп кайтканда хатыным үлгән иде инде, кызым белән улым өйдән бик яшьләй чыгып киткәннәр, алар, фамилияләрен алыштырып, детдомнарга урнашканнар, мин элек яшәгән өйдә бөтенләй чит кешеләр тора иде. Шулай да кайбер язулар табылды. Ләкин бик азы.
— Кызганыч,— дип куйды Альфред, чын күңеленнән уфтанып.
— Инде болай,— диде карт,— мин тегендә беренче авырлыкларны уздыргач, кинәт үзем өчен нииндидер бер рухи азыкка мохтаҗлык тоя башладым. Шуннан тагы үземнең яшьлек чорым белән серләшә башладым. Мин анда, булдыра алганның барын да эшләп, хәтердә калганнарның барын да тупладым. Эштән бушаган һәр минутымны шуңа биреп юандым. Инде менә, әйтеп бетергесез газаплардан соң, күптән

көтелгән якты көн килеп житте, мине азат иттеләр. Житмәсә әле, юлыма акча бирделәр, өстемә кием юнәттеләр, пенсия тәгаенләделәр. Инде миңа бөтен мөмкинлекләр ачылды. Теге, әлеге үземнең эшем турында, бригада тарихын әйтүем инде. Менә шулай. Кайту белән үземнең күңелемне егерме елдан артык вакыт жилкетеп торган эшкә керештем. Янадан хатлар яза башладым. Исән калган егетләр бармак белән генә санарлык иде. Тик шулай да кайберләрен табып эшкә керештем. Хәзер инде максатым барлык узылган юлны язу булмады. Мин баштан кичкәннәрне теркәүне генә максат итеп куйдым хәзер. Көн-төн эшләргә туры килде. Йөрәк тә, бөерәк тә, ашказаны да авырта үземнең, нервылар да иске мунчаладай тетелеп беткән. Тик шул эшне эшләмәсәм яши алмас булдым. Кайчак улым да, кызым да әйтәләр: «Нигә кирәк ул? — диләр,— сәламәтлегеңне карар идең, әти»,— диләр. Тик булдыра алмыйм. Шуның белән яшим.

Хәбибрахман озак сөйләүдән арып тынып торды.

— Тагы бер генә сорау, Хәбибрахман ага,— диде Альфред.— Сез Ташкентта яшәгәнсездер инде, тегеннән кайткач?..

— Әйе. Анда минем улым яши. Ул мине коткару өчен кайбер нәрсәләр ачыклану белән йөри башлаган. Мин аның янына кайтып төштем.

— Ә Үзбәкстан архивларында булмагансыздыр?

— Юк, анда була алмадым. Мин моңарчы истәлекләр белән генә эш иттем.

— Ә Казан музеена ничек барып эләктегез соң?

— Мин сүзне шуңа таба алып барам да инде, Альфред иптәш.

— Бетте. Мин сезне тыңлыйм.

— Нәрсәдә тукталган идем әле мин?

— Сез, бу эшне мин Ташкент шәһәрендә башкардым, дидегез.

— Әйе. Мин аны шунда яздым. Ләкин әйтергә кирәк, мин Казан белән дә бәйләнеш тоттым. Чөнки, ни әйтсәгез дә, безнең бригаданың анасы — Казан каласы бит. Инде житмәсә, мең тугыз йөз илле тугызынчы елны мине Казан музеена кунакка да чакырдылар. Минем кәеф тә ул чак чамалы иде. Тик мин шулай да килдем. Шуннан безнең бригада төзелүгә кырык еллык уңае белән зур бер очрашу булды. Мин шунда бригадада бергә хезмәт иткән иптәшләрне күрдем. Күбесе картайган, танырлык та түгел. Ә кайберләрен мин бөтенләй белмим дә икән. Шунда инде безне тәбрик иттеләр. Шуннан соң без дә үз чиратыбызда чыгып истәлекләр сөйли башладык. Шунда бер отставкадагы майор да чыгыш ясады. Минем ул кешене гомеремдә ишетеп тә белгәнем юк иде. Шул мин сөйләгән сүзләрнең барысын да юкка чыгармасынмы! Безгә Новая Белогорка янындагы сугышларда шактый зур газаплар кичереп рота командирын үлемнән саклап калырга туры килде. Мин ул чакны отделенный идем. Шуны мин эшләдем, дип бара теге. Аннан тагы бик күп һич булмаган нәрсәләр сөйләп бетерде. Мин белгән бик күп егетләрнең батырлыгын үзләштергән. 1920 елның 2 сентябрендә безгә Иске Бохараны алырга приказ булды. Каршы капкасына беренче булып ташланып, шәһәр эченә керүче Әтнә егете Гәрәев Гыйниятулла булды. Башкалар шуңа ияределәр. Менә бу юньсез, шул кеше мин идем, дип бара. Аннан тагы әллә ниләр сөйләп бетерде. Мин түзмәдем: «Туктагыз әле, — дидем,— сез кем соң? Мин бит шул вакыйгаларның эчендә кайнаган кеше, ләкин мин сезне бөтенләй хәтерләмим»,— дидем. «Мин Хәмзә Бакиров,— ди бу,— мин тугызынчы ротаның өченче взводында рядовой кызылармеец булып хезмәт иттем. Әгәр минем истәлекләрем белән танышасыгыз килә икән, фәлән журналның фәлән номерын, фәлән җыентыкның фәләненче басмасын карагыз»,— ди. Аның, баксаң-күрсәң, дөнья кадәр истәлекләре басылып чыккан, үзен төрле шәһәрләрдә ветеран, гражданнар сугышы каһарманы дип

ифрат хөрмәт итәләр, имеш. Мин, аптыравымнан ни әйтергә дә белмичә, өнсез калдым... Менә шулай итеп минем бик изге ниятләрем үземне һәм дусларны аклау өчен эшләнәчәк хосусый бер эшкә әйләнде дә калды.

— Гаҗәп хәл,— диде тәмам шаккаткан Альфред.— бу теге авантюрный романнардагы кебек килеп чыга бит.

— Менә теләсәгез ни әйтегез инде! — диде Хәбибрахман, куллары җәеп.

— Сез теге Бакировның әйткәннәрен халык алдында юкка чыгармадыгызмы соң?

— Ничек инде? Мин бик ярсып иптәшләр алдында чыгыш ясадым. Ләкин теге кеше күптән абруй казанган шул өлкәдәге бер белгеч булып исәпләнә икән хәзер. Хәтта шунысын да әйтим: мин истәлекләремне чыгарырга теләп журнал редакциясенә баргач, анда язылганнарның дөреслеген ачыклау өчен кулъязманы шул ук Бакировка җибәрделәр.

— Һәм сезнең аны фаш итәрлек бер генә дәлилегез дә юкмы?

Карт өметсез рәвештә кул селкеде.

— Бар иде. Хатлар бар иде. Истәлекләр бар иде. Көндәлекләрем бар иде. Мин, мәсәлән, авыл мөгаллиме, ул заманның гадәте буенча, фронтка элэгү белән көндәлекләр язып бардым. Чак исән калып, Самарага пополнениегә кайткач, ул көндәлек дәфтәремне шактый тулыландырып күчергәнемне дә хәтерлим әле. Ләкин ул хәзер кайда? Аны, элеккечә әйтсәк, бер хода гына белә инде, Альфред энем. Аннан, әлбәттә, архивлардан документларын да табарга булыр аның. Мәсәлән, егерменче елны өченче сентябрьдә Михаил Васильевич Фрунзе Иске Бохарада җиңүгә багышлап оештырылган парадта безне кызыл байрак бирелү уңае белән тәбрик итте. Хәтеремдә, соңрак ул Бохара операциясендә батырлык күрсәткән татар егетләрен дә котлады. Ул приказда, тәгаен, бу Бакиров юктыр. Чөнки мин аны белми калыр идемме соң!

Аңлаешсыз сүзләрне тыңлап тәмам ялыккан кызчык йөгереп бүлмәдән чыгып китте. Кинәт коридордан аның бабасына нидер әйткәне ишетелде.

— Бер генә минутка,— диде карт, урыныннан торып. Авыр адымнар белән аякларын сөйри төшеп, ул кызының нинди дер үтенечен башкарырга дип китте.

Альфред уйланып утырды. Мәсьәлә шактый катлаулы икән. Шулай шул, тарих ул — кешеләр язмышы, монда полк, бригада дип кенә булмый. Монда кеше язмышы уртада тора. Кинәт кеше язмышына бәйләнештә аның исенә әле Казанга узган килүендә очраган Латиф төште. Ул да әтисенең язмышы белән кызыксына бит. Кеше моңарчы тыныч кына яшәгән. Ә ниндидер сәбәп әтисен исенә төшергән, һәм ул тарихка мөрәҗәгать итә. Тукта, кем иде әле аның әтисе? Әйе, Ибраһим Касыймов.

Карт, кызын киендереп урамга озаткач, бүлмәгә керде. Чапаны артык шыксыз иде аның. «Менә ул картлык нишләтә, матурлыкка игътибар итми башлый кеше», дип уйланды Альфред.

— Мин күп сөйләшеп сезне ялыктырам бугай,— диде ул.— Юкса мин бүген сезнең белән танышу өчен генә килгән идем. Моннан соң сез үзегезнең ярдәмегездән баш тартмассыз инде, Хәбибрахман ага. Тик менә тагы бер сорау калган икән. Берәү әтисенең язмышы белән кызыксына. Аның әтисе күптән үлгән, шул татар бригадасында хезмәт иткән кеше икән үзе.

— Кем икән соң ул? — диде Хәбибрахман.

— Ибраһим Касыймов. Шундый кешене белмисезме?

Карт, карашын өскә төби төшеп, уйланып алды.

— Бер дә белмим шул. Ничәнче полктан соң ул?

— Анысы билгесез. Соравым бары, очраклы рәвештә белмисез микән, дип кенә.

— Ничектер бик таныш исем-фамилия инде үзе югыйсә,— диде Хәбибрахман, уйланып,— тик һич хәтерли алмыйм. Ниндирәк кеше икән соң ул?

— Менә аларын инде тулырак итеп улы әйтер. Бәлки әле фоторәсеме дә бардыр... Әгәр сез каршы килмәсәгез, мин сезнең адресны ул кешегә бирим. Ул бик үтенде. Бәлки хәтерләрсез.

— Бирегез. Килсен.

Альфред сәгатенә карап алды. Күз алдына үпкәләгән Луиза килеп баскандай булды. «Мескен, ул бәрәңге белән, Шамил белән чиләнеп ятадыр инде»,— дип уйланды. Ләкин карт яныннан китәсе килми иде әле. Кызык хәлләр кичергән иде бу карт. «Әз генә сорашам да, аннан китәрмен»,— дип уйланды Альфред.

# VIII

Ул шулай уйланды. Ләкин сорашуы әз генә булмады. Сорау артыннан сорау туды, кызыклы тарих сәхифәләре ачылганнан ачыла барды. Ахыр чиктә ялгыш кына сәгатенә күзе төшеп, Альфред, корт чаккандай, сикереп урыныннан торды. Әгәр ул җан-фәрманга чапмаса, көндезге поездга соңга калачак иде. Ул юньләп хушлаша да алмыйча, ашыгудан галошларын онытып чыгып чапты. Аның артыннан Хәбибрахман ишекне бикләп, кухняда бәрәңге әрчергә кереште.

Хәбибрахман абзый Казанга бөтенләй тарих язу эшен күздә тотып кайтмады. Хәер, бер тапкыр ул музейга барып килмичә булдыра алмады. Үзе өчен аерата кадерле тоелган стендлардагы яңалыклар белән кызыксынып йөрде. Ләкин шуннан артыгын кирәк санамады. Кияве чит илгә шактый озакка командировкага киткән иде. Бала янында калырлык, өйгә күз-колак булырлык бер генә кеше дә юк. Шуңа күрә генә, кызы бик үтенгәнгә күрә генә Казанга кайтты ул. Ә инде теге Бакиров корган серле эшкә юлыккач, барысына да кул селтәде.

Уралып-уралып бәрәңге кабыгы аска төшә. Хәбибрахман абзый бәрәңгеләрне бер-бер артлы әрчеп уйланып утыра. Карасана! Бу килгән егет күңелдәге йокымсырый башлаган дәртне, күптән инде хыялга аша алмый азапланган, әле бер сәбәп, әле икенче сәбәп аркасында тоткарланып торган теләк-омтылышларны кузгатып җибәрде түгелме соң?! Карасана! Хәбибрахман юләр, япа-ялгызым калдым дип бик ялгышкан икән ләбаса! Ах, теге намуссызның койрыгыннан эләктереп аласы иде бит!

Хәбибрахман хыялга бирелеп утырды. Егет, чыннан да, күңеле көткән кеше булса, Хәбибрахман аңа ярдәмне күрсәтми калмас. Ә теге архив материалларын табар. Табар, табар, тапмый калмас. Хәбибрахман яшь тарихчының ашыгычлык аркасында галошларын онытып калдырганын хәтерләде. Һәм елмаеп куйды. Юк, әгәр дә үзе юньле кеше булса, без бу егет белән шактый эш майтарырбыз. Тегенең кем икәнлеген фаш итәрбез.

Чын батырларның дөньяда юклыгыннан файдаланып, онытылмас елларның истәлеген урлаган кешегә карата Хәбибрахман утлы нәфрәт саклап яши иде. Моңарчы каракны бөтен дөньяга фаш итәрлек көчтерәк таба алмады ул. Хәзер исә, ничектер, әле бик анык рәвештә булмаса да, шул терәк барлыкка килердәй кебек иде. Белмәссең, бәлки бу Альфред менә дигән намуслы һәм батыр кешедер. Ни өчен һаман шикләнергә тиеш соң мин? Хәбибрахман бармагының киселеп киткәнен кан ага башлагач кына тойды. Аның йөзе чытылды, сукранып куйды, ләкин күңелендәге дәрт моңа карап сүнмәде.

Бераздан, бармагын бәйләп яңадан эшенә керешкәч, ул үзенең кайчандыр юкка чыккан көндәлек дәфтәре турында уйлана башлады. Шулай, анда барысы да язылган иде. Ул, документ буларак, тикшеренүчеләр өчен дә бик әйбәт булган булыр иде, ул бу Бакировның дәгъваларын да тәгаен юкка чыгарып ташлар иде. Ул көндәлеген өенә тентү булганга кадәр үк югалтты шул. Кемгәдер укырга биреп торды, ләкин бераздан кешесен хәтереннән чыгарды. Эш артык күп иде... Әйе, бик-бик үкенечле хәл.

Карт кызчыгының нәни утыргычына утырып эшли иде. Ул бәрәңгеләрен табактагы суда юды да күзләрен кыса төшеп, кесә сәгатенәерактанрак карап торды. Кастрюльдә ит күптән кайный иде инде. Кайтыр микән Кадрия? — дип уйланды карт. Ул, ниһаять, сәгатьнең ничәне күрсәткәнлеген белде һәм шул чакны тетрәнеп үзенең артык вакланып, артык картаеп киткәнлегенә игътибар итте. Һай, бу рәхимсез картлык! Шулай өйдә аш пешереп, бала карап утыра торган ир-егет идеме соң ул? Хәбибрахман газ плитәсендә бкырдап кайнап утырган ашны тәмам онытты. Кинәт бөтен тормыш ваклыкларына кул селтәп, үзенең җәмгыять өчен зур омтылышлар белән яшәргә тиешле кеше икәнлеге турында уйлады. Юләр, ул үләр өчен кайттымыни ирекккә?!

Хәбибрахман абзый олы бүлмәдәге көзгеле шифоньер алдына барып басты. «Һа, Хәбибрахман,— диде ул үзенә, ачы елмаеп,— барып җиткәнсең икән үзең дә! Сакал-мыек бүген кырылмаган, баш ишан мөритенекедәй иелгән, ә кигән кием, ташка үлчим, диваналарныкыдай». Хәбибрахман кабаланып өстендәге җиңсез чапанны салып ташлады. Ул аны башта диван-караватка ыргытты, аннары бераз уйланганнан соң коридордагы кухня ишеге өстенә ясалган иске-москылар ящигына илтеп атты. Олы бүлмәгә яңадан керде һәм шифоньерны ачып, аннан үзенең Казанга килгәч кенә тектергән кара вельвет пиджәген алып киде. Кадрия кайтып кергәндә карт әчке бүлмәдә язу өстәле янында тырыша-тырыша сакал-мыек кырып утыра иде.

— Ни булды? — диде кызы, аптырап,— әллә кунакка чакырдылармы, әти?

— Күңелем кузгалды, кызым,— диде Хәбибрахман,— миңа бер егет килде дә бөтен җанымны айкап китте.

— Соң? Әллә берәр күңелсезлек булдымы?

— Киресенчә. Ул егет безнең бригада тарихы белән кызыксына икән.

Кадрия, бу сүзләрне ишеткәч, өметсез рәвештә кул селтәп көлеп җибәрде. Ул коридор буйлап кухняга таба юнәлде. Хәбибрахман:

— Ит пешкән,— дип кычкырды,— бәрәңгесен сал да үзең бул-дыр! — Аның тавышында рәнҗү дә, ачу да сизелә иде.

Сакал-мыегын кырып бетергәч, карт шактый яшәргән, чибәрләнгән бер кыяфәттә, нәни кызы Ләйләне ияртеп, Кадрия янына, кухняга чыгып утырды.

— Син сорамадың бит әле,— диде ул,— минем нишләргә җыенуымны син сорамадың бит әле.

— И, әти җаным,— диде Кадрия, әтисенең яңагыннан сөеп,— берни дә эшләмә. Рәхәтләнеп өйдә генә яшә. Барысы да бар ич. Квартирыбыз иркен, җылы, ашарга бар, өстебез бөтен. Рәхәтләнеп яшә дә яшә. Болай да син, җанкисәгем, үз гомереңдә җитәрлек җәфа чиккәнсең инде, ичмаса, картайган көнеңдә бер рәхәтләнеп, тынычланып ял ит.

Хәбибрахман, әрнеп елмайган кыяфәттә башын селкеп, кызыннан күзен алмыйча карап торды. Үнтүгыз ел көрешмәдеdepәр алар. Хәбибрахман кулга алынганда Кадрия ун яшьлек, кубәләктәй җитез бер кыз бала иде. Ул чакны ук әнисенә тартым иде. Ә хәзер исә нәкъ әнисе: сөйгән дә каплаган. Ләкин барыбер әнисе түгел ул, Кадрия! — Үз заманының кешесе. Әнисе аның гади авыл кызы иде, кулында бернинди

һөнәре юк иде. Ә бу соң, бу бит күренекле белгеч. Ләкин шулай да ул, никадәр замана кешесе булмасын, никадәр культуралы һәм акыллы белгеч булмасын, этисенең күңелен аңламый. Ничек инде ул квартира, тамак, җылы урын белән генә канәгатьләнсен аның этисе?! Аңа зур, колачлы мәшгулият кирәк. Ул үзен бер генә минутка да хуҗа иркенә буйсынырга тиешле кунак итеп тоясы килми, ул үзен хуҗаларның берсе итеп тоярга күнеккән иде заманында, әле дә шулай буласы килә!

Кадрия стакан белән вермишель үлчи башлады.

— Кызым, мин шулай да теге кешене фаш итәргә кирәк дип уйлыйм,— диде Хәбибрахман.— Чөнки, ни әйтсәң дә, мин үземне үлгән иптәшләрем каршында җаваплы дип саныйм.

Кадрия сүзнең ни турында барганлыгын шунда ук аңлады. Ул инәлеп этисенә карады.

— И, эти бәгырем, синең кебек яше җитмешнең теге ягындагы кешеләрнең эшеме соң ул?

— Юк, барыбер, барыбер, кызым,— диде карт,— нигә син алай мине бик картайтырга ашыгасың әле?

Кадрия, бер сүз дә дәшмичә, шулпа чәчрәмәсен өчен сак кына ашка вермишель сала башлады. Ниһаять, эшләрен бетереп, этисе янына утырды.

— Эти,— диде ул, җитдиләнеп,— мин синең сәламәтлегең өчен борчылам. Сиңа доктор әйтте бит инде, син нервыларыңны сакларга тиеш, төрле борчылу-тетрәүләрдән сакланырга тиеш. Ә менә, сөйләвеңә караганда, теге кеше... Кем дисең әле фамилиясен?

— Бакиров.

— Әйе, сөйләүләреңә караганда, шул Бакиров бик шома кеше булса кирәк. Синең бернинди дә дәлилләрең юк бит. Шулай булгач, ничек итеп шундый тәҗрибәле подлецны җиңмәк кирәк?

— Мин бер яшь егет килде дип әйттем ич инде сиңа, кызым. Ул алынса... Ул бик булдырырдай егет күренә.

Кадрия тагы баягыча итеп өметсез көлеп кул селтәде. Бу көлү Хәбибрахманның беркатлылыгын да, теге егетнең әле ышанычлы булмавын да аңлатырга тиеш иде. Ләкин карт гарьләнә генә төште.

— Юк, син, кызым, мине алай кимсетмә инде,— диде ул.

Кадрия боларның барысын да аңлый иде. Ул бит бары этисенә яхшылык эшләү өчен генә шулай әйтә.

— Бетте, бетте, сүзем бетте, эти җаным, әгәр син шул кадәр нык кабынгансың икән,— диде ул, риза булып,— җаны теләгән — елан ите ашаган, ди.

Әлбәттә, болай әйтүе әле Кадриянең үз карашларыннан баш тартуы түгел иде. Ул бары, эти бераз җилкенер дә, билләренең сызлый башлавын тойгач, бу уйларыннан чигенер, дип өметләнә иде.

Хәбибрахман ул көнне яткач, төн уртасында уянып, бик озак уйланды. Аның күз алдыннан бер-бер артлы яшьлек көннәре узды. Сәгать өчләр тирәсендә ул уйларында үзенең җаны сөймәгән әлеге Хәмзә белән булаша башлады. Ниһаять, аның исенә Альфред әйткән Ибраһим Касыймов төште. Әйе, бик таныш исем иде. Хәбибрахман бик озак баш ватты. Хәтерендә сакланган бик күпләрне күз алдына китерде. Ләкин алар арасында бу юк иде. Ниһаять, таба алмыйча, ә шулай да таныш исем, дип, ул алҗып йокыга талды.

## IX

Ләкин карт кешенең йокысы сак була. Хәбибрахман абзый күрше бүлмәдәге Ләйләнең еламсыравына уянып китте. Әле биш тә тулмаган иде. Ләйлә исә йокы аралаш тагы нидер мыгырданды да, бабасын тагы уйлары белән ялгызын гына калдырып, татлы йокыга талды.

Хәбибрахман урта хәлле крестьян семьясында туып үсте, алты кыз арасында җиденче бала, төпчек булды. Әтисе дөньяның ачысын-төчесен татыган мужик иде. Аның фикеренчә, укымаган кешегә бу дөньяда көн юк. Шуңа күрә малаен алты яшеннән үк мәдрәсәгә йөрергә мәҗбүр итте. Бу елларда бишенче елгы беренче рус революциясенең шифалы җилләре авылларга да килеп җиткән иде инде. Хәзер авыл җирендә дә яңача дөньяви белемнәр бирел укыта башлаганнар иде. Бәхеткә каршы, мәдрәсә тоткан мулла да, күп үз ишләреннән үзгә буларак, яңалыкны алга сөрүче иде. Шуның аркасында Хәбибрахман читкә китмәсә дә, үз авылында укып та, революцияне шактый белемле һәм аңлы кеше булып каршылады. Аның күзен революция ачты. Ул «революционер» Керенский белән революционер Ленинны шул чорда гына аерып белә башлады. Менә көтелгән бөек Октябрь булды. Моны Хәбибрахман аңлы кеше буларак каршылады. Ул бу вакытны авыл мәктәбендә укытучы, яшь мөгаллим иде. Аңа үз ишләре белән шактый бәхәсләр алып барырга да туры килде. Заманында никадәр прогрессив күренмәсен, мулла үзе дә хәзер бу революцияне караңгы чырай белән каршылады. Ә Хәбибрахман исә революцияне үзенең көрәш нәтиҗәсе итеп алкышлады. Ләкин, күп тә үтмәде, аңа бәхәсне кулына корал тотып хәл кылырга туры килде. Ул комбед члены булып китте, аннары авыл советы секретаре булды. Ак бандитлардан качып йөрде, чак үлемнән калды. Һәм менә, ниһаять, революциянең язмышын хәл иткән тугыз йөз дә унтугызынчы ел килеп җитте. Хәбибрахманны кызыл армия сафына алдылар. Ул яшьтәшләре белән олауларга төялеп пристаньга китте. Моңлы гармун авазлары, хатын-кызның елап калуы, кызмача егетләрнең илереп, туган якларга булган барлык мәхәббәтләрен көйгә салып җырлаулары. Хәбибрахман боларны ачык хәтерли. Моңа инде бик күп еллар узган булса да, боларның барын да ишетеп, күреп тора кебек.

Карт үзенең әнисен, апаларын күз алдына китерергә тырышты. Әтисе авыру иде, ул озата алмады. Әнә алар әле дә тере кешедәй киңәш-нәсыйхәт, изге теләкләр әйтәләр. Аларның күзләреннән тыелгысыз яшь ага. Алар артта, басу капкасы янында калдылар инде, яулык болгыйлар, ә үзләре һаман, һаман елыйлар. Ә басу капкасыннан чыгып бераз киткәч, ат башында утыручы малай ачы итеп сызгырып җибәрде, чыбыркы белән атка сукты. Атлар лерт-лерт юырта башладылар. һәм бик күп егетләр өчен бәләкәй үр артындагы туган-үскән авыл мәңгегә-мәңгегә югалды...

Менә бусы инде Казан пристане. Купчелеге чабаталы, фәкыйрь киемле егетләрне пароходтан чыгарып дүртәрләп тезделәр дә таш түшәлгән булса да тубыкка җиткән баткак каплаган юл буйлап Казан каласына, тау башыннан Сөембикә манарасы күренгән якка таба алып киттеләр. Авыр котомкалар җилкәләрне баса, чапыр-чыпыр, чапыр-чыпыр килеп торган аяк тавышлары ишетелә, капчыклардагы кружка-кашыклар, сохарилар шалтырый. Алда кара муенлы, тузган бүрекле, чикмәнле кешеләр, Казан губернасының Идел буендагы төрле урыннарыннан җыелган егетләр. Алар, котомкаларын әледән-әле аркага җайлабрак салып, һаман юл буйлап атлыйлар. Авыр тәмәке исе, әчеп-күпчеп беткән тир сеңгән керле кием исе... Әнә шулай алар ашкынып алга атлыйлар. Алар ниләр буласын әле белмиләр. Ләкин алар үләр өчен бармыйлар, алар, баткак ерып, җиңәр өчен, совет власте өчен сугышырга баралар.

Хәбибрахман да шул кара муенлы, таза җилкәле татар егетләре арасында. Ул, газеталардан укып, Казанда Үзәк мөселман хәрби коллегиясе тарафыннан Беренче Идел буе аерым укчы татар бригадасы төзелгәнлеген белә. Тәтештә дә аларга, сез татар бригадасына җибәреләсез, дигәннәр иде. Менә алар шунда баралар инде...

Ниһаять, жыелу пунктына життеләр. Һа, нинди зур пулатлар! Нинди матур икән бу таш кала! Әле сугыш вакыты, әле күп урында коймалар да, капкалар да җимерек. Алар төзек чакны нинди иде икән бу Казан! Җәннәттер биредә, җәннәттер!..

Хәбибрахманның Беренче татар полкына күчү көннәрен гомерендә онытасы юк. Алар бригада комиссары Шамил Усмановны күреп шаккаттылар... Үзләредәй яшь-яшь егет. Ләкин ул нинди кыю, нинди җыйнак! Аның өс-баш киеменнән алып күз карашына, сүзләренә, тавышына кадәр барысы да ягымлы, дәртле. Менә ул кеше ичмаса! Әнә шундый булсаң иде! Бар бит бездә дә кешеләр, дип уйланды ул. Комиссар егетләргә бүгенге халыкара хәлләр, бүгенге тормыш турында аңлатып бирде. Аның сүзләрен, ничек аңлатуын Хәбибрахман төгәл генә хәтерләми хәзер. Ләкин комиссар, бик гади сүзләр белән, алда бик зур эшләр торганын, бүгенге көннең үтә читенлеген аңлаешлы итеп сөйләде. Полк командиры башта Әхмеров дигән кеше иде, аны полк Оренбур янында тар-мар ителгәннән соң Шәйхетдинов белән алыштырдылар. Ә полкның политкомы Хисеев иде...

Кинәт Хәбибрахманның күңеленә тагы теге сорау килде. Кем соң әле Ибраһим Касыймов? Ул озак хәтерли алмыйча ятты. Самара шәһәрендә Идел буенда чатырларда яшәүләрен күз алдына китерде. Азык-төлек яклары үтә начар иде. Бригада үз көнен үзе күрергә тиеш иде. Балыкчылык командалары оештыра башладылар. Китте иртә дә балык, кич тә балык. Хәбибрахман онытмаган: шунда мыжгучылар да булды. Тагы болай икән әле: мыжгуның, ә соңыннан инде карулашуның сәбәбе кием-салым җитмәүдән дә булды. Кемнәрдер, икенче батальоннан бугай, чабата киеп сугышырга кушасызмы, диделәр. Тавыш-гауга купты. Тукта, ул ничек булып бетте әле? Әйе, ул чак бригаданың командиры Йосыф Ибраһимов иде инде. Тукта, Ибраһиммы әле теге, әйе, Ибраһим Касыймов. Әй, керде бит башка бер исем. Тукта, кем иде соң әле ул? Әйдә-ә, чәнчелеп китсенсәнә! Белмим генә бит, кара, хәтеремә килми генә бит. Ә юкса, бик таныш исем инде. Иа, картайгач кешенең хәтере начарлана икән. Ярар, башка аның турында уйламыйм. Бетте.

Хәбибрахман тагы полкның юлы, авыр юлы, Оренбурдан Төркстанга бару газаплары турында уйлана башлады. Бары да хәтердә, юлда паровозларга ягулык юк иде. Арал диңгезе янында кипкән балык ягарга туры килде. Тиф чире белән авыручылар ешайды, ә Төркстанга тизрәк җитәргә кирәк. Анда безне көтәләр! Тиф белән көрәштеләр, яшәү өчен көрәштеләр. Алай гына да түгел, хәтта юлда ук надanлык белән дә көрәштеләр алар. Бригада белән берлектә эшелоннарда артистлар да, укытучылар да бар иде. Иа хода, яшьлегендә нинди дәртле, ялкынлы көннәр кичерде Хәбибрахман! Ә бит шулар турында яшь буынга тулы итеп, дөресен генә язып калдырырга кирәк. Ул киләчәк өчен әйбәт корал булачак аларга.

Хәбибрахман кинәт үзенең юлына аркылы баскан Хәмзә Бакировны хәтерләде һәм, чыдый алмыйча, ыңгырашып, икенче ягына борылды. Байтак вакыт тынычлана алмыйча, стенадагы хәтфә келәмгә карап ятты. Келәмгә кызыл һәм сары бизәкләр төшерелгән иде. Карт тынычлана төште һәм бүген үк башкарырга кирәкле эшләрс турында уйланды. Билгеле, ул, көн туу белән, үзенең язмаларын тагы бер актарып караячак. Ә бәлкем, онытылган берәр документ та килеп чыгар әле. Белмәссең, шуның аркасында мәсьәләне тиешле оешмалар алдында күтәреп чыгарга да мөмкинлек ачылыр. Юкса бит, коры кул белән баруда нинди мәгънә бар!? Баргач-баргач, аны шулай барырга кирәк инде, теге эһ дип тә әйтә алмасын. Ләкин... «Ләкин» шул менә! Ул инде булдыра алганын эшләп карамады түгел. Теге вакытны ул, барлык көчен салып, ялганчыны фаш итәргә теләде. Ни булып бетте соң?!

Берәр уңай нәтиҗә булдымы? Кайчандыр үзен кулга алган оешмаларның архивын тикшертеп карады, барыбер берни табылмады. Хәер, ул чакны бит ул япа-ялгызы эш итте. Аңа ярдәм итәргә теләсәләр дә, дуслары беркинди дә эш чыгара алмадылар. Дуслар дигәннән, аңга иң терәшеп сугышкан бер взвод кызылармеецларыннан ничә кеше исән калды соң? Хәбибрахман да тагы ике пенсионер. Аның да әле берсе бөтенләй йөри алмый, аягын-кулын паралич суккан. Ә икенчесе андый нәрсәләр белән кызыксынмаучы булып чыкты. Ул, мәсьәләнең торышын белгәч, ярдәм итәсе урында, киресенчә, Хәбибрахманны суытырга теләп, «Ташла, башыңны катырып йөрмә, аны бит бер нишләтеп булмый, исән-сау кайтып, балаларыңны күрүеңә куан да тик йөр»,— диде. Шулчак Хәбибрахман аны: «Син тәмам обыватель булып җиткәнсең икән, Хәернас»,— дип орышты. «Юк,— диде теге, үпкәләсәң үпкәләрсең, теге елны мин дә чак кына кулга алынмыйча калдым, хәтта ай ярым чамасы төрмәдә утырырга да туры килде. Шунда ант иттем. Моннан соң беркинди бәхәсле эшләргә тыгылмам, дип ант иттем. Менә шул»,— диде. Хәбибрахман рәнҗеп, бу обыватель Хәернаска бөтенләй кул бирмичә, дулап чыгып китте. Ул ахыр чиктә әлеге Нургали исемле паралитик дустын тапты. Ләкин вакыйганың ничек булуын, изге эш арасына ниндидер алама кешенең килеп кысылуын сөйләү белән чикләнде. Ул Нургалинең нидер эшли алуына ышанмый да иде. Авыру исә, Хәбибрахманны тыңлаганнан соң бөтенләй тынып, үзенең эчкә баткан күзләрен түшәмдәге ниндидер ноктага текәп яга башлады. Аны борчырга һич ярамый иде. Нигә, нигә әйтте соң Хәбибрахман аңа бу сүзләрне!? Ул Нургалинең сөяк белән тиредән генә торган ябык хәлсез кулын кыса башлады.

— Тукта, Хәбра,— диде Нургали,— ашыкма.

Хәбибрахман дустының кулын тоткан килеш аның кипкән йөзенә сорау белән текәлде.

— Ашыкма, Хәбра,— диде Нургали,— уйлашыйк. Ничек итеп без синең белән шундый әшәкелеккә юл куйыйк соң?! Бу бит хәзерге вакытны...— Ул артык бер сүз дә әйтмәде, кинәт ничектер күзән җыергандагыдай йөзен чыта башлады.

— Тынычлан әле, зинһар өчен,— диде Хәбибрахман, ник әйткәненә тагы бер кабат үкенеп.— Барысын да мин үзем башкарып чыгам. Син, зинһар, тик кенә ятуыңны бел, сиңа терелергә кирәк. Синең бар белгәнең шул булсын, диде. Ә тегенең турында син әз генә дә борчылма. Андыйларны гына әйләндереп салырлык көч-куәт бар миндә. Һу, болайракларын да юлдан алып ташлаган кеше мин...— Хәбибрахман шулчак сүзләрен тагы да ныграк дәлилләү өчен, буш кулын югары күтәреп, йодрык та янап куйды.

— Шулай дисеңме? — диде, ниһаять, Нургали тынычлана төшеп.

— Әлбәттә,— диде Хәбибрахман, бик батырланып,— һу, мин аны!

Күрәсең, Нургали шушы сүзләрдән соң үзенең чыннан да бу мәсьәләдә файдасыз кеше икәнлегенә ышангандыр, ул, кит инде алайса, дигәндәй, Хәбибрахманның кулын ычкындырды. Ул үзен беткән, яраксызга чыккан кеше дип саный, Хәбибрахманны үзенә караганда бик бәхетле, әле кулыннан барлык эш килә торган ир дип исәпли иде. Мөгаен, ул көнләшә дә иде, Хәбибрахман аңа буй җитмәслек биеклектәге баһадир булып күренә иде. Һәрхәлдә, Хәбибрахманга шулай тоелды, һәм ул, күңел эрнүенә түзә алмыйча, урамга чыккач, бераз вакыт бара алмас булып, йөрәгеп тотып стена буенда торды. Аның үзенең хәле дә «аллага шөкерлек» кенә иде шул.

Менә шулар иде аның бирерәге ярдәм итәрдәй дуслары. Бары менә шулар гына баштан узганнарның нечкәлекләрен беләләр иде. Башка иптәшләре исә, Хәбибрахман белән бергә данлы юл узуга карамастан, башка батальоннарда, башка полкларда һәм башка урыннарда хезмәт

иттеләр. Алар бу эштә түгел, бригаданың гомуми тарихын язган чакта гына үзләренең өстәмә материаллары белән Хәбибрахманның язганнарын баета алалар иде.

# X

Ике көннән соң Хәбибрахман абзый үзенең кадерле язуларын җентекләп укып утырганда, ишек шакыдылар. Карт күңеле белән Альфредны көтә иде, ләкин ишектән һич таныш булмаган бер ир кеше килеп керде. Күрер күзгә ул бик мәһабәт, олы гәүдәле, яхшы киенгән, йөзе дә мул тормышта яшәүчеләргә хас булганча чиста, ак иде. Хәбибрахман, шактый каушавына да карамастан, кешенең йомшак, симез кулларына игътибар итми кала алмады. Бу кеше Альфред әйткән Ибраһим Касыймовның язмышы белән кызыксынучы Латиф иде.

Латиф, исемен әйтеп, үзен тәкъдим итү белән Хәбибрахман барысын да хәтерләп, якты йөз белән кунакны эчке бүлмәгә чакырды.

Бүлмәгә кергәч, бермәл бер-берсенә карашып тордылар. Латиф өстәлдәге язуларга, хатларга игътибар итте һәм, утырырга рөхсәт сорагандай, кечкенә генә язу өстәле янындагы урындыкка күз салды.

— Рәхим итегез,— диде Хәбибрахман,— бәлки өстегезне дә салырсыз.

— Юк, рәхмәт, өсләр салып торырга вакытым юк,— диде Латиф. Ул, пальто итәген арттан сыпыра төшеп, утыргычка чүкте.

— Сезнең турыда миңа иптәш Хәйретдинов әйтте,— диде Латиф, өстәлдәге кәгазьләргә күз төшереп.— Сезнең вакыт бар инде, шөгыльләнергә?

— Нинди Хәйретдинов?

— Нигә, сездә булган ич теге яшь иптәш, тарихчы.

— Ә, Альфредны әйтәсезме! Шулай, шулай. Мин аны көтә идем әле. Сез ишек шакыгач, шул килдеме дип торам. Ул теге көнне артык кабаланү аркасында галошларын онытып калдырган.

Латиф кечкенә генә бүлмәнең җиһазларын игътибар белән күзеннән кичерде, стенадагы яшь ир кеше портретын күреп, сәерсенеп куйды — бу бит таныш инженер, приборлар заводының баш инженеры. Ләкин Латиф дәшмәде, эчтән генә елмайган хәлдә, үзенең нинди йомыш белән килүен ишетергә теләгән картка текәлде.

— Менә мондый хәл,— диде ул,— мин олыгая төшкән көнемдә генә булса да әти язмышы белән кызыксына башладым. Миндә саклаңган хатларга, мәрхүм әниемнең сөйләгәннәренә караганда, минем әти мин әле бөтенләй кечкенә чакны мобилизация буенчамы, я булмаса үз ирке беләнме, Кызыл Армия сафына китә. Белүемчә, ул татар бригадасына барып эләккән. Шундый бригада бар идеме? Сез шунда хезмәт иткән сез булса кирәк.

— Бар иде. Мин менә шунда хезмәт иттем. Мин дә, Альфред та шуның тарихын язу турында хыялланабыз.

— Мине, билгеле, аның бөтен тарихы кызыксындырмый,— диде Латиф һәм шунда ук, яхшы булмады, ахры, болай диюем, дип уйланып, кискенлекне йомшарту теләге белән, көлемсерәп үзенең төп теләген аңлатты.

— Аның исеме Ибраһим идеме? — дип сорады Хәбибрахман.

Латиф ничек белә бу дигәндәй сәерсенеп куйды.

— Сез аны белә идегезме әллә?

— Юк, миңа аны Альфред әйтте.

— Ә, алай икән. Мин тагы...— диде Латиф, ничектер хәлсез генә көл селкеп.

— Без аны башта анык.лыйк әле. Ул ничәнче елны алынган соң?

— Ул унтугызынчы елның яз ахырларында алынган, алар беренче пароход белән Казанга озатылганнар, анысын мин анык беләм. Никадәр кечкенә булмыйм, әнинең ул чакта әле, беренче пароход, Тәтештән киттеләр, дигән сүзләрен хәтерлим. Мине аның фронттагы язмышы кызыксындыра.

— Беренче пароход белән Тәтештән утырып киткән булса, без аның белән Казанга бер пароходта килгән булабыз.

— Шулаймы?

— Ибраһим Касыймов,— диде Хәбибрахман, уйланып,— үзе бик таныш исем инде югыйсә. Юк кына бит, хәтерли алмыйм. Бик күп вакытлар үтте шул. Юкса, бәлкем, бер кателоктан ашап, бер цепьтә үк яткanбыздыр әле. Сез аның карточкасын күрсәтә алмыйсызмы?

— Карточкасы юк шул. Ул гади авыл малае. Ярлы семьядан. Ну, нәрсә әйтим тагы. Әнинең сөйләгенә караганда, мин аңа шактый охшаганмын.

Хәбибрахман Латифны жентекләп күздән кичерде. Ләкин, затлы кара костюм, драп пальто кигән кешегә охшаш берәр иске танышын хәтерләү мөмкинлегеннән ваз кичеп, картларча мескен бер кыяфәттә елмаерга мәҗбүр булды.

— Юк,— диде ул, өметсез рәвештә,— ә исеме һаман колак төбендә янгырап тора. Касыймов Ибраһим.

Хәбибрахман кинәт башын күтәрде.

— Сезнең әтиегез бригада штабында хезмәт итмәгәндер бит?

— Анысын бер дә әйтә алмыйм.

— Юк,— диде Хәбибрахман, бу эшкә тәмам кул селтәп.— Мин сезгә Оборона министрлыгына язарга киңәш итәр идем. Аларның архивына.

— Әйе, мин аны беләм. Мин яздым. Тик, дөресен әйтим, мин аларның нинди җавап бирәселәрен алдан ук беләм.

Хәбибрахманның йөзенә аптырау билгеләре чыкты.

— Ә нәрсә кирәк соң сезгә?

— Минем рәсми белешмәдә шигем бар. Аның турында үлде дип хәбәр итәчәкләр.

— Ничек инде ул алай?

— Мин аларны бутаганнардыр дип уйлыйм. Ниндидер бер хаталык киткән дип уйлыйм.

— Ә нәрсәгә нигезләнеп әйтәсез соң моны?

Латиф көлемсерәп куйды.

— Бар инде. Шик тудыра торган кайбер мәгълүматлар алдым.

Хәбибрахман, ни әйтергә дә белмичә, сәерсенеп Латифка карап тора башлады.

Гаҗәп хәл. Күрәсең, бик туган җанлы, әтисенең исталеген гомер буена күңелендә саклап, кадерләп йөри торган кешедер. Ә күрер күзгә үзе шактый төксе, салкын. Мин андыйларны үз гомеремдә бик күп күрдем. Үзеннән бик разый, һич хәл ителмәслек мәсьәләләрне бар дип белми торган, беркайчан шикләнү-уйлану кебек нәрсәләр белән азапланмый торган кеше. Ләкин, баксаң-күрсәң, үзенең үзәгендә әйбәт, саф вөҗдан һәм кешелек утыра икән ләбаса. Ничек сиңа ярдәм итим соң?

— Беләсеңме, Латиф иптәш,— диде Хәбибрахман, анык бер карарга килеп,— мин, кирәк дип тапсагыз, сезнең әтиегез турында сорашып, үзем белгән, бригадада хезмәт иткән барлык иптәшләргә хат яза алам. Кем белә, бәлки шуларның берәрсе әтиегезне хәтерли торгандыр. Мин бит әлек-әлектән татар бригадасының тарихын язу белән җенләнеп йөргән кеше. Мин заманында бик күп егетләр белән бәйләнешкә кергән идем. Әлбәттә, аларның күбесе мин үзем тегендә вакытны китеп барганнар инде. Бу дөньядан дип әйтүем. Китеп барганнар. Тик шулай да

исәннәре дә бар әле. Хәзер Альфред кебек яшь коллегам да булгач, мин бу эшкә ныклап керешергә уйлыйм. Менә язармын, сорармын. Ярыймы?

— Бик ярый. Менә дигән булачак. Инде нинди дә булса чыгымнар була икән, анысына аптырамагыз. Минем исәптән булыр. Шулай ук нинди дә булса рәсми белешмәләр, я булмаса гомумән берәр учреждениенең эшкә катнашуы кирәк булса, туп-туры миңа мөрәҗәгать итегез. Язып куегыз әле минем служебный телефон номерын.

Латиф ике телефонының да номерын әйтте һәм урыныннан торып эшләпәсен киде.

— Димәк, шулай, сөйләштек инде алайса?

Ул картның кулын кысты. Бермәл икеләнеп уйланып торды. Әйтәсе иде, бабай бу нәрсәләрне хәзергә беркемгә дә такылдамасын иде. Ләкин Латиф батырчылык итмәде.

Ярамый, шикләнә башлар, дип уйланды. Аның күзенә яңадан стенадагы портрет чагылды. Шик юк, портретта Казан приборлар заводының баш инженеры, кем әле, әйе, Тимербулатов үзе. Латиф, чыгып китим дигәндә тукталып, бераз икеләнеп торганнан соң, рәсемгә бармак белән ишарә ясады.

— Кемегез?

— Киявем,— диде карт.

— Мин бит аны беләм,— диде Латиф, көлемсери төшеп.

— Ә, шулаймыни? Әле хәзер ул чит илдә командировкада.

— Чит илдә командировкада?

— Әйе, киткәненә ай чамасы була инде. Яңадан берәр ай торыр әле.

— Кара! Мин ул кадәресен белми идем. Аларның предприятиесе безнең системага кермәгәч... Шулай икән. Ә ул кайсы илдә соң?

— Ул башта Чехословакиядә булды. Хәзер инде Германиядәдер, шунда булырга тиеш иде.

— Германиянең кайсысында? Демократик Германиядәдер, билгеле.

— Әйе, ул анда да булачак, ләкин, минем белүемчә, хәзер Федератив Республикада.

Латиф бу сүзләрдән соң тынып уйланып торды. Бер секунд эчендә башында төрле уйлар кабынып сүнде. ГФР диген, ә? Мюнхен бит шунда. Гаҗәп икән! Әйтерсең лә, карт әнә шул кияве аркылы Латифның кичерешләрен, серләрен үтәли күреп тора, әйтерсең лә, ул барын да белгән хәлдә, юри, әвәрә итеп, Латиф алдында белмәгән булып кыйлана. Латиф рәсемгә тагы бер тапкыр күз төшереп алды. Аннан кара кырлы күзлек кигән озынча йөзле яшь инженер Тимербулатов тыныч кына карап тора иде. Юк, ахмак уйлар белән булашам мин, дип уйланды Латиф. Кайдан белсен инде ул инженер минем әти турында? Аларның очрашу мөмкинлекләре юк, бөтенләй юк. Хәзер бит ул көнентөнен чаба, заводларда, конструкция бюроларында, предпринимательләрдә була. Аның хәзер юньләп ял итәрлек тә вакыты юк. Ул муеннан эшкә баткан. Гомумән, аның янына да барырлык түгел хәзер. Бик теләсә дә, аның ниндидер ят бер мәсьәлә турында сөйләшергә физик мөмкинлеге юк. Ахмак уйлар...

Ул Хәбибрахман абзыйның кулын каты итеп кысты, уйларына бирелеп, аның нидер әйтүен дә ишетмәде, ишектән чыгып, таш баскычтан төшеп китте. Тышкы ишекнең пыяла өлгеләре чатнаган иде. Латиф ирексездән сукранып, әле яңа гына салынган өй, инде ватарга да керешкәннәр, дип уйлап алды.

Ул, ашыкмыйча гына, үзен көтеп торган җиңел автомобильгә таба юнәлде. Шофер кабинасына бикләнеп роман укый иде. Ул тиз генә китабын өстәге козырек астына кыстырды һәм сораулы кыяфәт белән Латифка текәлде.

— Управлениегә,— диде Латиф. Үзе шунда ук әле җебе өзелеп

бетмәгән уйларын дәвам иттерә бирде. Ә шулай да, очраклы рәвештә генә булса да минем әти белән бу Тимербулатов очрашса? дип сорады ул үзеннән. Ул хат язса, менә шундый-шундый кешене очраттым, мин аның улын беләм, ни өчендер ул кеше шул көннән бирле әтисенә җавап язмый, сәбәп нәрсәдә икән, дип хат язса? Я булмаса болай: ул каенатасына, я хатынына хат язып тормый. Тизрәк ярдәм итү теләге белән туп-туры трестка яза. Латиф, күзләрен йома төшеп, әгәр шулай булса, үзе эшләгән урында ниләр булачагын күз алдына китерергә тырышты. Тукта, тукта, моның ахыры әтинең анда нинди гамәл кылып яшәвенә бәйләнгән бит дип уйланды ул. Хәер, ул, ни генә эшләмәсен, барыбер дошман ягына барып эләккән. Һәм моңа аклану тапкан хәлдә дә, минем гомерем буена гражданнар сугышы каһарманы улы булып яшәвем алдап яшәү булып калмыймы соң?

Латиф көннәрдән бер көнне, шул мәсьәлә буенча теге Тимербулатовтан хат килгәч, управляющийның үзен чакыртып сөйләшүен күз алдына китерде.

Менә алар кара-каршы утырышалар. Хәер, икәү генә түгел, монда партия оешмасының секретаре булмый калмаячак. Менә алар өчәү мәгълүм кабинетта утыралар. Тегеләр Латифтан сорау алалар. Үзеңне бөтенләй башка сыйфаттагы кеше итеп күрсәткәнсең икән. Ә син бит дөреслектә менә нинди. Ай-яй-яй! Инде нишлибез?

Шулай, Латифның яңа табылган әтисе кем генә булмасын, Латифның гомере буена кристаллашкан дөньяга карашы, холкы һәм тышкы үзенчәлеге үзгәрмәячәк. Ләкин шул ук вакытта ул гомере буена үзенә шундый бер ышаныч сеңдерде, янәсе, дошманнан дошман туа, дустан дус туа. Илдә сыйнфый көрәшнең кызган чакларын үз күзләре белән күрде ул. Яшь иде әле, ләкин барын да аңлап торды. Мөнәсәбәтләрне яңарту өчен, бөек үзгәрешләрне төгәлләү өчен шундый кискен чаралар кирәк иде. Барысы да дөрес. Моны Латиф яшь булса да аңлады. Хәтерендә, Латиф балалар йортында чагында аның белән бергә уйнап дус булып йөргән бер малайны мәктәптән куып чыгардылар. Чөнки фаш ителде: малайның әтисе сәүдәгәр икән, һәм малай, өеннән качып, үксез бала чутыннан детдомга урнашкан, укуын дәвам иттергән. Менә шул малай фаш ителде. Латиф та, теге малай да алтынчы класста укыйлар иде ул вакыт. Бер партада утыралар иде. Теге сәүдәгәр малае фаш ителгәч, Латифның шул кадәр ачуы килде, ул кичәге дусты белән сөйләшмәс булды. Сыйнфый сизгерлекләре житмәгән малайлар гына, аңа рәхим-шәфкать күрсәткән булып, дошман малае тирәсендә ялагайланып йөрделәр. Ах, әрәм булдың, син бит нинди шәп укый идең, син бит бик сәләтле, фәлән-фәсмәтән, имеш. Ләкин Латиф алардан күп өстен булды. Ул бит бөек революция өчен гражданнар сугышында батырларча һәлак булган каһарманның улы, аның ниндидер кабахәт сыйнфый дошманнар каршында тәлинкә тотып торасы килми. Моңарчы теге нәгъләт жан белән дус булган икән, барысы да сыйнфый дошман токымының үзен алдавы аркасында гына ул. Юк инде, моннан соң Латиф дарысын бик коры тотар! Ул һәрбер яңа таныш белән сак кыйланыр, беркемнең дә тышкы үзенчәлегенә ышанмас. Һәр сарык тиресе астында бүре булуы ихтимал бит.

Һәм, әйтергә кирәк, шулай бер авызы пешкәннән соң ул гомере буена сак булды, бөтен революциянең нигез ташы булып исәпләнгән сыйнфый көрәш мәсьәләсендә үтә сизгер булды. Беркемгә дә бу мәсьәләдә рәхим-шәфкать күрсәтмәде. Институтта укыган чакларда булсын, беренче тапкыр Верховный Советка сайлаулар вакытында булсын, ул эшкә комсомол оешмасыннан иң ышанычлы кеше буларак катнаша иде. Булды төрле хәлләр. Халык дошманнарын фаш иткән чагы да, троцкийчы, бухаринчыларны фаш иткән чаклары да булмады түгел. Андый жыелышларда шомлы тынлыкны бозып, ул беренче булып

ярсулы сүз башлый иде. Аның кулындагы кылыч, әгәр шулай атарга мөмкин булса, һич тетрәү, каушауны белмәстән, туп-туры сыйнфый дошманнар агентының муен тамырына гына килеп төшә иде. Менә шулай булды бит. Һәм бу мәсьәләдә аны житәкләүче көчнең беренчесе безнең гадел революцион тәгълиматыбыз булса, икенчесе әтисе булды. Ул, Гамлетның атасыдай, улын, утлы фронт окопларыннан күтәрелеп, кулларын сузган хәлдә, шундый эшкә өнди иде.

Ә хәзер нәрсә соң? Юк, шәхси тормышында Латифның мондый хәл ителмәслек мәсьәләләр алдында торганы юк иде әле. Ул, барлык көчен туплап, тагы управляющий белән үзенең сөйләшүен күз алдына китерә башлады. Ана шундый суд булачак, шунда аңа хөкем чыгарылачак. Хәер, хөкемне аңа беркем дә чыгара алмый. Хөкемне ул үзе чыгарыр. Эш бит ахыр чиктә синең дәрәжәң төшүдә дә түгел, азрак эш хакы алып яңадан инженер сыйфатында производствога кайтуда да түгел, эш эчке тетрәнүдә, мәңгелек кыйбланы югалтуда. Тукта, ниләр, нинди әңгәмә булачак инде бу управляющий белән күзгә күз карашып сөйләшкәндә?

Ләкин Латиф хыялларын дәвам иттерә алмады, шофер «Волга»ны чиелдатып тормозлады да трест идарәсенең таш колонналы ишегә төбенә китереп туктатты.

## XI

— Латиф Ибраһимович, сезне өлкә комитетына чакырдылар,— диде секретарь кыз.

— Беләм,— диде Латиф, сәгатенә күз ташлап. Өлкә комитеты секретаренда завод-фабрика житәкчеләренең, шул жөмләдән трест работникларының киңәшмәсе булырга тиеш иде. Тиешле материаллар бар. Ләкин шулай да Латиф үзенең чыгышын яңадан бер кабат тикшерергә кирәк дигән карарга килде. Машинкасын текелдәтеп утырган секретарьга:

— Минем янга берәүне дә кертмәгез,— дип, үз кабинетына таба атлады.

Ул бик озак вакыт бер эш кәгазьләренә чумып, бер уйланып, өстәл янында утырды. Ишек ачылып китеп, аннан секретарь кызның бизәнгән йөзе күренмәсә, бәлки бу тагы да озаккарак тартылыр иде әле. Секретарь: «Телефон трубкасын алыгыз»,— диде. «Кем ул?» — дип сорады Латиф. «Үзе»,— диде секретарь, мәгънәле рәвештә елмаеп. Латиф управляющий белән сөйләшү өчен кабаланып телефон трубкасын алды.

— Менә нәрсә, Латиф Ибраһимович,— диде управляющий,— миңа киңәшмәгә бармаска рөхсәт иттеләр. Мин пленумга әзерләнеп утырам. Син кара инде анда, шәбрәк әзерлән. Мәсьәләне теге өченче көн сөйләшкәнчә куй.

— Яхшы! Борчылмагыз,— диде Латиф. Тагы берничә секунд көтеп торды. Ләкин башка сүзе юк иде башлыкның. Латиф трубканы урнына куйды да бөтен барлыгын умарта кучедәй сара башлаган тынгысыз уйлардан көч-хәл белән арынып, яңадан кәгазьләренә чумды.

Ул бераздан шоферга шалтыратты. Секретарь аша тагы берничә кешене чакыртып өстәмә материаллар алды һәм урамга чыгып зәңгәр «Волга»сында өлкә комитетына киңәшмәгә китте. Житди эш белән артык мавыгу аркасында ул үзенең башка барлык борчуларын онытты. Киңәшмәдә аның мие икегә бүленмәде, бары тиешле эш белән генә шөгыльләнде. Ләкин өенә кайтырга юлга чыккач, кинәт аның хәтерен бүген көндезге очрашу вакыйгасын күз алдына китереп бастырды. Каһәр суккыры икән инде, әйтсәң дә әйтмәсәң дә. Тагы теге теш сыз-

лавы кебек борчый торган уйлар Латифның миен камап ала башладылар.
Ул бөнә арыган, талчыккан һәм артык ярсыган бер кыяфәттә кайтып керде. Гөлбикә, ашарга әзерләп, каядыр чыгып киткән иде. Үз бүлмәсендә диванга ятып китап укыган улына Латиф:
— Әниең кайда? — диде.
— Әллә,— диде Марат, китабыннан аерыла алмыйча гамьсез генә,— нәрсәдер әйткән иде, оныткаnмын.
— Мин сиңа ничә тапкыр ятып укыма дип аңлаттым инде. Күзләреңне бозасың ич.
Малай бер сүз дә дәшмәде. Ләкин яткан килеш укуын дәвам иттерде. Латиф, аннан башка да ярсыган нервыларын авырлык белән тыеп, үз бүлмәсенә керде. Өстәлендә яткан бүгенге почтаны караштыргалады. Җирле промышленностька карата язылган зур подвал мәкаләне укый башлады. Бераздан ул үзенең бик каты ачыкканлыгын тойды һәм кухняга чыкты. Гөлбикә аңа ашны, кабат җылытсаң тәмсезләнә дип, суынмасын өчен ашъяулыкка төреп калдыра иде. Латиф, төргәкне сүтеп, тәмле тавык шулпасы ашады. Шунда ук тәлинкә белән икенче блюдо да бар иде. Латиф шулай ук кәбестәгә төреп пешергән ит дулмасын яратып ашарга кереште. Ул арада тышкы салкыннан алсуланып киткән Гөлбикә кайтып керде.
— Әле генә кайттыңмы? — диде ул, ботыларын салып.
— Әйе. Киңәшмәдә утырдык.
— Ичмаса, берәр җиргә барыр идек. Атнасына бер тапкыр гына булса да иртәрәк кайтырга була торгандыр ич. Аптырагач, билләһи, тол хатыннар кебек япа-ялгызым киногa киттем.
— Я, нишлим соң инде, эш бит! Мин бит анда тик утырмыйм, Гөлкәй.
— Шулайдыр инде,— диде хатын, көрсенеп. Кинәт нидер исенә төште, яктырып: — Рафаэльнең хатын укыдыңмы? — диде. Аларның олы уллары ул. Мәскәүдә, менә бишенче елын инде университетта укый.
— Юк, укымадым,— диде Латиф,— ниләр яза соң?
Гөлбикә көлеп җибәрде.
— Акча сорый.
— Эшләре комга тәрәлгәнмени?
— Соң Мәскәү бит ул, картым! Нишләмәк кирәк,— диде Гөлбикә.
— Күпме сорый соң?
— Анысын үзеп әйтмәгән. Бурычка баттым, зинһар, әти, җибәрә күр, булдыра алганча дигән. Менә хатын укып карарсың әле.
Латиф йөзен чытты.
— Шул гына җитмәгән иде...
— Я, нигә инде алай сөмсерең коела? Үз балаң ич.
— Юк, аның аркасында гына түгел, Гөлкәй,— диде Латиф,— беләсең ич, теге хаттан соң секунд саен, минут саен җанымны ниндидер пычак каезлап тора.
— Мин дә аның өчен бик борчылган идем. Уйладым-уйладым да төкеримсәнә дидем. Я эшеннән чыгардылар, ди, я эш хакын әзрәк бирә торган урынга күчерделәр, ди, үлмәбез әле. Кеше яши ич.
Латиф шаккатып хатынына текәлде.
— Гаҗәп! Син мәсьәләнең бөтенләй кирәкмәс ягы белән кызыксынасың, Гөлбикә. Эш дәрәҗәдә, я булмаса акчадамыни?
— Нәрсәдә соң?
Латиф йөрәгенә төртеп күрсәтте.
— Менә монда. Әгәр ул теге як кешесе булып чыкса, мин кем булачакмын? Я, әйт!
Хәзер Гөлбикә үз чиратында аптырауга калды.
— Кем дип, ничек инде? Синең бит кендегең аңа бәйләнмәгән.

— Па! Сиңа әйтүе җиңел. Мин бит гомерем буе аның юлын дәвам итеп, аның васыятьләрен үтәп яшәдем. Һәм ул кинәт мин уйлаган кеше булып чыкмаса?

— Мин сине аңламыйм, Латиф. Әллә инде саташа башладыңмы? — диде Гөлбикә. Ул куркынып Латифның йөзенә текәлде. «Кара инде, булса да булыр икән кеше. Кем булса да барыбер түгелмени? Синең атаң кем дә, бабаң кем, хет шайтан үзе булсын. Эш андамыни? Эш бит синең үзеңдә, үзеңдә, күгәрченем». Гөлбикәнең күз карашы, кыяфәте шулай ди иде. Ирен әле бу дәрәҗәдә үк аптыраган бер хәлдә күргәне юк иде аның. Хат килгәннән бирле тынычлыгы югалганын, начар йоклавын ул белә. Ләкин сәбәбе үзе белгәннән башкадыр һәм теге хат кына ирен бу дәрәҗәдә үк юкка чыгарып ташламас дип уйлый иде хатын. Кара инде бичараны! Бөтенләй коелып төшкән.

Латиф, хатынының уйларын бүлдереп, бүген эш арасында бер карт кешене күрүен, тегенең Латиф мәсьәләсе турында белешеп дусларына хат язарга вәгъдә итүен сөйләде. Ләкин ул Хәбибрахман киявенең хәзер чит илдә һәм бәлки инде шушы минутта Мюнхенда булу мөмкинлеге турында әйтмәде, курыкты.

Хатыны савыт-саба җыя калды. Вакыт шактый соң булганга күрә, Латиф, чишенеп, үз караватына ятты да кулына газета алды. Ә төн уртасында аның янына чистарынып, пакьләнеп, ислемайлар сөртенеп, Марат уянмасын дип шыпырт кына ярым-ялангач Гөлбикә кергәндә, ул шулай йокысызлыктан алҗыган төксе бер кыяфәттә караватында утыра иде әле.

## XII

Альфред әле яңа гына Казаннан кайтып кергән иде. Баланы итәгенә алып өстәл янына утырды. Караватта күкрәгеән савып утырган Луизага ара-тирә караштыргалап үз эшенә керешә. Луизаның күкрәкләренә нидер булган, Шамил сөтне калдырып имә. Луизаның болай да тыгыз күкрәкләре хәзер бөтенләй тулып киткәннәр. Ул бик авыртадыр. Альфред аларның авыртуын үзе кичергәндәй тоярга тырышты, ләкин гомумән авырткалыгын гына аңлады, кызганып, хатынына тагы бер карап куйды.

«Луизаның хәзер артык көйсезләнүе дә шуннан гына бит. Юкса ул андыймы соң?! Ул бит алтын. Акыллым бит ул минем, Люлю», дип уйланды Альфред.

Әле генә тыныч утырган бала Альфредның күзлегеннән әләктерде дә, нәни балаларга хас булганча, чытырдатып тоткан хәлдә күзлекне йолкып та алды.

— Улым, улым, харап итәсең бит,— диде Альфред. Әтиле-уллы алар күзлек өчен тартыша башладылар. Күрәсең, күкрәкләре бушап калгач, Луиза тынычлана төшкәндер, ул хәзер яктырып боларны күзәтә иде. Бала күзлекне бирергә теләмичә акырып елый башлагач, аннары Альфред аны тынычландыру өчен күзлеген аңа кидертергә керешкәч, Луиза бөтен өй эчен янгыратып көлеп җибәрде. Ул бер кулы белән матур ап-ак күкрәген тоткан, икенчесендә сөт саугыч иде. Альфред аңа гаҗиз булып карады да:

— Идәнгә җибәримме әллә булмаса? — диде.

— Әйтә күрмә. Шундый салкын идән. Әнә кара,— диде Луиза, тәрәзәгә төртеп. Чыннан да урамда ябалак-ябалак кар ява, ул бик рәхәтләнеп, иркенләп, озаклап яварга исәпли иде, ахры.

Альфред, күзлек белән эш барып чыкмагач, баланы утырткан тезен сикертә-сикертә такмакларга тотынды.

— Хәзер эшемне бетерәм, үзем карармын,— диде Луиза,— тик берүк идәнгә төшермә. Беркөннәрне дә, мич авызына кереп, көл ашаган. Әллә ниләр булыр, сизми дә калырсың!

Ап-ак башлы, йомры, тик тормас Шамил хәзер өстәлдәге язуларга, китапларга үрелә башлады. Монысы инде бернигә дә ярамаган эш иде! Беркөнне шулай Альфред, кадерле китабын Шамилгә тоттырып, адәм хурлыгына бер калды инде. Шамилнең китап битен йомарлап, ертып алуын сизми дә калдылар. Җитәр! Альфред Шамилгә өстәл читендә яткан яшелле-кызыллы кабырчык балыгын тоттырды. Ләкин аны бала бәреп кенә очырды. Альфред нишләргә дә белмичә, әллә булмаса берәр иске китапны бирергә инде, дип икеләнә башлаганда, ниһаять, Луиза, эшен бетереп, аягүрә басты.

— Ай, минем нәнекәчем. Кил, улым, кил үземә!

Малай акыруыннан туктады, әнисенең жылы күкрәгенә башын төртеп, яшьле күзләре белән рәнжү аша әтисенә карап торды. Әйдә, ачуланмагаең, әллә нишлә. Акырма гына. Альфред күзләре белән генә елмаеп, башын чайкап торды.

— Ну, үзсүзле дә инде! Кайсыбызга охшап шулай булды микән бу, Луиза?

Луиза яңадан караватына барып утырды да:

— Билгеле, сиңа,— диде.

— Ә нигә миңа?

— Чөнки син кире беткән.

— Әйттең сүз! Чынлабрак карасаң, син, Люлю, миңа караганда жиде тапкыр кирерәк әле.

— Я, менә берәр мисал китер.

— Ни пычагыма дип мисал китереп вакытымны уздырыйм. Син аны үзең дә беләсең ич!

— Ә менә мин синең кирелегең турында әллә ничаклы мисал китерә алам.

— Я, әйтеп бак.

— Бәрәңгене үзең ал, калдырып казыйлар дип әйттемме?

— Ну, әйттең.

— Син, киреләнеп, алмадың бит.

— Я, шуннан?

— Өченче көн мунча кер, күршеләр мунча яккан, дәштеләр дип әйттемме?

— Ну, әйттең.

— Син, киреләнеп, бармадың?

— Я, я.

— Җәзилә апа авырса да, бездә авырсын, хәзер хәле яхшыра төшкән икән, барып алып кайт, дидемме?

— Ну, әйттең. Шуннан?

— Син кире беткән, шуңа күрә бармадың. Ә улың үзеңнең копиян.

Альфред китапларын читкәрәк этеп куйды да хатынына таба ук борылып утырды.

— Мин дә сиңа әйтим инде алайса. Мин бәрәңге алмаганмын икән, мунча кермәгәнмен икән, Җәзилә апаны алырга бармаганмын икән, моның бик уважительный сәбәбе бар. Мин сиңа да, миңа да, безгә дә кирәк эш эшләдем.

— Эш инде пычагым, әйтерең бар эш дип!

— Алай дияргә хакың юк синең. Ул тарих безнең өчен изге тарих. Син чын мәгънәсендә череп таркалган обыватель. Мещанка син, беләсеңме!?

— Ә син коршаеп каткан милләтче.

— Юк, мин интернационалист!

— Милләтче син, милләтче!

— Юк дим, мин интернационалист, интернационалист!

— Ха-ха, каян килеп чыккан бу интернационалист? Карагыз моны!

Альфред сикереп урыныннан торды. Боларның бәхәсләрен шакка-

тып күзәткән Шамил, әтисенең күзлек пыялалары ялтыравына сәерсенеп, кинәт елмая башлады.

— Бераз оят кирәк иде,— диде Альфред, үзен кулга алырга тырышып,— синең өчен бер изге әйбер дә юк бу дөньяда!

Бу вакытны Луиза мышкылдап елый башлаган иде инде. Аның күзләреннән яшь тамчылары тәгәрәп төшә, тетрәнүдән, ярсудан уттай янган матур йөзен мул итеп чылаталар иде. «Юк, юк,— дип уйланды Альфред, кинәт суынып,— бу сүзләрне Луиза үзе әйтмәде, аның җене әйтте. Ул артык ярсыган, үзен тота алмас хәлдә, бары шуңа күрә генә...».

Луиза аның саен елавын көчәйтә бара иде. Ниһаять, ул авызын бәлешәйтеп үксергә үк керешге.

— Мондый... рәхимсез... булачагыңны белсәм... яшь гомеремне... синә... әрәм итәр идеммени!.. Җансыз, узурпатор... ы-ы...

Әнисенә карап торган Шамил дә, хәтәр бер нәрсә сизенеп, шыңшырга тотынды. Луиза мескен бер кыяфәттә баласын күкрәгенә тагы да ныграк кысты.

— Елама, нәнием, елама ап-агым.

Бик-бик кызганыч булып киттеләр алар Альфредка. Луиза белән бала бер-берсенә сыенганнар да күз яшьләрен агызып үксеп елыйлар иде.

— Я, җитәр инде,— дип куйды Альфред, түзә алмыйча. Барып, хатыны белән улын бердән кочты.— Тынычлан инде, я инде, я.

Ләкин Луизаның артык нык хәтере калган һәм ул тиз генә тынычланырдай түгел иде.

— Я инде, Люлю,— диде Альфред, ялынып,— без бит болай гына. Икебез дә артык кызып киту аркасында гына. Кирәкми, я инде, Люлю.

Ул, хатынын һәм улын тагы да ныграк коча төшеп, Луизаның күзләренә текәлде. Алар шулай озак кына вакыт сүзсез утырдылар. Луизаның күз яшьләре әкренләп кипшенгәндәй булды. Шамил исә, тынып, йокымсырый башлады.

— Баланың йокысы килгән, Люлю, яткыр,— диде Альфред, ярарга тырышып.

Луиза, һич каршылык күрсәтмичә, борынын тарткалый-тарткалый урыныннан торды да:

— Ай, минем нәнием, ай минем чебием,— дип сөйләнә-сөйләнә, сакланып кына Шамилне бишегенә салды. Альфред, ватылмасын дип, күзләгән өстәлгә куйды. Үзе Луизаның кайнар тәнен кочаклап, аның тулы-кызарып янган иреннәреннән үбә башлады. Береадан ул, таушалмасын дип, пиджәген дә салып ыргытты. Тәмам тынычлангач, Луиза иренең йөзенә туп-туры карап, сорау бирде:

— Кайсыбыз безнең кирерәк соң?

— Әйдә, мин була бирим,— диде Альфред, барысына да кул селтәп,— тик елама гына.

Ул кинәт хатынын утырган җиреннән күтәреп алды. Шулай күтәргән килеш кенә иреннәреннән тагы суырып үпте.

— Караватка салыйммы? — диде.

Хатын ризалыгын белдереп күзләрен бердән йомып алды. Ләкин Альфред өлгермәде, кемдер бик каты итеп ишек дөбердәтергә тотынды.

— Менә мә,— диде Луиза, мутлык белән тел очын күрсәтеп. Альфред аны тиз генә аягына бастырды, ашыгып күзләген, пиджәген киде. Бик эшкә чумгандай булып өстәл янына барып утырды. Луиза көзге алдында чәчләрен ашык-пошык төзәткәләп алды, пышылдап:

— Ярый әле, ишек бикле булган име-е? — дип, күз кысып куеп, өйалдына йөгерде.

Өйгә үзе белән суык ияртеп кергән кеше мәктәп директоры Әхмәдиев иде.

*Дәвамы бар.*

Әнвәр Давыдов

# ЙОКЫСЫЗ ТӨННӘН СОҢ[1]

РОМАН-СИМФОНИЯ

* * *

Тик авылда бит әле
Гали байлар да исән.
Кара кая битләре:
«Вәлиең кая?» дисәң.
«Белмим!» Салымын түли.
Ә йорты ныгый һаман.
Әйтерсең, эшләп йөри
Байларга любой заман.
Байый Хисмәт, Зыялар.
Югалтмаган үзләрен,
Ташпулатлар куялар
Челтәрләп карнизләрен...
Алар Гали киявен
Арага алмакчылар.
— Тешләдеме кигәвен,
Син бит бабаңа сыңар.
Сәвиттә дуслык кирәк...
Без аңа каршымыни.
Тик хамнар сине сөйрәп
Йөртә... син ялчымыни?!
Кузгаталар күңелнең
Иң төпке агымнарын.
Ул хәтерләмимени
Туйгысыз чагы барын!
Бу байлар каршында да
Бай булып күренәсе!
Кеч җитә барысына да?
Тик Вәли колагәсе
Төшә дә уй кисәлә
(Дөрес, ул күренмәде
Соңыннан. Гайни белә,
Бу — котылу түгел әле.)
Байлар — ябышкак кебек,
Һәр тыныч почмакталар,
Сөйләп табышмак-үгет
Гайнине очраталар.

[1] Ахыры. Башы 1 санда.

— Бул син безнең арада.
Ә сәвит булсын дусың.
Кем белә, кем әле алда
Әйтер сүзнең соңгысын.
Без булышсак, тагын да
Синең артыр гына дан.
Түрдә — урының табында.
Һаман сылу Гөлзадаң.
Шул җиргә җиткәч тагын
Гайни күңеле бикләнә.
Болыт каплый чыраен.
Сакалы — һәр төктә дә
Сөңге бар күк тырпая.
Үз-үзен тыя көчкә,
Һәм борылып китеп бара.
Һаман шул төшә искә.

* * *

Тсс...
Чыш... пыш...
Имешш...
Авыл буенча
Хәбәрләр: тиешш
Зур эш булырга...
Күп җирдә... имешш,
Кузгалган инде
Күрелмәгән эшш...
Алалар җирне...
Җыялар, имешш,
Игенне, малны,
Ә теләмәсәң
Коялар канны...

Тагын, ябышкак сыман,
Сыра Гайни тирәсен
Авылның «чын мөселман»,
«Чын динле» даирәсе...
«Денсез большәвикләргә
Тамчы бирелмәүчеләр»,
«Аллаһ әмере белән
Байлык, җир биләүчеләр»,
«Тьфу, ходай сакласын,
Харамга тимәүчеләр...»
«Тик каферләр алдавын
Тотмаска» димләүчеләр.
Гайни аларның барын да
Белә биш бармак кебек,
Кайсының үз абзарына
Кайсы вакытта кереп
Асравының ыштанын
Мыш килеп салдырганын...
Кайсы кабакта иманын
Хәмергә алыштырганын.
Тик бүген алар хәвефе
Кагылып китә аңар да.

Кырда бодай хәтфәсе,
Көр маллары абзарда.
Күпме сугышлар үтеп
Җаны белән сакланган.
Инде бүгенгә җитеп
Барысын алса башкалар?

* * *

Сүзләр дөрескә
Чыкты шикелле.
Җилләр авылга
Давыл китерде.
Кич саен җыен,
Бәхәс, талашу.
Бугазларны ерып
Чыга бар ачу.
Гали, Зыялар,
Дөрес, дәшмиләр.
Шаулый, яныйлар
Тик ирләрчәннәр.
— Сәвит яңадан
Талый җирләрне!
Деннән, алладан
Аера безләрне!
Шәриф һәм теге
Тын егет Салих
Көрәшче кеби
Өсләрен салып,
Төшендерәләр
Тырышып барын,
Укып беләләр
Газит-мазарын.
Чәйнәп салалар
Ленин, Сталин
Сүзләрен алар,—
Ничек оста диң!
Шулай маңгайдан
Тирләр тамганчы.
Берегә һаман
Нык ярлы-ялчы.
Өерелә читкә
Куштаннар. Дошман
Җиңә алмый һич тә.
Колхоз оеша.
Гайни барысын да
Читтән күзәтә.
Уйлар томан сыман...
Авыр түзәргә.

Трах... Шаррррт... челдерр..
Нардомга төтен тулды.
Кемдер
Ыңгырашып егылды.
Шәрип кычкырды:
Тынычлык!
Тышка! Урап ал, иптәшләр!
Ычкынды...

Таңны котлады этэчлэр...

Көннэр агымы,
Шаулы җыелышлары да —
Бар тормышы авылның
Очрады күк
су асты ташларына.
Колхоз җанлана.
Бар аның үз тормышы.
Кечкенэ чанага
Салып ярлы китерэ орлыкны.
Атлар җыела.
Лэкин бик гаҗэп:
Элек таза атлылар —
Өстери колхозга шундыйны —
Була кабыргасын санап.
Ике атлылар
Кинэт кала бер атка.
Җитэклэп экрен генэ
атлыйлар...
Казанда майлы карта.
Гөрли колхоз йорты эче...
Исереп яз исенэ,
Кар өстендэ
Сабаннар рэтли Гаяз-тимерче.
Сабан баулары ишелэ.
Триер... Бөтен кечкэ:
Гөрр-гөрр...
Шушы гөр тама кичкэ,
Туктамый бер.

Эйе, китэр өчен килми бер көн дэ...
Тормышының шушы иртэсен —
(Булса иде эгэр иркендэ!) —
Ничэ тапкыр! —
килде аның кире сүтэсе!

Башкача итеп яңадан ясыйсы!
Башны миңгерэүлэткэн ярадай,
Гел бер якка тартты язмышны
Шушы көннэр... явыз кайнагай...

* * *

Шартт... Яра авыл төнен
Тагын обрез тавышы...
Файдаланалар кулын кемнең
Курокка басар өчен?
Бушка аталар.
Гайни утлы томан аша
Барысын күзэтэ читтэн.
Колхоз аякка баса.
Шэрип исән, Салих исэн...
Шарт... Тагын төн ярыла.
Нидер сизеп, тавышка
Сикерэ Гайни, колхоз йортына ыргыла,
Салихны алып китэлэр больниска.
Тикшерүлэр.
Куштан Миннэхмэт

Телгә ала Гайни исемен:
Хат курсәтә.
Авылда гайбәт...
Гайни дәшми... ни дисен.

Шәрип тагын
Хурлыктан йола Гайнине.
Тик ялкын
Һаман ялый мине...
Язгы гөрләвекләр
Гайни күңелендә —
Кырга ашкыну хисе урынына
Яңа төрле шикләр
Алып килделәр:
Уй упкыннары кайнап ургыла.

Гайнинең иң шәп кыры
Яңа колхозга эләгә.
Дөрес, начар түгел яңа урын,
Ләкин, күпме сөйләмә,
Ачуны булмый басып...
Кояш көлә... Җир кибә...
Кызыл флаглар асып
Колхоз басуга китә.

Бер атлы сабан алып
Үз кулы белән сөргән;
Аннан совхозга барып
Халык әмере белән,
Күп еллар үсә торган
Гаҗәп үлән кайтарып
Үстергән яшел юрган.
Хәзер кәсләр кантары
Шуларны басып китә.
Крачинлы машина
Шулар башына җитә...
Димәк, Гайни башына.
Җыела ниндидер халык
Миннәхмәт капкасына.
Гайни күңеле ярсына.
Кушыла шунда барып.
— Җимерәбез, куабыз
Денсезләрне кырыбыздан.
Тагын үкенү туа бит:
Ник баш тартты обрездан.
Басып кыры чигенә,
Салихна тебәр иде.
Йөрәктәге бар утны
Көпшәдән түгәр иде.
Шыпырт кына Гөлзада
Өйгә чакырып кәрый,—
Сүгенеп селтәнә аңа.
Язмышка йодрык яный.
Кузгалалар басуга,
Атлап зур урам аша.
Кыя кебек, каршыга
Күрше карчыгы баса.

— Гайни! Улым да минем
Анда... Дошманмы ул сиңа?
Ачу, юаш тетендэй,
Ничектер җиргэ иңэ.
Аптыраш кубесендэ...
Каранышып алалар....
Милиция куренгэч,
Тетендэй таркалалар.

Гали бай мендэрлэренең
Мамыгы уйный җилдэ.
Эллэ кемнэрдер мена
Кабык чанага атлар җигэ.
Тейилэр бар семьяларын.
Хисматлэр, Зыяларның...
Табаннар ыңгыраша
Авыр кейгэ:
Соловкига... Соловкига...

* * *

«Вставай страна огромная...» —
Станциялэрдэ җыр.
Тен — аналар моңая...
Айкала-чайкала чор.
Эшелоннар мыж килэ.
Станциягэ барсаң:
Кайсыннан җыр беркелэ,
Кайбереннэн тама кан.
Кенбатышка исэннэр —
Иван, Петр, Хэкимнэр.
Кенчыгышка — мескеннэр...
Яралылар... ятимнэр...
Кенбатышка — танклар,
Артиллерия, укчылар.
Кенчыгышка — заводлар...
Туп, ядрэ коючылар.
Кенбатышка — ил, ана
Фатихасын алганнар...
Кенчыгышка — (ил яна!)
Йортсыз-җирсез калганнар.
Бер эшелоннан халык
Гариптэй авыр гына
Акты акрын чайкалып
Гайнилэр авылына.
Ничектер рэис бу юлы
Һэр кирэкне барлауны,
Урнаштыру, туйдыруны
Гайни естенэ аударды.

Мэш килеп йөрде Гайни.
Ачыкканнарга ашын
Пешереп казаннар кайный.
Ана юа баласын.
Салам тушэк җэелэ
Бик арып калганнарга,

Эш тә тәгаенләнә
Тик торалмаганнарга.
Гайни үзе сизмәстән
Ешрак сугыла бер өйгә.
Ял иткәнме килгәчтән
Урнашканнар бергә?
Карасаң, кайгырту да
Артыграк шикелле.
Яхшы каршылый хуҗа
Үзенә төшкән икене.
Алар аналы-кызлы:
Җиде яшьлек Тамара,
Яшькелт күзле Наталья —
Аксыл зур толымнары...
Хуҗалар карт та карчык —
Кызларын, оныкларын
Гүя алдылар каршы,
Өстәлгә куеп барын.

Иртәгесен эшкә чыга
Наталья Ивановна.
Гайни тагын ашыга
Никтер аның янына.
Тикшерә чачкеч винтенең
Дөресме куелганын,
Ә күзәтә битенең
Елмаеп уелганын.

Шат кәеф-сафа белән
Узамы көн, яки дә
Бүгенге җәфа белән,—
Барыбер ул үтә кичә.
Кичләрен кайчагында,
Картларча йомыш табып,
Сүз кушып Наташага,
Керәп чыга, өфтанып.
Бер кичне караңгыда
Капка төбендә алар,
Икесе дә караңгалап,
Ничектер очрашалар.
Гайни еш сулыш ала.
— Ну... скажи-ка... где твой муж?..
Наталья елыша да:
— Он погиб... погиб, Гайнуш...
Суык... Әйе, без ятим,
Тик икәү Тома белән.
Гайни сыйпап аның чәчен...
Елыта тыны белән...

Гомер үтә... бер елмая,
Бер сүгенә солдаткалар:
«Кибә мескен Гөлзада».
«Гайнигә ни? Натка бар!»

* *

Гайни әкрен генә ачә капкасын.
Гаҗәпләнмичә генә
уздыра эчкә,
артыннан
Тын гына иярәп килгән Наткасын.
Бүлмәне Ләйлә яхшы җыештырган.
Ут янә... шулай да
авыр һәм моңлы.
Юрганнардан
ниндидер сер отып калган гүя кровать-
диван.
— Ну старик, что с тобой? Аңлат әле, әллә
инде соңмы?
Юк, соң да түгел, иртә дә...
Гайни күңелендә һаман бер теен:
Кесәсеннән алып
теге хатның саргайган битләрен
Кейли Натальяга
Гарәп хәрефләренең
әрнүле көен...

Ерак түгел инде үләсем...
Ләкин әле сулыш алганда
Килми йөрәгемне бүләсем
Башка белән... Аңла син, аңла.
Көнләү түгел... Барыбер кайтырсың...
Хәсрәт башка... Үкенү яндыра...
Һәр тармагын, һәрбер аерысын
Бәгыреңнең аңлап бардым ла...
Тик нигә соң хаксыз шик белән
Син янганда, сөрем сарганда,
(Ах, мин әле үкенеп җилкенәм!)
Каршы чыкмадым мин ялганга?! —
Юл — үтелгәч гади күренә,
Әле шулай синең өчен дә.
Шатлык арты хәсрәт килүенә
Җавап әзер синең эчеңдә.
Тик мин генә синең тормышта
Калдым бугай гаҗәп сер сыман.
Юк, син мәгънә эзләп тырышма.
Көнләү дә соң... Җаным, ярсыма.
Үз рәтендә килер бер иртә,
Уйларыңа чумып аңларсың...
Минем кебек серле бит син дә.
Арлы-бирле җирдә айкалдың.
Сәбәп: бәхетең каралган саен,
Өмет — хыял булып балкыды.
Аңа — көчең, яшьлек ярсуың,
Һәр көнең... Ә мин — «Гали бай кызы...»

Мин үскәндә бәхет нурлары
Балкып торды һаман өстемдә.
Китапларның серле юллары
Хыял уяттылар эчемдә.
Намус, сафлык, изге батырлык!
Ягъни шулар тормыш мәгънәсе.

Тик аларны шомга батырып,
Төшә авыр хаклык шәүләсе.
Берсен-берсе өйдә алдыйлар...
Аннан бегә бөтен авылны.
Шунда юллар алып кайттылар
Шат әфисәр Вали абыйны.
Тойдым, абыемда җыелган
Саф батырлык, яшьлек көчләре.
Бер көн... елау... печән өеменнән...
Иң яшь асрау кызны көчләде.
Аңладым мин... Үрнәк ул түгел.
Сүнмәде тик яшьлек хыялым.
Матур, көчле, аңлы бер егет
Коткарыр дип мине уйладым
Ялган тулы түбән тормыштан...
Тартты шәһәр уем очларын.
Шунда көмеш кебек арыштан
Калыктың син... миңа очрадың...
Башладым мин шундук янарга...
Көрешүләрдә нәрсә сөйләдең,
Тыңламадым, ләкин аларда
Ишеттем үз хыялым көйләрен.

Читән алачык
Сыйдырды тик хыялларның башта бик азын.
Яшь күңелемне әмма киң ачып
Алдым авыр эш романтикасын.
Сөйдем... Ләкин курыктым кире
Биек өйгә синең чакырудан,
Җимерүче итеп сөйдем мин сине,
Шул өйләрне изге ярсудан.
Сугыш... киттең... киттем сине мин,
Сүнмәде ут эчтә бер минут...
Революция... уемда иң батыр син.
Кызыл бант... лента... пулимут[1].

Без хатыннар ләкин бик сәер.
Нинди хыялларга чумсак та,
Уттан исән кайтып керсә ир
Тынабыз без туган почмакта.
Авыр көннәр. Аклар... тантана...
Шул ут янды һаман эчемдә:
Гайни, хыялымны таптама,
Ташлан ярсып алар өстенә!
Тәвәккәлем идең! Кыймадың.
Монда сиңа әллә ни булды.
Йортны ураган биек коймамы
Бүлде илдән синең юлыңны?
Мин дә инде... үкен-үкенмә...
Ачар идә белемем күзеңне...
Синең томаналык иркенә
Бирелдем мин... таптап үземне...
Ах, теге кич, ник син буйсынып
Чаптың самогонга... Ә абый,
Күңеле белән барысын тоеп,

[1] «Пулемет»ның гарәп хәрефе белән язылышы.

Пычрак уе белән чамалый
Минем горурлыкны җиңәргә...
Карта уйный — мине банкка...
Әмма шундый пычрак җирдә дә
Урын табыла икән хаклыкка.
Зәңгәр күзле тын гына егет...
Читтә тора иде...

— Бар бер чик
Һәр нәрсәдә, тор шуны белеп:
Моның өчен үзем, поручик,
Үтерәм сезне... Шунда уянды
Тугры рыцарь минем хыялда.
Бутады ул бөтен уйларны.
Ул чакырса мине... мин анда...
Син әйләндең бик тиз. Ярады.
Хыялымнан айнып, кайттым мин...
Оныттым бар йөрәк ярамны.
Туган кочагыма кайттым мин...
Тора алмый авыру кеше,
Көтмәгәндә китсә сөртенеп.
Абыйны калдырдык... Туганлык хисе...
Бәгырьгә аскан авыр гер кебек.
Син уйладың: синең ачудан
Саклыйм аны... әчтән тик янып,
Мин... курыктым үзем ярсудан
Түгәрмен дип туганым канын.
Ул хәйләкәр: «Мине ачсаң, ди,
Теге зәңгәр күзле рыцарь да...»
Ул иң авыр урынны сайлый...
Кагыла иң катлаулы сергә.
Ышан, ышан, мин бер секундка
Сөя алмадым синнән бүтәнне...
Тик ул егет...
Мин кыз вакытта
Гашыйк образларны күтәрде...
Ул чагында сиңа аңлатып
Булмас иде... Көннәр узалар...
Бер аңлатыр, дидем мин, вакыт...
Хәзер үкенеп күңелем сызлана.
Дәрья-дәрья яшьне түгәсе,
Янып ташланасы куеныңа...
Сөйлисе барын... Елап үбәсе...
Яңәшә чыгасы авыр юлыңа...
Шулай кирәк булган...
Мин әммә
Катлаулы «зур» җаннар турында
Яшьлек бәркеп үткән хыялда
Әсир...
Янәсе ара зур монда...
Еллар үтте, күмде шикелле
Бар яраны, бөтен әземне...
Элеккедәй син гел сөйкемле,
Элеккедәй дәрткә сиземле...
Әйе, сөйдем, сөйдем бер сине...
Адашсаң да кайчак төннәрен,
Беләм син дә сөйдең бер мине,

Булсын анда әллә кемнәрең...
Ләкин аңламадың... Бар моңым да
Артык гади сиңа күренде...
Зур бай кызы... чыкты ярлыга...
Шәйле-мәйле шуңа күңеле...
Әмма минем кебек үзең дә
Арлы-бирле җирдә әйкәлдың.
Сау бул, җаным. Җәлләп өзелмә.
Вакыт килер, син дә аңларсың.
Ә хәзергә... миннән... аерылгач
Башыңны артык басса томаннар,
Теге рус хатынына күңелең ач.
Ул мөлаем күренә, ул аңлар.
Ярый, сау бул, күз алмам.
Бердәнберем, Гайнием,
Тын кысыла...
        Нинди авыр йөк калдырам...
Җаным, җилкәңә һәм бәгыреңә синең...

Төн буе...
        бер сүзсез...
                икәү...
Таң аткач
        чыгалар ишек төбенә.
Нидер пышылдый
        тәрәзә төбендәге ялгыз карт юкә.
Томаннан
        нindидер сигналлар
                ишетелә.

— Юк, томаннан түгел бу сигнал...
Улының улы Илгиз ясаган
Радио кебек,
        теге бүселгән
Иске юрган
        үзенә яшеренгән ерак-ерак авазларны
Гайни дулкынына җайлап
Җибәреп тора һаман...

Томан тарала.
        Шундый пейзаж ачыла...
Нindидер нур килеп
                тула эчкә.
Алар капка төбенә чыга.
Наталья — тракторына...
        Гайни — лабораториягә,
                кырына...
                        Эшкә!..

**Гариф Галиев**

# БӨТЕНЕСЕ ДӘ БЕРГӘ

хикәя

Игеннәр өчен яз да һәм җәй дә бик әйбәт килде. Ләкин, уракка төшүнең икенче көнендә һава торышы кинәт үзгәрде: төне буе салкын җил исте, вакыт-вакыт еракларда күк күкрәгән тавышлар ишетелде, яшен яшьнәде. Иртәгесен инде күк йөзендә соргылт-кара болытлар куерды һәм төш алдыннан, бу куе болытлар бөтен тирә-якны томалап алды да, чиләкләп-чиләкләп яңгыр коя башлады. Бик тиз арада урамнарда гөрелделәр ага башлады, чокырлы-чакырлы урыннарда кечкенә-кечкенә күлләр хасил булды, елгаларда сулар артты. Шулай кайдадыр болыт артларында әллә нинди куркыныч тавышлар чыгарып, утлы камчылар селти-селти шактый вакыт яуды-яуды да кинәт туктап калды. Ни чаклы гына көчле яумасын, авыл арасында моның зыяны күренмәде. Мәгәр яңгырдан соң кешеләр басудан кайгылы хәбәр алып кайттылар:

— Арыш басуын боз сукты, — дип үттеләр урамнардан.

Колхоз председателе Заһидулла агай идарәдә утыра иде. Ул бу борчулы хәбәрне ишетү белән, идарә ишек алдының лапас астында торучы җигүле ат янына чыгып, тарантасына утырды һәм басуга таба юл тотты.

Боз суккан мәйданның күләмен үз күзләре белән чамалап белү өчен ул арыш басуының түреннән үк әйләнергә булды. Кара айгыр бу юллардан күп йөргәнлектән, үз көенә генә атлый бирде. Заһидулла агай исә боз суккан җирләрне бик игътибар белән карап барды. Бәхеткә каршы, боз арыш басуының бер кырыеннан аерым полоса булып кына үткән. Шулай булса да зыян аз түгел иде.

Нишлисең, килгән зыян килгән инде. Ашлык шактый чәбәләнгән, урыны-урыны белән нык кына сөрлеккән. Хәзер менә шул мәйданны ничек урырга кирәк? Төп мәсьәлә шунда.

Басуны әйләнеп чыккач, ул туп-туры комбайнчыларга таба юнәлде һәм Камай участогына килеп туктады. Ул килгәндә Камай яңгыр аркасында туктап калган комбайны янында маташа иде. Бу күңелсез хәлдән кәефләре кырылганлыктан булса кирәк, алар салкын гына исәнләштеләр. Бурага керергә генә торган ашлыкның әрәм булуы турында зарланышып алдылар. Заһидулла агай боз суккан арышны урының берәр ысулын табарга кирәклекне аңлатты. Камай исә үзе дә шул хакта баш ватканлыгын сөйләп бирде һәм яңадан эшен дәвам итте. Менә ул комбайнына менеп утыргычны ачты һәм аннан үзенә кирәкле тимер кисәге алды. Шул вакыт Заһидулла агай утыргыч астында яткан бер төргәк чимер чыбык белән каеш йөгән күреп калды. Тукта, моны мин яз көне, карабодай чәчкән чакта трактор кабинасындагы утыргыч астында күргән идем бит. Нишли икән бу йөгән белән, нәрсә өчен кирәк икән ул аңа? Кирәк булмаса, аны монда йөртмәс иде. Күрәсең,

... дип уйлап алды эченнән генә. Заһидулла агай ашыгып эш итә торган кешеләрдән түгел, ә, киресенчә, бик сабыр холыклы. Нинди генә сәер хәлләр алдында да тиз генә күтәрелеп-бәрелеп китми иде ул. Әле дә, гәрчә Камайның комбайнда болай йөгән йөртүе бик гаҗәп тоелса да, Заһидулла агай моңа артык шаккатмады һәм бу турыда Камайга бернинди сорау да бирмәскә булды. Шулай да, эченнән генә һаман уйланды, авылга кайтып килим дисә, әнә тегендә кыр вагоны янында өр-яңа мотоцикл тора, өстәвенә, кирәк булса-нитсә дип, шул ук кыр вагонында колхоз ике велосипед тота. Теләгән механизатор утыра да китә ала. Йомыш төшә икән, өенә кайтып киләсе, мунча керәсе, өс-башын алыштырасы бар икән, аңа берәү дә каршы килми, рәхим итеү, утыр да чап. Аннары безнең ике җинел автомобилебез дә бар. Тәҗел генә барасы җир булганда без аларны да бирә алабыз. Әгәр кирәк икән, мөмкинлек булганда, безнең машина бирүдән бер кайчан да баш тартканыбыз юк. Тукта, тукта, диде ул нәрсәдер хәтерләгәндәй, бу Камайны әйтәм, яз көне ул бер вакыт төнлә белән Чишмә авылына барып кайту өчен ат сораган иде түгелме? Ләкин мин аңа бирмәдем шикелле. Ни өчен бирмәдем? Ул нинди йомыш белән баруын ачык әйтмәде бугай. Әллә шуңа хәтерe калып, кирәк чакта атлардан файдаланамы? Ә атны кем бирә аңа? Димәк, кем дә булса бирә торгандыр. Йөгән атка, ат Камайга кирәк. Шулай булмаганда ул ни өчен кабинкасында йөгән йөртсен!..

Заһидулла агай ничаклы гына уйласа да, никадәр генә башын ватса да, мәсьәләнең очына чыга алмады. Юк-бар сораулар белән Камайны да интектермәде. Йөгәнне гүяки күрмәгәнгә салышты. Шул көнне кичен алар баш агроном Гатаулла белән механизаторларның киңәшмәсен җыярга һәм анда чәбәләнгән арышны ничек урдыру турында киңәш-табыш итәргә тиешләр иде. Инде кояш баеп килгәнлектән, Заһидулла агай, Камайга үзенең әйтәсе сүзләрен әйтеп, авылга кайтып китте.

Өенә кайткач ашап алды, азрак ял итте. Аннары киңәшмә үткәрү өчен идарәгә китте. Идарәнең ишек алды кайсы зәңгәр, кайсы яшел, кайсы кара төстәге мотоцикллар белән тулы, бу исә киңәшмәгә басудагы барлык механизаторларның кайтканлыгын күрсәтеп тора иде. Арыш басуын боз сугып киткәннән соң кәефе киткән Заһидулла агайның, бу тәртипне күргәч, күңеле күтәрелеп китте.

Көтелмәгән мәзәк тә булды шунда ук: идарәгә кереп, механизаторлар белән сөйләшә башлауга ул әлеге йөгән белән тагын очрашты. Ләкин бу юлы йөгән кабинкадагы утыргыч астында түгел, ә Камайның билендә иде.

Камай йөгәнне пиджак эченнән биленә ураган иде. Аңа ни өчендер пиджакның сәдәпләрен ычкындырырга туры килде. Ул сәдәпләрне тиз генә яңадан эләктерде эләктерүен. Мәгәр шул вакыт Заһидулла агайның очлы күзләре йөгәнне күреп өлгерделәр. Тик ул бу юлы да аны күрмәмешкә салынды. Бөтен комбайнчыларны үзенә ияртеп иң алдан баручы һәм бик булдыклы егетне юк-бар сорау биреп борчыйсы килмәде аның. Шулай да бу мәсьәлә аның күңелен гел кытыклап торды. Менә ул киңәшмәне ачып җибәрде һәм сүзне баш агрономга бирде. Баш агрономның кыска гына чыгышыннан соң механизаторлар сөйли башладылар. Берәүләр камылны төптәнрәк кистереп уруны хупладылар, берәүләр мотовилоның араталарына кайбер үзгәрешләр кертүнең кирәклеген ышанычлы мисаллар белән исбат итте, икенчеләр нинди тизлек белән урырга кирәклегенә тукталдылар. Кыскасы, мәсьәләне уртага салып ныклап тикшерделәр. Камайның чыгышы уйлап табу, һәртөрле җайланмалар куллану ягыннан киңәшмәдәгеләрнең бөтенесен дә үзенә тартты. Ул тәкъдим иткән метод бик тирән һәм төпле булганлыктан, дөрестән дә, ашлыкны әрәм-шәрәм итмичә урып-җыюда иң

кулай метод булып табылды. Комбайнчылар шул төнне үк басуга — эш урыннарына барып, комбайннарга тиешле үзгәрешләр кертергә булып таралдылар.

Механизаторлар идарәдән ишек алдына чыккач, бер мизгел вакыт мотоцикллар кабызган тавышлар яңгырап торды. Аннары алар берберартлы ишек алдыннан чыгып урамнарга юл алдылар һәм бөтен авыл диярлек шушы машина тавышларына күмелде. Бу сугыш кырларында була торган хәлләрне искә төшерүче, үзенә бер төрле ярсулы тавыш иде. Әйе, болар ыргылып фронтка кереп баручы бик көчле сугышчан бер отряд бит. Тыныч көннәрдә, тыныч басуларда ил байлыгы өчен төнне көнгә, көнне төнгә ялгап көрәшүче механизаторлар алар. Ә әле кайчан гына, Заһидулла агайның малай чакларында, кешеләр тимер сабанны да рәтләп көйли белмиләр, ә инде алты тешле сугу машиналарын эшләтә белү турында уйлап та карыйсы юк. Ә хәзерге яңа игенчеләр йөзләрчә частьлардан торган комбайннарны ничек эшләтергә кирәк тапсалар, шулай көйли алалар. Аларның һәрберсе элекке йөз игенчегә тора. Алар йөртә торган агрегатларның һәрберсе дистәләрчә атны алыштыра. Менә бит нинди заманнар килде. Өстәвенә үзләре утырып йөри торган мотоциклларны алып кара, болар безнең ата-бабаларыбызның төшләренә дә кермәгән машиналар лабаса!

Заһидулла агай идарәнең тәрәзәсенә таянган килеш колхоз механизаторларын озатып калганда әнә шулай уйланды. Бу уйлар аның үзе алдына кайбер сораулар да куйды. Без игенчелек эшен үз җилкәсендә шулай алып баручы машинистларның-механизаторларның кадерләрен беләбезме соң? Дөресен әйтергә кирәк, бу яктан аның вөҗданы борчылырлык түгел иде. Ул хәзер генә түгел, ә колхозлашуның беренче елларыннан ук машинада эшләүчеләргә җил-янгыр тигермичә, аларны һәр кайчан яклап килде. Ул елларда Заһидулла агай бригадир иде. Авылда хәзерге кебек уннарча тракторчылар юк иде ул чакларда. Аларны хәзерләү дә бик кыен иде. Бердән, курсларга укырга җибәрергә кулай кеше таба алмыйча йөдиләр иде, икенчедән, укып кайткан машинистлар еш кына очракта МТСларда калалар һәм үз колхозларында аларга, ничаклы гына теләсәләр дә, эшләргә туры килми иде. Менә шуның аркасында заманында Заһидулла агай бригадирлыктан чыгып, бер елны үзе механизаторлар курсына китте һәм аны тәмамлап кайтты да шактый еллар колхозда машинист булып эшләде. Аннары инде аны бер кышны колхозның председателе итеп сайлап куйдылар һәм шул елдан алып ул гел үз постында калып килә. Аны алыштыру турында берәүнең дә бер кайчан да авыз ачып сүз кузгатканы юк. Чөнки аны колхозчылар яраталар, Заһидулла ул бөтен механизаторларны үзе белә, бөтен басуларны үзе актарып чыккан кеше, безнең өчен аннан да кулай кеше бер җирдә дә табылмас, диләр. Менә шундый бөтен халык тарафыннан ихтирам ителә торган председатель ул Заһидулла агай. Шулай булса да ул бүген ничектер үзеннән риза түгел, һәм моның сәбәбе Камай билендәге әлеге йөгәнгә бәйле иде. Ул бу мәсьәләне башыннан һич кенә дә чыгарып ташлый алмады. Йөгән ни өчен кирәк? Әлбәттә, кешеләрне йөгәнләргә түгел, ә ат йөгәнләү өчен. Димәк, Камай нәрсә өчен булса да аттан файдалана. Шулайдыр, шулай булмаса, ул яз көне, Заһидулла абзый, миңа бер ат беркетегез әле, дип үтенмәгән булыр иде. Ә мин аңа, кирәк саен сорап җигәрсең, сиңа бер үзеңә ничек инде бер ат беркетик, дип җавап бирдем. Кирәк чакта җигәрсең, дидем диюен, ләкин ул яңадан ат сорамады бит, ә үзе йөгән йөртә.

Запас частьларга бик мохтаҗлыкка төшкәнлектән, Камай, моннан берничә ел элек, әле армиягә киткәнче, аны-моны уйлап тормастан, колхоз айгырына атланып, бер төнне күрше колхозга барган һәм аларның бер комбайннарын «чишендереп» кайткан иде. Аның бу ярамаган

эшен соңга калып булса да Заһидулла агай сизенеп алды алуын һәм аны башкаларга белдермичә генә бик каты шелтәләде, кеше әйберенә янадан кул сузмаска, запас частьларны болай «тапмаска» ант иттерде. Бу начар гадәтен Камай кабатламады бугай.

Утыргыч астында йөгән белән бергә кечкенә генә төргәк тимер чыбык аны тагын уйланырга мәҗбүр итте. Комбайн яки трактор өчен мондый нәзек чыбыкның һич кенә дә кирәк түгеллеген ул бик яхшы белә, чөнки вакытында ул үзе тракторчы булган кеше. Бу бер бәйләм тимер чыбык Камайга ни өчен кирәк булган, ул аны каян алган? Әллә соң бүген төнлә егетне күздән ычкындырмаскамы? Нинди дә булса ярамаган эш эшләп йөрмиме? Ул шунда ук бу уйларыннан кире кайтты. Шул кадәр тырышып эшләүче, нормасын көн саен арттырганнан арттырып үтәүче бу алдынгы механизаторның нәрсәсеннән шикләнәм соң әле мин? Йөгәненең дә, тимер чыбыгының да кирәге бардыр, мина нигә бу мәсьәләне төпченергә!

Ул үзен-үзе тынычландырды һәм өенә кайтып китте.

Иртәгесен ул агроном белән бергә боз суккан арыш басуына килде. Алар анда, комбайнчыларны җыеп, нинди метод белән уру турында тагын бер тапкыр сөйләштеләр. Камай чәбәләнгән арышны ничек уру турында кичә сөйләгән сүзләренә группа белән урырга кирәклеген өстәп әйтте:

— Биш комбайн белән басуның боз килгән ягыннан төшеп урырга керешәбез. Әгәр көн аяз торса, кичкә чаклы без бу мәйданны «ялап» та чыгарбыз,— диде.

Боз сугу аркасында башлары сынып, чәбәләнеп беткән арыш басуына иң элек комбайн белән ул кереп китте.

Куз күреме кадәр җирдә хәрәкәт итүче, кабинкалары ап-ак зонт белән капланган, яңып торгандай кып-кызыл комбайннар бер-берсенә юл бирә-бирә киң диңгездә йөзүче корабларны хәтерләтә, аерма шунда гына, диңгез кораблары тын гына йөзәләр, ә болар туктаусыз гөрелти.

Комбайнчыларның эшләре мәгълүм бер эзгә төшкәч, Заһидулла агай, уң ягы аз гына кыйгая төшкән тарантасына утырып, атын авылга таба борды.

Бу көн аеруча киеренке булды: комбайннарның еш кына пычаклары тыгылды, мотовило аралары сыңгалады, авырга килү аркасында кайбер частьлары ватылгалады. Ләкин, барлык кирәк-яраклар һәм эретү-кою кораллары үзләре янында булганлыктан, бөтенесе дә эш барышында төзәтелде.

Ниһаять, кояш чыкканчы башланган һәм бик кызу тотылган бу удар эш кояш баеганчы тәмам булды. Урылган җирләрне сыйфат инспекторы булып йөрүче картлар барып тикшерделәр һәм эшкә югары бәя бирделәр. Җир өстендә эскәк белән эләктереп алырлык та баш калмаган, валлар бер төрле калынлыкта һәм, камыл төптән кистерелгәнлектән, тигез салынган иде. Өстәвенә күк йөзе зәп-зәңгәр төс алып, аязып китте.

Әле кичә генә арышны боз сугу аркасында халык кара хәсрәткә баткан иде. Ә инде бүген ашлыкның әрәм-шәрәм булмаганлыгын күргәч, һәркемнең күңеле күтәрелде, кәефе яхшырды. Кичен идарәнең ашыгыч утырышы җыелды һәм анда комбайнчыларны кыйммәтле әйберләр белән бүләкләделәр. Иң беренче бүләк, әлбәттә, Камайга бирелде.

Ул көнне Заһидулла агайның район үзәгендә яшәүче кызы бәбәйләве турында телефоннан хәбәр иткәннәр иде. Шунлыктан, утырышны ябу белән, хатыны Әсмабикәне утыртып, ул кияүләренә китте. Анда хатынын калдырып, инде бик соң булса да кайтырга булды. Чөнки мондый кызу урак өстендә Заһидулла агай иртүк басуда булуны үзе өчен бер кайчан да бозылмый торган закон итеп алган иде.

Авылга ике-өч километр кала бер күпер бар. Менә шушы күпергә якынлашканда гына ул арттан ат атланган бер кешенең килгәнлеген абайлап алды. Җайдак аны тиз генә узмакчы иде. Ләкин, караңгы булуга да карамастан, Заһидулла агай аны танып өлгерде.

— Камай, бу син түгелме соң, туган?

— Әйе, мин,— диде Камай, кыяр-кыймас кына.

— Кая бардың болай соңгарып?

— Чишмәлегә барган идем, Заһидулла абзый,— дип җавап бирде Камай юаш кына тавыш белән.

Заһидулла агай гадәтенчә артык төпченергә ашыкмады:

— Велосипедың бар ләбаса синең, иярләмәгән атка атланып йөргәнче, аның белән уңайрак булыр иде,— дигән булды.

— Велосипедны бала-чага алып китүчән була, Заһидулла абзый. Кая да булса калдырып, берәр җиргә кагыласың икән, хәзер утырып «шуалар», ә атны аны бәйләп калдырасың да йомышың булгач өйгә керәсең дә китәсең.

— Шулаен шулай инде. Синең бит мотоциклың да бар, атка атланып йөрү ботка төшә бит ул.

— Мотоцикл, бердән, бик тавышлы, икенчедән, аңа утырсаң, өсбаштан бензин исе аңкый...

Егет нәрсәнедер әйтеп бетермәде. Заһидулла агай аны тагы сүзгә тартты.

— Аңкыса... Аннан нәрсә була?

— Алар бензин исен яратмыйлар бит, Заһидулла абзый.

— Кемнәр?

— Кызлар...— дип, кинәт көлеп җибәрде егет.— Яздан бирле синнән яшереп йөри идем, Заһидулла абзый, тәки әйттердең.

Заһидулла агай да кет-кет итеп көлә башлады. Сүз арасында ул тагы сорау бирде:

— Йөгәнең авызлыксыз икән, бу бик кырыс ат бит. Авызлыклы йөгәнең юкмыни соң?

— Авызлыклы йөгән шалтырый бит, Заһидулла абзый, ә мина шыпырт кына барып кереп, шыпырт кына чыгып китәргә кирәк.

— Каян?

— Кергән җирдән.

Заһидулла агай тагы кет-кет итеп көлде. Һәм секунд эчендә үзенең яшь чагын хәтерләп алды.

Ул егет булып үскән чакларда атларны төннәлеккә я елга буйларына, я әрәмәлеккә илтеп тышаулау, ә инде иртә белән көтү чыккан вакытта аларны барып алу гадәте бар иде. Кулга йөгән тотып, атлар алырга киткәндә, үткенрәк егетләр үзләренең яратып йөргән кызлары янына аларның сыер саварга чыккан урыннарына кагылалар, шунда серләшеп алалар. Ә инде алар яныннан кузгалып киткәндә, әле йокыларыннан тормаган өлкәннәр уянмасын өчен, йөгәннәрне авызлыкларыннан тотып, ишек алларыннан шыпырт кына чыгып таялар иде. Чөнки шулай итмәгәндә, йөгәннең авызлыгы шалтырап, өйләрдән кемнең булса да уянып чыгу куркынычы бар һәм бу хәлнең киләчәктә егет белән кызның яңадан кавышуына киртә булуы мөмкин. Яшь җаннар моны алдан күрәләр һәм шуның өчен алдан сагаялар да иде. Үткән яшьлекнең еракларда калган күңелле бер көннәрен күз алдыннан кичергәч, Заһидулла агайның йөрәк түрендә яткан бик нечкә кыллары, тавыш бирер-бирмәс кенә, йомшак кына итеп яңгырап алды, бер мизгелгә күзләре яшьләнде, иреннәре кибеп калгандай булды. Әйе, бик тиз генә арада булып алган бу кичереш аның өчен авыр да, җинел дә һәм моңсу да, ямансу да иде... Ләкин, нишлисең, аккан сулар, искән җилләр кире кайтмаган кебек, ул

кеннәр дә кире кайтмый бит инде. Заһидулла агай шушы кичерешләр арасында эченнән генә үзеннән үзе сөйләшеп тә алды, менә кайда икән егетнең үзе белән йөгән йөртүенең сере, менә кайда икән, ә мин ат менеп берәр мутлыкка йөрми микән дип шикләнә идем аннан. Кинәт аның исенә теге бер төргәк тимер чыбык килеп төште. Һәм ул, үзен тынычландырган өчен Камайга рәхмәт әйткән кебек, ягымлы гына тавыш белән сорап куйды:

— Кабинаның утыргыч астында да, билендә дә йөгән күргән саен эчем поша иде. Хәзер инде аның серенә төшендем һәм тынычландым. Ә менә шул ук утыргыч астындагы бер төргәк тимер чыбык сиңа ни өчен кирәк? Шуны да әйтеп бирче?

— Ул минем үземә кирәк түгел, Заһидулла абзый, әлеге кызга кирәк.

— Кызга?

— Әйе, ул кыз колхозның колмак плантациясендә эшли. Быел колмак бик уңган икән. Нәрсәгә үрелеп үсәргә белми ди. Ә колмак үрелеп үссен өчен плантациядә баганадан баганага тимер чыбык сузалар. Ул, тимер чыбыкны әйтәм, бик күп кирәк икән, үткән шимбәдә, әгәр таба алсаң, миңа тимер чыбык алып кил әле, дигән иде. Мин аны шул кыз өчен хәзерләгән идем. Бүген илтеп тә бирдем.

— Шайтан икәнсең,— диде Заһидулла агай, тагы көлә-көлә.— Кем кызы соң ул? — дип сорады.

— Аның әтисе — синең дустың, Заһидулла абзый, ул синең белән бергә колхозлар төзеп йөргән кеше.

— Җиһаншамы әллә?

— Әйе, әйе, Җиһанша исемле.

— Аның Галимә исемле бердәнбер кызы бар иде. Шул инде, алайса?

Егетнең авызы бөтенләй ерылып китте:

— Шул, шул, Заһидулла абзый.

Заһидулла агай ярым шаярып һәм ярым җитди рәвештә әйтә куйды:

— Алайса мин үзем башкода булам. Анда барып йөрү өчен вакыт та күп китә... Кызның үзен монда алырга кирәк... Өйләнергә!..— дим.

Камай аның шулай дип әйтәчәген сизенеп алган иде инде. Шулай да ул аз гына үзен тыйнаграк тотарга тырышты:

— Бездә ана кулай эш юк бит, Заһидулла абзый, ул шуна аптырый. Яраткан һөнәремне ташлыйсым килми дигән була.

— Колмак плантациясендә эшли диденме әле?

— Әйе, колмак үстерә ул. Колмак үрелеп үсә, үрмәли-үрмәли әллә кайларга кадәр сузыла, аны үстерү кызык, ди. Ә безнең колхоз колмак үстерми бит.

Заһидулла агай бик каттый фикергә килде һәм аңа карап, бик матур итеп елмайды да:

— Орлыгын гына алып килсен, менә дигән итеп үстерербез,— диде.

Аның болай әйтүен ничек теләсәң, шулай аңларга мөмкин иде. Һәм Камай моны, үзе теләгәнчә, киң мәгънәдә аңлады бугай:

— Шулай, шулай Заһидулла абзый,— диде ул бик шатлыклы тавыш белән.

Юлның нәкъ уртасыннан үзенең күп еллардан бирле җигеп йөри торган һәм уң ягы аз гына кыйгайган тарантасына утырган Заһидулла агай, аның белән янәшә кечкенә җирән кашкага атланган Камай бара.

Менә алар колхоз атларын төнnәлеккә тышаулап җибәрә торган әрәмәлеккә килеп җиттеләр. Заһидулла агай зур гына гәүдәсе белән тарантасның читенә ята төшеп, үзе белән янәшә бара торган Камайга йомшак кына итеп дәште:

— Атынны шушында тышаулап калдыра торгансыңдыр бит... Төшеп минем янга утыр,— диде.— Йөгәненне дә биленә бәйләмә, кулыңа гына

тот, бүгеннән башлап жирән кашка синең юлдашың булсын, мин әле синең турыда башкачарак уйлый идем,— дип өстәде һәм тагы кеткелдәп куйды.

Камай бөтенесен дә аңлап алган иде инде. Ул елмая-елмая атыннан төште, аны тышаулады да, йөгәнен салдырып алып, үз иркенә, башка атлар арасына жибәрде. Аннары тарантаска Заһидулла агай янына менеп утырды. Ул инде аның алдында үзен бик кыю тота һәм теләсә нинди сорауга әчке бер дөреслек белән, ягъни бер нәрсәне дә яшермичә жавап бирергә дә һәм теләсә нинди темага сүз ачарга да хәзер иде. Аның шундый хәлдә булуын гүяки аңлаган кебек, Заһидулла агай, атның дилбегәсен бушата төште дә, сорап куйды:

— Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр иген урдырасың, кайбер көннәрне егерме бишәр гектарга житкереп, норманны йөз илле проценттан да арттырыбрак үтисең. Төннәрен Чишмәле авылына да барып киләсең. Кайчан йоклыйсың соң син, ничек армыйсың?

Камай озак уйланып тормады:

— Аның проценты да, нормасы да, йөгәне дә, тимер чыбыгы да, Галимәсе дә, йокысы да, аруы да, армавы да — бөтенесе дә бергә инде, Заһидулла абзый, шуннан үзең аңларсың,— диде.— Бүген утыз гектар бодай урдырырга чамалап кайтам әле, валлаһи менә, күрерсең, абзыкаем,— дип өстәп тә куйды.

— Булыр, булыр, монысына да ышанам, егет кеше үз сүзендә нык тора ул,— диде Заһидулла агай, куанып. Аннары күңеленнән үзе белән үзе сөйләшеп, эченнән генә мәгълүм бер фикергә килде: «Әйе, кеше турында начар уйлаудан һәр даим сакланырга кирәк. Хикмәт менә нәрсәдә, бөтенесенең дә бергә булуында икән шул, ә! Моны син, Заһидулла, исеңдә бик нык тот. Юкса, кайчакта син бер яклы гына уйлыйсың. Алай ярамый...»

Бу вакытта инде алар авылга якынлашып киләләр иде.

## Гамил Афзал

# Нишләдең син, Пушкин?

Шанхайда хунвэйбиннар Пушкин һәйкәлен җимерделәр.

(Газеталардан)

Якты хисләреннән ялкын алып,
Кызыл гөлләр үсте күп булып.
Мәскәү күкләрендә ак болыт ла,
Шанхай күкләрендә күк болыт.

Күтәрелде төтен уңда, сулда,
Урамнарда утлар яналар.
Егерменче гасыр уртасында
Хунвэйбиннар китап ягалар.

Син бу җирдә изге кунак идең,
Килгән идең шигъри юл белән.
Таш күзеңнән яшең чәчрәп чыкты,
Маңгаеңа суккач лом белән.

Еладың син: бигрәк явыз иде,
Ачы иде Дантес пулясе,
Мәтәшагыйрь Мао кулыннан да
Үләсе бар икән, үләсе!

Кояш булып күккә менгән идең,
Йолдыз булып телдән төшмәдең.
Дус дигәнгә ышанып килгән идең,
Нишләдең син, Пушкин, нишләдең?

Дөнья сөяр, горур җырлар булсын,
Вакыт юар тарих тапларын.
Кара көнелләргә харам булсын,
Вәйран булып яткан ташларың!

●

Фәлсәфәне ничек кенә боргалама,
Берәр генә өч нәрсә бар бу дөньяда,
Иң кадерле,
иң мөкатдәс,
иң изге зат:
Туган илең,
туган телең,
туган ана.

●

Мең төрле
Мәкерле киртәләр.
Болытлы, томанлы иртәләр.
Чырайсыз йөзләргә кул селтәп,
Даһилар дөньядан китәләр.

Таң ата,
Офыклар аллана.
Болытлар чайкала елгада.
Җир йөзен кочарга ашкынып,
Даһилар туалар дөньяга.

## Тукай турында уйланганда

Халык көткән,
заман көткән якты йолдыз
Рәхмәт белән балкып чыкса ил күгендә,
Үн килмешәк өрә-өрә чабып йөри
Шул йолдызны тизрәк өреп сүндерергә.

●

Рәхәт булып калды бу күңелдә.
Ал бизәге итеп бу чорның,
Нәни китабымны ил күгенә
Ак күгәрчен итеп очырдым шул.
Ак күгәрчен итеп очырдым.
Тыныч булып калды бу күңелдә...

●

Суык җилләр кискән язмышымда
Зәңгәр күзле яшьлек ялгышым,
Төрле уйлар туган бу башымның
Таратасың җилгә кайгысын.
Мин елмаям сиңа еллар үткәч,
Айлы кичләремне сагынсам.
Ялгышмагач яшьлек — төче күмәч,
Их, тагын бер шулай ялгышсам!

●

Якты уйларымның иң яктысын
Якты йолдыз итеп яндырам,
Кайнар яшьләремнең иң ачысын
Кара җиргә сибеп калдырам.

Ил иңендә кызыл гөлләр үссен,
Яктылыкка, нурга үрелсен.
Ачы яшьләр ачы җиргә сеңсен,
Гөл азыгы булып күмелсен!

## Рәшит Гәрәй

### Кайгырма диләр дуслар

Кайгылы чакларым була,
Кайгырма диләр дуслар.
Кайгы хәтта кош канатын
Каера диләр дуслар.

Мин бит очар кош түгелмен,
Җир — минем яратканым.
Шул җиргә сыенып яшәсәм,
Каерылмас канатларым.

Имәннәрне киссәләр дә,
Тамыры киселмидер.
Кайгы кичермәгән кеше
Шатлык та кичермидер.

### Урман аша уза поездлар

Җырлар дисәң, монда ул җырларның
Кайсы кирәк җанга — шунысы бар.
Урман аша узган поездларның
Гудоклары никтер моңсулар.

Бүген бигрәк шулай... Юлчыларның
Сагынулары әллә көчлеме?
Шул сагынулар, кушылып бер-берсенә,
Гудокларга әллә күчтеме?

Сөйгән ярым китте... Хушлашуы
Гудокларга кушылып ишетелде.
...Вагоннарга утырып, каеннар да
Мине ташлап китте шикелле.

### Чишмәләрдә тәңкә чыңы

Чишмәләргә кемнәр көмеш тәңкә
Сибеп киткән икән таңнарда?..
Яннарына туктап тыңлап торам:
Тәңкә чыңын ишетәм аларда.

Чулпылары шунда калган мәллә
Су алырга килгән кызларның?
Ат эчереп кайткан егетләрнең
Күрәм никтер моңсу узганын.

Алар күңелендәге моңнар белән
Чыңлый мәллә яшел болыннар?
Чишмәләргә илткән сукмакларда
Үземнең дә яшьлек моңым бар.

## Ап-ак бәхет булып

Бу яшьлек соң кеше гомерендә
Кемгә килеп, кемнән китмәгән!
Без үпмәгәнмени егет чакта
Уттай янып торган битләрдән!

Без йөрмәгәнмени болыннарда
Ак чәчәкләр кадап түшләргә.
Шул чәчәкләр ап-ак бәхет булып
Кирә инде хәзер төшләргә.

Яшьлек хисем, ахры, чәчәкләргә
Бөтенләйгә калган үрелеп.
Ялган хисләр генә иртә сүнә,
Чын мәхәббәт була гомерлек.

## Зиратына килдем...

Карлыганнар белән сыйлый иде
Ул карт безне исән чагында.
«Килүегез өчен рәхмәт» диеп,
Кала иде бакча янында.

Дуслар хаты аша ишеттем мин
Аның инде дөнья куйганын...
Бакчасына түгел, менә бүген
Зиратына килдем мин аның.

Ул һаман да шулай көлә-көлә
Басып тора кебек каршымда.
«Килүегез өчен рәхмәт» диеп,
Язган аның кабер ташына.

## Әй, кайда син, яшьлек...

Биек-биек таулар кичәр идем,
Булсаң әгәр таулар артында.
Әй, кайда син, яшьлек... җавап кайтар...
— Якында мин, бик-бик якында.

Йөгәненнән тотып алыр идем,
Килсәң әгәр җитез чапкында.
Әй, кайда син, яшьлек... хәбәрең бир...
— Якында мин, бик-бик якында.

Кояш булып күктә янар идем,
Тунсаң әгәр зәһәр салкында.
Әй, кайда син, яшьлек...
— Мин бит синең
Йөрәгеңдә янган ялкында.

## Истәлеккә калган каурыйлар

Кыр казлары инде киткәннәр дә,
Көз җиткәнен сизми калганмын.
Кыйгак-кыйгак дигән тавышлары
Ишетелми инде аларның.

Сер сакламас җилләр күл өстеннән
Дулкыннарны ярга каулыйлар.
Камышларга моңын сөйли кебек
Истәлеккә калган каурыйлар.

## Мәхмүт Хөсәен

### Сонетлар

●

Бик инсафлы гомер иткәндә,
Җитмешенче җәйгә җиткәндә,
Сөйде-куйды бабаң берәүне...
«Күрче, диләр, бу карт юләрне!..»

«Юк, бәйләнмәс сезнең чәч,— диләр,—
Син бит шәфәкъ, ә ул — янар таң!
Син бик олы, ул бик яшь,— диләр,—
Хәтәр ут ул! Курык аңардан!..»

«Юк! — дигән карт.— Утка ургылам:
Я көл булып очам җилләргә!..
Я, кабынып, үзем нур булам
Һәм юл ерам текә үрләргә!..»

Мәхәббәт — ут. Сөймә курыксаң.
Юк, китерми курку зурлык, дан.

●

Сиңа урын — йөрәк түреннән!
Син — тормышта алтын тәхетем,
Төнне куып көнел уреннән,
Таң бөркүче тере бәхетем.

Башка төшкән бәла-казаның
Төеннәрен бергә чиштең син.
Сикәлтәле юллар газабын
Бергә татып, бергә кичтең син.

Мәхәббәттән ярсып шашканда,
Дәваладың бәгырь ярасын...
Кояшларга, күккә ашканда,
Канат булды кайнар карашың.

Кайнар караш ташны эретә,
Вулканнарны, сүнсә, терелтә!

●

*М. Садрига*

Сабый чагың охшаш Тукайга:
Утка-суга яшьли төшкәнсең.
Башыңнан ук юлның шулай да
Давылларны кыю кичкәнсең.

Нигезенне завод ныгыткан,
Хезмәтне жыр иткән эшче син.
Походта һәм утта чыныккан
Корчагиннар рухлы кеше син.

Актан чәчәк ата күңелең.
Ә ак — дошман һәрчак карага!
Сафлык багы — бөтен гомерең.
Син — чал бөркет безнең арада.

Жырлар тузмый, йөрәк тузса да,
Ерган юллар ерак узса да.

●

Яшь дигәнең йөзгә житсә дә,
Көйри жанда яшәү күмере.
Колачын киң жәеп үтсә дә,
Хәйран кыска кеше гомере.

Бер башында, янып-ялтырап,
Йолдызларга яшьлек үрелә.
Бер башында анын, калтырап,
Тезен чүккән картлык күренә.

Яшәмибез мәңге нишләп, әй?
Синең, гомер, бик тиз агышың...
Таудан бәреп чыккан чишмәдәй,
Чылтырамый ник гел тавышың?

Яшен ташы чатнап өлгерми,
Юк та була гомер — күренми.

●

Жырлар яздың, диләр, күп кенә.
«Ә юк, дуслар, бу бик аз»,— димен.
Чирәм алар, яшел чүп кенә...
Әле алда күкрәр яз»,— димен.

Яз дип янам, таңдай кабынып!
Кайчак куям ләкин абынып...
Ялгышлардан тизрәк арынып,
Алга очам, канат кагынып.

Түбәсенә үрлим кыяның,
Теш-тырнагым белән ябышып.
Ямен, тәмен тоеп дөньяның,
Заман белән яшим ярышып.

Йөрәк янар дөрләп — сүнгәнче!
Үр менәрмен юлда — үлгәнче!

1968.

## Марс Шабаев

### Кашкарыйлар сары...

Кашкарыйлар шундый сап-сары...

Сары сагышларга атладым,
Арадан бер акны тапмадым.

Нигә үсми икән аклары? —
Сары ялкыннарга уралган да,
Янып тора ишек аллары.

Сөйләделәр: Саттар бакчачының
Төсе яшь, диеп, шуларда.
Төсне төскә кушып, ул сарыны
Үзе тапкан, үзе чыгарган.

Саттар разведчикны хәтерләтеп,
Кашкарыйның сары таҗында
Сары патрон тулы диск ята —
Атлый Саттар кырык биш яшында.

Саттар шул яшыннан кайтмаган...
Ул калдырып киткән матурлыкны
Кашкарыйлар һаман саклаган.

Барлаганда хәрби сафларны
Исәпләгез аны, Саттарны.

Кашкарыйлар шундый сап-сары...

### ...Ра-ра-о-ом!

Ык буе. Үсмер чак.
Болыннан кайтабыз.
Аргы як — таулы як:
— ...ра-ра-о-ом...—
Янгырый кайтаваз.

Кайтаваз илерә:
— ...ра-ра-о-ом...
Юк паром.
— ...ра-ра-о-ом...
Буыннар йомшаган —
Эт булып аруым.

Тан яна кабынган,
Йокылы, чиклы җир.
— ...ра-ра-о-ом...—
Паромчы
Куышта йоклыйдыр.

Белми дә ул синен
Дөньяда барлыгын.
— ...ра-ра-о-ом!
— ра-ра-о-ом!! —
Бетәсен карлыгып.

...Олыгайдым, ир булдым.
Ык түгел арада —
Яшьлекне:
— ...ра-ра-о-ом...—
Чакырып карарга...

— ..ра-ра-о-ом!
Паромчы
Чыкмаса чыкмасын;
— ра-ра-о-ом! —
Паромчы
Йокласа йокласын.

Янгыра, кайтаваз:
— ...ра-ра-о-ом...
— ...ра-ра-о-ом...
Кайтарчы, кайтаваз,
Үсмер чак аруын.
— ...ра-ра-о-о-о-о-ом!

## Соңлый язган тәүбә

Кояш таплы, ай таплы дип,
Җырлауларым житәрлек.
Юләрлек —
Кояшларның һәм айларның
Булмый исен китәреп.

Сон булса да — уң булсын дип,
Тәүбә иттем: җырламам
Яңадан...
Мәнге бетмәс таплар булмас,
Бетәр әле берзаман.

Күккә карасаң — күк биек...
Җәйрәп ята Җир-анам —
Кызганам.
Җир тапларын юар өчен
Җиңнәремне сызганам!

## Чыршы урыны—урманда

«Яшел чыршы, балкып торчы...» —
Яңа елда җыр шулмы?
Булмә түрендә куябыз
Шаулап торган чыршыны.
Ә урманда иптәшләре
Шаулыйлардыр һаман да.
Бәйрәм, мәҗлес...
Шау чыршыдан
Елап чәер тамганда,
Көлешәбез.
Шампан ургый
Фәлән ел хөрмәтенә.
Яшел чыршы, балкып торчы —
Егыла күрмә генә...
Бәйрәм үтә, шәмнәр сүнә,
Уенчыклар җыела.
Пеләшләнә яшел чыршы,
Кипкән ылыс коела.
Булды чыршы өй түрендә,
Булды һәркем телендә.
Сәгать сукты — көне бетте,
Урыны койма төбендә...
Хәзердән үк килә минем,
Зар елап, баш орасым:
Фәлән еллыгым көнендә
Булмасын утырасым
Якты залларның түрендә,
Тагып дан мишурасын.
Чәере тамар чакларда
Дан нигә чыршыга соң?!

II ◆ II

## Мөхәммәт Садыйков

### Балыкчы карт

Елгаларда балык беткәндә дә
Китмәс, ахры, елга ярыннан.
Су читендә үскән камышларның
Моңы таныш сабый чагыннан.

Эштән кайткач китә яр буена,
Яр буеннан китә эшенә.
Канат җилпеп йөзгән шук балыклар
Йөдәтәләр кереп төшенә.

Язын, җәен, көзен яр буенда,
Кышын боз өстендә — толыптан.
Калкавычлар чирткәнен көтеп,
Бар хәсрәтен, гамен оныткан.

Үлгәндә дә чирткән калкавычлар
Күренерләр аның күзенә.
Сабырлыгын гына мирас итеп
Алып калыр идем үземә.

●

Җөне буе зәңгәр күктә йөзеп
Җәйге кояш арый.
Үләннәрнең чәчен тарый-тарый
Ул офыкка барый.

Кич утырып кызлар чигү чигә,
Матур чәчәк кайый.
Тәрәзәдән өйгә әллә егет,
Әллә аймы карый?

Шомырт чәчәк аткан бакчаларда
Сандугачлар сайрый.
Таң алдыннан, картлар йоклаганда,
Күрешергә ярый...

## Юлда

Вокзал. Эшелоннар. Йөкләр
Төялгән: «Не кантовать!»
Поездлар чаба, поездлар
Көнчыгыш якка карап.
Кученеп бара төньякка
Чияләр, алмагачлар.
Уйлыйлар бугай: «Гомергә
Ят жиргә китә башлар».
Биләүдәге сабый сыман
Уянган үсентеләр.
Бөре бәбәкләре аша
Офыкны күзәтәләр.
Җил аша сораулар биреп,
Пышылдыйлар колакка:
«Тамыр жәеп яфрак яру
Читендер ят туфракта?»
Ә мин түбәсе урманлы
Тауларга карап торам.
Пышылдыйм алмагачларга:
«Үзем дә сезнең сыман».
Яшәве рәхәттер дә бит
Туган-үскән туфракта,
Анда да жимеш үссен дип,
Күчерәләр төньякка.
Хыяллар-идеаллар белән
Төньякка күченәбез.
Туган жирнең жылылыгын
Без анда күчерәбез.

## Юлдагы уйланулар

Эчәр суым, ашар ризыкларым
Туган жирдә әллә беткәнме?!
Нигә туган жирдән аердың дип,
Мин жилләргә сөйлим үпкәмне.

Мин, мөгаен, әле кирәк кадәр
Кайгы, шатлык суын эчмәгән.
Азмы монда мин сулыйсы һава,
Мин эчәсе салкын чишмәләр.

Азмы әле мин ашыйсы ризык,
Мин татыйсы татлы тәгамнәр?!
Төрле таулар түбәсеннән чыгып,
Кояш мине азмы сәламләр.

Мин кояштан нурны, жирдән дымны
Үземә кирәк кадәр алмаган.
Шуңа, ахры, өлгермичә йөрим
Салкыннарга түзем алмадай.

## Нәҗип Мадъяров

●

Аерылабыз туган-үскән җирдән;
Болыннардан, урман, кырлардан.
Тик аерылып булмый туган җирне
Яратудан, сагынып уйлаудан.

●

Ялгыз гына карап йөргән чакта
Борма-борма инеш буйларын,
Тукталдым да, үзен күрми генә,
Көтүченең моңын тыңладым.

Гомеремдә күпме көй ишетеп,
Күпме генә ләззәт алмадым!
Тик тугайның иң шәп җыр сәхнәсе
Икәнлеген яңа аңладым.

●

Балкый офык таң нурлары белән,
Өметләнеп карый кеше аңа.
Гүя бәхете уянасын күреп
Елмая ул йөзен куеп таңга.

Яңа офык кичке шәфәкъ белән,
Моңсуланып күзли аны кеше.
Әйтерсең лә, аңа килеп җиткән
Көтеп алган бәхетенең киче.

●

Язгы ташкын шавы сагындырды,
Өянкеләр җыры сагындырды.
Җәйге кичкә күңеллелек биргән
Бакаларның хоры сагындырды.

Туган җирем синең күкрәгеңдә
Гамьсез генә күпме гомер үткән!
Чит җирләрдә белдем, ул авазлар
Кайда да бер төсле түгел икән.

●

Җитсен, дидем, шау-шулы яз,
Ул да җитте.
Ташкыннарын йөрәгемнән
Агызып үтте.

Тынды сулар, үз хәленә
Кайтты инеш.
Ә күңелдә ташкын тын[illegible]й,
Мин — шул килеш.

◆ ◆ ◆

# ФРОНТКА ДА, ФРОНТТАН ДА

*Ватаныбыз сугыш күкрәүләре астында, ут һәм дәһшәт эчендә яшәгәндә, Бөек Октябрь революциясе казанышларын яклап калыр өчен илбасар фашистларга каршы зур көрәш барган елларда, башкалар кебек үк, татар язучыларының да бик күбесе, кулларына корал тотып, алгы сафларда сугыштылар. Шул авыр шартларда язучыларның үзара язышуларында әдәбият турында кайгырту, яну, рухлану, әдәбият һәм сәнгатьне үстерү турында борчылу, уйланулар чагыла. Бу хатлар, күптән язылуларына карамастан, бүген дә искермәгәннәр, заманча яңгырыйлар. Алар истәлекле хатлар булarak та безнең өчен кадерле. Бу санда без фронттан һәм фронтка язылган, әлегә кадәр матбугатта чыкмаган хатлар урнаштырабыз.*

## Әхмәт Фәйзинең Салих Батталга язган шигъри хаты[1]

САЛИХ ДУС!

Бездә чиллә... Сыра эчәсе
Төшеп бирәр салкын подвалга,
Без эчмәдек, эссе кабинетта
Хат язарга калдык Батталга.

Эссе, малай! Йөрәк һәм ми кайный,
Күңел әллә нишли, чукынчык,
Син болай ит, Салих: безнең өчен
Тын океанда бер кат чумып чык.

Бездә чиллә, ләкин йөрәк, акыл
Түзәрие шиксез аңарга,
Юк, бөтенләй башка кайгы белән
Туры килде бүген янарга.

Син беләсең, без бит һәркайсыбыз
Үзебезчә аерым яшьнәдек,
Әмма безнең күкрәү бергә булды,
Без бер күкрәү булып яшәдек.

---

[1] Сугышның Көнбатышта инде зур корбаннар бәрабәренә җиңү белән тәмамланган, ә Көнчыгышта әле башланмаган вакыты. Әхмәт Фәйзи татар совет шагыйрьләренең күбесе сугыштан кайтмавына әрни һәм бу хәл аны исәннәре турында кайгыртуга өнди.

Хатны «Мин» дип түгел, «Без» дип башлаганда тагын үзе белән кемне истә тотып язгандыр? — анысы билгесез.

С. Б.

Нишләдек без? Эшләдекме? Нәрсә?
Каерылып карыйм артыма;
Бар дияргә йөрәк базмаса да,
Юк дияргә йөрәк тартына.

Юк, эш анда түгел, сугыш дигән
Нәләт суккан камыт кидек бит,
Булмасае менә шул мәшәкать,
Эзгә төшеп килә идек бит.

Таралыштык... беребез уңга китте,
Беребез сулга: бөек таралу!
«Дан приказ ему на запад,
Ей в другую сторону».

Сабый гына Муса... Тик ул безнең
Көйле сүзнең бик зур ире бит,
Кем уйлаган элек, ул «Моабит»
Төрмәсендә гомерен бирер дип?

Фатихны ал... Нинди егет иде!
Җиде тапкыр җиңгәч үлемне,
Сугыш бетте дип торганда гына
Чит җир туфрагына күмелде.

Әйе... йөрәк сыкрый, күңел әрни,
Бүген көннең яме, коты юк,
Иң кирәктә, әйе, тансык чакта
Кинәт менә шагыйрь Кутуй юк.

. . . . . . . . . . .

Ярар җитте, әйдә эшкә күчик,
Долой җылау, мәлҗү һәм изрәү,
Һәм, кыскасы, безгә син бик кирәк,
Кайт әле, кайт монда син тизрәк.

ӘХМӘТ ФӘЙЗИ.
11 июль, 1945 ел, Казан.

# Шәрәф Мөдәрриснең Нури Арслановка язган хатлары

## ТУГАНКАЙ НУРЫЙ!

Идрис Туктарның акыллы бер сүзен хәтереңә төшерәм: «Җил шәмне сүндерә, ә ялкынны көчәйтә». Әйдә шулай булсын, аның шулай булуы яхшы да.

Нурый! Мин никадәр шат, дустым. Синең хакта, синең сугышчан юлың һәм атаклы «Зоя»ң хакында миңа томанлы гына хәбәрләр килгәләде, ә мин кызу һәм өлешчә псих бер егет, синең соңгы уңышларың белән котырына-котырына шатландым. Сиңа рәхмәт әйтәсем килә, чын патриот, саф, олы хисле шагыйрь булуың өчен рәхмәт әйтәсем килә.

Ян, туганкай, ялкын булып, үс гөл булып! Син сугыш төтенен суладың, ә сугыш ялкынын чәч. Ничектер җылы хисләр язасым килә, я ярый, дус, үзең аңла инде. Мин кичә төнлә алгы сызыктан кайттым, бүген тагын китәм. Фикерләрем таркау, үзең дә сизәсең булса кирәк.

Сәхәптән хат алдым. Яратам мин ул беркатлы, эчкерсез егетне. Тик иҗат өчен аңа мөмкинлек кенә юк.

Ә башкалар... язмыйлар, язсалар да бик сирәк.

Мин хәзер «Полководец» дигән, аһәңле, югары пафослы зур бер әйбер эшлим. Син укырсың, үзеңә җибәрермен.

Нурый! Син шигырьләреңнең күбесен безгә җибәр. Безгә ул бик кирәк. Бәлки «Зоя»ны җибәрерсең. Һичшиксез, басылачак. Җибәр, Нурый. Әле Казанда кайчан басыла ул!

Туганкай, хәзергә гафу ит. Менә полкка барып җитим, анда, аулак блиндажда, сукыр лампа яктысында озынрак хат язармын. Минем туган авылым — Чүпрәле районы, Каракитә авылы. Чүпрәлегә барсаң — күз сал.

Сәлам белән: Шәрәф.

1943.

## ДУСТЫМ НУРЫЙ!

Менә сиңа газета җибәрәм. «Мәхәббәт хаты»н бастык. Киләчәк номерларның берсендә «Тантана»ны да бирәбез. Тагын җибәреп тор. Безгә шигырьләр бик кирәк. Йотып кына торабыз. Ләкин бездә гонорар дигән нәрсәнең исе дә юк.

Барысына да сәлам. Һәм сиңа үзеңә кайнар вә кайнар сәлам белән: Шәрәф.

Октябрь. 1943.

## НУРЫЙ ДУСКАЙ!

Сәлам сиңа. Сагындым, шайтан алгырысы, үзегезне. Бөтенләй башка җирдә — Ватан сугышының иң кызу, иң шөһрәтле урынында эшкә башладык. Иске урын ерак төньякта калды. Хәзер Болгар хакындагы дастанны эшләп бетерәм. Синең дә тизрәк эшләвеңне телим.

Безгә хат һәм әйберләр җибәр. Сиңа кабат сәлам белән: Шәрәф.

Февраль. 1944.

## Александр Фадеев

# ПОЛК КОМАНДИРЫ

*Авыр һәм дәһшәтле 43 ел... Ленинград тирәсендә каты сугышлар бара. Шундый көннәрнең берсендә оборона тотучы солдатлар янына бер төркем рус язучылары килеп чыга. Араларында Александр Фадеев та була. Мәшһүр рус язучысы төрле подразделениеләрдә йөри, офицерлар һәм солдатлар тормышы белән таныша. Ахырдан, шунда алган тәэсирләренә нигезләнеп, «Полк командиры» исемле очерк яза.*

*Үзенең әлеге очеркында Александр Фадеев зур ихтирам, тирән хөрмәт һәм бары аңа гына хас күзәтүчәнлек белән татар халкы, шул халыкның бер улы — майор Мостафин[1] хакында яза.*

*Очерк башта «Огонек» журналының 1943 елгы 17 санында басылган. «Ленинград блокада көннәрендә» исемле җыентыгын матбугатка әзерләгәндә (ул китап 1944 елда басылып чыга), Фадеев, күрәсең, бу әсәре турында кабат уйлана һәм журнал вариантына соңгы ике абзацны өсти.*

*Кайбер биографик мәгълүматлар. Әхмәт Төхфәт улы Мостафин 1905 елда Оренбург өлкәсенең Шарлык районы Яңа Муса авылында туа. Башта берничә ел Оренбург татар халык мәгарифе институтында, соңыннан Казан җир төзелеше техникумында укый. Техникумны тәмамлагач, Баулыда җир төзүче булып эшли, шуннан армия сафларына алына. Әүвәл кече командирлар мәктәбен, аннары Мәскәүдә Фрунзе исемендәге хәрби академияне тәмамлый. Фин сугышына катнаша, беренче көннәрдән үк диярлек Бөек Ватан сугышына китә. Ленинград янындагы иң кыен участокларның берсендә 3 елга якын вакыт полк белән командалык итә, сугышчан заданиеләрне уңышлы башкарып чыкканы өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә. Бераз соңрак аны дивизия штабына начальник итеп күчерәләр. 1943 елның 26 сентябрендә һәлак була.*

***Очерк татар телендә беренче тапкыр басыла.***

***РЕДАКЦИЯ***

Без, бер төркем язучылар, фронтка, майор Мостафин полкына килеп чыктык. Ул үзе әле яңа гына алгы сызыктан кайтып кергән иде, итекләре тузанга батып беткән. Без блиндаж янында басып тора идек, мин командирны күздән кичердем. Аның өс-башы, хәрбиләрнекеннән бигрәк, тыныч хезмәт кешесенекенә тартым. Гомумән, игътибарны җәлеп итәрлек берние дә күренми. Тыйнак, акыллы кешеләрдә була торган кыяфәт. Кара кучкыл йөз, кыска гына итеп кыркылган кара мыек, хәрәкәтләре табигый, сабыр, төгәл. Кулына каяндыр урманнан кисеп алган таяк тоткан. Ул таяк аңа Суворовка охшарга тырышу өчен түгел, ә бәлки, урман эчендә йөргәндә, чәчәк һәм үләннәрнең башларын кыеп бару өчен кирәктер, күрәсең, шулай йөргәндә уйларга җиңелрәк.

Ул безне блиндажына чакырды. Үзе шунда ук щетка алып итекләрен чистартырга чыгып китте. Моңарчы күргән башка нәрсәләр кебек үк, аның бу эше дә нигәдер миңа бик ошады.

Майор Мостафинның блиндажы гаҗәеп дәрәҗәдә аның үзенә охшаган иде. Чиста итеп җыештырылган, әмма алай искитәрлек байлык һәм купшылык юк диярлек: кәгазь чүлмәкләргә утыртылган кәгазь чәчәкләр дә, стеналарга элене торган мөгезләр һәм трофей кораллар да, командирлар блиндажын бизи торган башка әйберләр дә

---

[1] Әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның әтисе.

күренми. Аның һәр нәрсәсе үз тәртибе белән куелган, һәм бiредәге бөтен әйбер бу блиндаж хуҗасы өчен сугыш барыннан да элек хезмәтнең бер төре дип әйтеп тора кебек. Аның блиндажында эш кешесе, хәрби хезмәткәр обстановкасы иде.

Майор Мостафинның хәрби академия тәмамлавын, фин сугышына һәм беренче көннәрдән үк бу сугышка катнашуын без белә идек инде. Фронттагы иң авыр участокларның берсендә ул полк белән командалык итә. Һәм, алгы сызыктан өзлексез ишетелеп торган мылтык һәм пулемет тавышларына карап, биредә һәрвакыт эш кызу икәнлеген чамаларга мөмкин.

Безнең сорауларга ул кыска һәм төгәл итеп җавап биреп барды. Аның полкындагы солдат һәм командирларның байтагы хәрби тормыш юлларын сугышның беренче көннәреннән үк башлаган кешеләр икән. Командирларның мәгълүм бер өлеше фин кампаниясенә үк катнашкан булган. Әмма солдатларның зур күпчелеге әле яңа килүчеләр икән.

— Безгә үз частегызның аеруча атаклы сугышчылары, геройлары хакында сөйләсәгез икән.

— Геройларыбыз бар,— диде ул,— тик сан ягыннан башка частьлардагыдан артык булмас.

— Шулай да.

Майор Мостафин берничә кешенең фамилиясен атады һәм кыскача гына алар башкарган эшләр белән таныштырды.

— Ә тагын? — дип сорадык.

— Тагын безнең искиткеч гыйбрәтле язмышлы пулеметчыбыз бар,— дип башлады ул буйсынган кыяфәттә, әйтерсең, ул турыда бер генә тапкыр сөйләмәгән һәм бу аны инде туйдырып үк бетергән иде. Тик күреп тора: тыңларга бик теләүчеләр булгач, тагын бер тапкыр кабатларга туры киләчәк.— Ул хатын госпитальдә эшли иде, болай, үз ирке белән ялланып. Бервакыт иренең фронтта үлүе турында хәбәр алды. Шуннан, госпитальдәге төп эшен башкару белән бергә, пулеметтан атарга өйрәнә башлады, һәм, пулеметны тәмам өйрәнеп җитүен аңлагач, фронтка җибәрүләрен сорарга кереште. Хатын-кыз бит, башта җибәрергә теләмәделәр, ләкин бәрыбер үз дигәнен итте, хәзер менә коралын белүе буенча булсын, төз ату һәм батырлык буенча булсын, полктагы иң яхшы пулеметчылардан санала.

— Ни исемле соң ул?

— Әллә Китти, әллә Кэт шунда; сугышчылар Катя дип кенә йөртәләр.

— Күрергә мөмкинме аны?

— Мөмкинен мөмкин, әлбәттә, ләкин аны алгы сызыктан чакыртып алу, ничектер, килешми, ә сезгә...— дигәч, ул сүзеннән туктап калды.

— Без, әлбәттә, бик шатланып, үзебез аның янына барыр идек.

— Алай икән, мөмкин. Тик аңа кадәр мин сезгә бездәге һәр батальон каршында оештырылган курсларны күрсәтергә теләгән идем; ул курсларда без иң чыдам, тәртипле һәм тәҗрибәле сугышчыларны укытабыз, кече командирлар итмәкче булабыз үзләрен.

Төшке аш вакыты иде, рота поварлары һәм аларның ярдәмчеләре батальон кухняларының берсеннән алгы сызыктагы сугышчылар өчен чиләк-чиләк аш һәм ботка алалар. Ашы итле, ә ботка тары ярмасыннан пешерелгән, солдатлар аны «блондинка» дип йөртәләр һәм, нигәдер «брюнетка» дип атамыйча, күбрәк «безнең строевой» яки «кадровой» дип йөртә торган карабодай боткасына караганда, әзрәк яраталар, шулай да «блондинка» тамак туйдырырга җитәрлек иде. Мин, ни өчендер, майор Мостафин полкына килгәндә күргән мунчаны искә төшердем. Мускуллары беленеп торган кызгылт тәнле, йөз, муен һәм куллары кояшта янган сугышчылар, туйганчы чабынганнан соңдыр инде, күрәсең, яңа каен себеркеләре белән әле һаман бер-берсенә сыдыра-сыдыра һәм күңелле шаулаша-көлешә блиндаж мунчадан һавага йөгерешеп чыгалар иде.

Миңа шунысы ошады: юлда безгә очраган солдат һәм командирлар майор Мостафин алдында артык калтырап төшмәделәр, ләкин аларның Мостафинга мөнәсәбәтләрендә артык туарылу кебек нәрсә дә сизелми иде. Монда нәрсәдер эшчеләр белән мастерларның цех башлыгына мөнәсәбәтләренә охшаш иде; белемле булуына ышангандa, цех башлыгын да шулай хөрмәт итәләр һәм аңа да буйсыналар бит.

Без килгән батальон урманлы җиргә урнашкан иде; батальон икенче эшелонда тора икән. Курсантларның өйрәнүләрен тукгатып тордылар, һәм шуннан соң без алар белән әңгәмә уздырдык. Сугышчылар арасында русча начар белә торган татарлар байтак икән, майор Мостафин үзе татар, шуңа ул сугышчыларның сорауларын һәм безнең җавапларны тәрҗемә итеп барды.

Рус солдатлары арасыннан пар коңгыздай елтыр кара күзле бер яшь кеше аеруча күп сорау бирде. Ул кәтмәгәндә каяндыр солдатлар артыннан килеп чыга да пулеметтан аткандай тотына тезәргә:

— Көньяк Африкадагы нинди ил Германиягә каршы сугыш игълан итүдән баш тарткан?

— Гитлерның нефть запасы күпме?

— Иранданиләр бар?

Аның барлык сораулары халыкара хәлләргә кагылышлы иде. Кайчан ул безнең җавапларны аңлап та бетерми, андый вакытта кабатлап сорый, җавапларның кайберләре, күрәсең, аны канәгатьләндереп җиткерми булса кирәк, тик ул обстановканы бәхәсләшер өчен уңай санамый иде шикелле.

Мин батальон командирыннан:

— Кем ул? — дип сорадым.

— Калинин өлкәсенең бер колхозыннан килгән комсомолец, агитаторлыкка укый.

— Кайда укый соң ул?

— Һәр җирдә, һәркемнән, һәрнәрсәдән: бөтен кешедән сораша, газеталар, китаплар укый. Менә дигән сугышчы. Ерак китәчәк.

— Ярар, хәзер Катяны күрергә вакыт, — дидек без.

— Өлгерербез, башта ашап алырга кирәк, — диде Мостафин.

Һәм менә без яңадан Мостафин блиндажында. Хәзер мин сезгә җиткерергә теләгән сүзләр Мостафин тарафыннан эзлекле бер чыгыш төсендә сөйләнмәде, ә бәлки безнең күп санлы сорауларыбыз һәм аның җаваплары нәтиҗәсендә туды. Майор Мостафинның сугышта алып барган күзәтүләре менә нәрсәгә кайтып кала:

— Безнең сугышчыларыбыз — бик шәп кешеләр, әле яңа гына килгәннәре дә менә дигәннәр. Аларны фронтта күп нәрсәгә өйрәтергә мөмкин. Беләсезме, аларны нәрсәгә өйрәтүе кыен? Күп техника катнашкан хәзерге сугыштагы хәрби хәрәкәтләрне реаль күзалларга өйрәтүе кыен. Сугышчы алгы сызыкта утыра, дошманның алгы сызыгын күрә. Ул ата, дошман да ата. Кайчак аны миналар һәм снарядлар борчый, кайчак бер яисә ике-өч самолет бомба ташлыйлар яки, ныклы артиллерия әзерлегеннән соң, дүрт-биш танк артыннан ияреп килүче дошман подразделениесе аны позициясеннән бәреп чыгарырга тырышып карый. Кайчак ул — сугышчы — үзе һөҗүм операцияләрендә катнаша, ут астында окопларга бәреп керә, штыгын эшкә куша, кыскасы, һөҗүм вакытында башкалар ни кичерсә, шуны кичерә. Ул инде байтак яралы кешеләр һәм мәетләр күргән, үзе дә үтергән, шуннан соң ул барысын да күрдем, барысын да беләм, дип уйлый башлый. Әгәр аннан: «Дошман синең участогыңа бәреп керергә омтыла, син ничек хәрәкәт итәрсең?» — дип сорасаң, ул: «Күрмәгән нәрсә түгел... Алар, значит, безнең өскә килә икән, без, значит, аларны дөмбәсләячәкбез», — дип җавап кайтарачак. Ләкин аңа әнә шуны ачык итеп күз алдына китерүе бик кыен. Нәкъ аның участогына артиллерия утының бөтен көче яуганда, бөтен бер авиация берләшмәләре аның өстенә йөзләрчә һәм меңнәрчә бомба ташлаганда һәм уннарча, йөзләрчә танк ыргылганда, аларның күбесе искиткеч геройлыклар күрсәтәчәк, тик кайберләре генә башта югалып калыр. Нәкъ менә шунда инде кече командирлар һәм куәтле техника сугышына катнашучы тәҗрибәле солдатлар алдына төп бурыч куела: алар бөтен кешене үз тирәләренә тупларга һәм командалык итәргә, тик, башкалар өчен сугышып, беренче минутларда ук үлеп бетмәскә тиешләр. Бездә шәхси батырлык үрнәкләре бик күп, әмма әгәр ул батырлар үз бурычларын барыннан да элек башкаларны үз тирәләренә туплауда, көн саен аларны үз тәҗрибәләренә өйрәтүдә һәм кыен минутта, бөтен кеше өчен сугышмыйча, алар белән командалык итүдә күрмәсәләр, коры батырлык кына җитмәячәк. Кече командирларны һәм алдынгы сугышчыларны шулай тәрбияләргә кирәк ки, алар үзләрен җитәкчеләр һәм укытучылар итеп тә сизсеннәр, кирәк чакта, кырыс начальниклар да итеп аңласыннар. Чыдамлы булу — дисциплиналы булу ул. Сезнең берегез миннән ни өчен курсларга болай да

күпне белүче тәҗрибәле сугышчыларны җыясыз, ә яңа килгәннәрне түгел? — дип сорады. Чөнки әлеге тәҗрибәле сугышчылардан без бүгенге сугышка яраклы командирлар тәрбиялибез. Ә яңа килгәннәрне исә әлеге кадрлар ярдәмендә сугышның үзендә тәрбияләргә кирәк. Сез миңа геройлар хакында сораштыгыз. Миңа калса, частьның даны, башкалар арасында торган чын урыны геройлар һәм ул геройлар башкарган батырлыклар саны белән генә билгеләнми, ул бөтен часть бергәләп үтәгән чын сугышчан эшләр белән билгеләнә.

— Ә шулай да Катяны күрсәтегез инде,— дидек без соңыннан, көлешә-көлешә.

— Катянымы? — Майор Мостафин елмаеп куйды.— Хәзер, мөгаен, соңдыр инде, караңгы төшкәнче кайтып җитә алмабыз.

Бу күрә торып алдашу иде.

— Сез гафу итегез инде,— диде майор, кызара төшеп,— ләкин без аның янына үтә алмабыз. Аның янына эләгү өчен, сазлыклы ачык урыннан узарга кирәк. Без анда траншея казый алмадык: су баса, урыны да утка тотыла. Без, ни дисәң дә, хәрби бурыч кушканга йөрибез, ә сезгә... ходай күрсәтмәсен, ул-бу булса, үзегез дә җәл, аннары сезнең өчен җавап та бир.

Дөресен әйтергә кирәк, иң яшебез кырыкта булган, күбебез кимендә ике, ә кайберләребез хәтта дүртәр сугышка катнашкан таза ирләргә мондый сүзләрне ишетеп тору уңайсыз булды. Нәкъ шул минутта Катяның кайдадыр сугышып йөрүен белеп тору хәлне тагын да кыенлаштыра иде.

— Аңа ярый, ә безгә юк,— дидек без, көнелсез генә.

— Ул бит солдат,— диде Мостафин, тыныч кына.

Кичен, Мостафин яныннан үз блиндажыбызга кайткач, Катя хакында күп гәпләштек, күп уйлаштык. Нинди икән ул? Фронтка нинди хисләр белән килде икән? Әгәр ире өчен үч алу теләге китергән булса, ул хакта әле дә хәтерлиме икән, әллә, фронт тормышына ияләшкәч, әлеге хис тоныклана төштеме икән? Әлбәттә, һәммәбезгә бер нәрсә ачык: ул гадәти генә хатын булмаска тиеш. Аны күрә алмый калуыбызга тагын бер кат үкенештек. Ахырдан арабыздан беребез әйтте:

— Аның каравы тагын да мөһимрәк һәм кызыклырагын күрдек.

— Нәрсә соң ул?

— Без майор Мостафинны күрдек. Ул, әле батальон белән командалык иткән чакта ук, дошман фронтының аеруча ныгытылган бер участогында елга аша чыгып, аның ерак тылына үтеп керә, авыр яралы булуына карамастан, шунда ныгып кала. һәм шул батырлыгы белән дан алган кеше.

Бүген, әлеге сөйләшүдән соң байтак вакыт узгач, майор Мостафин хакында тагын берничә сүз әйтәсе килә.

Безнең зур батырлык күрсәткән һәм күрсәтеп килүче геройларыбыз бик күп. тарихта тиңе булмаган ул гаҗәеп батырлык үрнәкләре хаклы рәвештә безнең халкыбызны куандыра. Әгәр майор Мостафин полкында күргән һәм ишеткән нәрсәләрдән безне Катя Брауде вакыйгасы үзенә күбрәк тарткан икән, монда гаҗәпләнерлек берни дә юк. Безнең илдә аның кебек гүзәл һәм батыр хатыннар, кызлар байтак, алар һәрчак безне сокландырып торалар. Үзе башкарган һәм башкарачак гүзәл эшләр өчен безнең армия, барыннан да бигрәк, Мостафин кебек кешеләргә, характер һәм холыкларын безнең армия тәрбияләгән, гади солдаттан алып иң югары комсоставка кадәрге гүзәл кешеләргә бурычлы. Безнең Кызыл Армия менә шул һәртөрле кыланулардан азат булган, гади, тыйнак, акыллы кешеләр — нык ихтыярлы, үз эшләрен тирән белүче, башкаларны тәрбияли белүче кешеләр, кешеләрне җитәкләүче кешеләр җилкәсендә тора, шуларның ярдәме белән ул җиңеп чыгачак.

## М. Новигатский

# КУТУЙ КАТУКОВ ТАНКИСТЛАРЫ АРАСЫНДА

*Истәлекләрдән өзек*

...Мин аның белән 1945 елның 14 гыйнварена каршы төндә, Висла елгасының аргы ягындагы плацдармда очраштым. Машина фараларын бик аз гына вакытка яктыртып алган чакларда танклар, туплар, сугыш кирәк-яраклары тутырылган ящиклар, блиндажлар һәм сугышчылар күзгә чалынып китә иде. Беренче Белорус фронты гаскәрләре Познань һәм Берлин шәһәрләре юнәлешендә һөҗүмгә күчү өчен әзерлек алып баралар, артподготовка башлануын көтәләр иде. Корреспондент буларак, сугышчылар арасында йөри торгач, бер блиндажда ут яктысы күреп алдым мин. Ишегә урынына корылган плащпалатканы ачып, блиндажга кердем. Зур электр лампочкасы эленгәнлектән, блиндаж эче күзләрне чагылдырырлык дәрәҗәдә якты иде. Үзем дә белмәстән, Катуков танкистлары янына килеп эләккәнмен. Полковник И. И. Гусаков командалык итә торган 44 нче гвардия бригадасы штабы урнашкан блиндаж булып чыкты бу. Блиндаж өстәленә рация куелган. Ә аның янында бригада штабы начальнигы подполковник А. И. Воробьев басып тора иде.

— Оборона Халык Комиссариатының «Красная звезда» газетасы корреспонденты,— дип доклад ясадым мин Воробьевка.

— Иртәрәк килгәнсез икән, артподготовка башланырга әле өч сәгать вакыт бар. Аңарчы фронт матбугаты вәкилләре белән танышып торыгыз,— диде ул һәм блиндаж сәкесендә утыручы кешегә ымлады.

Ак якалы кыска тун кигән урта буйлы кеше, урыныннан кубып, өстәл янына килде дә:

— Кутуй, Беренче Белорус фронты газетасы сотруднигы,— дип, кул биреп күреште. Аннары кинәт күңеллеләнеп китеп, малайларча шуклык белән кулын бүрегенә тидереп, честь бирде.

— Мине Кутуй дип яисә исемем белән Гадел дип кенә атагыз,— диде ул, яныма утырып. Аның йөзе дустанә елмаю белән балкый, чак кына кысылган күзләрендә кешегә ышаныч һәм кызыксыну чагыла иде. Аягындагы киез итеге, өстендәге окоп тузаны кунган сырган чалбары, бил каешына тагылган трофей маузер, иңенә аскан иске кыр сумкасы — барысы да аның сугышның ачысын-төчесен инде җитәрлек татыган фронтовик икәнлеген әйтеп тора. Ул төндә без Кутуй белән шактый озак гәпләшеп утырдык. Ул миңа үзенең тормышы, иҗаты, кайчан һәм ничек фронтка китүе турында сөйләде.

...Көз бәйләнеп бара торган вакыт. Акрын гына ябалак кар явып тора иде. Шул чакны Катуков гвардиячеләре Лодзь, Познань юнәлешенә — Одер һәм Шпрее ярларына дошман оборонасын өзү өчен һөҗүмгә ыргылдылар. Без да алга киттек. Элек дошман оборонасы булган урында безнең артиллерия утыннан актарылып ташланган траншеялар, ватык минометлар, туплар, автомашиналар, үлгән немец гәүдәләре күренеп кала.

— Урман эченәрәк кергән саен, утын күбәя бара,— диде Кутуй, шуларга карап.— Шушы һөҗүм алдыннан ясалган артиллерия әзерлегә өчен ике миллионнан артыграк

снаряд китерелгән булган. Армиянең политбүлек начальнигы генерал Журавлевтан ишеттем.

Без, Катуков армиясе политбүлеге работниклары белән бергәләп, танкистларның алдынгы отряды артыннан бара башладык.

— Без хәзер 1914 елның көзендә Варшава — Лодзь операциясе вакытында рус солдатлары кайзер Вильгельм гаскәрләрен туздырган җирләр буйлап барабыз,— диде Гадел.— Равка, Базура, Пилица, Варта елгалары, Радом, Опатов, Скерневицы, Козеницы, Сохачев, Гура-Кальвария шәһәрләре инде беренче бөтендөнья сугышыннан ук безнең халыкка яхшы таныш.

— Шушындый үтә дә хәрби мәгълүматларны кайдан алдың син, Кутуй? — дидем мин, кызыксынып.

— Әле шушы көннәрдә генә «Беренче бөтендөнья сугышы» исемле китапны укып чыктым. Авторы Зайончковский, Польшадагы сугышлар турында бик әйбәт язган,— диде Гадел.

Ул көнне без дошманнан калган блиндажда кундык. Түбәсенә берничә рәт юан бүрәнә тезеп ясалган бик нык блиндаж иде ул. Стена буйларына сәкеләр дә эшләнгән. Ишек буендагы элгечләрдә немец шинельләре, каскалар эленеп тора. Бер почмагында шактый зур бәрәңге өеме. Миче дә, юынгычы да, пыялалы лампасы да бар. Стенадагы кадакларга табалар, кастрюльләр эленгән. Сәке астында бер чиләк су, шешәләр тезелеп тора.

— Кара ничек барысын да шәплән әзерләп куйганнар, шушында кыш уздырырга ниятләнгәннәр, күрәсең. Ләкин бик ашыгып чыгып сызарга туры килгән, ахрысы, шинельләрен кияргә дә өлгерә алмаганнар,— диде Гадел, блиндажны карап-тикшереп чыккач.

Иртән торгач, Гадел радиоалгычны көйләп җибәрде. Мәскәүдән Беренче Украина фронты гаскәрләренең Ченстохов, Краков шәһәрләрен азат итүен, Беренче Белорус фронты гаскәрләре дошман оборонасын өзеп, оператив иркенлек алганлыкларын тапшырып торган чак иде.

— Андый-мондый җирдә генә түгел, бәлки Берлин юнәлешендә оператив иркенлек алынган бит! Тыңлагыз әле, иптәшләр, тарихи хәл ләбаса бу! — диде Кутуй, бу хәбәргә чын күңеленнән куанып.

Ул көн җылы һәм кояшлы булды. Азат ителгән авылларны, хуторларны артта калдырып, без юлыбызны дәвам иттек. Без алга барабыз, ә җирле халык төрлесе төрле җирдән мал-туарларын җитәкләп йортларына кайта. Алар барысы да безне ачык йөз белән каршы алалар һәм:

— Виват, виват Советская Армия! — дип, куанышып озатып калалар.

Гадел дә бик шат иде. Аның әледән-әле машина әрҗәсеннән торып:

— Нех жив Польска республика! — дип, балаларча куанып полякларга кычкырып баруы бүген дә күз алдымда тора...

Шул көнне кич бер поляк өенә кереп, без үз газеталарыбызга мәкаләләр әзерли башладык. Тукталып, сугышчылар һәм командирлар белән сөйләшеп торырга вакыт булмаганлыктан, минем блокнотым бөтенләй буш иде. Миңа Гадел ярдәм итте — клеенка тышлы калын дәфтәрен бирде ул миңа. Икенче көнне иртүк «Красная звезда» газетасына хәрби телеграф аша тапшырган герой танкист, легендар Җамбулның оныгы турындагы очеркым Гаделнең шул дәфтәрендәге материаллардан файдаланып язылды.

— Рәхмәт, дустым, бик зур ярдәм иттең миңа! — дидем Гаделгә.

— Рәхмәт әйтеп торырлык эш юк монда,— диде Гадел,— кызарып-оялып китеп.— Мин бу фронтта куптәннән эшлим бит инде, ә сез әле яңа кеше. Үзең үлсәң үл, әмма иптәшеңне коткар дип әйткән бит Суворов. Һәркайда үзара ярдәм итешеп яшәргә кирәк.

...Бервакыт без Ново-Място шәһәрендә Гадел белән армия элемтә бүлегенә бардык. Чираттагы мәкаләләребезне редакциягә җибәрергә кирәк иде. Элемтә бүлеге начальнигы офицер Захаров безнең үтенечебезне тыңлады да дежур торучыга материалларыбызны чиратсыз гына тапшырырга боерды. Әмма шул чакта кинәт якында гына атышу башланды. Аннары элемтә бүлегендә сакта торучы сакчы йөгереп керде дә:

— Немецлар килә! — дип кычкырды.

— Барыгыз да коралларыгызны алыгыз! — дип боерды элемтә бүлегенең сак начальнигы капитан Шитковский. Элемтәчеләр, шул чакта шәһәрдән үтеп баручы укчы полк сугышчылары белән бергәләп, Гадел дә дошманга каршы сугыша башлады. Ә эш менә болай булган икән: чолганышта калган гитлерчылар, җиде бронетранспортерга утырып, качып китмәкче булганнар да ялгыш шәһәргә килеп кергәннәр һәм атыша башлаганнар. Ләкин дошманның бу отрядын безнекеләр бик тиз туздырып ташлады. Шул бәрелештән соң Гадел яңадан элемтә бүлегенә килде. Маңгаеннан дары сөременнән каралган тир тамчылары тамып торса да, ул үзе бик шат һәм ярсыган иде. Мәкаләләребезне тапшыргач, ул миңа әлеге бәрелеш турында бик рәхәтләнеп, көлә-көлә сөйләп бирде.

...Без Познаньнан төньяк-көнчыгыштарак урнашкан бер авылга килеп җиткәндә, армия штабы сакчылары чолганыштан качып баручы гитлерчыларга каршы сугышалар иде. Ә авыл мәктәбендә поляк кызлары һәм егетләре үзләренең милли гимннары — «Еще Польша не сгинела»ны («Польша үлми»не) җырлыйлар. Гадел алар белән бик тиз уртак тел табып, сөйләшеп китте. Әлеге яшь-җилкенчәкләрне немецлар Познаньга траншеялар казырга алып китмәкче булып җыйганнар икән. Әмма, бәхетләренә каршы, Катуков танкистлары килеп җитеп, аларны коткарып калган. Хәзер алар үз авылларына кайтырга машина көтеп утыралар.

Гаделнең кешеләр белән шул чаклы тиз аралаша алуына исем китте минем. Менә бу авылга килеп туктавыбызга күп булса ярты сәгать вакыт үткәндер, ә ул инде поляк яшьләренең фашистлар оккупациясе вакытында нинди шартларда яшәүләрен дә, хәзерге уйларын да, киләчәккә планнарын да сораштырып белергә өлгерде. Бер бүген генә түгел, гомумән, шулай өлгер һәм җитез ул. Беркайчан да аптырап, каушап калмый. Солдатлар белән дә, офицерлар һәм генераллар белән дә хәзер сөйләшеп, танышып китә. Курәсең, шагыйрь һәм язучы булгангадыр, теләсә кемнең күңелен бик тиз яулап ала ул.

Хәрби корреспондент буларак, Гаделнең тагын бер бик әйбәт сыйфаты бар: бик җитез ул һәм күп санлы вакыйгаларның нәкъ менә бүгенге көн өчен кирәклесен тотып ала. Тырыш һәм тәвәккәл. Тотынса, беркайчан да үз дигәнен итмичә калмый. Бервакыт шулай бер танк корпусына бардык без. Корпусның штаб начальнигы полковник Воронченко белән сөйләшеп, кайбер мәгълүматлар алырга ниятләгән идек. Полковникның эше бик тыгыз иде булса кирәк — сөйләшергә теләмәде.

— Дислокацияне үзгәртергә боерык килде, соңрак сөйләшербез, — диде.

Әмма Гадел аптырап калмады.

— Биш кенә минут, биш кенә минут кирәк безгә! Фронт һәм үзәк матбугат хезмәткәрләре өчен ничек тә биш минут вакыт табарсыз инде! — диде. Ул моны шундый итеп үтенде — полковник, никадәр җитди булырга тырышса да, көлеп җибәрмичә булдыра алмады. Аннары:

— Ярый, яхшы, ышандырдыгыз, ләкин, карагыз аны, биш кенә минут сөйләшә алам, — дип ризалык бирде һәм тәрәзә янына килде дә:

— Әнә, карагыз әле шушыннан күренгән кырга, — дип, үзе дә сизмәстән сөйләп китте. — Гади генә кыр түгел ул. Әле күптән түгел генә бик кызу сугыш булып үтте анда. Моннан бер сәгать элек әнә теге күренеп тора торган урманнан сугышчан тәртипкә тезелеп, гитлерчыларның бер зур группасы килеп чыкты да безнең штаб урнашкан шушы авылга һөҗүмгә ташланды. Фашистларның көче зур, бер полктан артыграк кеше иде алар. Ә безнең нибары өч бронетранспортерыбыз да ике танкыбыз гына бар. Кыскасы, хәл кыен безнең. Әмма, шулай булса да, дошман атакасын кире кактык, ә сугыш кыры, газетчылар теле белән әйтсәк, дошман гәүдәләре белән тулып калды.

— Безгә шул урыннарны карарга рөхсәт итегез әле? — диде Гадел, кинәт балаларча дәртләнеп китеп. — Бик кызык хәл бит: корпус штабы дошман атакасын кире каккан. Шул урыннарны үз күзебез белән күреп кайтсак — менә диген әйбәт мәкалә булачак бит, шедевр!

Гаделнең чын күңеленнән канатланып әйтелгән шушы сүзләреннән соң полковник Воронченко, биш минут турында бөтенләй онытып, тиз генә бронетранспортер чакыртты һәм, консультант булып, үзе дә безнең белән бергә утырып сугыш кырына барды.

Сөйләшә торгач, без аның белән бөтенләй танышып киттек. Полковник үзе дә язгалый торган кеше, әле шушы көннәрдә генә «Танкист» журналында мәкаләсе дә басылып чыккан икән.

Без сугыш булган урынга килеп җиткәндә, ак флаг күтәреп, урманнан немец парламентерлары килеп чыкты.

— Әле генә булып үткән сугышта җиңүчеләргә бирелергә киләләр,— диде Гадел, шаярып штаб начальнигына мөрәҗәгать итеп.

— Капут, капут, плен! — диде парламентерларның башлыгы, безнең машина янына килеп җиткәч.

— Коралларыгызны ташлагыз да, сафка тезелеп, авылга барыгыз! — диде аларга штаб начальнигы.

— Яволь, яволь[1],— диешеп, әсирләр баш кагып калды.

Бераздан ике мең чамасы кешедән торган дошман колоннасы урманнан чыкты да авыл ягына юнәлде.

Без әйләнеп кайтканда, машинага төяп, әсир ителгән утызлап немец генералларын һәм офицерларын алып килгәннәр иде. Аларны күргәч, Гадел бик куанды һәм:

— Дошманның шушылай күпләп әсир ителүе бик кызык хәл, газета өчен әйбәт материал бу! — диде.

...Бик матур көн иде ул. Юл буйларындагы кар эреп, күләвекләр барлыкка килгән. Февраль башы гына булуга карамастан, кояш та шактый нык кыздыра. Җылы, рәхәт. Алдан сөйләшү буенча, без Гадел белән Вормсфельде дигән бер авылда очраштык. Беренче гвардия танк армиясе командующие генерал Михаил Ефимович Катуков янына барып, үзебезгә кирәкле кайбер нәрсәләр хакында сөйләшергә тиеш идек.

Без килгәндә командарм үзендә — өч урындык, агач өстәл һәм поход кровате куелган җыйнак кына бүлмәдә — утыра иде. Кереп исәнләшү белән үк, Гадел аңардан безне берәр төрле транспорт белән тәэмин итүен үтенде.

— Һөҗүм вакытында танкистлардан артта калырга ярамый безгә. Геройлар турында язу өчен, аларның батырлыкларын үз күзең белән күрергә кирәк! — диде ул.

Катуков каршы килмәде. Портфеленнән бер бит кәгазь алды да корпус командиры Бабаджанянга язу язып бирде: «Корреспондентларга машина бирүегезне һәм аларны кирәкле документлар белән тәэмин итүегезне үтенәм», диелгән иде анда.

Без командармга рәхмәт әйттек тә берничә сорау бирергә рөхсәт сорадык.

— Рәхим итегез,— диде Катуков.

— Армиянең Висладан алып Одерга кадәр кызу темп белән уңышлы һөҗүм итеп килүе сәбәбе нәрсәдә, иптәш командующий! — диде Гадел.

Командарм бу уңышка разведканың һәм элемтәнең яхшы оештырылган булуы, танкистларның корал һәм ягулык белән тиешенчә тәэмин ителүе, гаскәрнең барлык төрләре дә үзара ярдәмләшеп эш итүе, көнен дә, төнен дә тынгылык бирмичә, дошманны кысрыклап-куып бару аркасында ирешелүен әйтте.

...1945 елның марты, көн кичкә авышып бара. Ландсберг шәһәреннән көнбатыштарак урнашкан бер авылдагы өйнең икенче катында Гадел бик мавыгып офицерлар белән әдәбият, сәнгать турында сөйләшеп тора иде. Шунда кайсыдыр аның үз иҗаты турында сөйләвен үтенеп сорау бирде. Әмма Гадел язган әсәрләре турында сөйләмәде. Язачак әсәрләре турында әйтте.

— Сугыштан соң,— диде ул,— «Тапшырылмаган хатлар»ның икенче китабын язарга, «Рөстәм маҗаралары»н томамларга уйлыйм. Аннары Бөек Ватан сугышы турында бер повесть язмакчы булам. Аның өчен материал җитәрлек. Яшь буынга сугыш батырларын, һәр совет кешесе ил каршында, халык каршында, тарихның үзе каршында имтихан биргән авыр сугыш елларын сурәтләп күрсәтергә кирәк.

Ул көнге әңгәмә ярты төнгәчә сузылды.

— Нигәдер кәеф китебрәк тора әле,— диде Гадел, ятарга җыена башлагач.— Температурам да күтәрелде. Иртәгә редакциягә кайтмакчы булам...

Икенче көнне без Гадел белән әлеге авыл урамында аның юл уңаена баручы машина көтеп тордык. Авыру булуына карамастан, күңеле көр иде аның. Һаман шулай, гадәтенчә, шаярып, көлеп сөйләште. Редакциягә кайтырга дип, машинага менеп утыргач та елмаеп хушлашты һәм кул болгап китеп барды.

[1] Хәзер, хәзер!

Мин бу аерылышуыбыз соңгы аерылу булыр дип һич тә башыма китермәгән идем. Әмма, кызганычка каршы, без бүтән күрешә алмадык. Суык тиюдән башланган шул авыруыннан терелә алмыйча, Гадел Кутуй, инде дошманны җиңгәч, 1945 елның 16 июнендә, хәрби госпитальдә вафат булган.

Ләкин әдәби әсәрләре белән дә, солдат буларак та илгә турылыклы хезмәт иткән Гадел Кутуйның китаплары бар. Шул китаплары белән мәңләгән укучылар күңелендә хәзер дә яши ул. Аның исеме легендар Муса Җәлил исеме белән рәттән тора.

# КУТУЙНЫ САГЫНАМ

Сугыш алды елларында Гадел Кутуй Мәскәүгә шактый еш килгәләде. Бер килүендә ул башкаланың татар эшчеләре клубында үзенең «Тапшырылмаган хатлар» исемле повесте буенча үткәрелгән укучылар конференциясендә катнашты. Әсәргә карата төрле фикерләр әйтелде: мактаучылар да күп булды, яманлаучылар да табылды. «Тапшырылмаган хатлар» минем үземә бик нык ошаган иде. Шунлыктан мин дә дәшми кала алмадым: сүз алып, трибунага чыктым һәм повестьны мактап сөйләдем. Минем фикерне залда утыручылар да хупладылар булса кирәк, сөйләп бетергәч, гөр килеп кул чаптылар.

Мин трибунадан төшкәч, яныма, күңелле елмаеп, Гадел Кутуй килде.

— Әллә апам, әллә җиңгәм буласызмы: фамилияләребез дә бер төрле, уйларыбыз да бер үк икән! — диде ул.

Шунда без беразсөйләшеп утырдык. Гадел үзе иҗат иткән Галия образын үзе дә бик яратуын әйтте.

Кутуй белән икенче тапкыр Мәскәүдәге татар мәктәбендә очраштык. Ул бу юлы үзе генә түгел, шагыйрь Нур Баян белән килгән иде. Без, татар укытучылары, дәресләр беткәч, укытучылар бүлмәсендә генә өстәл әзерләп, аларны чәйгә дәштек. Шунда күңелле генә сөйләшеп утырдык. Сүзебез күбрәк әдәбият һәм сәнгать турында барды. Аннары Гадел Кутуй да, Нур Баян да үзләренең шигырьләрен укыдылар. Кутуй аеруча шат иде, үзен, күптәнге дуслары янындагыча, бик иркен тотып шаярып-көлеп утырды.

Ә өченче очрашуыбыз очраклы һәм бик ашыгыч кына булды. Кутуй хәрби киемнән һәм трамвайда бик җитди кыяфәттә бара иде. Танышып күрешкәч, мин аннан:

— Кая баруың болай? — дип сорадым.

— Фронтка, хәбәрче булып,— дип, кыска гына итеп җавап бирде ул. Аннары Кутуй, минем белән хушлашты да, трамвайдан төшеп китте. Мин дә аңа хәерле сәфәр теләп, дошманны җиңеп, исән йөреп, сау кайтуын теләп калдым.

Еллар үтте. Дошман җиңелде. Ләкин Гадел Кутуй туган илгә әйләнеп кайта алмады.

Әмма, үзе булмаса да, мәңге онытылмаслык әйбәт әсәрләре калды. Ул әсәрләрне укып, мәңләгән китап яратучылар Кутуйны зур хөрмәт белән искә алалар. Шул күп санлы укучыларның берсе буларак, мин дә яраткан язучым Гадел Кутуйны бик еш сагынып искә алам. Әгәр исән-сау әйләнеп кайткан булса, ул әле тагын бик күп әйбәт әсәрләр язып безне куандырыр иде, дим.

Җае чыкканда үземне борчыган бер нәрсәне әйтеп үтмичә булдыра алмыйм. Сүз соңгы елларда Ватан сугышында һәлак булган Гадел Кутуй, Нур Баян, Фатих Кәрим кебек талантлы язучыларыбызның ничектер игътибардан читтә кала башлавы турында бара. Сугыштан кайтмаган урта кул язучылар турында әйткән дә юк инде, хәтта Абдулла Алишны да тиешенчә күтәреп чыга алганнары юк әле әдәбият белгечләренең. Теләгем шул: сугышта вафат булган язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез иҗаты да исән язучылар һәм әдәбият белгечләре игътибарыннан читтә калмасын, ул язучыларның үз әсәрләре дә, алар иҗатын тикшерүгә багышланган мәкаләләр һәм башка төрле материаллар да газета-журнал битләрендә әледән-әле басылып барсын иде!

**М. КУТУЕВА,** пенсиядәге укытучы.

Рафаэль Мостафин

# БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ

*Яшьләр прозасы хакында уйланулар*

**БЕРЕНЧЕ МӘКАЛӘ**

## Һава хәлләре турында берничә сүз

Радиодан һава хәлләрен тыңлаганда, без, Казан кешеләре, гадәттә, үзебездә нинди көннәр буласын белү белән генә чикләнмибез, Мәскәүдәге һавалар белән дә кызыксынабыз. Чөнки беләбез: әгәр башкалада кинәт салкынайтып җибәрә икән, ике-өч көннән салкыннар безгә дә килеп җитәчәк. Анда яңгырлар башланган булса, безгә дә плащ һәм зонтларны барлый торырга вакыт.

Әдәби һаваларның торышы белән дә шул ук хәл диярлек. Бездәге әдәби һавалар да күп очракта башкаладагыга карап йөри. Тик бу очракта инде вакыт аермасы көннәр белән генә түгел, ә еллар белән исәпләнә. Хәтерлисездер, бер заман Мәскәүнең яшь шагыйрьләре арасында, традицион ритмика һәм үлчәүләрдән баш тартып, хисләр ассоциациясенә корылган ак шигырь белән мавыгу башланган иде. Ике-өч елдан шул ук мода безгә дә килеп җитте. Тагын күпмедер вакыт узгач, әдәби геройларны юри ваклау, чынбарлыкның кимчелекле һәм кара яклары белән мавыгу тенденциясе көчәеп китте. Һәм бу чир дә безне читләтеп узмады. Мәскәүдә бу хактагы шау-шулар, бәхәсләр басылып, мәсьәләгә тулы аныклык кертелгәнгә дә байтак инде. Бездә исә әле булса бик үк фәнни һәм дөрес булмаган карашлар очраштыргалап тора. Шуңа күрә әдәби герой һәм чынбарлык, аларның бер-берсенә мөнәсәбәте кебек мәсьәләләргә яңадан әйләнеп кайтырга туры килә.

Гадәттә һәртөрле яңа карашлар һәм яңа фикерләр яшь язучыларга тизрәк йогучан була. Бу аңлашыла да. Өлкән буын әдипләрнең тормышка карашлары күптән формалашып, тәмам утырып җиткән була, алар бер сайлаган позицияләрендә ныграк торучан, әдәби зәвык, әдәби кыйбла кебек мәсьәләләрдә дә шактый таләпчән һәм тотрыклы булалар (дөрес, бу тора-бара рухи торгынлыкка да китерергә мөмкин). Яшьләр исә, ашкынып-йотлыгып дигәндәй, тормыштагы һәр яңалыкны сендерә баралар. Бу — яшьләр иҗатының көчле ягы. Әмма шуннан ук аларның көчсезлеге дә килеп чыга, чөнки һәр яңа нәрсә яхшы да булып бетмәгән кебек, һәр иске начар гына булмый. Уйламый-нитми төрле модалар артыннан куарга тырышу аркасында, безнең яшь язучылар төрле ялгыш адымнар да ясап ташлыйлар, еш кына бүгенге чынбарлыкны шактый берьяклы сурәтлиләр, ул да түгел, заман героен бозып күрсәтә башлыйлар. Бу бигрәк тә Ватан сугышы чорына багышланган әсәрләрдә ачык күренә.

Ватан сугышы темасына яшь прозаикларыбызның һәрберсе диярлек тукталып үткән. Н. Фәттахның «Артта калган юллар»ы һәм А. Гыйләҗевның «Берәү» повесте, Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повесте һәм М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары», В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар»ы... Зур кызыксыну белән каршы алынып, укучылар арасында төрле бәхәсләр, капма-каршы фикерләр уяткан бу әсәрләрнең барысы да соңгы 2—3 ел эчендә басылып чыкты. Аларның авторлары — 30 яшьтән 40 ка кадәрге кешеләр. Яшьләре ягыннан кайберләрен урта буын вәкилләре рәтенә дә кертергә булыр иде. Әмма аларның иң өлкәннәре дә, 1953—54 еллардан соң гына әдәбият мәйданына килеп, янарак, үзгәрәк иҗтимагый һәм иҗат шартларында формалашкан кешеләр, һәм аларның әсәрләрендә дә тормыштагы яңа җилләр тәэсире ачыграк күзгә ташлана.

Нәрсә, нинди сәбәпләр яшь прозаикларны шулай актив рәвештә Ватан сугышы темасына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр итә соң? Андый сәбәпләр, билгеле, күптер инде. Мин шуларның икесенә һәм барлык яшь прозаиклар өчен уртак дип уйланганнарына тукталмакчы булам.

Беренчедән, алар балалык дәверләре яки яшьлекләре каһәр төшкән сугыш елларына туры килгән буын вәкилләре. Балачак хатирәләре исә хәтердә аеруча озак һәм аеруча җанлы саклана торган була. Алар фронттагы вакыйгалар хакында язмыйлар диярлек, чөнки берсе дә ул вакыйгаларга үзе катнашмаган. Аларның төп темасы — сугыш елларындагы авыл тормышы.

Балачак хатирәләренең бер үзенчәлеге бар: никадәр генә тормышчан, җанлы күренмәсеннәр, алар еш кына берьяклы һәм алдаучан булалар. Гадәттә, бала тормышны читтән торып күзәтә. Күренешләрнең тышкы ягына ул зурларга караганда да көчлерәк һәм ныграк игътибар итә, аның саф, эчкерсез күңеле аз гына ялганны һәм кечкенә генә хаксызлыкны да тиз тоеп-сизеп ала. Әмма еш кына шул күренешләр хакында хөкем йөртергә, аларга бәя бирергә аның көче һәм тәҗрибәсе җитми. Балачак хатирәләренең шул үзенчәлеге яшь прозаикларның сугыш темасына багышланган әсәрләрендә дә шактый ачык сизелә.

Икенчедән, яшь прозаикларның яңа буыны Бөек Ватан сугышы елларындагы тормыш турында я ң а с ү з, ү з с ү з е н әйтергә тырыша. Аларның әсәрләрендә үз элгәреләре белән ачыктан-ачык яки шактый яшертен төстә бәхәскә керү сизелеп тора. Билгеле булганча, язучылар коры сүз белән генә бәхәсләшмиләр. Алар китаплары белән дә бәхәсләшәләр. Әнә шул бәхәскә без кинрәк тукталмакчы булабыз да.

## Заман дөреслеге һәм фактлар дөреслеге

Сугыш чоры турында, шул исәптән тыл эшчәннәре хакында да, аз язылмаган. Г. Бәшировның «Намус», М. Әмирнең «Саф күңел», Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» һәм «Газинур» романнарын, Г. Кутуй, И. Гази, А. Шамов, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Г. Галиев, А. Расих, Х. Госман һәм башка язучыларның хикәя-повестьларын гына искә төшерү дә җитә. Дөресен әйткәндә, өлкән буын татар прозаикларының һәрберсе диярлек тегеләйме-болаймы бу темага тукталып узган, аңа күпмедер өлеш керткән. Билгеле, әдәби эшләнешләре буенча да, тирәнлекләре ягыннан да Ватан сугышы чорына багышланган проза әсәрләренең төрлесе төрле дәрәҗәдә. Шуның белән бергә, ул әсәрләрнең күбесе өчен уртак кайбер гомуми сыйфатларны да аерып күрсәтергә мөмкин.

Өлкән буын язучыларыбыз вакыйгаларның кайнар эзләре буенча

барганнар. Аларның әсәрләре заман ихтыяжларына җавап рәвешендә туган, ирек һәм бәйсезлекләрен саклау өчен совет кешеләре алып барган көрәшкә алар китаплары белән катнашканнар. Сугыштан соң язылган күп кенә китапларда да шул изге көрәшнең кайнар сулышын тоярга мөмкин, аларга дәһшәтле сугышның кайнар шәүләсе төшкән. Шуңа да күбесенең гомуми пафосы — җиңеп чыккан халыкның героик характерын тудыруга юнәлтелгән.

Кагыйдә буларак, бу әсәрләрнең үзәгендә үзе эшләгән һәрнәрсә өчен җавап бирүдән курыкмый торган, җилкәсендә теләсә нинди авырлыкны күтәрергә әзер, нык ихтыярлы характер, ачык максатлы герой образы тора. Бу чор татар әдәбияты халкыбызның түземлелеген, характер һәм идея ныклыгын гәүдәләндергән үзенчәлекле, хәтердә калырлык образларның бөтен бер галереясе белән бай. Г. Бәшировның «Намус» романыннан Нәфисә, М. Әмирнең «Миңлекамал» драмасыннан Миңлекамал һәм «Саф күңел»еннән Сания кебек образларның яңалыгы, тарту көче һәм мөлаемлыгы бүген дә югалмаган, ихтимал, беркайчан да югалмас. Бу әсәрләрнең үзәгенә хатын-кыз образлары куелган икән, бу да, күрәсең, очраклы хәл түгелдер, чөнки сугыш елларында тыл тормышының бөтен авырлыгы хатын-кыз җилкәсенә төшә.

Ул чорда чыккан китаплар буенча халкыбызның характеры ни рәвешле чыныга һәм аның үз көченә ышанычы арта баруын, горурлык тойгысы көчәя төшүен күзәтергә мөмкин. Бу буын язучылар, күбрәк, масштаблы характерлар, героик образлар иҗат итү белән шөгыльләнгәннәр, гадәттән тыш вакыйгалар белән мавыкканнар (соңгысы Г. Әпсәләмов әсәрләрендә аеруча нык күзгә ташлана). Ләкин сугыш исәпсез-сансыз корбаннар, чиксез күп бәла-казалар чыганагы да иде бит әле. Ул халык хуҗалыгын какшатты, үзе белән кан һәм күз яшьләре, ачлык һәм газаплар алып килде. Әмма бернинди авырлыкларга да карамастан, халкыбыз бирешмәде, тез чүкмәде һәм чигенмәде. Совет кешеләре күрсәткән тарихи батырлыкның бөеклеге дә әнә шунда. Металлның ныклыгы утта сыналган кебек, кеше характерының ныклыгы ул кичергән газап-михнәтләр белән билгеләнә.

Әйе, болар һәммәсе дә дөрес. Шуның белән бергә кешенең характеры ул яшәгән шартларга да бәйле бит әле. Шартлар дөреслегенә хыянәт иттемне, бу шунда ук образларны, характерларны ярлыландырачак. Мәгълүм сәбәпләр аркасында, өлкән буын әдипләребез мәсьәләнең бу ягына һәрвакытта да тиешле игътибар биреп җиткерә алмадылар. Сугыш еллары турындагы күп кенә әсәрләрдә авыл халкы кургән кыенлык-авырлыклар кечерәйтеп күрсәтелде, үткен конфликтлар һәм тормыш каршылыклары шактый шомартылды, хыялда гына булган нәрсәләр чынбарлык төсендә сурәтләнде. Мондый төр кимчелекләрдән ул еллар әдәбиятының «Намус» романы шикелле хәтта иң яхшы үрнәкләре дә азат түгел иде. Шуңа күрә яшьләрнең сугыш чоры күренешләрен ничек тә тулыландырырга тырышулары, өлкән буын язучылар игътибарыннан читтәрәк калган әйберләр турында сөйләргә омтылулары — табигый һәм аңлашыла торган нәрсә.

Беренчеләрдән булып, бу эшкә прозабызның талантлы вәкиле Р. Төхфәтуллин алынды. Аның авыл тормышына багышланган хикәяләре, «Авылдашым Нәби», «Йолдызым» кебек үзенчәлекле һәм талантлы повестьлары 50 еллар ахыры, 60 еллар башы татар прозасы өчен куанычлы яңалык булды. Сугыш еллары авылын бөтен катлаулыгында сурәтләүче беренче татар прозаигы Р. Төхфәтуллин иде кебек. Шуның белән бергә, аның әсәрләре күңелдә авыр тәэсир дә калдырмый, авырлыкларны сурәтләү — аның өчен үзмаксат түгел. Ул сабыр һәм эшчән, тыйнак һәм тырыш, бай рухлы һәм юмарт күңелле гади кешеләрне күрә белә. Авыл тормышындагы реаль кыенлыкларны җиңү процессын-

да аларның характерлары ачыла, алар безнең алга тотып-капшап карыйсы килерлек дәрәҗәдә тере кешеләр булып килеп басалар.

Шушы әсәрләрендә үк башка күп яшьләргә хас бер характерлы үзенчәлек сизелеп тора. Әдәби әсәрләр язганда Төхфәтуллин үз тәҗрибәсенә, тормышта үзе күргәннәргә таяна. Бу аның әсәрләренең исемнәрендә үк күзгә ташлана («Авылым хикәяләре», «Авылдашым Нәби», «Йолдызым»...). Шул ук вакытта язучының шәхси тәҗрибәсе халык туплаган бай тәҗрибә белән каршылыкка да керми. Ул кечкенә детальләрдә зур мәгънә таба, күпчелек очракта конкрет, реаль прототиплары ук билгеле мәгълүм бер авыл кешеләре хакында сөйләсә дә, шулар аша бөтен халкыбызга хас типик сыйфатларны ачып сала. Р. Төхфәтуллин искиткеч индивидуаль һәм шул ук вакытта зур гомумиләштерү көченә ия образ иҗат итә белә. Бу инде зур нәрсә. Чөнки язучы хезмәтенең, әдәби осталыкның төп кыенлыгы да менә шунда бит.

Авыл тормышындагы авырлыклар һәм кыенлыклар хакында күпме генә сөйләмәсен, Р. Төхфәтуллин шул ук вакытта гомум тарихи перспективаны да күздән ычкындырмый. Без ул кыенлык һәм авырлыкларны н ә р с ә х а к ы н а кичерүебезне күрәбез, корбаннарның юкка гына бирелмәвенә, акрынлап булса да, тормышның даими рәвештә алга баруына, яхшыра баруына ышанабыз.

Кызганычка каршы, Төхфәтуллиннан соң сугыш елларындагы авыл хакында әсәр язучы кайбер авторларга еш кына шул п е р с п е к т и в а х и с е, а л г а к а р ы й б е л ү җитеп бетми. Аларга хәтле берәү дә күрмәгән, игътибар итмәгән факт һәм күренешләр турында сөйлибез дип, яшь прозаиклар вакыт-вакыт икенче читкә ташланалар, алсу төсләрдән качабыз дип, чамасыз күп күләмдә соры һәм кара буяулар кулланa башлыйлар. Шундый хәл Н. Фәттахның «Артта калган юллар» исемле зур күләмле хикәясендә (асылда аны повесть дип әйтергә була) аеруча ачык күзгә ташлана.

Автор Ватан сугышы елларындагы авыл хакында яңа сүз, үз сүзен әйтергә тели. Кем беләндер бәхәсләшергә, полемикага керергә теләү әсәрнең төп героен сайлаудан ук күренә. Әгәр Нәфисә — алдынгы бригадир, Миңлекамал — колхоз председателе, Сания — шәһәр Советы председателе, икенче төрле әйткәндә, алар барысы да билгеле бер мәгънәдә башкалардан өстен торган, абруйлы, билгән постлары белән үк мактаулы һәм хөрмәтле кешеләр булсалар, Н. Фәттах повестеның төп герое Хәмдия исә — иң гади бер колхозчы. Алай гына да түгел, ул качак, хезмәт фронтыннан качкан дезертир; шул чорның кырыс законнары буенча аны суд, төрмә көтә. Хәмдия качып-посып яшәргә, хәтта күршеләреннән дә яшеренергә мәҗбүр. Ул — төшенке рухлы, алданган татар кызы; җилдән тапкан баласы белән ялгызы калган, шуның өчен үзен коточкыч гаепле санап, оялып-кызарып яшәргә мәҗбүр ителгән мескен кеше.

Н. Фәттах җиңү таны яңа беленә генә башлаган, колхозларның һәм колхозчыларның соңгы запасларына хәтле беткән иң авыр, ач бер чорны — 1944 елның язын сайлый. Сер түгел, бу елларда авыл кешеләре арасында ачтан шешенеп үлүчеләр һәм, кырда калган ашлык ашап, агуланып үлүчеләр дә булгалады. Һәм Н. Фәттах бик җентекләп, объектив һәм гадел булырга тырышып, авылдагы иң ярлы гаиләнең иң кыен бер вакыттагы тормыш хәлен сурәтли. Күршеләренә ничек тә җиңелрәк, аларның, ичмасам, сыерлары бар. Хәмдияләрнең исә хәтта тавыгы да калмаган. Н. Фәттах җентекли-җентекли ач бала ничек елаганны сурәтли, «беркадәр бәрәңге, беркадәр он сыман нәрсә салып пешерелгән» аштан килгән буш һәм тәмсез ис турында озаклап яза, бер пот бәрәңге өчен өстәге сырманы сатарга туры килүе турында сөйли. Нәтиҗәдә шактый авыр һәм караңгы картина күз алдына баса.

хәтта әсәрнең бәхетле азагы да (ниһаять, Хәмдияне аңлаучы һәм яклаучы бер кеше очрый) ямьсез хисләрне йомшарта алмый.

Бу повестьның дөньяга чыгуын авторның батырлыгы дип караучылар да булды. Әйе, авыл хакында моңарчы берәүнең дә бу рәвешчә кыю язганы булмагандыр, ихтимал. Ләкин бу бер Нуриханның гына тәвәккәллеге түгел, бу бөтен җәмгыятьнең, тормышыбызда очраган кимчелекләрне ачарга, хакыйкатькә туры карарга көче һәм кыюлыгы житкән партиябезнең тәвәккәллеге иде. Татарстан язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редколлегиясенең шушы повестьны тикшерүгә багышланган утырышында Г. Бәширов әсәрне яклап чыкты һәм, кызып китептер инде, бәлки: «әгәр «Намус»ка бүген тотынсам, мин аны нәкъ шушы повестьча язар идем», дип әйтеп ташлады. Болар, билгеле, арттырыбрак әйтелгән сүзләр; үзенчәлекле, зур художник буларак, Г. Бәширов, һичшиксез, башкача, үзенчәрәк язар иде. Ул, күрәсең, чирек гасыр гомер узганнан соң, тормышның, теге яки бу сәбәпләр аркасында, вакытында игътибар биреп житкермәгән якларын да күрсәтер идем, дип әйтергә теләгәндер. Бу яктан караганда, «Артта калган юллар» — безнең әдәбиятның кыюлыгы артуы хакында сөйли торган факт. Кыен мәсьәләләргә жиңел җавап биреп котылырга теләгән әдәбият, чынбарлыкның нииндидер якларын юри читләтеп узарга тырышкан әдәбият, тормыш күренешләренә алсу күзлек аша гына карарга гадәтләнгән әдәбият, телиме-теләмиме, котылгысыз рәвештә вагаячак, түбәнгә тәгәрәячәк.

Әмма ни генә булмасын, Н. Фәттах повестенда тасвирланган күренешләр, автор уйлаганча ук, тулы дөреслек түгел, шуның бер кыры, бер өлеше генә әле. Әйе, сугыш елларында халкыбызга искиткеч кыенлыклар күрергә туры килде. Нурихан әсәрендә язылганнар, факт буларак, тормышта, чыннан да, очраган-күренгән нәрсәләр. Тик автор аларны ни өчен шулай куерта, нинди максат белән әсәренә кертә соң?.. Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым» повестеннан Гөлзифаны искә төшерегез. Аның тормышы да Хәмдиянекеннән әллә ни жиңел түгел, әмма Гөлзифа характерының иң гүзәл сыйфатлары нәкъ менә шул авыр шартларда ачыла да. Гөлзифа жиңел юллар эзләп йөрми һәм иң кыен елларда да тормышның гел болай тормаячагына тирән ышанып яши. Н. Фәттах әсәрендә исә кыенлыкларны сурәтләү үзмаксатка әйләнебрәк китә. «Авылда хәлләр менә ничек кыен иде, сугыш елларында кешеләр әнә нинди авырлыклар күрделәр, моңарчы алар хакында беркем дә язарга базмады» — повестьның буеннан-буена шундыйрак фикер уздырыла сыман. Нәкъ менә шуның аркасында Н. Фәттах әсәрендә без, фактлар дөреслеге белән очрашсак та, гасырның олы хакыйкатен күрмибез. Узган сугышта без ничек жиңә алганбыз, нәрсә, нинди көч халкыбызга шул барлык кыенлыкларны кичерергә һәм буй бөкмәскә ярдәм иткән? Н. Фәттах әсәре буенча бу сорауларга җавап табуы шактый кыен.

Билгеле, мәгълүм бер тарихи чор турында без һәр әсәрдән тулы хакыйкатьне, соңгы сүзне таләп итә алмыйбыз. Бу бөтен әдәби хәрәкәт өстенә йөкләнгән бурыч. Аерым очракларда язучы шактый таррак мәсьәләләр дә күтәрергә хаклы. Әмма шул чагында да ул зур дөреслекне онытмаска, индивидуаль, конкрет нәрсәләр артында бөтен тормышка хас сыйфатларны күрә белергә тиеш. Шуңа да ул язучы. Фикеремне ачыграк аңлату өчен, бер чагыштыру китерәм. М. Шолоховның «Кеше язмышы» хикәясендәге Владимир Соколов нинди генә кыенлыклар күрми. Әсирлек хурлыгын татый, концлагерьларда газап чигә, күп мәртәбәләр үлем белән йөзгә-йөз очраша, гаиләсен югалта... Тик шул хикәяне укыганда кеше рухының ныклыгы һәм бөеклеге өчен күңелдә куаныч һәм горурлык хисләре уяна. М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре»н укыганда да нәкъ шундый ук хисләр уяна. Ә Н. Фәттах әсәре исә,

барыннан да бигрәк, кызгану хисе уята. Чыннан да, әсәрнең төп герое көчсез һәм кызганыч бер кеше булып хәтердә кала.

Автор үз әсәрен изге нияттән чыгып язган бит, дип әйтүләре мөмкин. Сүз дә юк, әсәрдә гуманизм төшенчәсе, безнең заманга хас булганча, киңрәк мәгънәдә алына. Әгәр элегрәк аерым шәхес механизмның бер шөребе генә булып исәпләнсә, әгәр кайчандыр аерым шәхеснең теләк-омтылышлары, бөтен җәмгыять омтылышлары югарылыгыннан торып караганда, берни дә тормаса, без хәзер бу мәсьәләләр хакында башкачарак уйлыйбыз. Җәмгыятьнең яхшылыгы, гуманистик характеры һәр аерым кешенең, шул исәптән Хәмдия кебек гади кешеләрнең дә, никадәр мул һәм иркен, тыныч һәм рәхәт яши алуы белән билгеләнә. Социалистик гуманизм шәхси интересларның һәм иҗтимагый интересларның аерылмас бердәмлегеннән гыйбарәт. Кыскасы, ил кайгысы — ир кайгысы һәм, киресенчә, ир кайгысы — ил, бөтен җәмгыять кайгысы.

Н. Фәттах повестенда бер кеше — Хәмдия кайгысы бөтен ил кайгысы кебек яңгырый. Кызганычка каршы, автор шуның белән канәгатьләнә, бердәмлекнең икенче ягын — ил кайгысы ир кайгысы булырга тиешлеген күрсәтми. Гуманизм кешене җәлләү, аны пассив кызгану хисе генә түгел әле. Ул, барыннан да элек, тормышка актив мөнәсәбәт дигән сүз. Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» дигән повестенда гаять үзенчәлекле, катлаулы һәм хәтердә калырлык бер образ — колхоз председателе Суфиян бар. Ул үз-үзенә дә һәм башкаларга карата да ифрат рәхимсез кеше: кырга башак җыярга чыккан ач хатыннарны куып кайтара, кырдан алган бер уч арыш өчен тотып яңакларга да күп сорамый. Һәм шул ук Суфиян, хезмәт көненә түләргә башка мөмкинлеге булмагач, тота да, киптерергә дигән булып, колхозчыларга 300 центнер ашлык өләшә. Суфиян болайрак фикер йөртә: кирәк икән аны гаепләрләр, колхозчылар исә юньләп эшләсеннәр һәм юк-бар белән буялып йөрмәсеннәр. Шуның аркасында, ул җитәкләгән колхозда халык шактый ярыйсы яши, ә кайбер «йомшак күңелле, кешене җәлли белә торган» председательләрнең колхозчыларына шактый кыенга туры килә ул елларда.

Бу мисалны мин коры кызгану хисе генә гуманизм түгел әле, кызгану кешене кимсетергә генә мөмкин, дигән фикерне раслау өчен китердем. Шигем юк, Н. Фәттах ин изге ниятләрдән чыгып кулына каләм алгандыр. Әмма, ни генә булмасын, ул сурәтләгән тормыш күренешләре берьяклы, ярты-портырак һәм, димәк ки, ялгыш та чыккан.

Билгеле, әсәрне бәяләгәндә икенче чиккә ташланырга да ярамый. Н. Фәттах повесте социалистик реализмның тышындагы, теге ягындагы әсәр, аны, янәсе, критик реализм әсәрләре арасына кертү дөресрәк булыр иде, дип әйтүчеләр дә булгалады. Мондый карашлар, минемчә, безнең әдәбиятның иҗат методын артык тарайтып, гадиләштереп аңлаудан килеп чыга. Әйе, социалистик реализм методының төп тенденциясе яңа чынбарлыкны һәм яңа геройны раслаудан гыйбарәт. Әмма социалистик реализм методы безнең тормыштагы кимчелекләрне тәнкыйть итүне кире какмый, киресенчә, хуплый һәм яклый. Әгәр инде авторга тирәнлек җитми, ул безнең тормышны берьяклы сурәтли икән — бу, билгеле, бөтенләй башка нәрсә. Монда инде методның бер гаебе дә юк. Никадәр генә кимчелекле булмасын, Н. Фәттахның бу повесте дә яшәргә хаклы. Чөнки ул Ватан сугышы чорындагы авыл тормышының шиндидер яңа якларын ача, аны яңа штрихлар белән баета. Повестьта сурәтләнгән вакыйгалар укучыны дулкынландыралар, уйланырга мәҗбүр итәләр. Без әсәрне «безнеке булганга» һәм «безнеке булмаганга» гына бүлеп утырудан, аны я күккә чөеп мактый, я аяк астына салып таптый гына торган заманнардан үздык шикелле. Әдәби әсәрне бөтен катлаулылыгында аңларга, аның көчле һәм көчсез якларын диалектик бердәмлектә күрә һәм бәяли белергә өйрәнергә вакыт.

## «Берәү» повесте
## һәм аның тәкәббер герое

А. Гыйләҗев — заманында Нурихан Фәттахка каршы ачы пародия язып чыккан кеше. Тыштан караганда, алар бер-берсенә охшамаган әдипләр. Н. Фәттах юри катлауландырылган һәм чамадан тыш «иде» фигыльләре белән тутырылган озын җөмләләр кулланып язарга ярата. Аның стиле тоташ куаклык һәм куе яфраклы, чәбәләнеп беткән ботаклар белән капланган урман куелыгын хәтерләтә. А. Гыйләҗев исә тыгыз һәм динамик тел белән язарга омтыла, аның стиле шул ук урман куелыгына, әмма көзен яфраклары коелып, шәрәләнеп калган урман куелыгына тартымрак. Н. Фәттах, гадәттә, өзлексез дәвам итә торган вакыйгаларны сайлый. Кагыйдә буенча, аның әсәрләрендә кыска гына вакыт аралыгы алына, һәм геройларның шул вакыттагы эш-хәрәкәтләрен ул бик җентекләп, тәфсилләп сурәтли. А. Гыйләҗев, киресенчә, хронологик яктан зур вакыйгаларны иңләргә тырыша, вакыйгаларны кыю рәвештә бер урыннан икенче урынга күчереп йөртергә, үз геройларының үткәндәге биографияләрен искә төшерергә, озын-озын чигенешләр ясарга ярата.

Бу авторларның иҗат кешесе һәм гомумән кеше буларак аерымлыкларыннан килеп чыга торган тагын уннарча үзенчәлекләрен күрсәтергә булыр иде. Әмма төп нәрсәдә — тормыш күренешләренә якын килүдә — алар искиткеч охшашлар. А. Гыйләҗев әсәрләрендә дә колхоз тормышындагы кыенлык һәм кимчелекләргә күбрәк игътибар итү, сугыш елларындагы һәм сугыштан соңгы еллардагы авыл турында яңа сүз әйтергә тырышу күзгә ташлана. Менә шуңа күрә дә А. Гыйләҗевнең «Берәү» повесте («Казан утлары» журналы, 1966 ел, 5—6 саннар), минем уемча, Н. Фәттахның «Артта калган юллар»ы белән бер үк рәттә тора.

Повестьта бөтен әсәргә ачкыч хезмәтен үтәрлек бер эпизод бар. Әсәрнең төп герое — авыл хуҗалыгы институты студенты Исхак — мәшһүр татар шагыйре белән очрашу кичәсенә бара. Шагыйрь сугыштан соңгы авыл яшьләре тормышына багышланган «Бәхет поэмасы»н укый башлый. Тыңлап утыра-утыра Исхак бөтенләй аптырап кала. Бу шагыйрь дигәннәренең, бер генә тапкыр булса да, авылда булганы бармы икән? Булса, һәрнәрсәгә канәгать булып яшәүче мондый ваемсыз егетләрне һәм кызларны ул кайдан тапты икән дә авыл тормышындагы кыенлыкларны ничек итеп бөтенләй үк күрми китә алды икән?.. Авторның әйтергә теләгәне шактый ачык: тормыш кыенлыкларын шомартып һәм бизәп күрсәтми торган, дөресен, бары дөресен язган әдәбият кына яшәргә һәм ихтирамга лаек. А. Гыйләҗев үзе дә әнә шундый дөреслеккә омтыла. Ачы, хәтта күпмедер дәрәҗәдә юри күпертелгән рәхимсезлек белән, ул хезмәт көненә нибары йөз грамм арыш оны тигән еллардагы, халык күтәрә-түли алмаслык налоглардан иза чиккән еллардагы, дуамал колхоз председательләре йорт саен кереп, я штраф салу, я камчы белән куркыта-куркыта халыкны эшкә куып йөргән еллардагы авыл тормышы, шундагы кыенлыклар турында яза.

Хәмдия белән чагыштырганда, Исхак, билгеле, үзенә бер төрле характерлы кеше, башка масштаб кешесе. Ул күп нәрсә хакында уйлый һәм фикер йөртә алырлык югары белемле агроном. Исхак халыкка кирәкле һәм файдалы булу турында хыяллана. Ләкин, Хәмдия кебек үк, ул да киләчәккә ышанычын югалткан һәм рухи төшенкелеккә бирелгән кеше. Исхак беренче тапкыр сугыш елларында (ана бу вакытта нибары 13 яшь була) төшенкелеккә бирелеп, боегып кала. Яратып

йөргән кызы Сания һәлак була. Бигрәк тә әнә шул хәсрәт бөгә егетне. Шуннан 28 яшькә кадәр ул өйләнми йөри, хәтта хатын-кызлар янына якын да килеп карамый.

Студент елларында практика узганда егет икенче тапкыр шундыйрак хәлдә кала. Яна председатель Хөсәен белән бергәләп, ул җиң сызганып колхоз эшенә алына: район вәкиле Тазюков белән конфликтка керүдән дә курыкмыйча, колхозчыларны буш яткан җирләрне сөрергә күтәрә, кешеләрдә ышаныч хисен терелтеп җибәрә һәм әйбәт кенә уныш үстерергә булыша. Әмма, икмәк заданиесен үтәмәс борын колхозчыларга аванс биргән өчен, председательне эшеннән алалар, туры сүзле Нуруллаңы, аны яклап маташканы өчен, ябып ук куялар. Исхак, дөреслек һәм гаделлек эзләп, ары сугыла, бире сугыла, берни дә тожыра алмагач, авылдан бөтенләйгә чыгып китә.

Нурулла — Исхак яратып, гыйшык тотып йөргән Саниянең әтисе дә бит әле. Бу — егет өстенә төшкән кайгыны тагын да тирәнәйтеп җибәрә. Нурулла Исхакның иң якын, үз иткән, кирәк чакта ярдәм һәм киңәш сорап бара торган кешесе. Асылда, Нурулла әсәрдәге төп герой өчен вөҗданлылыкның һәм гаделлекнең тере символы. Инде шул кеше аяк астына салып тапталгач, Исхак үзен дә тапталган саный. Шул рәвешчә, югары белемле агроном, шәһәргә килеп, үзе яратмаган эшкә урнаша һәм акрынлап тормышка кул селтәгән тәкәббер ялгызакка әйләнә. Әсәрнең исеме үк шуңа басым ясый: «Берәү».

Н. Фәттахның Хәмдиясен кызганган кебек үк, без Исхакның да хәлен аңлыйбыз һәм аны да кызганабыз. Тик, Н. Фәттах кебек үк, А. Гыйләҗев та үз героеннан әллә ни югары күтәрелә алмаган. Аның артык нечкә хисле һәм нәзберек героен һәртөрле бюрократлар һәм түрәләр рәнҗеткән, ә үчен ул бөтенләй гаепсез авылдашларыннан, туган халкыннан, хәтта карт көнендә япа-ялгызы торып калган әнисеннән алмакчы. Хәтта отпуск вакытларында да авылына кайтмыйча, Исхак шәһәр конторапарында чалбар төбе туздырып йөргән арада авылда эшләр, акрынлык белән булса да, алга тәгәри тора. Кемдер эшли, хуҗалыкны күтәрә, бюрократизмга, искелек тарафдарларына каршы көрәшә. Тик бу эшләрдә Исхакның тырнак очы кадәр дә катнашы юк. Әсәрнең соңгы битләрендә генә, халык хуҗалыгының башка тармакларындагы кебек үк, колхоз авылында да эшләрнең һаман яхшыра баруына ышанган Исхак үзенең әүвәлге карашларының дөреслегенә шөбһәләнә башлый. Ул үзе кебек үк ялгызак һәм сугышта һәлак булган Саниягә бик нык охшаган бер кыз очрата. Автор әйтеп бетермәсә дә, без төп геройның, тора-бара, шәхси тормышта да үз бәхетен табачагына ышанабыз.

Бер мәсьәләдә автор белән килешми булмый: безнең тормышта барган үзгәрешләрнең Исхак кебек рәнҗетелгән һәм рухи төшенкелеккә бирелгән кешеләргә дә уңай тәэсире булды, алар күңелендәге калын боз катламы акрынлап эри барды һәм алар яңадан тормышта үз урыннарын таптылар. Тик автор үз герое характерындагы тискәре сыйфатларны һәм Исхак сайлаган позициянең ялгыш булуын ышандырырлык рәвештә күрсәтә алмаган. Исхак белән Хөсәен арасында барган сүзсез бәхәстә Хөсәен җиңеп чыга. Ул эшчән, актив һәм һәркем тарафыннан хөрмәт ителә торган кеше, колхозчылар аны яңадан председатель итеп сайлыйлар. Ә Исхак, әйтерсең, авыл тормышыннан сызып ташланган кеше, аны искә төшерүче дә юк диярлек.

Язучы теләсә нинди герой, шул исәптән, рухи төшенкелеккә бирелгән, китек күңелле герой сайларга да хаклы. Әмма, ни генә булмасын, ул үз героеның кимчелекләренә сокланып утырмаска, аннан өстенрәк, акыллырак һәм зирәгрәк булырга тиеш. Әгәр тормыш китек күңелле герой манарасыннан гына торып тасвирлана икән, тарихи перспективаның котылгысыз рәвештә бозып күрсәтеләчәген көт тә тор. Исхакның

үз тирәсендәге кешеләргә мөнәсәбәтендә нинди дер өнәмәү, явызлык хисе сизелә, вакыт-вакыт ул хәтта күрәлмаучылык тойгысына әйләнә. Геройны аңларга да мөмкин: явыз да булсын ди, ул рәнҗетелгән кеше. Әмма кайбер очракларда авторның үз күзләрен дә томан пәрдәсе каплый. Шуннан инде бер ише персонажлар гел кара буяулар белән генә сурәтләнә башлый. Әйтик, колхозның элекке председателе Сәлих образы һәрьяктан начар итеп бирелә. Башта ул колхоз икмәген урлый, мылтыктан атып, каравылчы Нурулланы яралый. Шуннан, ничектер, председатель булып ала да, деспотка һәм кире беткән кешегә әйләнә, колхозчыларны төрлечә мәсхәрәләп, хәтта тотып кыйный ук башлый. Председательлектән куылганнан соң да Сәлих искиткеч кабахәт һәм әшәке кеше булып кала бирә. Без бу образның логикасын, характерының умыртка сөяген, аны хәрәкәткә китерә торган пружинасын аңламыйбыз. Район вәкиле, карьерист Тазюков образы турында да шуны ук әйтергә кирәк.

Ә бит теләгәндә А. Гыйләҗев үз геройларының җанына керә белә. Исхакның әнисе Мәһибәдәр, Саниянең эти-эниләре Хәербанат белән Нурулла яратып һәм зур мәхәббәт белән сурәтләнгәннәр. Аяз Гыйләҗев — һичшиксез, талантлы һәм үсә торган язучы. Шуңа да бүген үк кисәтеп куясы килә: тормышка берьяклы караш аның талантына зыян итәчәк, тиз һәм дөрес үсүенә комачаулаячак.

## Герой һәм автор позициясе

Шул ук кимчелек, тагын да ялангачрак рәвештә, шагыйрь һәм драматург Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» исемле повестенда («Казан утлары» журналы. 1967 ел. 1—3 саннар.) кабатланды. Бу повестьта да сугыш елларындагы яшьләр тормышы, аларның икеләнүләре, шик-шөбһәләре, төрле ялгышулар, газаплы эзләнүләр аша яшәүнең асылын аңларга, тормышта үз урыннарын табарга тырышулары турында сөйләнә. Ә. Баянов повесте да ачыктан-ачык полемик рухта язылган. Әсәренең беренче битләрендә үк, дусларына һәм үзен якын күрүчеләргә мөрәҗәгать итеп, автор болай ди:

«Бу язмаларда эзлекле сюжет үсеше тапмасагыз, гаҗәпләнмәгез, монда — минем бары тик фикерләрем, уйларым, уйлануларым һәм мин аларны сезгә тапшырам, сезнең белән уртаклашам. Алар кайбер кануннарга туры килмәсәләр, моны тәртип ихтирам итмәүдән дип түгел, ә дөреслеккә мәхәббәтемнең зуррак булуыннан дип белерсез...» («Казан утлары» журналы. 1967 ел. 1 сан. 47 бит).

Һәм, дөрестән дә, автор тапталып, штампка әйләнеп беткән сюжет төзү алымнарыннан, геройларны механик рәвештә уңайга һәм кирегә генә бүлеп йөртүдән котыла алган. Әсәрнең жанрын ачыклау да шактый кыен. Автор үзе аны «лирик повесть» дип атаган. Моның өчен беркадәр нигез дә бар: повесть төп геройның эчке монологы рәвешендә язылган, әсәрдә лирик чигенешләр, фәлсәфи уйланулар, көтелмәгән ассоциацияләр тулып ята. Агыйдел буенда печән чабу күренешләрен, герой күңелендә беренче мәхәббәт хисе кузгалуын сурәтләгән битләр нәкъ көтелгәнчә, шагыйрь каләме белән язылган. Әмма, чама белән, әсәрнең өчтән бер өлешен укыганнан соң повестьның лирик яңгырашы сизелерлек йомшый. Калган өлешләре шигърилектән шактый ерак булган, өстәвенә әле натуралистик эпизодлар белән чиратлашып барган гадәти проза стилендә язылган.

Повесть зур шау-шу кузгатты. Шул кадәресен әйтеп үтәргә кирәк, әсәрнең формасы хакында сүз бөтенләй булмады диярлек, бәхәс төп герой тирәсендә барды. М. Маликованың «Казан утлары» журналында (1967 ел. 8 сан) басылган мәкаләсе шулай атала да: «Кем ул Әнис

Бадигин?» Шундый ук кызулык белән аңа А. Гыйләҗев каршы чыкты: «Ә син үзең кем, укучы?» («Казан утлары» журналы. 1967 ел. 11 сан). Бәхәскә укучылар да катнашты. Тора-бара бәхәс «Социалистик Татарстан» битләренә күчте һәм үзәк матбугатта дәвам итте. Хәзер, шау-шулы бәхәсләрнең кайнарлыгы бераз басыла төшкәч, мәсьәләнең асылына төшү һәм ниндидер уртак бер фикергә килү җиңелрәк булыр кебек.

Редакциягә җибәргән хатларның берсендә укучыбыз А. Әхмәдиева, аерым мәсьәләләрдә Әнис белән килешеп бетә алмавын белдереп, болай ди:

«Мин повесть турында кайбер уй-фикерләремне генә яздым. Әсәрнең идеясенә тукталмадым. Бәлки, аның идеясе дә шул Әнис образын дөрес чагылдыруга бәйләнгәндер...» («Казан утлары» журналы. 1967 ел. 9 сан. 151 бит).

Искиткеч дөрес искәрмә! Әсәрнең идеясе аерым, үзбаш яшәми бит. Идея авторның нинди герой сайлавына, аннан да бигрәк, ул геройны ничек аңлый һәм бәяли белүенә бәйләнгән. Димәк, бәхәсләр вакытында сүз Әнис Бадигинның кем булуы, аның уңай яки тискәре сыйфатлары хакында гына түгел, ә бәлки күп тапкыр мөһимрәк мәсьәләләр турында, әйтик, авторның идея позициясе турында да барган икән.

Ә. Баянов повестена эзлекле анализ ясаганнан һәм төп геройның эш-хәрәкәтләрен, кылган гамәлләрен игътибар белән күздән кичергәннән соң, М. Маликова: «Әнис Бадигин дөньяда үзе өчен генә яши, ул — эгоист», дигән нәтиҗәгә килә. Чыннан да, беренче мәхәббәтен Бадигин үзе җимерә. Алай гына да түгел, инсафлы һәм тыйнак, әмма кирәгеннән артык йомшак табигатьле һәм карышусыз Фәһимәне ул һәлакәт юлына китереп җиткерә. Әсәрнең үзендә бу эпизод, шактый томанлы сурәтләнеп, төрлечә юрауларга урын калдырса да, «Фәһимәнең рухы шул хәлендә була, һәм ул, шул хәлдән чыга алмыйча, атылып үлә», дип М. Маликова дөрес әйтә бугай. Гомумән, М. Маликованың байтак фикерләре белән килешергә мөмкин.

Ленаның мәхәббәте Фәһимәнеке кебек эчкерсез үк тә түгелдер, бәлки. Шулай да ул Әнисне кайнар мәхәббәт белән сөя. Тик Әнис Бадигин Ленага да бәхет китерми. Инде шактый еллар үтеп бераз акыл дигән нәрсә кирә төшкәч, Әнис Лена белән кабат очраша. Ленаның аны элеккечә үк яратуына һәм бары тик аны гына яратуына ышана. Һәм тагын бик җиңел, газапланмый-интекми генә аны ташлап китә. Аның Ленага мөнәсәбәтендә тәкәбберлек, үзен зурга кую һәм мин-минлек әллә каян сизелеп-күренеп тора. Ул үз язмышын Лена белән бәйләп ялгышмавы өчен шатлана, бәйләгән булса, янәсе, ул үзе дә аның кебек үк бәхетсез кеше булып калыр иде.

Аларның мөнәсәбәтләренә күз ташлыйк. Лена олырак, тәҗрибәлерәк һәм, Әнискә караганда, күп тапкыр булдыклырак. Әнисне җайлырак, җиңелрәк юллар сайларга Лена өйрәтә, һәм Әнис, инде консерваториягә кабул ителгәннән соң, материаль кыенлыклардан шүрләп, үз хыялыннан үзе үк баш тарта, беренче очраган техникумга барып керә. Әнисне квартира гаугасына сөйрәп кертүче кеше дә Лена, һәм Әнис, эчтән газаплана-газаплана, кызара-кызара булса да, Шаһнәхмәтевларны бүлмәдән сөрешә. Аны Фәһимәдән биздереп, көчләп диярлек үзенә өйләнергә мәҗбүр итүче кеше дә шул ук Лена. Сүз дә юк, Лена — начар кеше, иң гадәти мещанка, өстәвенә, әле ерткыч табигатьле мещанка. Әмма шулай да ул Әнистән әйбәтрәк кеше. Ни дисәң дә, Лена үз-үзен онытып, кайнар итеп сөя белә һәм мәхәббәте хакына теләсә нинди кыенлыкларга түзәргә әзер тора. Әнис исә үзеннән башка берәүне дә яратмый. Лена өчен иң кыен, иң авыр көннәрдә аны ташлап авылга китеп бара, шундый чакта кирәгем чыгар, Ленага ярдәмем

кирәк булыр дип тә уйламый. Хәер, аның бу адымы Әнис алга сөргән әшәке мораль принциплары белән дә яраша.

— Көчсезләрне рәнҗетүдән куркырга ярамый. Югыйсә үзеңне рәнҗетерләр,— ди Әнис.

Һәм каяндыр ишеткән шушы «теориясен» дәлилләү өчен, оялары белән кубарып алып, кош балаларын һавага чөя, тешләре белән бугазын чәйнәп, кыр куянын үтерә... Күренеп тора, мондый комсызлык һәм вәхшилек Әниснең кыю булып күренергә генә тырышуын раслый, аның куркак һәм көчсез булуыннан килә.

Повестьның төп героен тулаем дөрес характерлаганнан соң, М. Маликова беркадәре турысызыклырак нәтиҗә ясый. Янәсе, Әнис Бадигин — бик начар кеше, ә автор аны турыдан-туры хөкем итми, шулай булгач, повесть үзе дә начар һәм уңышсыз. М. Маликова яшьләр әсәрне дөрес аңламаслар, Бадигинга иярүчеләр табылыр, повесть үсеп килүче яшь буынга тиешле юнәлеш бирмәс, дип шикләнә.

А. Гыйләҗев М. Маликова фикерләрендәге шул йомшак якларга каршы чыга. Мәкалә авторы безнең укучыларның культура һәм гомуми белем дәрәҗәсе үсүгә шатлана, аларга әзер рецептлар тоттырып һәм манный боткасы гына ашатып торырга ярамый хәзер, ди. Бу яктан А. Гыйләҗев, һичшиксез, хаклы. (Тик шунысы гына бераз эчне пошыра: укучыга ышанырга, аны хөрмәт итәргә чакырып чыккан мәкаләнең үз тоны бераз һавалырак, хәтта тупасрак тоела. Сүздә А. Гыйләҗев әсәр хакында төрле фикер булырга мөмкин ди, әмма кылганда, үзе кебек уйламаучыларга ачуланып каш астыннан карый.)

Бадигин, М. Маликова уйлаганга караганда, катлаулырак образ. Бу мәсьәләдә А. Гыйләҗев хаклы. Балачакта аның табигатендә күп кенә әйбәт яралгылар була. Саф күңелле, шигъри табигатьле Әнис бөтен йөрәге белән музыканы ярата, гүзәллеккә омтыла. Аннан соң, Бадигин турында без күбрәк аның үз сүзләре буенча гына хөкем йөртәбез. Асылда безнең алда ул үзен-үзе фаш итә, күңеленең иң яшерен почмакларына да укучыны үзе алып керә. Яшьлеген искә төшереп, ул бушка үзгән елларын кызгана һәм: «Әгәр кайтарсалар, мөгаен, мин аны башкачарак үткәрер идем...» ди.

Бадигин образына гомуми бәя бирүдә Гыйләҗев үзе дә Маликовадан әллә ни аерылмый диярлек. Түбәндәге юлларга игътибар итегез: «Леналар мөхите кавырсыны катмаган бу сәер егеттән ялган кеше, әшәке кеше, кара эчле кеше, эгоист ясый, бөтен тормышын гарипләндерә». («Казан утлары» журналы. 1967 ел. 11 сан. 155 бит.)

Маликова башлаган анализны тагын да тирәнәйтә төшеп, Гыйләҗев Бадигиннарны формалаштырган социаль шартларга игътибар итә. Сугыш һәм ул тудырган кыенлыклар төрле кешегә төрлечә йогынты ясый. Берәүләрне чыныктыра, тагын да түземлерәк һәм инсафлырак итә, икенчеләрне гарипләндерә һәм мораль яктан тарката. Әгәр Бадигин үзенең хыялларын тормышка ашыра алмаган икән, монда күбрәк шул елларның авыр тормыш шартлары гаепле (дөрес, ул үзе дә житәрлек тырышлык һәм активлык күрсәтми). Әгәр аның тирәсендә яшь ягыннан үзеннән олырак кызлар бөтерелә икән, бу да очраклы хәл түгел. Аларның үз яшьтәшләре, сөйгән ярлары һәм кияү буласы егетләре ничә ел инде сугыш кырларында йөри, күпләре кабердә ук ята. Шулай итеп, үз игътибарын автор сугыш еллары чынбарлыгының башкалар күзе төшмәгән якларына күбрәк юнәлтә.

Ләкин А. Гыйләҗев мәкаләсенең әсәргә гомуми бәя биргән урыннары белән килешеп булмый. Әсәрне яклап калырга тырыша торгач, А. Гыйләҗев повестьны артык үзенчә аңлата башлый һәм авторга бөтенләй аның уенда да булмаган нәрсәләр тага. Аның мәкаләсе буенча хөкем йөрткәндә, повесть Әнис Бадигиннарны, аларның тормышка карашын хөкем итүгә, аның социаль тамырларын ачып салуга

багышланган булып чыга. Әгәр чыннан да шулай икән, искиткеч шәп булыр һәм бәхәсләшеп торырга урын да калмас иде. Бөтен бәла дә шунда: еш кына автор үзе дә героеннан югарырак күтәрелә алмый, шуның эчендә эреп беткәндәй була, дөньяга аның күзләре белән карый, кешеләрне Әнис бизмәне белән үлчи. Әгәр артык йомшак характерлы Фәһимәне һәм күбрәк үз эшләре белән генә мәшгуль Суфиянны исәпләмәсән, Бадигин тирәсендә рәтле кешеләр бөтенләй диярлек күренми. Без Әниснең әниләрен дә, әнисен дә күрмибез. Ихтимал, алар Әнис тормышында әллә ни әһәмиятле урын биләмиләрдер. Бердәнбер дус кешесе Хәмит бар, тикшерә башлагач, анысы да юньсез булып чыга.

Дөньядагы барлык эгоистлар кебек үк, тормышындагы кыенлыклар өчен Әнис дөньядагы бөтен кешене гаепли, тик үзен генә гаепләми. Әйтик, аңардагы «Бетховенның үлүендә» кем гаепле соң? Повесть буенча хөкем йөрткәндә, бөтен кешелек гаепле булып чыга. М. Маликова дөрес яза, авыр сугыш елларында, өлкән туганнары аны фашизм утыннан саклап калу өчен кан койганда, гомерләрен биргәндә, Әнис Бадигинның мондый «претензияләре» сәер һәм беркатлы яңгырый. Укучы Г. Нәҗметдинов: «Аңлашылып бетми. Ул (Әнис Бадигин—Р. М.) яшьлеген кемнән дә булса таләп итәме, нәрсәгәдер үкенәме? Мин, аның замандашы буларак, үкенмим»,— дип яза («Казан утлары» журналы. 1967 ел. 9 сан. 153 бит). Ул хаклыдыр кебек...

Күрәсез, сүз авторның идея позициясе, ул позициянең тайгаграк булуы хакында бара. Инде бер тапкыр әйтелгәнчә, язучы җаны теләгән тема, теләсә нинди герой сайларга хаклы. Әмма шуларны хәл иткәндә, чишкәндә безнең чорның төп закончалыкларын истән чыгармаска тиеш. Бадигин, шиксез, тормышчан образ. Әмма, повестьтагыча, аны акларга, якларга тырышу белән берничек тә килешеп булмый. Билгеле, аны аңларга мөмкин, ә гафу итәргә һич тә мөмкин түгел.

Әмма шулай да, авторның идея позициясе күпме генә бәхәсле һәм тайгак күренмәсен, повесть безнең әдәбиятны үзенчәлекле, кызыклы материал белән баетты. Р. Бикмөхәммәтов белән килешергә кирәк («Литературная Россия» газетасы, 1968 ел. 12 сан): бирелә Бадигинны сүгеп яки мактап язу гына җитми, әсәргә төпле анализ ясарга лазем. Ә повесть төрлечә фикер йөртү өчен шактый бай азык бирерлек.

## Боз кузгала

Сугыш турында язучы башка яшь прозаиклар кебек үк, Э. Баянов та тормыш күренешләрен тасвирлау, яңа фактлар һәм яңа материал алып килү ягыннан кызыклы, көчле, әмма шул күренеш һәм фактларга бәя биргәндә шактый өстен йөзә. Әсәрнең нигезендә шактый берьяклы һәм субъектив характердагы балачак һәм яшьлек хатирәләре ятуы билгеле бер роль уйнагандыр, мөгаен. Баяновның төп герое төрле хаталар һәм ялгыш адымнар ясый, ары сугыла, бире сугыла. Бу аңлашыла: ул әле кавырсыны чыгып җитмәгән яшүсмер генә. Авторның үзеннән исә без күбрәкне көтәргә хаклы.

Балачак хатирәләренең берьяклы һәм чикләнгәнрәк булуы В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» исемле повестенда да сизелеп кала. Чагыштырмача зуррак күләмле шушы беренче әсәрендә автор үз буынының автопортретын ясарга, чын күңелдән, гади генә итеп, бала күңелендә сакланып калган сугыш еллары авылы турында сөйләргә тели. Әсәр яңалыгы һәм тормышчан булуы белән көчле, дөньяга якты, яңача мөнәсәбәте белән игътибарны җәлеп итә. Анда бернинди ясалмалык, тарту-сузу сизелми, бу инде табигый талант өчен кирәкле төп сыйфат. Ләкин язучыдан күбрәк сорала. Тормышны ничек бар шулай

сурәтләү генә житми, тормыш күренешләрен гомумиләштерә алу, чынбарлыкны тирәнтен танып белү сорала, ә яшь авторга нәкъ шул кадәресе житенкерәми дә. Дөрес, бу әсәрдә без нинди дә ялгыш фикерләр, берьяклы карашлар очратмыйбыз. Ләкин аның нәни героеның дөньяга карашы кирәгеннән артык тар һәм чикләнгән, тормыш турындагы күзаллавы артык гади һәм беркатлырак.

Кечкенә Равил тирән бер фажиганең шаһиты була. Әнисе өйдә югында аны үз янына сыендырып торган жиңгәсе, артык тинтерәтә һәм аптырата торгач, өлкән яшьләрдәге колхоз председателе Самат белән «чуала» башлый. Шулчак ире Искәндәрнең үлүе турындагы хәбәрнең нигезсез булуы беленә, менә-менә ул үзе кайтып төшәргә тиеш. «Гөнаһсын» яшерү нияте белән, Нәсихә аборт ясата һәм һәлак була... Тирән дулкынландырырлык, хәтта тетрәтерлек вакыйгалар алынган, истә калырлык, үзенчәлекле образлар сайланган. Әмма нәни героеның тар карашлы даирәсе белән кул-аягы бәйләнгән автор үз геройларының психологиясенә тирән үтеп керә һәм әлеге драманы төбеннән ача алмаган. Шуңа да, тулаем алганда, повесть шактый өстәнрәк язылган жиңелчәрәк тәэсир калдыра.

Шуның белән бергә, аңа хәтле сугыш турында язган яшьләрдән аермалы буларак, бу бәләкәй повестьта сугыш елларының кыенлыкларын куертып, юри күпертеп күрсәтергә тырышу сизелми. Моны басым ясап билгеләп үтәргә кирәк. В. Нуруллин бер нәрсәне дә яшерми, күрмәмешкә салышмый. Әмма әлеге авырлык һәм кыенлыклар алгы планга да куелмаган. Авторны, барыннан да бигрәк, кешеләр, аларның характерлары кызыксындыра. Бу әсәрнең герое, Ә. Баянов повестендагы кебек, бөтен кешелеккә каршы куелмаган. Автор сугыш елларындагы балаларның бик тиз өлгерүләре, үзләрен солдатлар, шинельсез солдатлар итеп хис итүләрен сурәтли. Менә шуңа да, никадәр генә жиңел, өстән язылган кебек күренмәсен, «Шинельсез солдатлар» безнең яшь прозада яңа этап башлануы, «боз кузгалуы» хакында сөйли. Тормышка шулай яңача якын килүнең аерым билгеләре бераз әлегрәк М. Рафиковның «Илһам авазы» исемле повестенда да чагылган иде. Бу лирик повестьта, зур мәхәббәт һәм ихлас күңел белән, яшьлекләре сугыш елларына туры килгән буын турында сөйләнә. Зур гомумиләштерү көченә ия булырлык кызыклы характерлар очрамаса да, әсәр лирик жылылыгы, эмоциональ тәэсир көченең зурлыгы белән алдыра.

Шул ук яңалык сыйфатлары, тагын да калкурак булып, М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» исемле беренче повестенда гәүдәләнә. Сугыш елларының авыр шартлары М. Мәһдиев әсәрендә үзгәрәк планда — юмор аша сурәтләнә. Автор тормыштагы көлке ситуацияләрне тота белә, үз геройларын характерлау өчен искиткеч оста детальләр куллана. Юмор жанрында эшләүче прозаикларыбызның ифрат аз булуын да искә алсак, бу әсәрнең чыгуы — аеруча шатлыклы күренеш. Автор характерлар коя белә. Әркәшә белән Әлтәфины да, Зарифуллинны һәм география укытучысын да шулкадәр ачык итеп күз алдына китерәсең, әйтерсең, син алар белән бер класста укыгансың. Шунысы аеруча шатландыра: М. Мәһдиев моңа бер-ике характерлы штрих ярдәмендә ирешә; геройларының биографияләрен дә сөйләми, катлаулы сюжет линияләре корып та маташмый. Әсәр нык профессиональ кул белән язылган. Ул — корыч пружина кебек кысылган, акылга һәм ирониягә бай проза.

Әмма урыны-урыны белән әдәби детальләр үзмаксатка әйләнеп киткәли. Бер биттә шактый уңышлы төсмерләнгән геройлар икенче биттә үк бөтенләй югалалар. Әсәрне бер ноктага тупларлык һәм таралып китүдән саклап торырлык зур һәм яңа фикер — идея бердәмлеге житми. М. Мәһдиев сугыш чоры балаларының аңы формалашуны күрсәтә, аларның ничек укулары, фән нигезләрен һәм тормыш законнарын

аңларга өйрәнүләре турында сөйли. Ләкин, шул процессны баштан ахырга кадәр күзәтү өчен, авторның әлеге язмалары артык кыска һәм өзек-өзек. Аның геройлары нигездә тышкы штрихлар ярдәмендә генә тасвирлана. Сизелеп тора: педучилище завучы Хәлим Фәтхиевичның характеры повестьта сурәтләнгәннән күп тирәнрәк һәм катлаулырак булгандыр. Ләкин автор аны тиешенчә ача алмаган. Шуна күрә завучның кулга алынуы укучыга аз аңлашыла һәм әсәрнең бөтен агышы белән йомшак бәйләнгән сыман. Педучилищедагы башка укытучылар тагын да өстәнрәк сурәтләнгән. Автор үз героеның дөньяга карашындагы чикләнгәнлекне җиңеп бетерә алмаган. Әсәрдәге кимчелекләрнең кайберләре, күрәсең, шуның белән дә аңлатыладыр.

* * *

Шул рәвешчә, яшь прозаикларның бөек Ватан сугышы чорына багышланган әсәрләрен күздән кичереп уздырдык шикелле. Алар бу чор тормышын сурәтләүгә багышланган әдәбиятка нинди яңалык китергәннәр соң? Беренчедән, без аларның үз элгәрләре тарафыннан сурәтләнгән картиналарны тагын да тулыландыра төшүләрен күрәбез. Икенчедән, сугыш чорында безнең халык кичергән реаль авырлыкларны сурәтләгәндә, алар кырыс булырга, бары тик дөресен генә язарга омтылалар, әмма вакыты белән буяуларны шактый куертып та җибәрәләр. Алар үз геройларын һәрнәрсәдән канәгать, шоп-шома кешеләр итеп түгел, бәлки эзләнүчән, катлаулы характерлар итеп күрсәтергә тырышалар. Кагыйдә буларак, алар әйбәт тасвирлый беләләр. Әмма тормыш күренешләрен һәрьяктан тирәнтен бәяләү мәсьәләсенә килгәндә, еш кына көчләре җитеп бетми.

Дөрес, хәзер инде тормышның тискәре якларын гына күпертеп күрсәтү, кимчелекле геройлар белән юри мавыгу чоры үтеп бара шикелле. В. Нуруллин һәм М. Мәһдиевләрнең «Казан утлары» журналының 1968 елгы саннарында басылган әсәрләре безнең яшь прозаның бу балачак чиреннән арынып килүе хакында сөйли. Әмма сугыш еллары чорындагы авыл темасын яктырту инде тәмамланды, диярgә иртәрәк әле. Теманы берьяклы хәл итү генә тәмамланды кебек. Безнең прозада, К. Симонов романнары кебек, ул чор вакыйгаларын яңа, бүгенге позицияләрдән торып яктырткан тирән әсәрләр юк әле. Әмма безнең прозаикларның андый әсәрләр тудырырга көчләре җитәр дип уйларга кирәк.

Герой хакындагы бәхәс дәвам итә. Кем үзе һәм заманы турында дөрес, ышандырырлык итеп, иң мөһиме, дөрес философик позицияләрдән торып сөйли алыр, кем замандашларыбызның тормышчан һәм тулы канлы образларын иҗат итә алыр, кем фактлар һәм детальләр дөресләгән чынбарлыкны танып-белү тирәнлеге белән бәйли алыр — бу бәхәстә шул җиңеп чыгар.

Исхак Зәбиров

# ҖӘЛИЛ КӨРӘШТӘШЛӘРЕ

## Җиңү көнен күрә алмады...

1967 елның көзендә мин Берлин, Дрезден, Лейпциг шәһәрләрендә — Җәлил хәрәкәт иткән урыннарда булдым, немец язучысы, публицисты һәм тәрҗемәчесе, Германия-Совет дуслыгы җәмгыяте члены, ару-талуны белмәс, олы җанлы кеше Леон Небенцальне күреп сөйләштем, ул җыйган бик күп яңа документларны өйрәндем.

Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең үлеме турындагы бу яңа документларның кайберләре узган елның февралендә Совет матбугатында инде игълан ителде. Мин бу мәкаләдә Муса Җәлилнең элек Урта Азиядә яшәгән һәм хәзер дә шунда яшәүче кайбер көрәштәшләре турында сөйләргә телим.

Шуларның берсе — Гариф Шабаев.

Билгеле булганча, 1945 елның язында, Берлин шәһәрен штурмлаганда, Совет гаскәрләренең бер подразделениесе Моабит төрмәсен сугышып ала. Шунда бер солдат — аның исеме әлегә кадәр билгеле түгел — төрмә җимерекләре, кирпеч ватыклары арасыннан ниндидер немец китабы битенә русча язылган язу таба. «Мин, татар шагыйре Муса Җәлил,— дип язылган була анда,— әсир ителгәннән соң, сәяси эштә гаепләнеп, Моабит төрмәсенә ябылдым, һәм, мөгаен, тиздән атарлар. Әгәр дә бу язу руслардан кемнең булса да кулына төшсә, иптәшләргә — Мәскәүдәге язучыларга сәлам тапшырсын!»

Озакламый Муса Җәлилнең фашист концлагерьларында, төрмәләрендә язган шигырьләре дә Ватанга кайтып житте, шагыйрьнең героик язмышы турында Совет кешеләре шактый нәрсәләр белә алдылар.

Менә безнең алдыбызда унбер еллык эзләнүләрдән соң җәлилчеләрнең җитәкчеләрен җәзалап үтерү турында Леон Небенцаль тапкан яңа документлар.

Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең җәзалап үтерелүе көне элек тә укучыларга билгеле иде. Шпандау төрмәсендә Җәлил белән бер камерада яткан италияле хәрби әсир Рениеро Ланфредини (ул 1967 елның декабрендә үлә) сөйләве, соңрак Көнбатыш Берлинның генераль прокуратурасында табылган һәм доктор Каул тарафыннан Леон Небенцальгә җибәрелгән документлар — Әхмәт Симаев һәм Гариф Шабаевның үлемнәре алдыннан тутырылган карточкалары буенча ул көнне төгәл әйтергә мөмкин иде инде. Менә ул карточкага язылганнарның татар теленә тәрҗемәсе:

«Шпандау хәрби төрмәсе. Фамилиясе — Шабаев. Туган елы — 15. XII. 1907. һөнәре — легионер. Хәрби әсирләр кенәгәсендәге номеры — 828/44. Империскийи хәрби судның РКА — П — 343/43 карары белән Плетцензеедәге 4 нче блокка урнаштырылды. Җинаяте — җимерү эше. Судка кадәрге тоткында булуын исәпкә алу — үлем җәзасы. Чыгарылу сәбәбе — 25. 8. 1944 е. җәзалап үтерелде. Генераль прокурор печате. «Каммергерихт». Берлин. Имзаны раслыйм — канцелярия мөдире».

Барлык җәлилчеләр дә шул ук көнне, хәтта бер үк сәгатьтә җәзалап үтереләләр.

Бик кызыклы, игътибарны үзенә тарта торган бер деталь бар. Үзләренең гадәттән тыш педантлыгы белән аерылып торган фашист палачлары Гариф Шабаев карточкасын

аннан-моннан гына тотырганнар. Анда хәкем итәлүченең исеме дә, тоткан дине дә, «җинаятьләре дә (әле соңгысын санап чыгу җәза алдыннан тотырыла торган карточка өчен мәҗбүри булган) әйтелмәгән. Күренеп тора: фашистлар Совет патриотларын мөмкин кадәр тизрәк юк итәргә тырышканнар...

Леон Небенцаль яңа тапкан документлар исә җәза алдыннан түгел, җәзалап үтерелүнең икенче көнендә — 1944 елның 26 августында язылганнар.

Плетцензеедәге җәзалап үтерү нәтиҗәләрен фашист палачлары Шарлоттенбургта (Берлин янында) штандесамт дигән учреждениедә (бездәге ЗАГС тибында) теркәгәннәр.



*Гариф Шабаев*

Фашист чиновнигы Глюк махсус кенәгәгә, җәзалау вакытында булган шаһит — Плетцензее төрмәсе надзирателе ярдәмчесе Пауль Дюррхауэр сүзләренә таянып, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Әхмәт Симаев, Фоат Булатов, Гайнан Курмашев, Абдулла Батталов, Гариф Шабаев, Зиннәт Хәсәнов, Фоат Сәйфелмөлеков, Сәлим Бохаров һәм Әхәт Әднәшевнең бер үк сәгать эчендә җәзаланып үтерелүе турында язган.

Гариф Шабаевның җәзалап үтерелгәннән соң тутырылган карточкасы буенча аның Берлинда, Фридрих урамында, 247 йортта торганлыгы мәгълүм. Ата-анасы турында мәгълүматлар күрсәтелмәгән. Мөнәвәрә Шабаевага (кыз вакытындагы фамилиясе Беркутова) өйләнгәнлеге әйтелгән.

Гариф Хафиз улы Шабаев Уфа шәһәрендә туган. Яшүсмер вакытында, егерменче елларда, әтисе-әнисе белән Үзбәкстанга күчеп килгән.

Тугыз еллык мәктәп бетергәннән соң, ул финанс хезмәткәрләре курсларында укый. Аннары Алты Арык районында, соңрак Ташкентта Госстрах оешмаларында эшли.

1938 елда Шабаевлар семьясы бөтенләй Ташкентка күчеп килә. «Югары дәрәҗәдә намуслы һәм киң кругозорлы белгеч», дип характерлыйлар аны эшендә.

Гариф Шабаев Үзбәкстан ССР Финанс халык комиссариатының Үзгосстрах начальнигы белән эшләгән җиреннән, сугыш башлануның бишенче көнендә үк, үзе теләп фронтка китә. Ул дошманнарга каршы батырларча сугыша, ләкин, камалуга эләгеп, әсир төшә.

Гарифның хатыны Мөнәвәрә Шабаев, сугыш беткәч тә әле, ирен хәбәрсез югалган дип кенә белә. Сугыштан соң бер ел үткәч кенә, 1946 елның 17 июнендә, ул ире турында хәбәр ишетә. Шабаев Гариф Хафиз улының фашист тоткынлыгында концентрацион лагерьда һәлак булуы турында әйтелгән була анда. Аның нинди шартларда һәлак булуын да, татар шагыйре Муса Җәлил җитәкчелек иткән антифашистик яшерен оешманың актив члены икәнлеген дә белмиләр әле ул вакытта.

«Культура эшләре» белән шөгыльләнүче Муса Җәлил дошманның тирән тылында лагерьдан лагерьга тоткарлыксыз күчеп йөрергә, тоткыннар белән аралашырга мөмкинлек ала. Менә шулай йөргәндә, Муса Җәлил Вустрау лагеренда Гариф Шабаевны очрата да инде.

Һәрвакыт оптимист рухлы, җаны-тәне белән җиңүгә ышанган Гариф Шабаев кыенлыклар, тоткынлык газаплары алдында йомшап төшми.

Люблин янындагы концлагерьда булган вакытта ук Гариф Шабаев Фоат Булатов белән дуслаша, һәм алар бергәләп качарга план коралар. Ләкин бу план гамәлгә ашмый кала — фашистик-миллэтче «Идел-Урал» комитетына әсирләрне яллар өчен Берлиннан махсус комиссия килеп төшә. Белемлерәк әсир татарларны берга туплыйлар да Вустрау лагерена озаталар. Шунда Гариф Шабаев Җәлилнең якын көрәштәше һәм фикердәше булып китә.

Очрашкан вакытларында алар күбрәк антифашистик листовкалар бастыру һәм тарату турында сөйләшәләр, чөнки Шабаевка мондый листовкаларны бастырып чыгаруны оештыру бурычы йөкләнгән була. Озакламый Фоат Булатов белән Шабаев Берлинга күчерелә. Муса Җәлил аларны «Идел-Урал» комитетына типография белгечләре дип тәкъдим итә. Гариф Шабаевка моңа кадәр бер вакытта да хәреф җыю, басу машиналары белән шөгыльләнергә туры килмәсә дә, ул җиң сызганып эшкә керешә һәм тиз арада бу эшнең нечкәлекләрен өйрәнеп тә ала.

Яшерен оешманың икенче бер члены — элек Казанда чыгып килгән яшьләр газетасы сотруднигы, журналист һәм шагыйрь Рәхим Сәттаров «Идел-Урал» газетасына фото-хәбәрче итеп урнаштырыла.

Типографиядә үз кешеләр булдырылгач, антифашистик листовкалар басып чыгару да җайга салына. Бу листовкалар хәрби әсирләрне Гитлерга каршы көрәшкә чакыралар, алар лагерьларда татар хәрби әсирләре арасында киң таратыла.

Татар легионының беренче батальоны, немец офицерларын үтереп бетереп, Витевск тирәсендә партизаннар ягына чыга. Батальонның бер генә солдаты да Совет Армиясенә үз туганнарына каршы бер генә пуля да атмый.

Шулай итеп фашистларның татар легионына баглаган өметләре сабын күбеге булып җилгә оча.

Берлинда, Радом, Едльня, Крушино, Познань лагерьларында совет патриотлары алып барган эшләр турындагы хәбәрләр Чехословакия, Франция һ. б. урыннардагы тоткыннар арасында тарала, алар күңелендә җиңүгә булган ышаныч, өмет хисләрен арттыра, фашистларга каршы көрәш дәрте уята.

Ләкин Муса Җәлил, Гариф Шабаев һәм оешмадагы башка патриотларга җиңү көнен күрү насыйп булмады...

1943 елның җәендә Муса Җәлил легионерларның үзәк лагеры урнашкан Едльня шәһәренә килә. Биредә хәрби әсирләр фашистларга каршы восстание башлап җибәрергә тиеш булалар. Башта Гариф Шабаев күпләп бастырган листовкаларны тарату планлаштырылган була. Ләкин восстание көнен фашистларга хыянәтче җиткерә һәм Муса Җәлил, кулга алынып, Варшава төрмәсенә озатыла. Аның артыннан башка патриотлар да кулга алына. Лагерьның барлык почмагында фашистлар тентү үткәрәләр. Алар листовкалар, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гайнан Курмаш һ. б. ларның кулъязмаларын табып алалар.

Ачлык та, җәзалаулар да, төрле мәкерлекләр дә җәлилчеләрнең ныклыгын какшата алмый.

Италияле хәрби әсир Рениеро Ланфредини үзенең истәлекләрендә Шпандау төрмәсендә 53 һәм 153 камераларда татар патриотлары белән бергә утыруы турында яза. 1944 елның 25 августында иртән төрмә сакчылары ишекне ачалар да татар патриотларына киенергә кушалар. Кулларына берни алырга да рөхсәт ителми. Барысы да аңлап ала: димәк, алар үтереләчәк инде. Ланфредини белән хушлашып, татарлар болай диләр: «Безне үтерергә алып китәләр, ләкин без курыкмыйбыз, чөнки Ватан өчен үләбез». Патриотлар батырларча, елмаеп үләләр. Соңыннан Ланфрединига рухани Юрытко татарларның асып үтерелүе турында сөйли. Ләкин, билгеле булганча, алар гильотинада башларын кисеп үтерергә хөкем ителгәннәр бит!..

Леон Небенцаль үзе дә бу турыда Юрыткодан сорашкан икән. Менә нәрсәләр сөйләде ул миңа:

«Плетцензее төрмәсендә үлемгә хөкем ителгәннәрнең гадәттә гильотинада башларын кисканнәр. Бу җәза өч минутта башкарылган. Фашист палачларына һәр үтерелгән кеше өчен күп акча бирелгән. Шуңа күрә алар «тырышканнар»: һәр хөкем ителгән кешене 11 секундта үтерүгә «ирешкәннәр». Ләкин, әйтүләре буенча, 1944 елның 18 августында авиация һөҗүме вакытында гильотина җимерелгән. Гитлерчылар гильотина куелган сарай эченә металлдан өрлек куеп, шуңа сигез тимер ыргак элгәннәр. Шул ыргакларга берьюлы сигез кешене асканнар. Асылганнар шунда 20 минут торырга тиеш булган. Ә палачлар, чиратта башка хөкем ителгәннәр торганга, аларны жаннары чыккач ук алалар. Гитлерның юстиция министрлыгы Плетцензее, Шпандау, Тегель төрмәләрендә үлемгә хөкем ителгәннәрне кичекмәстән үтереп бетерергә боерык бирә. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре дә әнә шулай җәзалап үтереләләр».

Узган елның февралендә Леон Небенцаль игълан иткән яңа документларда җәлилчеләрнең башларын кисеп үтерелүе әйтелгән. Димәк, Юрытко раславы юкка чыга. Ләкин ул версияне бөтенләй үк кире кагу да дөрес түгелдер кебек. Чөнки, беренчедән, карточкалар җәзалап үтерүнең икенче көнендә тутырылган. Икенчедән, моның бердәнбер шаһиты Пауль Дюррхауэр дигән кеше әлегәчә үзе табылмаган. Дөрес, аның элегрәк көнбатыш Берлинда яшәгәнлеге мәгълүм. Совет журналистлары, бигрәк тә «Комсомольская Правда» газетасының үз хәбәрчесе Г. Гурьков, аны эзлиләр. Ләкин, кызганычка каршы, бу эзләүләрнең нәтиҗәсе юк әле.

Мөгаен, бу бердәнбер шаһит табылыр һәм батырларның үлеме турында ул төгәлрәк итеп сөйләр.

Миңа еш кына Гариф Шабаевның семьясы белән очрашырга туры килә. Патриотның хатыны Мөнәвәрә ханым, бик кыен һәм катлаулы кичерешләргә карамастан, әле дә үзен нык тота һәм яхшы сизә. Ул хәзер пенсиядә. Ире кебек үк, озак еллар финанс эшендә эшләгән. Кызы Лилия В. И. Ленин исемендәге Ташкент университетының физика-математика факультетын тәмамлаган. Ташкент аэропортында метеорология хезмәте буенча баш инженер булып эшли. Аның улы Володя да инде зур булып үсеп килә.

Әйе, Вовка зур булып үсәр, һәм, без шиканабыз, бабасы Гариф Шабаевның дошман алдында тез чүкмәвен аңлар һәм бабасы кебек, бабасының дусты Муса Җәлил кебек батыр, сугышчан булырга тырышыр.

## Ул эшафотка икенче булып менгән...

Җәлилчеләрдән иң беренче Гайнан Курмашев җәзалап үтерелә. Бу 1944 елның 25 августында 12 сәгать 06 минутта була.

Өч минуттан соң гильотина эшафотына Фоат Сәйфелмөлековны мендерәләр...

Икенче көнне фашист чиновнигы аның турында (һәм билгеле булганча, аның бүтән көрәшче дуслары турында, әлбәттә) түбәндәге карточканы тутыра:

**«№ 2967**

**Берлин — Шарлоттенбург, 1944 елның 26 августы.**

**Бухгалтер Фоат Сәйфелмөлеков. Мөселман.**

**Торган урыны — Сталинабад.**

**Үлгән җире Берлин, Шарлоттенбург, Кенгсдам, 7.**

**1916 елның 16 июлендә Ташкентта (Россия) туган.**

**Таныклык номеры — (тутырылмаган).**

**Атасы — Хуҗарахмат Сәйфелмөлеков. Соңгы вакытта торган урыны билгесез.**

**Анасы — Нәҗимә Сәйфелмөлекова. Кыз чактагы фамилиясе — Шафиева. Гиждуванда (Россия) туган.**

**Никахы (бу графа сызылган).**

**Никахының теркәлгән урыны — (тутырылмаган).**

**Берлин, Мантейфельштрассе, 10 йортта торучы надзиратель ярдәмчесе Пауль Дюррхауэр сүзләре буенча язып алынды.**

**Бу белешмәләрне хәбәр итүче — билгеле кеше, һәм ул үлемнең шаһиты булуын раслады.**

**Үлемнең сәбәбе — башын кисү.**

**Укылды, расланды һәм имза — Пауль Дюррхауэр.**

**Төп нөсхәдәгечә дөреслеге раслана:**

— *Берлин, Шарлоттенбург, 26 август, 1944. Хезмәт вазифасы буенча — Глюк.*

Актив җәлилчеләрнең берсе Фоат Сәйфелмөлековның исеме Татарстан язучылары союзына Моабит дәфтәре килеп кергән көннән башлап билгеле.

Карточка, немец педантлыгына хас булмаганча, бик шапшак тутырылган. Анда үлемгә хөкем ителгән Сәйфелмөлековның семья хәле бөтенләй күрсәтелмәгән, атисе-

нең исеме дә дөрес язылмаган — Хуҗаәхмәт урынына «Хуҗарәхмәт» диелгән. Әйе, фашистлар совет патриотларының башларын тизрәк кисәргә ашыкканнар.

Соңгы көннәргә кадәр аның сугышка кадәрге тормышы, хезмәте турында мәгълүматлар билгеле түгел иде. Сугыштан соңгы 23 ел дәвамында эзләнүләр дә нәтиҗә бирмәгән. Күптән түгел мин Фоат Сәйфелмөлековның туган сеңелесе Фания Хуҗаәхмәт кызы Хәбибуллинаны эзләп таптым. Ул Ташкентта, Чиланзарда тора икән. Аңарда Сәйфелмөлековның хезмәт кенәгәсе һәм сугышка кадәр төшкән рәсемнәре сакланган.

Фоат Сәйфелмөлеков Ташкентта туган. 1938 елда Сәмаркандта халык хуҗалыгы институтын тәмамлаган, аннан Таҗикстан ССРның сәүдә халык комиссариаты карамагына җибәрелгән. Таҗикстанда башта экономист-товаровед булып эшләгән, аннары, 1940 елның 3 февралендә Кызыл Армия сафына чакырылганчы, колхоз базарлары группасы белән җитәкчелек иткән.

Фоат Сәйфелмөлековның туганнары сугыш вакытында аның исеме үлгәннәр санында да, билгесез югалганнар исемлегендә дә булмавы турында хәбәр алганнар. Шуннан соң Фоатның язмышы хакында 1968 елның җәенә кадәр берни дә белмәгәннәр.

Бохарада яшәүче җитмеш алты яшьлек әнисе улының фашист тоткынлыгында батырларча көрәше һәм җәзалап үтерелүе турындагы хәбәрне күтәрә алмады, урынга егылды һәм узган елның сентябрендә дөнья куйды...

Фания Хәбибуллинадан тыш Фоатның Зәкия һәм Фатиха исемле тагын ике туганы бар. Алар Бохарада яши.

## «Филармония артисты»

Киевны яклап каты сугышлар бара. Дошман бер-бер артлы яңа көчләрен һөҗүмгә кертә. Кызыл гаскәрләр соңгы чиккә кадәр позицияләреннән чигенмиләр. Ләкин көчләр тигез түгел.

Сержант Гарәф Фәхретдинов үз отделениесе оборона тоткан урыннан фашистларны тылга үткәрмәде, кызылармеецлар шактый якынлашкан дошман төркемнәренә каршы контратакага берничә мәртәбә күтәрелде.

Менә күз алдында, янында гына, төтен, тузан катыш ялкын баганасы күтәрелде, каты шартлау тавышы ишетелде...

Икенче көнне генә ул аңына килде. Бөтен тәне сызлана, әрни иде. Каршысында немец офицеры, ул нәрсәдер акырына, ләкин сүзләре ишетелми. Гарәф аның кыймылдаган иренен карап кына ни әйткәнен аңлап алды:

— Тор! — дип кычкырына булса кирәк.

Бер сәгатьтән аны допроска чакырдылар.

— Фамилияң, исемең ничек? — Гарәфнең колаклары азрак ачыла башлаган иде инде.

— Алишев Дим,— дип җавап бирде Гарәф.

...Лагерьдан лагерьга күчеп йөри-йөри яралар төзәлде. Тоткынлыктан котылырга тырышып карарга да мөмкин иде инде. Һәм ул, җаен туры китереп, бер качты, ике качты. Ләкин һәр тырышу уңышсыз булды: аны һәрберсендә тоттылар, кыйнадылар, хәтта, анадан тума чишендереп, тозлы суга салдылар.

1942 ел. Дим Алишев — Гарәф Фәхретдиновны, качкан җиреннән тагын тотып алып һәм бик каты кыйнап, Польша җирендәге Демблин лагерена китереп ташладылар. Бу лагерь — иң каты режимлы лагерьларның берсе. Ачлыктан гадәттән тыш ябыккан, кыйналулардан имгәнеп беткән Гарәф бүтән тоткыннар белән бергә эшкә йөрер хәлдә түгел иде. Шул вакыт ул әйбәт кенә җырлый белүен исенә төшерде: тавышың яхшы икән, көчең булмаса, аны да эшкә кушарга мөмкин бит. Һәм ул җырлады. Ватан турында, ирек турында, җиңү турында җырлады. Аның җырлары пешекчеләргә дә ошый иде, алар, яшереп-яшереп кенә, Гарәфкә өстәмә апара биргәли торган булып киттеләр.

...Демблин крепостенда Гарәф инде айдан артык тора. Ул бернәрсәгә игътибар итә башлады: кичерәк кенә буйлы, кара тут йөзле бер тоткынны бик күпләр ихтирам итәләр, аның белән ни турындадыр киңәшәләр, аңардан нәрсәдер сорашалар.

ә бу тоткын һәркемгә елмаеп җавап бирә, һәрберсен тынычландырырга тырыша, үгетли.

Көннәрнең берендә, туган илне искә төшереп, моңлы гына бер көй сузды Гарәф. Җырлап бетерүе булды, әлеге тәбәнәк тоткын аңа ниндидер кытыршы кәгазь кисәге сузды:

— Менә бу җырны җырла,— диде.— Күңеллерәк җыр бу.

Гарәф шатланып куйды: әгәр үз кеше, ышанычлы иптәш булып чыкса, әкренләп тагын качу ягын кайгырта башларга вакыт.

— Таныш булыйк,— дип сүзен дәвам итте бу кеше,— мин — Гумеров, шигырьләр, җырлар чыгарам. Мин яңа җырлар язармын, ә син җырларсың. Килештекме?

— Мин риза...

Гумеров биргән җыр Идел турында, Ватан турында иде.

Икенче көнне лагерьда пешекче булып эшләгән Абдулла Батталов, Гайнан Курмашов дигән кешеләр әлеге Гумеровның танылган татар шагыйре Муса Җәлил икәнлеген әйттеләр.

Мусаның тагын бер һөнәре беленде — ул менә дигән итеп мандолинада уйный икән. Белмәгән көе юк. Җырын яза да нинди көйгә җырларга кирәклеген мандолинада уйнап күрсәтә. Шундый чаклар да булгалый: кайчандыр, бала вакытта, картлардан ишеткән көй Гарәф хәтеренә төшә, ул аны көйләп күрсәтә. Ул арада булмый, Муса бу көйгә җыр да чыгарып өлгертә.

— Укып чык әле,— ди аннары.— Минемчә, шул көйгә җырларга мөмкин моны.

Бу җырлар язылган кәгазь кисәкләре кулдан кулга күчеп йөри торган булып китте — чын листовка диярсең! Хәер, аларның тәэсире листовкаларда языла торган ялкынлы сүзләрнекеннән бер дә ким түгел иде. Артыграк та булмаса әле.

...Фашистлар, Муса Җәлилнең күренекле татар шагыйре икәнлеген белеп, аны үзләренең Советлар Союзына каршы көрәш максатларында файдаланырга уйладылар. 1942 ел ахырында аны бу лагерьдан алып киттеләр...

Тау белән тау гына очрашмый, диләр. Гарәф тә Муса Җәлил белән бөтенләйгә аерылмаган икән әле.

1943 ел башланып күп тә үтмәде, крепостьтагы бөтен әсирләргә сафка тезелергә сигнал булды. Сафтан 13 кешене сайлап алдылар. Алар арасында Гарәф Фәхретдинов та бар иде.

Аларны Демблиннан 70—80 километр ераклыктагы Едльня лагерена алып киттеләр. Бу лагерьда татарлар, башкортлар һәм Идел буендагы башка милләт вәкилләре шактый икән. Рушат Хисаметдинов — легионерларга «культура хезмәте» күрсәтә торган татар-башкорт капелласы җитәкчесе — Гарәфне эзләп табып, аны немецларга Казан филармониясе артисты, дип тәкъдим итте. Гарәфнең элек Казанда булганы да юк, хәтта «филармония» сүзенең мәгънәсен дә белми иде. Ул, әлбәттә, башта ни әйтергә дә белми, аптырап калды.

— Шулай кирәк, тегене-моны каршы әйтмә,— диде Хисаметдинов.

Соңыннан гына белде Гарәф: Рушат Хисаметдиновка аның турында Муса Җәлил сөйләгән икән. Үзе ул монда түгел, югарырак «эшкә» беркетелгән булып чыкты. Бу капелланы турыдан-туры оештыручы да шул Муса икән.

Капелла тиздән хәрби әсирләр арасында зур популярлык казанды. Гарәфнең биюләрен дә, Муса Җәлил шигырьләрен көйгә салып җырлавын да тамашачылар бик ярата иделәр.

1943 ел башында «капелла артистлары» Рушат Хисаметдинов, Гарәф Фәхретдинов, Абдулла Батталов (ул анда Басыйров фамилиясендә йөри иде), Зиннәт Хәсәнов, Фоат Сәйфелмөләков һ. б. ларны, «яхшы хезмәт күрсәткәннәре өчен», Берлинга экскурсиягә җибәрделәр. Бу экскурсияне Муса оештырган иде, һәм ул аларны каршы алды. «Экскурсант»ларны башына эшләпә, өстенә кара костюм кигән, галстук таккан Муса Җәлил үзе озата йөрде, капелла членнарына терле күрсәтмәләр бирде, өйрәнеп җырлау өчен, яңа шигырьләрен, җырларын тапшырды.

Бу экскурсиядән соң Гарәф Фәхретдинов капелланың хәрби әсирләргә культура хезмәте күрсәтү өчен генә түгел, ә башлыча яшерен патриотик эш алып бару өчен оештырылганын аңлады һәм үз бурычларын тагын да тегәлрәк, җиренә җиткеребрәк башкарырга кереште.

Гарәф Мусаның иң якын көрәштәшләреннән берсе — Гайнан Курмаш группасында иде. Үзенә тапшырылган барлык заданиеләрнең үтәлеше турында ул бары тик Гайнан Курмашка гына белдерергә, башка кешегә бер сүз дә әйтергә тиеш түгел. Ә мондый заданиеләрне шактый күп башкарды Гарәф: яшерен киңәшмәләр вакытында сакта торды, көйгә салып, совет яклы патриотик җырлар башкарды, кирәкле кешеләргә телдән яки язма рәвештә төрле хәбәрләр җиткерергә ярдәм итте.

Муса, легионерлар арасында «культура эшләренең торышын тикшерергә» дигән булып, лагерьга еш кына килгәли иде. Ул группа җитәкчеләре белән генә түгел, аерым легионерлар белән дә сөйләшә, һәркемнең хәленә керергә, һәркемдә ышаныч тудырырга тырыша, көрәшкә рухландыра иде.

Кораллы восстаниегә әзерлек алып барылуы Гарәфкә билгеле иде инде. Ул бу әзерлек эшенә мөмкин кадәр күбрәк өлеш кертергә тырышты. Ә «чама белмичә» тырышырга ярамый иде, чөнки һәр эшне күзәтәләр, аны бик сак башкарырга кирәк.

Муса Җәлил Едльня лагерена килүенең берсендә Курмашев, Хисаметдинов һәм Сәйфелмөлеков белән бик озак киңәште. Гарәфкә сакта торырга, андый-мондый куркыныч була калса, шундук сигнал бирергә куштылар. Ул-бу булмады, Муса, киңәшмә беткәч, Гарәфкә рәхмәт әйтте.

Ун-унбиш көннән Муса тагын лагерьга килде. Аңа немец унтер-офицеры киеме кигән бер шадрарак битле егет һәм гражданский киемле тагын өч кеше ияргән иде. Гарәфкә һәм тагын берничә әсиргә «немец офицеры»ның чемоданын сакларга куштылар.

Берничә көннән «немец офицеры»н һәм дүрт «немец солдаты»н яшерен оешма членнары (аларның икесе — шофер) — фронт ягына таба алып киттеләр.

...Озак еллар үткәч Гарәф Фәхретдинов немец офицеры киемендәге егетнең рәсеменә карап, Мусаның көрәштәше — шагыйрь һәм журналист Рәхим Саттар булуын белде. Ә ул вакытта аның кем икәнен беркемгә дә әйтмәделәр. Чөнки ул легионнан Кызыл Армия командованиесе белән бәйләнеш урнаштыру өчен җибәрелгән иде.

Ләкин аларның язмышы әлеге көнгә кадәр билгесез. Бәлки аларны гестапо кулга алгандыр һәм җәзалап үтергәндер.

...Бу вакытларда Муса Җәлил Г. Тукай әсәрләре буенча «Шүрәле» операсы өчен либретто тәмамлады. Капелла аны сәхнәгә куярга әзерләргә кереште. Репетицияләрнең берсенә Муса Җәлил үзе дә килде. Ул бу килүендә Гарәфкә «Таң», «Кайту» исемле текстлар калдырды. Бу маршларны Гарәф «Шүрәле» операсы премьерасында башкарырга тиеш иде.

Ләкин премьера булмый калды.

Провокатор-хыянәтче Мәхмүт Җамалетдинов доносы буенча, восстание буласы көн фашистларга билгеле булды, һәм гестапо яшерен оешма членнарының барысын да кулга алды.

Кулга алынганнарны чишенергә һәм тезләнергә мәҗбүр иттеләр, барысының да кулларына богау кидерделәр. Матрацларны, мендәрләрне теткәләп, кульъязмалар, хатлар һәм блокнотларны җыйдылар. Курмашев мендәре эченнән, матрац астыннан Муса Җәлил кульъязмалары, листовкалар чыкты. Гарәф Мусаның кырыкка якын шигыре тупланган бер кечкенә дәфтәрчекне саклап калган иде, ләкин аны да табып алдылар.

Соңыннан, туган илгә кайткач, Муса Җәлилнең хәтерендә калган шигырьләрен Гарәф аерым бер дәфтәргә язды, бу дәфтәрне ул хәзер дә күз карасы кебек саклап тота.

...Бу вакыйгалардан соң, фашистлар татар легионерларын Советлар Союзына каршы сугышта файдаланудан ваз кичтеләр. Ләкин, җәлилчеләр үзләре төрмәләрдә утырсалар да, алар башлаган эш дәвам итте. Фашистлар Гарәф Фәхретдиновның яшерен оешмага турыдан-туры катнашканын исбат итә алмадылар. Аны Франциягә, Леон шәһәре янындагы лагерьга озаттылар. Немецлар уннарча мең әсирләрне «Атлантика валы» дип аталган корылмалар төзү эшенә куйды.

Совет әсирләре, монда китерелгәч тә, качу җаен эзләргә керештеләр. Ләкин ничек качарга? Францияне фашистлар оккупацияләгән, француз телен беркем дә белми, һәр адым саен үлем сагалап тора.

Гарәф Фәхретдинов җитәкчелегендә унсигез кешелек патриотлар группасы, җай

туры китереп, сакта торган часовойны демектерделәр, аның пулеметы белән коралланып, тауларга качып киттеләр. Йөри торгач, алар француз партизаннарына килеп кушылдылар. Француз каршылык күрсәтү командованиесе биргән документлар Гарәф Фәхретдиновта хәзер дә саклана. «Овернидәге эчке каршылык күрсәтү көчләре командующие,— дип язылган аларның берсендә,— үзенең 1944 елның 24 августындагы № 106 приказы белән рядовой Фәхретдинов Гарәфнең батыр солдат булуын билгеләп үтә. 1944 елның 11 августында Бэн янындагы сугышта ул кул пулеметы белән иптәшләренең чигенүен каплап торды, аннары, тормышын куркыныч астына куеп, яраланган отделение командирын сугыштан алып чыкты... Ле-Пюи шәһәрендәге сугыштан соң аңа шеф-сержант званиесе бирелде һәм ул бүләккә тәкъдим ителде.

Җиңү көнен шеф-сержант Гарәф Фәхретдинов Франциянең Дижон шәһәрендә каршылады...

Гарәф Фәхретдинов Татарстанда, Бөгелмә районының Карабаш авылында 1920 елда туган. 1937 елда ата-анасы белән Бохара өлкәсенең Каган шәһәренә күчеп килә. Бохара укытучылар мәктәбен тәмамлый һәм Каган мәктәпләренең берсендә укыта. Шуннан армиягә алына...

Хәзер дә ул Урта Азиядә яши.

Сугыштан соң туган илгә кайткач, Гарәф Алмалык шәһәрендә төзүче булып эшкә урнашты. Хәзер ул Яңа Ташкент шәһәрен сала, «Высотстрой» удар трестының арматурщиклар бригадасын җитәкли, коммунистик хезмәт ударнигы. Ташкент төзүчеләре аңа зур ышаныч күрсәттеләр: ул профсоюзларның Ташкент өлкә комитеты члены, идарә комитетының председатель урынбасары.

Үзешчән сәнгатькә мәхәббәте хәзер дә сүрелмәгән. Алмалыкта яшәгәндә, «Строитель» клубында татар-башкорт җыр һәм бию түгәрәгенең җитәкчесе иде. Ә хәзер Ташкентта «Дуслык» ансамбленең актив члены.

* * *

**Югарыдагы мәкаләләр авторы, Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыгы темасына кандидатлык диссертациясе әзерләүче И. Забиров, Муса Җәлилнең шигырьләре тупланган дәфтәрләреннән берсен саклап калган Бельгия патриоты Андре Тиммерманска фашист төрмәләрендәге шартлар турында язуын үтенеп, хат җибәргән иде. Аңа түбәндәге җавап хаты килде.**

*«Терлемон, 2 август, 1968 ел.*

*Забиров әфәнде!*

*...Башта ук шуны әйтергә тиешмен, мин язучы түгел һәм сугыштан соң үткән гомер минем хәтердәге бик күп нәрсәләрне юып төшергән. Аннары мин бүтәннәрдән бернәрсәсе белән дә аерылып тормаган гади бер кеше. Шулай да теләкләрегезне хәл кадәренчә канәгатьләндерергә тырышам.*

*1942 елның 6 сентябрендә кулга алынган көнемнән алып 1945 елда азат ителүемә кадәр мин 12 төрмәдә, 40 камерада утырдым. Моңардан ачык күренә: әлбәттә, төрмәләрдә минем белән бергә утырган шактый гына иптәшләр бар иде.*

*Фашист төрмәсен тасвирлау мөмкин түгел. Сәбәбе бик гади: бу биналарны карап йөрергә сакчылар миңа мөмкинлек бирмәде. Минем карашымча, Германиядә дә, башка илләрдә дә төрмәләр бертөрледер, бер-берләренә охшаштыр. Күз алдына китерегез: камера дип атала торган гадәттән тыш кечкенә бер бүлмә — аркылысы 3 метр, буе 4, биеклеге 3 метр. Калын стеналарның нинди төскә буялганлыгын да белерлек түгел, пычранып беткән. Сул яктагы почмакта мебельгә охшаш өч аяклы бер нәрсә тора. Аның янында өске ягы кителгән коңгырт төстәге төнге чүлмәк. Рәттән ике кирпеч ята — алар әлеге чүлмәкне чистарту өчен. Икенче бер почмакка тагын бер чүлмәк куелган — аңысына тоткынга тиешле көнлек су салынган. Камераның каршы ягында — ике катлы сәндерә — ятак урыннары...*

*Пычранып беткән такталардагы язуларны укып, бу ятакның мин бик күп тоткыннарга хезмәт иткәнлеген аңладым. Бу язмаларның күбесе, әлбәттә, тоткыннарның соңгы истәлекләре булып калган...*

*Сәндерә янында вакыт үтүдән каралып беткән өстәл һәм ике-өч утыргыч кебек нәрсә тора. Өстәл турысына, түшәмгә, кечкенә генә электр лампасы эленгән.*

*Тышкы стенада идәннән ике метр ярым биеклектә — аркылы-торкылы уникегә бүленгән тәрәзә. Бу бердәнбер яктылык һәм һава керә торган урын. Ишек эчке яктан күңелдә чирканыч тудыра торган соры төстәге броня белән тышланган.*

*Төнге чүлмәктән авыр ис килә.*

*3 нче рейх тоткыннарының «резиденциясе» әнә шундый. Бу «торак урыны»нда яшәү яки үлем мәсьәләсе хәл ителә. Мин шундый урында табәнәгрәк буйлы, нык гәүдәле, очкынланып торган күзле, кара чәчле кеше белән күп көннәр дәвамында бергә яшәдем. Аның өстендә буй-буй зәңгәр төстәге драп костюм иде. Муенына кызыл төстәге галстук бәйләгән, аякларында — ботинка. Мине поляклар һәм немецлар каршы алды. Камерадашлар белән таныштык. Шунда әлеге кешенең Гумеров икәнлеген белдем.*

*«Дәүләт гостиницасында акылдан язган туганнар»ны очратудан куркып, баштарак мин алар белән аралашмаска тырыштым. Гумеровның язмышын белгәч, һәм алар миңа икмәк белән ярдәм иткәннән соң, безнең арадагы салкынлык бетте, яңа дуслык, барлык кыенлыклар аша кичкән дуслык туды. Гумеров Дрезденга киткән көн миндә бик авыр тәэсир калдырды. Аның белән киткән 12 дусның мин икесен генә белә идем.*

*Менә мин сезгә шуларны белдерергә теләдем. Әйе, вакыт инде безне ул вакыйгалардан ерак аерды. Җәлил хәтердә калган, ә детальләр онытылган.*

*Аның хатынына чын күңелдән сәлам әйтегез һәм иң яхшы теләкләремне белдерегез.*

*Андре Тиммерманс».*

# ӘХМӘТ СИМАЕВ— ҖӘЛИЛ ДУСТЫ[1]

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.

XX гасырда шагыйрь башы өстендә палач балтасы ялтырар, дип, элегрәк кем дә булса башына китердеме икән? Әмма хәзер безгә билгеле: Муса Җәлил язган югарыдагы юлларда аллегория юк, аларда чын хакыйкать сурәтләнә. Хәзер без Җәлилнең нинди үлем белән үлгәнен ачык беләбез.

1944 елның 25 августында 12 сәгать 18 минутта Берлинның Плетцензее төрмәсендә шагыйрьнең башы киселә... Алты минуттан соң Җәлилнең дусты һәм шәкерте Әхмәт Симаев эшафотка менә һәм башын гильотина пычагы астына куя.

Икенче көнне төрмә смотрителе ярдәмчесе Пауль Дюррхауэр Берлинның Шарлоттенбург районындагы штандесамтка — ЗАГС тибындагы учреждениегә килә. Аны Глюк дигән чиновник каршы ала. Штербебух дип йөртелә торган кенәгәдә түбәндәге язу барлыкка килә:

---

[1] «Журналист» журналының 9 санынннан (1968 ел) Сергей Кристи мәкаләсе (тәрҗемә).

«Әхмәт Симаев. Журналист һәм шагыйрь. Меселман. 1944 елның 25 августында, 12 сәгать 24 минутта үлде. Торган урыны — Вильмерсдорферштрассе, 15. Үлеменең сәбәбе — башы киселде. Туган елы — 1915 елның 28 декабре. Краснослободск шәһәрендә (Россия)[1]. Атасы — Садретдин Симаев, әнисе — Шәрифә Симаева, кыз вакыттагы фамилиясе — Старкова. Хатыны — Валентина Симаева, кыз вакыттагы фамилиясе — Листопад. Берлинда, Мантейфельштрассе, 10 да торучы надзиратель ярдәмчесе Пауль Дюррхауэр сүзләре буенча язып алынды. Бу белешмәләрне хәбәр итүче — билгеле кеше һәм ул үлеменең шаһиты булуын раслады».

Кем соң ул, Әхмәт Симаев?

Бик күп яшьләргә хас булганча, ул үзенең иҗади эшчәнлеген шигырьләр язудан башлый. Аның беренче остазы Муса Җәлил була. Утызынчы еллар башында Муса Җәлил җитәкчелек иткән әдәби түгәрәккә абыйлы-энеле Әхмәт белән Фәттах та актив йөриләр, әдәбият турындагы әңгәмәләргә, төрле бәхәсләргә катнашалар. Бу әңгәмәләр еш кына Фәттах квартирасында дәвам итә торган була. Муса еш кына Симаевлар квартирасында куныл та калгалый. Ә иртә белән Әхмәт аны Таганкадан Столешниковога озатып куя.

Менә шундый очрашулар, бер-берсен үзара хөрмәт итү Әхмәтнең киләчәктәге тормышына да йогынты ясый. Муса үзенең яшь дусты Әхмәтне поэзиягә генә түгел, журналистика эшенә дә тарта. Бу вакытта Муса Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. Әхмәт Симаевның беренче шигырьләре әнә шул газета битләрендә дөнья күрәләр. Ә Әхмәт метрополитен төзелешендә эшли торган була. Үзенең эшен, уйларын шигырьләрендә сурәтли ул. Шигырьләренең исемнәре генә дә бу турыда ачык сөйли: «Метрострой», «Бригадир Кугуасов», «Колхоздан хат».

«Метрострой ударнигы» газетасының актив хәбәрчесе Симаев бу елларда (1933—1936) күп кенә хәбәрләрен, шигырьләрен бастырып чыгара, редакциянең һәр заданиесен күңел биреп башкара.

Озак та үтми, Әхмәт Мәскәүдән сиксән километр ераклыктагы Воскресенск шәһәренә күчә. Анда ул матбугат эшендә эшли, корректор ярдәмчесеннән газета редакциясенең җаваплы секретаре булып үсә. 1939 елда Мәскәү педагогия институтының әдәбият факультетына читтән торып укырга керә.

Әхмәт күп эшли, күп яза. Ләкин, кызганычка каршы, аның кульязмалары сакланмаган. 1940 елда ул армиягә алына һәм аның шигырьләре, хатлары, тәрҗемәләре, көндәлекләре саклана торган папка редакциядә, өстәл тартмасында кала. Сугышлар Мәскәү тирәсендә барганда, редакция архивын яндырырга туры килә.

Әмма «Коммунист» газетасы калган. Дулкынланып, газетаның 1938—1940 елларда чыккан саннарын актарам. Газета битләрендә Симаев фамилиясе еш очрый. Газета аның тормышында зур роль уйнаган, аның дөньяга карашын, әдәби талантын үстерергә ярдәм иткән, аңарда партияле журналист шәхесе, бөек интернациональ туганлык рухы, Ленин идеяләренең тантанасына тирән ышаныч тәрбияләгән.

«Коммунист» газетасының әдәби битләрендә еш кына Әхмәт Симаевның шигырьләре басылган. Шул ук вакытта ул татар шагыйрьләренең әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп тә чыгарган һәм тәрҗемәнең авторы А. Влиндор дип кул куйган. А. Влиндор — Симаевның псевдонимы.

Без Гитлер Германиясендә Җәлил шигырьләренең фашизмга каршы көрәшкә өндәп яңгыравын беләбез. Тегель, Моабит төрмәләрендә — остаз һәм шәкерт бергә булган һәр җирдә — Муса шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итүче Әхмәт Симаев булганлыгына шик юк.*

«Коммунист» газетасында эшләүче журналистлар аңа дусларча Анатолий дип эндәшкәннәр, Ә ул үзен Андрей дип йөртергә яраткан, ә хатыны аңа Сима дип эндәшә торган булган. Аның шундый төрле исемнәрдә йөрүе эзләнүләр вакытында шактый кыенлыклар тудырды.

Баштарак аңарга командование йөкләгән беренче хәрби задание соңгысы булган дип исәплиләр иде. Алай түгел икән, ул фронтта алты айга якын булган.

---

[1] Немец чиновнигы ялгышкан. Әхмәт Садретдин улы Симаев элекке Пенза губернасы, Краснослободск өязенең (хәзер Мордва АССР) Усть-Рахмановка авылында туган.

Симаевның хатыны аның фронттан 1942 елның 12 февралендә язган хатын хәтерли. «Валя, мин хәзергә безнеке булмаган үзебезнең җирдә. Моның нигә шулай икәнен үзең аңлыйсың. Мин командировкада. Мине, заданиене үтәп кайткач, өйгә, отпускага җибәрергә вәгъдә бирделәр. Көт. Кызыбызны чиксез күрәсем килә.

**ӘТИЕГЕЗ СИМА»**

Фәттах та февраль аенда аңардан кош теле тикле генә хат кисәге ала. «Мин тылда, озакламый күрешербез»,— дип яза ул.

Ләкин Әхмәт Симаев туганнары белән бүтән очраша алмый. Ә кызын ул бер мәртәбә дә күрә алмый, аңа Людмила дип исем кушканнарын гына хат аша белә.

Туганнары һәм дуслары Әхмәтне хәбәрсез югалган дип исәплиләр. Әмма ул әле һаман фронтта дошманга каршы сугышуын дәвам итә. 250 нче һава десанты полкы дошман тылында заданиене үтәгән вакытта рация начальнигы ефрейтор Симаев 1942 елның 20 январеннан алып, кыен метеорологик һәм сугыш шартларында, Көнбатыш фронты штабы белән өзлексез бәйләнеш тота. Полк командиры майор Солдатов, өлкән батальон комиссары Сычушкин, полк штабы начальнигы капитан Подлобко Симаевның бу батырлыгына зур бәя бирәләр. Күптән түгел мин СССР Оборона Министрлыгының кадрлар буенча Баш идарәсеннән, «1915 елда туган Симаев Әхмәт Садретдин улы Көнбатыш фронтының 1942 ел 31 майда чыгарылган 0624 приказы нигезендә «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән исәпләнелә»,— дигән хәбәр алдым. Әхмәт Симаев бу хөкүмәт бүләге турында үзе берни дә белмәгән.

...Симаевтан бүтән хат килми. Мөгаен, чолганыштан сугышып чыккан көннәрдә хатлар да, кешеләр кебек хәбәрсез югалганнардыр.

Әмма, һич тә көтмәгәндә, Воскресенск шәһәренә Әхмәт хатыны исеменә бер хат килеп төшә. Бу хат, кызганычка каршы, сакланмаган. Шулай да аны хатыны күңеленнән белә. «Хөрмәтле иптәш, безнең сугышчан дустыбызның хатыны! — диелгән була анда.— Безнең командирыбыз Андрей Симаевның кайда икәнен сез белмисезме? Ул сугышчан заданиеләрнең берсеннән кайтмады. Бәлки, ул яралангандыр һәм бу турыда сезгә хәбәр иткәндер. Без Андрейны яхшы иптәш булуы, батырлыгы өчен хөрмәт итә идек. Әгәр ул һәлак булган икән, аның өчен без каһәр төшкән дошманнан үч алырга ант итәбез!»

Симаевның язмышы беркемгә дә билгеле булмый. Үзенең остазы һәм дусты Муса Җәлил, үзенә тиңдәш башка көрәштәшләрен очратканчыга, фашизмның нәкъ үзәгендә революция өчен көрәшкә керешкәнгә кадәр аңарга да «кырык үлем аша» узарга туры килә.

Еллар буе, бәлки, хатым булмас,
Хәбәр булмас минем турымда.
Туфрак күмәр баснан эзләремне,
Үлән үсәр киткән юлымда.

Немец әдибе Леон Небенцаль 1958 елда Берлинда басылып чыккан «Икенче бөтен дөнья сугышы тарихы проблемалары» дигән китапның икенче томына кергән мәкаләсендә болай дип яза:

«Җәлил һәм аның иптәшләре фашизмга каршы көрәшләрен аеруча авыр шартларда алып баралар. Розенберг кешеләре, фашизмга сатылган татар ак эмигрантлары комитеты үзләре оештырган «Идел-Урал» легионын даими күзәтү астында тоталар һәм андагы әсирләрне милләтчел рухтагы көчле пропаганда белән сугарырга тырышалар».

«Идел-Урал» комитеты асылда дошманнар Идел буенда һәм Уралда оештырырга исәп тоткан «дәүләт»нең резервта торган «хөкүмәте» ролен үтәргә тиеш булган. Комитетның башында Габдрахман Шәфи Алмаз дигән сатлык эмигрант торса да, асылдагы җитәкчесе доктор Унгляубе белән «большевиклар һәм Азия проблемалары белгече» профессор Менде булган. Идел буе, Башкортстан һәм Астрахань далаларын үз эченә алачак империя комиссариаты белән идарә итүне Гитлер гауляйтер доктор Отто Шульманга тапшырган.

Муса Җәлил җитәкчелегендәге яшерен оешма менә шундый инәсеннән җебенә кадәр исәпләп төзелгән көчкә каршы торган.

Мәскәү янынннан чигенергә мәҗбүр булган дошманның тирән тылына самолеттан сикергәч, фашистларга әсир ителгән Әхмәт Симаев мондый шартларда совет разведчигының үзлегеннән карар кабул итәргә тиешлеген белә, әлбәттә, һәм ул иң авыр юлны сайлап ала.

Симаевка «Политик яктан ышанычлы» дигән таныклык биреп, гитлерчылар бик нык ялгышалар. Вустрау лагеренда — гестапо һәм «Идел-Урал» комитетындагы ак эмигрантларның һәр әсиргә чиктән тыш шикләнеп караган урында патриотик оешма үзенең эшен башлап җибәрә. Мондый оешмада эш алып бару фикерен Симаев әсир төшкән көненнән башлап үзендә йөртә һәм ул анда — Вустрауда — Муса тәкъдимен бик теләп күтәреп ала.

Тиздән Әхмәт Симаев та лагерьдан яшерен оешманың үзәге урнашкан Берлинга күчеп килә.

Мин тиремне саклап исән калсам,
Үлем миннән аша сикерсә,
Шул яшәүме булыр, «хаин!» диеп,
Ил битемә минем төкерсә?!

Ул вакыттагы вакыйгалар инде еракта калды. Хәзерге заман биеклегеннән инде ул вакыйгаларның эзләре бик үк ачык күренми. Шулай да без беләбез: ул вакытта большевизмга каршы идеологик көрәш фронтының үзәге Берлин аша үткән. Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Әхмәт Симаев һәм башка патриотлар шушы фронтның иң алгы сызыгында Ватан идеяләрен тормышка ашыру өчен көрәшкән яшерен оешма төзиләр.

«Идел-Урал» комитеты исеме астында патриотлар антифашистик характердагы листовкалар бастырып чыгаралар, совинформбюро хәбәрләрен тараталар. Алар Берлиндагы һәм Германиянең башка шәһәрләрендәге хәрби заводларда эшләүче чит ил эшчеләре белән бәйләнешкә керәләр. Каршылык күрсәтү челтәре киңәйгәннән киңәя. Оешманың үзәге «IV Азатлык комитеты» дигән имза белән коралды восстаниегә чакырып, татар һәм рус телләрендә листовкалар чыгара. Комитет членнары, Берлинда, гестапо күз алдында диярлек, Польша территориясендәге лагерьлардагы яшерен группаларның вәкилләрен җыеп, киңәшмәләр үткәрәләр.


Әхмәт Симаев Комитетның зур тәвәккәллек таләп иткән җаваплы заданиеләрен башкара. Ул, рус теленнән башка немец телен дә ярыйсы гына белгәнгә, тәрҗемәче нәртмичә генә Берлин һәм Германиянең башка шәһәрләрендә иркенләп йөри алган. Журналист буларак, көнчыгышта оккупацияләнгән өлкәләр министрлыгында, пропаганда министрлыгында үткәрелгән төрле пресс-конференцияләргә катнаша, Шәфи Алмаз белән дә «дусларча» мөнәсәбәттә була. СС рейхсфюреры, көнчыгыштагы оккупацияләнгән өлкәләр министры Розенберг янына кереп сөйләшүен дә аның күпләр беләләр. Болар барысы да аңа үз эшен шик төшермичә башкарырга мөмкинлек бирә.

Ул немец патриотлары белән очраша, Варшавага барып, партизаннар, поляк патриотлары белән элемтәгә керә. Җәлил китеп йөргән вакытларда, Алиш белән бергәләп, Берлиндагы бүтән яшерен оешмалар белән бәйләнеш тота. Әхмәт, Җәлил кушуы буенча, совет командованиесе, безнең разведка белән бәйләнешкә керергә тырыша. Шул максат белән, ул квартирасында аерым детальләрдән радиотапшыргыч җыя.

1943 елның августында һич тә көтмәгәндә кулга алулар башлана...

Совет патриотларының эшен тикшерү биш ай дәвам итә. Әлбәттә, төрмә иҗат итү урыны түгел, бигрәк тә үлемгә хөкем ителгәннәр камерасы. Әмма Җәлил шул шартларда да иҗат эшен дәвам иттерә.

1942 елның маенда рейхстаг фюрерның иң югары хөкем итү дип игълан иткәннән соң, фашист юстициясе аның санкциясеннән башка үзлегеннән берничә карар да чыгара алмый. Шуңа күрә, мөгаен, «Идел-Урал» комитетындагы үнбер татарның «җимерү эшләре» турында хәбәр алганнан соң, Гитлер, «җинаятьче»ләр мөсельман булганга, «нейтраль» Төркия белән бәйләнешне истә тотып, хөкем процессын закон нигезендә үткәрергә кушкандыр. Ә «закон нигезендә» суд эшләрен башкару, әлбәттә, үлем җәзасы бирүне гарантияләгән.



*Дрезден шәһәр төрмәсе бинасы*

1944 елның февраль азагында җәлилчеләрне Берлиннан Дрезденга китергәннәр. Дрезден төрмәсендә, һәрберсе аерым камераларда утырганда, аларга хөкем карарын җиткерәләр. Патриотларны коммунистик нигезгә корылган, дошман булган дәүләт рамкаларындагы оешмада эш алып баруда, коралларын фашистик дәүләткә каршы юнәлтергә чакырып, легионерлар арасында листовкалар бастырып таратуда, җинаятьчел төстә чит ил радиостанцияләрен тыңлауда гаеплиләр. Легиондагы коралны күтәрелешне, легионерларның партизаннар ягына чыгуын аларның яшерен эшләренең нәтиҗәсе итеп карыйлар. Ә Әхмәт Симаев, болардан тыш, Совет командованиесе тарафыннан җибәрелгән разведчик буларак та гаепләнә.

Воскресенск шәһәренең «Коммунист» редакциясендә Әхмәт Симаевны акрынлап оныталар. Аны белгән кешеләр төрлесе төрле якка таралып бетә. Җитмәсә тагын шәһәрдә: «Симаев әсир төшкән икән», дигән хәбәр тарала. Әхмәт семьясы зур кичерешләр белән яши.

1945 елның ноябрендә генә: «Кызылармеец Симаев Әхмәт Садретдин улы герман әсирлегендә 1944 елның февралендә концентрацион лагерьда һәлак булды»,— дигән хәбәр килә.

Озакламый, кызыл кара белән язылган бер хат килеп төшә. Совет Армиясе лейтенанты Лукьянов анда, безнең гаскәрләр Дрезден төрмәсен алганнан соң, төрмә стенасына язып калдырылган түбәндәге сүзләрне укуы турында яза: «Монда Әхмәт Симаев утырды. Журналист, Мәскәүле. Без Россиядән унбер кеше. Без барыбыз да икенче герман империя суды тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителдек. Бу язуны тапкан кешедән, әгәр ул Ватанга исән-сау кайтса, безнең язмыш турында туганнарыбызга һәм якыннарыбызга хәбәр итүен үтенәм. 24 март, 1944 ел».

Бельгиядән Андре Тиммерманс тапшырган нәни дәфтәр кайтып җиткәнче үк, бу язу Муса Җәлил турында дөреслекне эзләүчеләргә юл күрсәтүче маяк булды.

Дошман тылында фашизм белән көрәшнең данлы сәхифәләрен актару нәкъ менә шул язудан башланып китте.

Шамил Рәкыйпов

# ЕГЕРМЕ ИКЕНЕҢ БЕРСЕ

ОЧЕРК



Мин сезгә моннан утыз ел элек булып узган бер вакыйга турында сөйләргә телим.

Күз алдыгызга китерегез: горизонтта мәһабәт сопкалар тезелешеп тора. Аларның Безымянная, Тигровая, Заозерная, Сахарная Головка дип аталганнары иртән кояш чыкканда зәп-зәңгәр томан эчендә калалар. Азрак җил исеп куйды исә томан тарала башлый. Менә шул чагында сезнең каршыгызда гаҗәеп күп төрле төсләр белән җемелдәп сихри бер дөнья ачыла. Тау итәкләрендә ямь-яшел агачлар, хуш исле печәне, мең төрле авыруга дәва булырлык чәчкәләре, авыз суларыңны китерерлек тәмле җиләге белән дан тоткан үзәнлекләр, әрәмәләр, болыннар пәйда була.

Мондагы урманнарда кыргый җәнлекләр һәм киек-кошлар бихисап күп. Чиста сулы күлләр, чем-кара туфраклы басулар да аз түгел бу якларда. Күлләрендә эре балыклар, вак маймычлар мыжлап тора, кырларында исә дөге, бодай, соя мул уңыш бирә. Болардан тыш биредә катлам-катлам булып яткан ташкүмер массивларын күреп хәйран каласың. Әгәр инде күп санлы бухталары булган Посьет култыгы, андагы ифрат уңайлы гаваньнар турында сөйли башласаң... Әйе, алар теләсә нинди диңгезченә үзләренә гашыйк итәрлек. Бу җирләр борын-борын заманнан Россиянеке исәпләнгән.

Көтмәгәндә, җәйге челләдә күктән яуган салкын кар шикелле, 1938 елның 20 июлендә япон илчесе Сигемитсу Хасан күленнән көнбатыш яктарак урнашкан бу җирләргә үз хөкүмәтенең дәгъвасы барлыгын белдерде, аннан совет гаскәрләрен алуны таләп итте.

Ә 29 июльдә көндезге сәгать дүрттә...

Чик сакчылары заставадан дүрт-биш километр ераклыктагы үзәнлеккә печән чабарга киттеләр. Тирә-якта берсеннән-берсе биек, берсеннән-берсе мәһабәт сопкалар. Атлар ак, кызыл, зәңгәр һәм башка төстәге чәчәкләр белән чуарланган үзәндә бөдрәләнеп, берсе икенчесенә уралып үскән үләннәрне күкрәкләре белән ерып баралар. Билгеләнгән урынга килеп җиткәч, кораллар өчаяк сыман итеп бер-берсенә сөяп куелды. Сузып-сузып чалгы янаган тавышлар ишетелде. Аннары чик сакчылары, киек казлар кебек тезелешеп, үзәнлекне иңли башладылар. Иң алдан уртача буйлы, киң җилкәле, җитез хәрәкәтле бер егет басты да чалгысын селтәп җибәрде. Ул — отделком Батыршин. Аның эзләренә баса-баса диярлек буйга Батыршиннан бераз калкурак украин егете Чернопятко селтәнеп бара. Алар элек-электән үк якын дуслар. Лисичанскидагы тау техникумын да бергә тәмамладылар, шахтада да бергә эшләделәр. Менә бирегә дә бергә алар... Иван һәр яклап Батыршинга охшарга тырыша. Бүтәннәр алардан шактый артка калдылар. Күренеп тора: кулларына чалгы тотып, үз гомерләрендә беренче тапкыр печән чабарга чыккан шәһәр егетләре. Ә печән чабу ул крестьян эше белән яшьтән үк таныш булганнарның да беләкләрен тиз талчыктыра. Чабыласы җир бик акрын кими. Ни өчен дисәң, покосны киң алып булмый — үләне куе һәм биек.



Аның караvы, һавасы ни тора, һавасы! Күк йөзендә кояш елмая, әрәмә буйларында кошлар сайраша. Үлән төбе дымлы: киселгән сабакларның яфрак-чәчәкләрендә әле кибеп бетәргә өлгермәгән көмеш чыклар җемелди.

Табигать кочагында хозурланып, төшкә чаклы ару-талуны белмичә эшләделәр. Отделение командиры Батыршин яшь солдат Кабушкинны үз янына чакырып алды. Чалгысының чөен какты, очы белән җиргә кадалмасын өчен чалгыны ничек тотарга, покос алган чакта ничегрәк селтәнергә икәнлеген күрсәтте.

— Шәһәр егете булырга охшыйсың, кайдан син? — дип сорады ул Кабушкиннан.

— Казаннан.

— Казаннан?! Кунакка килеп бер атна үткәч, саумы, кодагый, дигәндәй, ник моны башта ук әйтмәдең? Мин дә Казаннан ич, канатым!

— Сезне Донбасстан диделәр бит, иптәш отделком.

— Татарстаннан мин. Ә Донбасста җиденчене бетердем, аннары ике ел шахтада эшләдем. Маркшейдер идем. Глубокий руднигында. Әти-әниләрем хәзер дә Казанда. Әтием дә шахтер иде. Хәзер, ул эшли торган җирдәге профессор сүзләре белән әйтсәк, Әбүбәкер Хөснетдинович медицина институтында хуҗалык эшләре мөдире. Сез кайсы урамда торасыз?

— Карл Маркс урамында, иптәш отделком. Авыл хуҗалыгы институты йортында.

— Менә әкәмәт! Яшәвебез дә, эшләвебез дә институтларда икән безнең. Үзебез генә чи наданнар.— Батыршин көлеп куйды. Аннары күзен кыскалап элеккегечә күтәренке рухта дәвам итте:— Ничего, Ваня, муенга утыртылган котелокларыбыз форма өчен генә куелмаган булса, укырга да өлгерербез әле. Менә мин үзем, соң булса да уң булсын дигәндәй, инә белән кое казый башларга исәплим. Безнең халык белем алуны шулай ди. Укырга беркайчан да соң түгел, Ваня. Укырга кирәк безгә, укырга...

— Сорарга рөхсәт итегез, иптәш отделком: ә сезнең семья Казанда кайсы урамда тора?

— Маяковский урамында. Минем анда калган энекәшләр, ачуым килмәгәе, үзләре бер отделение булыр!

— Уһу, шулай укмени?

— Өчәү. Сафиулла, Ибраһим һәм Әнвәр. Әнвәр — балалар йортыннан. Аның әнисе үлгән булган. Хәзер бездә үсә. Мировой егет. Я, әйдә, азрак ял итеп алыйк...

Гыйльфан хуш исле печән өстенә чалкан ятты да, ниндидер уйга чумып, күзләрен йомды. Нәрсә уйлый икән ул? Казанда яшәүче туганнарын сагынамы, әллә Донбасстагы дуслары, эшләгән шахтасы, беренче тапкыр забойга төшүе турында уйлыймы?..

Менә Иванга постка басар вакыт та җитте. Солдат һәр җирдә солдат булып кала: урманда утын киссә дә, болында печән чапса да. Ул һәрвакыт уяу, сизгер булырга тиеш. Чик буенда исә бу уяулык һәм сизгерлек икеләтә, өчләтә таләп ителә.

Чик сакчылары ял итәләр. Үзәнлекнең сул ягында иярләре ычкындырылмаган атлар утлап йөри. Алар, башларын чайкый-чайкый, койрыклары белән селтәнәләр, тибенәләр. Печән өсте бит: чебен-черкинең күп чагы. Горизонтта сопкалар, шул сопкалар итәгеннән безнең чикләр сузыла... Чү, саңгырау гына яңгырап, атыш тавышлары ишетелә түгелме? Көтмәгәндә якындагы сопкалар арасындагы сукмак буйлап җан-фәрманга чабып килүче җайдак күренде. Иван, мылтыгын алга сузып, аңа туктарга ишарәләде. Кызылармеец, сакчы таләбенә буйсынып, атыннан сикереп төште, парольне әйтте һәм: «Япон самурайлары чикне боздылар!» — диде.

— Коралга!

Барысы да күз ачып йомганчы атларга сикереп атландылар һәм җан-фәрманга чаптырып Хасан күле районына юл тоттылар. Бу минутта Батыршин, әйтерсең, бөтенләй икенче бер кешегә әверелде. Тешләрен чытырдатып кысканга, аның ияк сөякләре

калкып чыккан, гәүдәсе алга таба авышкан, күзләре уттай яна иде. Самурайлар белән кайдарак бәрелешергә туры киләчәген юлда барганда ук күз алдына китерде, күңелennән ул үзенең отделениесен сопка түбәсенә ничек урнаштырсаң уңайлырак булачагы турында уйланды, кызылармеецларның коралларын барлады.

Алда көзге төсле җемелдәп яткан Хасан күле күренде. Күл өсте тыныч. Яр кырыендагы озын камышлар да, үз-үзләрен онытып нәрсәдер тыңлаган шикелле, тыптын торалар. Шул камышлар арасыннан әра-тирә генә пырылдап кыр үрдәкләре күтәрелә. Кинәт камышлар чайкалып куйды. Батыршин «Әзерләнергә!» — дип боерык бирергә дә өлгермәде, бер төркем кызылармеецлар белән застава начальнигы лейтенант Терешкин килеп чыкты.

— Молодцы, егетләр, тиз килеп җиттегез,— диде ул һәм күл читенә таба ишарәләде.— Атларны шунда калдырыгыз...

Барысы да аның артыннан иярделәр. Менә алар, куе камышларны аера-аера, күл читенә якынлаштылар. Анда борынына кул пулеметы куелган көймә инде күптән әзер тора иде. Чик сакчылары ишкәкләргә тотындылар. Лейтенант аларга кузгалырга боерды.

Тирә-юньне дикъкать белән күзәтеп, сак кына, тавыш-тынсыз гына иштеләр. Әлегә шикләнерлек берни дә сизелмәде. Менә алар ярга чыктылар һәм бераз баргач сопкага күтәрелә башладылар. Кояш баеп килә. Шулай да көн һаман бөркү. Эсселектән гаҗиз булган табигать, әйтерсең, тын гына йокымсырый. Кая карама чәчәкләр, чәчәкләр... Җыясы иде хәзер шул чәчәкләрне уч тутырып, бүләк итәсе иде аларны бер генә минутка да күз алдыннан китми торган иң кадерле, иң якын кешеләргә. Алар да, назлы чәчәкләр дә, шушындый матур үзәнлеккә үлем кул сузуын белмиләр шул әле. Япон самурайлары алып килә ул үлемне. Әнә Безымянная биеклегендә атышлар бара. Ярсып-ярсып пулеметлар тырылдый, гранаталар шартлый.

Застава начальнигы лейтенант Терешкин Батыршинга отделениесе белән янәшәдәге биеклек итәгенә — күлнең көньяк өлешенә күчәргә боерык бирде.

— Үзәнлекне күзәт, Малахин отрядына булышырсың,— дип өстәде ул, Батыршин боерыкны кабатлагач.

Офык артына батып баручы кояшны томалап, кинәт куе болытлар агыла башлады. Озак та үтмәде, коеп яңгыр яварга тотынды. Чытырдатып яшен яшьнәде, көчле күк күкрәвенә миналар һәм снарядлар гөрселдәве кушылды. Үзләре ачкан утка ышыкланып, самурайлар киләләр дә киләләр. Терешкинның унпап сугышчысына каршы саранча өере чаклы гаскәр агыла. Лейтенант нәрсә дип Батыршин отделениесен үз янынннан җибәргәндер. Бу тикле көчкә ничек каршы торыр ул? Ләкин боерык үтәлергә тиеш.

Батыршин шуны бик ачык аңлый: дошман Хасан күле районындагы Заозерная һәм Безымянная биеклекләрен алып, Посьет култыгына хуҗа булырга, шуннан Владивостокка һөҗүм башларга ниятли.

Юк инде, пограничниклар исән чакта бу мәкерле план алай ансат кына гамәлгә ашмаячак.

Батыршин үз отделениесе белән яңа позициягә күчте. Кулындагы бинокльдән күзләрен ул үзәнлеккә һәм Заозерная биеклегенә текәгән. Анда каты бәрелеш бара. Лейтенант Терешкин егетләре, пулеметтан атып, самурайларның бер өлешен җиргә сыенырга мәҗбүр итте. Ә бер төркеме үзәнлеккә үтәргә омтылды. Терешкин отделениене менә ни өчен бирегә җибәргән икән. Самурайлар Малахин отрядын чолганышта калдырырга исәп итәләр. Алар әле Батыршин отделениесенең монда яшеренеп ятуын белмиләр. Килегез, бәдбәхетләр, әйдә, якынрак килегез.

Самурайларның инде еш-еш сулыш алуларына кадәр ишетелә кебек. Аларның якалары ычкындырылган, җиңнәре беләккәчә сызганылган. Пычак шикелле штыклары алга сузылган. Песи кук сак кына басып атласалар да, кызу атлыйлар. Менә инде алар якын ук килеп җиттеләр. Шулчак Батыршинның командасы яңгырады.

— Огонь!

Пулемет, тегү машинасы кебек тигез текелдәп, дошманга ут яудыра башлады. Бу яктан үзләренә берниндм каршылык көтмәгән самурайлар җиргә дистәләп-дисталәп аудылар. Куркып кычкырган, ыңгырашкан тавышлар ишетелде. Шулай да аларның бер төркеме әле атуыннан һаман да туктамаган иде. Әле анда, әле монда гранаталар шартлады. Ахырда японнар барыбер үкчә ялтыратырга мәҗбүр булдылар.

— Утны туктатырга! — дип кычкырды Батыршин, алар күздән югалгач.— Патроннарны саклыйк, егетләр. Бөтенләйгә китүләре түгел әле бу кысык күзләрнең. Менә күрерсез: алар тагын борылып килачәкләр. Ягез, мөмкинлектән файдаланып, бераз тамак ялгап алыйк...

Отделение командиры, әченнән нидер көйли-көйли, консерв банкасын ачарга кереште, иптәшләренең күңелен күтәрергә теләп, ара-тирә шаяртып, терле мәзәкләр сөйләп алды. Әйтерсең, ул моннан биш кенә минут элек үлем белән йөзгә-йөз очрашмаган, әйтерсең, менә хәзер генә чираттагы увольнениедән кайтып кергән!

Батыршин белә: солдатның күңеле күтәренке булса, аңа берни дә куркыныч түгел. Ядрәләр явып торганда марш уйнасаң, солдат Карпат тавына да менә, дип тикмәгә генә әйтмиләр ич.

Төн житте. Карпат якларында төннәр ниндидер, ә бирегә алар күзгә төртсәң күренмәслек караңгы булалар. Монда бар ышаныч колакларда. Батыршинның егетләре таңга кадәр чиратлашып сакта тордылар. Төн тыныч кына үтте. Самурайлар көндез дә күренмәделәр. Әмма кич житүгә чик буенда яңадан хәрәкәт башланды. Башта берәнсәрән атылган мылтык тавышлары ишетелде, аннары артиллерия эшкә кереште, танклар үкерергә тотынды.

— Ну, сынатмыйк, дусларым! — диде Батыршин һәм каскасын иплэбрәк киеп, бил каешын кыса төште.— Курыкмагыз. Курыкмаган кешедән жен үзе өркә, диләр Донбасс шахтерлары.

Сары төстәге гигант ташбакаларга охшаган танклар Заозерная биеклегенә таба юнәлделәр һәм, үзәнлеккә житкәч, күздән югалдылар.

Ажгырып кузгалган танкларны күрүгә барысының да тәннәре чымырдап, эсселесуыклы булып китте. Әйе, танк кадәр танкка каршы тору уен эш түгел. Аңа син аткан пулялар стенага борчак сибү белән бер. Тубыннан да ата, пулеметыннан да сиптерә, инде алай гына жиңә алмый икән, якын ук килеп окобың өстенә менә, кинәт борылып, үзеңне тереләй кабергә күмә.

Кем нинди хис кичергәндер, әмма дошман танкларын беренче күргән яшь солдат Иван Кабушкин шулай уйланды. Нигә булган хәлне яшерергә: ярый әле ул аждаһалар безнең өскә килми дип, эчтән генә сөенеп тә куйды ул. Биеклектә көчле шартлау тавышы яңгырагач, жиргә тагын да ныграк сыена төште, аның чырае агарды.

Заозерная биеклегендә кабат гөрселдәгән яман шартлаулар һаваны тетрәтте. Иванның күңелендәге баягы уй яңадан баш калкытты: «Ярый әле... бәлки»...

Ләкин үз-үзен юкка гына тынычландырган икән: дошманның бер танкысы алар саклый торган үзәнлеккә килеп чыкты. Ахрысы, ул Малахин отрядының артына төшәргә исәпли иде. Нинди карарга килер икән хәзер отделком Батыршин, засадада отряд барлыгын сиздереп, батырларча, танкка каршы чыгармы, әллә бу очрашудан шүрләп, аны үткәреп жибәрерме? Мөгаен, үткәреп жибәрер...

Танкны инде күптәннән күзәтеп торган Батыршин, катлаулы мәсьәлә чишәргә җыенган укучы кебек, башын кашып куйды, нәрсәдәндер риза булмыйча борынын жыерды. Аның күзләре кысыла төште, маңгай жыерчыклары тирәнәйде.

Тынгысыз Иванның күңелендәге кызыксыну көчәйгәннән-көчәйде: нишләр икән отделком хәзер, бу бәладән котылыр өчен нинди жай табар икән?

— Кызылармеец Кабушкин! Минем арттан!

Батыршин окопка иелеп, аннан патрон әрҗәсенә охшаган ниндидер яшел тартма алды да, шуышып куе үлән арасына кереп китте. Кабушкин аның артыннан иярде. Димәк, алар танк алдына чыгып, шушы «күчтәнәч»не аның юлына күмеп өлгерергә тиешләр.

Алда — чик сакчылары дозорга йөри торган сукмак. Танк шул сукмак буйлап үтәргә тиеш. Чөнки бирегә башка юл юк. Ләкин ничек үтәр: бер як чылбыры белән сукмакны таптап үтәрме, әллә аны уртада калдырырмы?

Батыршин туктап танк гөрелдәвен тыңлады, тир бәреп чыккан маңгаен жиңе белән сөртеп алды һәм еш-еш сулап:

— Менә шушында... тол сыярлык итеп казы,— диде. Үзе кулындагы тартманың шнурын ашыга-ашыга сүтәргә кереште.

Сукмакка шуышып килгән жирдә сөрлегеп калган үләннәрне торгыза-торгыза кире чигенделәр һәм жиргә ятып көтә башладылар.

Танк алар янына килеп җитүгә, Батыршин шнурны үзенә тартты. Коточкыч шартлау бөтен үзәнлекне дер селкетте. Йөзгә көчле һава дулкыны китереп бәрде, тирәякка әче ис таралды, танк төтенли-төтенли яна башлады.

— Иплән кирәк, җайлап кирәк,— диде Батыршин, еш кына үзе яратып җырлый торган җырның сүзләрен кабатлап һәм кайту ягына борылырга ишарә ясады.

Кабушкин командирының куркусызлыгына һәм салкын канлылыгына гаҗәпләнми булдыра алмады: ни өчен бу кеше белән бергә булганда иң-иң куркыныч нәрсәләр дә алай булып тоелмый икән? Нәрсәдә икән моның хикмәте? Кабаланмый, үз-үзен өзгәләми, тәвәккәл... Менә кемнән өйрәнергә кирәк батырлыкка.

Яңадан үзәнлеккә әйләнеп кайттылар. Күршедәге Заозерная биеклегендә сугыш җәһәннәм төсен алган. Самурайлар, ярсыган диңгез дулкыннары кебек, бер-бер артлы килеп һөҗүм итәләр дә, таш кыяга бәрелгәндәй, кирегә мәтәләләр. Аларның сафлары сирәгәя, тау итәгендә хәрәкәтсез яткан гәүдәләр арта бара. Ләкин моңа карап аларның тукталырга исәпләре юк. «Банзай!» дип кычкыра-кычкыра алар кабат һөҗүмгә ташланалар. Безнекеләрнең давыллы пулемет утына эләккәч, кабат чигенергә мәҗбүр булалар, әмма озак та үтми, тагын күтәреләләр.

Менә алар яңадан үзәнлеккә таба үрмәли башладылар. Батыршин отделениесе чакырылмаган кунакларны бу юлы да мылтыклар һәм пулеметлар сые белән каршылады.

Японнарның авыр артиллериясе пограничниклар позициясенә туктаусыз снарядлар яудыра. Снаряд төшеп ярылган саен, көпшәк җир тетрәнеп куя, күккә чөелгән су фонтаныннан чәчрәгән тамчылар биткә тиеп, туктаусыз атудан кызган пулемет көпшәләрен чаж-чож иттерә.

Батыршин янына Иван Чернопятко шуышып килде.

— Яраланучылар ничәү? — дип сорады ул, дустының флягасыннан йотлыга-йотлыга су эчеп.

— Алтау.

— Лейтенант яралыларны кичекмәстән күлнең теге ягына чыгарырга кушты. Хәзергә утны да туктатмаска боерды.

— Боерык үтәлер.

— Хуш, Гыйльфан. Әгәр ул-бу була калса...

— Шайтаным да булмас... Я, сау бул.

Чернопятко килгән юлыннан шуышып кире китеп барды. «Яралыларны теге якка кем чыгарыр? Яшь солдат Кабушкинмы? Ул бик сыек күренә. Ярый ла йөзә белсә... Әгәр белмәсә... үземә чыгарырга туры киләчәк».

Бу урында күлнең киңлеге ярты километр чамасы. Гыйльфан итекләрен, гимнастеркасын салып ташлады. Яралы бер сугышчыны аркасына күтәреп, суга сикерде һәм тирән итеп сулыш ала-ала сыңар куллап йөзеп китте. Малай чакта тырыша-тырыша йөзәргә өйрәнү менә кайчан ярап куйды аңа. Японнар күлгә пулеметтан атарлык якын түгел. Әмма снаряд һәм миналар уч иткән шикелле әле алда, әле артта гөрселдәп шартлыйлар. Һава дулкыны башка китереп бәрә, шарлавыктай томырылган су бөтереләп, күлдәгеләрне өрле-бирле айкый, Батыршин сизә: боерыкны үтәү җиңел булмаячак, кулларның җеп өзәрлек тә хәле калмады, йөрәк авыр йөк астында калып тыпырчынган шикелле еш-еш тибә. Менә, ниһаять, аяклар җиргә тиде. Батыршин судан чайкала-чайкала чыкты да яралы иптәшен яр читендәге куаклык төбенә яткырды һәм яңадан каршы як ярга таба йөзеп китте.

Менә аның аркасында тагын бер яралы. Тагын мең газаплар белән күлне кичү. Ул инде вакыт исәбен дә, ару-талуны да онытты. Аның күңелендә бары тик бер генә уй: тагын биш сугышчыны алып чыгасы бар... Дүртәү калды, өчәү... Менә соңгысы... Кем белә, әгәр яралылар уникеләп булса, бәлки унике тапкыр йөзеп чыгарлык куәт табар иде әле ул үзендә. Кеше үз бурычын тирәнтен аңласа, аны үтәргә чын күңеленнән алынса, аның тәне-йөрәге шул зур бурычны үтәп чыгу өчен гаҗәеп бер җегәргә ия була, һәм ул барысына да түзә икән.

Үзәнлектәге атышлар вакытында тагын берничә кеше яраланды. Батыршин ул көнне авыр яралы сигез сугышчыны үлемнән коткарды. Соңгы тапкыр күлне иңләгәндә ул аңын җуя язды. Наганы төшеп калган иде, бәлки, чума-чума шуны эзләү дә, күп өстенә чүмәлә дигәндәй, хәлне мөшкелләткәндер. Коралны табып, ярга чыгып егылгач,

атышлар басыла төшүен шәйләп алды. «Безнекеләрне кырып бетерделәрме әллә? — дигән шөбһәле уй йөрәген чәнчеп үтте аның.— Юк, булмас. Анда застава начальнигы лейтенант Терешкин, якын дусты Чернопятко. Әнә, мылтык тавышлары яңадан ишетелә башлады. Тизрәк ярдәмгә!»

Батыршин камышлар арасына йөгерде. Кайда булыр хәзер аның иптәшләре?.. Тукта, нишләп атышлар кинәт тагын тынып калды соң әле? Яр буйлап бераз баргач, ул хәрәкәтсез яткан ике кешегә килеп юлыкты. Болар Чернопятко белән Кабушкин иде. Алар бер-ике генә тапкыр булса да иркенләп сулыш алыр өчен шуләй тукталып калганнар икән. Батыршин Чернопятконың яраланган булуын күреп алды.

— Ваня, дустым, хәлең ничек?

— Ярыйсы, Гыйльфан... Үрмәлибез менә...

— Ә лейтенант кайда?

— Алар Спесивцев белән... ут ачып безне каплый-каплый чигенәләр.

— Алайса мин дә аларга ярдәмгә ашыгыйм.

Японнарның артиллерия уты көчәйгәннән-көчәя. Әйтерсең, дөньяның асты-өскә килә. Җир актарыла, камышлар дерләп яна, әче төтен сулышны буа, тончыктыра.

Шушы җәһәннәм эченнән Терешкинны эзләп табарга кирәк.

Атышлар кайдадыр сул яктарак ишетелә башлады. Ул да булмады, кул пулеметы сөйрәп, камышлар арасыннан кызылармеец Спесивцев килеп чыкты.

Батыршин карашын аның күзләренә төбәде.

— Мин уң флангны каплап тордым,— диде Спесивцев, Батыршинның сораулы карашына җавап итеп.— Ул... бер ун минут чамасы бардыр инде — атмый.

— Киттек, Ваня, лейтенантны эзләргә!

Бу җирләр хәзер дошман кулында. Монда барыннан да элек саклык, сабырлык таләп ителә. Терешкин исәндер? Бәлки, авыр яраланып, атарлык хәле генә калмагандыр? Әнә аның пулемет көпшәсе тырпаеп тора. Ә һушын җуйган лейтенант үзе пулемет кырында чалкан ята. Ут телләре аңа таба үрмәли. Янып күмерләнгән камыш сабаклары чыжылдап суга ава...

Батыршин юлбарыс җитезлеге белән алга ыргылды. Менә ул балчыкка, канга буялган застава начальнигының күкрәгенә колагын куеп тыңларга керешә. Застава начальнигы ишетелер-ишетелмәс кенә ыңгырашып куйды.

— Иптәш лейтенант! Иптәш лейтенант!.. Спесивцев! Бинт китер! Тизрәк носилка әмәллә!

Яраларын бәйләп, лейтенантны носилкага салдылар. Тез тиңентен ләмгә бата-бата, акрын гына кузгалып киттеләр. Ләкин озак барырга туры килмәде, япон пулеметы карт эт кебек ырылдый башлады. Уңда да, сулда да чиелдек ямьсез тавыш белән самурайлар кычкырыша. Баш очыннан сызгырып үткән пулялар камыш сабакларын, куак тармакларын кыеп-кыеп төшерәләр...

Атышлар бераз тынгандай булды. Ләкин Терешкинны носилкада аягүрә күтәреп бару куркыныч иде әле. Винтовкалардан ясалган носилкага бил каешларын бәйләп түш белән шуышырга керештеләр. Шулай өч километр ара үтелде, ниһаять, Безымянный биеклегенең көнчыгыш кашагасына килеп чыктылар. Якында гына танк моторы тавышы ишетелде. «Безнекеләр!»

Дөрестән дә, безнең танк иде бу. Яралыны танк өстенә күтәреп салдылар. Ләкин бераз баргач та, танк тукталып калырга мәҗбүр булды. Алда бар нәрсәне үзенә суырып ала торган сазлык башланып китте. Хәзер инде кайтырга бары тик бер генә юл калган иде, күл аша... Батыршин аны тугызынчы тапкыр кичәргә әзерләнде.

Менә ул застава начальнигын җилкәсенә күтәрде, саклык белән генә суга керде һәм акрын гына йөзәргә тотынды.

Бу юлы ул аргы якка чыгып җитә алырмы? Хәлдән таеп тәмам һушыннан язмасмы? Юк, ул анда ничек кенә булса да чыгып җитәргә тиеш.

...Лейтенант Терешкинны госпитальгә салдылар. Батыршин үзе дә яраланган булган икән: аны да шунда калдырмакчылар иде, калмады.

Хасан күле районында япон сугыш чукмарлары башлап җибәргән сугыш унөч көн дәвам итте. Алган биеклекләрен ныгытып, яңа өстәмә көчләр туплаган хәлдә, алар ныклы каршылык күрсәттеләр. 6 августта безнең җәяүле гаскәрләр, артиллерия,

дылар. Икенче көнне дошман егерме тапкыр контрһөҗүмгә күтәрелеп карады. Ләкин 650 солдат һәм офицерын югалтып, кире чигенде. Ахырда самурайлар килешү сорарга мәҗбүр булдылар.

Ватан үз улларының батырлыгына бик зур бәя бирде. Йөзләрчә кызылармеецлар һәм командирлар медальләр һәм орденнар белән бүләкләнделәр. Ә аеруча зур кыюлык күрсәткән егерме ике батырга Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Алар арасында лейтенант П. Ф. Терешкин, отделение командиры Гыйльфан Батыршин һәм аның якын дусты Иван Чернопятко да бар иде.

Совет Татарстаны үзенең беренче Героен зур хөрмәт белән каршылады. Батыршин завод-фабрикаларда, колхоз һәм совхозларда, мәктәпләрдә кунак булды, якташларына сугыш эпизодлары турында сөйләде, аларның хезмәттәге уңышлары, тормышлары белән кызыксынды...

Бөек Ватан сугышын Гыйльфан Хәрби академияне тәмамлап каршылый. Илебез өстенә дәһшәтле үлем килгәндә, ул тагын алгы сызыкта. Майор Батыршин сугыштан җиңүче булып Мәскәүгә кайта. Аның күкрәген, күрсәткән батырлыкларының билгесе булып, күп санлы орденнар һәм медальләр бизи.

Сугыштан кайткач, ул озак ял итми: күңеле аны кабат чик буйларына чакыра. Хәрби хезмәттән буш вакытларында гарәп һәм инглиз телләрен өйрәнә.

1947 ел. Токио. Бу шәһәр ул чакта бөтен дөнья җәмәгатьчелегенең игътибар үзәгендә торды. Биредә иң югары чинлы япон хәрби җинаятьчеләрен хөкем итү процессы барды.

Менә җир шарында чыга торган күп санлы газеталардан килгән хәбәрчеләр, хөкем процессында катнашучы башка барлык кешеләр совет офицеры Гыйльфан Батыршинның речен тыңлыйлар. Аның шаһитлек күрсәтмәләре чын дипломатларныкы кебек тирән эчтәлекле, кыска һәм кире кагылмаслык. Батыршин япон империалистларының Хасан күле районындагы ерткычлыкларын һәркемне ышандырырлык дәлилләр белән фаш итә. Аның гаепләү сүзләрен чик сакчысы Иван Чернопятко да куәтли.

Кайтканда алар чик буендагы хәрби тормышның бөтен ваклыкларына чаклы искә төшерделәр, сугышта һәлак булган дусларын, иптәшләрен юксындылар.

Самолет болытлар өстеннән оча. Моторлар тигез гүли. Вакыт-вакыт болытлар арасында хасил булган «тәрәзәләр»дән диңгез өсте күренеп-күренеп кала. Туган ил ярларына да ерак калмый инде. Әмма шулчак самолет кинәт тетрәнеп куя һәм, атылган кош кебек, түбәнгә мәтәлә. Усал дулкыннар һәлакәткә очраган самолетны үз кочагына ала... Бу бәхетсезлек 1947 елның 1 декабрь көнендә була.

Үз халкы, үз Ватаны өчен искиткеч фидакарьлек эшләгән, тиңсез батырлыклар күрсәткән кешенең йөрәге тибүдән туктаса да, ул күңелләрдә яши.

Илебез чикләре буендагы заставаларның берсендә һәркөн ике тапкыр отделком Батыршин фамилиясе яңгырый, яшь солдатлар аңа багышланган стенд янында Ватанга соңгы сулышкача турылыклы булырга ант итәләр. Хәзер менә ике дус — игезәк ике кораб ерак көнчыгышның ахактай сулы диңгезләрен иңли. Алар — «Гыйльфан Батыршин» һәм «Иван Чернопятко» исемле океан пароходлары. Әйтерсең, мәңге аерылмас бу ике дус төпсез упкыннар кочагыннан ычкынганнар да, корыч броняга төренгән баһадирлар шикелле, илләр гизәргә, кешелеккә яңа бәхетләр яуларга чыкканнар...

**А. Марченко,**
тарих фәннәре кандидаты

# ДУСЛЫК КИЧТЕ УТЛЫ ЮЛЛАРНЫ

Узган елның декабрь аенда Советлар Союзы һәм Чехословакия арасында үзара ярдәмләшү, хезмәттәшлек һәм дуслык договорына кул куюга чирек гасыр тулды.

Бу дуслык фашизмга каршы көрәш елларында кан белән ныгыды, сугыштан соңгы төзелеш елларында сыналды.

Узган елның җәендә контрреволюцион элементлар Чехословакияне социалистик үсеш юлыннан алып ташларга маташтылар. «Демократияләштерү», «либераллаштыру» лозунглары астына яшеренеп, алар, көнбатыш империалистлары ярдәмендә, Чехословакия Коммунистлар партиясенә яла яктылар, халыкта коммунистларга карата булган ышанычны какшатырга тырыштылар.

Әмма халыкара империализмның һәм Чехословакиянең үзендәге реакцион көчләрнең бу мәкерле уйлары барып чыкмады. Чехословакия хезмәт ияләре, Советлар Союзы һәм башка социалистик илләр халыклары ярдәмендә, контрреволюциянең кабахәт планнарын җимерделәр. Социалистик интернационализм принципларына тугрылыклы чех халкы үзенең революцион сизгерлеген, Советлар Союзы белән ике арадагы дуслыкка бирелгәнлеген саклап калды. Шундый шартларда Совет-Чехословакия договорына кул куюга 25 ел тулуны билгеләп үтү чиксез зур әһәмияткә ия булды.

Билгеле булганча, СССР һәм Чехословакия арасында сугыш елларында ук төзелгән бу договор дуслык, үзара ярдәмләшү һәм сугыштан соң хезмәттәшлек турындагы беренче договор иде. Бу вакытта Лондонда урнашкан һәм башында президент Э. Бенеш торган эмиграциядәге чех хөкүмәте, халык массаларын үзеннән бөтенләй читләштерүдән куркып, әлеге договорга кул куярга мәҗбүр булды. Ул договорны төзү турында Бенеш Советлар Союзына 1943 елның март башларында тәкъдим ясады. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, президентның мондый карарга килүенә Советлар Союзының Сталинград янында җиңүе һәм безнең илебез территориясендә төзелгән чит ил хәрби берләшмәләренең беренче часте — Людвик Свобода командалыгындагы аерым чех батальонының фронтка чыгып китүе сәбәп булды.

Советлар Союзында чех хәрби частеның оеша башлау көне итеп 1942 елның 5 феврале — элеккеге чех армиясенең инде 1939 елның көзендә үк СССРда булган бер төркем солдат һәм офицерлары Оренбург өлкәсендәге Бозаулык шәһәренә килгән көн исәпләнә.

1941 елның 27 сентябрендә төзелгән совет-чех килешүендә Советлар Союзындагы барлык хәрби чех частьлары тулысы белән чех хәрби командованиесенә буйсынырга, ә бу частьларда хезмәт итүчеләр Чехословакия законнарын һәм Уставларын тегәл үтәргә тиешләр, диелгән иде. Күренүенчә, бу килешү буенча социалистик дәүләт территориясендә буржуаз хөкүмәткә, буржуаз республика законнарына, буржуаз армия уставларына буйсынучы чит ил хәрби частьлары төзү күздә тотыла. Чехословакия буржуазиясе исә бу частьларны беренче көннән үк үз йогынтысы астында тотарга өметләнде. Шулай итеп, чех буржуазиясе беренче планга антифашистик көрәш һәм милли-азатлык хәрәкәте максатларын түгел, Чехословакия территориясе фашистик Германиягә каршы сугышкан илләрнең гаскәрләре тарафыннан азат ителгәч, анда

партиясе бу чорда үзенең төп бурычы итеп немец-фашист оккупантларын җирдән тәмам себереп түгү бурычын санады. СССРда төзелгән чех хәрби частьлары йөзендә ул республика территориясен дошман оккупациясеннән азат итү өчен актив катнашучыны гына түгел, илдә социаль үзгәрешләр кертү өчен көрәшкә күтәреләчәк халык массаларының кораллы көчен күрде. Ул чакта СССРда яшәгән ЧКП җитәкчеләре. Советлар Союзында хәрби чех частьлары төзелә башлаган көннән үк, аларга карата зур игътибарлылык күрсәттеләр. Чех сугышчылары арасында эшләү өчен партиянең тәҗрибәле эшлеклеләре — ЧКП Үзәк Комитеты Политбюросының элекке членнары Богуслав Врбенский һәм Ченек Грушка, ЧКП Үзәк Комитеты членнары Ян Гарус, Йозеф Штетка, Иван Туряница, Ярослав Достал һәм башкалар җибәрелде. СССРдагы хәрби чех частьларында Клемент Готвальд, Ян Шверма, Вацлав Копецкий, Рудольф Сланский, Зденек Неедлы, Зденек Фирлингер һ. б. лар бар иде. ЧКПның хәрби чех частьларындагы партия оешмасы җитәкчесе итеп партиянең күренекле эшлеклесе, В. И. Ленин әсәрләрен чех теленә тәрҗемә итүче Ярослав Прохозка билгеләнде.

Хәрби чех часте сугышчыларын көрәшкә әзерләүдә, аларның политик аңлылыгын үстерүдә 1942 елның маенда Клемент Готвальдның Бозаулыкка килүе һәм барлык сугышчылар алдында чыгыш ясавы зур әһәмияткә ия булып тора. Чех коммунистларының даими кайгыртучанлыгы нәтиҗәсендә, 1942 елның җәенә батальондагы сугышчыларның күпчелеге мораль һәм политик яктан сугышка тулысынча әзер була. Моның шулай икәнлеген Людвик Свободаның, чех хәрби частен совет-герман фронтына җибәрүне сорап, Кызыл Армиянең Верховный Башкомандующиена язган хаты бик ачык раслый.

Чехословакия коммунистлары яшьләре, политик карашлары һәм социаль чыгышлары төрлечә булган патриотлардан кыска гына вакыт эчендә югары хәзерлекле сугышчан хәрби часть төзүгә ирештеләр.

Бу уңышларның нигезен ныгытуда җирле власть органнары һәм хәрби учреждениеләр йөзендә Советлар Союзы күрсәткән эчкерсез ярдәм хәлиткеч роль уйнады. Чех солдатларын һәм офицерларын хәрби-политик яктан хәзерләүгә майор Пархоменко җитәкчелегендәге хәрби комиссарлар көчләрен дә, вакытларын да кызганмадылар, фронт шартларына туры китереп, алар белән төрле-төрле сугыш өйрәнүләре уздырдылар. Кулларына корал алган чех сугышчылары данлы Кызыл Армия белән иңгә иң торып сугышуны үзләренә зур бәхет санадылар. Одесса, Севастополь, Москва, Ленинград һәм Сталинград сугышлары тудырган геройлар үрнәгендә үз-үзләрен аямыйча көрәштеләр.

1943 елның 2 февралендә полковник Людвик Свобода җитәкчелегендәге хәрби чех частеның фронтка китүе турында хәбәр игълан ителде.

* * *

Совет һәм чех солдатларының утлы юлларны кичкән сугышчан дуслыгы 1943 елның мартында Харьков янындагы сугышларда башланды. Бу дуслык Советлар Союзында яшәүче күп милләтле халыкларның, шул җөмләдән татар халкының, куркусыз улларын һәм кызларын берләштерде. Ул хакта сөйләүче документларның әле күбесе өйрәнелмәгән, батырларча һәлак булган геройларның әле исемнәре дә ачыкланып җитмәгән. Ләкин башка халыкларның, шул исәптән татар халкы вәкилләренең, уртак дошманга — герман фашизмына каршы чех сугышчылары белән иңгә иң торып сугышулары турында сөйләүче аерым эпизодларда да социалистик интернационализм үзенең ачык чагылышын таба. Ә Украинадагы Соколово авылы совет патриотизмы, социалистик интернационализм һәм халыкларның туганнарча дуслыгы мәңгелеккә кан белән беркетелгән урыннарның берсе булып тора. Соколово тирәсендәге җирләр руслар һәм чехлар, словаклар һәм украиннар, татарлар һәм осетиннар, грузиннар һәм әзербайҗаннар, үзбәкләр һәм башкортлар каны белән сугарылган.

Командирының фамилиясе белән «Свобода» дип аталган чех батальоны Харьковка 1943 елның 1 мартында килә һәм 3 мартка каршы төндә Соколово авылы янында оборона тотарга, Мжа елгасы аша дошманның бер генә танкысын да үткәрмәскә сугышчан приказ ала.

К. В. Билютин полкы белән П. Н. Широнин взводы булган 25 нче укчы дивизия гвардиячеләренең бердәм хәрәкәт итүе совет һәм чех солдатларының сугышчан дуслыгын тагын да ачыграк чагылдыра.

Широнин взводы гвардиячеләре украин панфиловчылары буларак билгеле. Аларның 25 сенә дә СССР Верховный Советы Президиумының 1943 ел 18 май Указы нигезендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Украина панфиловчыларының батырлыгына һәм үлемсезлегенә беренче буларак бәя биргән кеше татар халкының куркусыз улы подполковник Рәхмәтуллин була. Лейтенант П. Н. Широнин гвардиячеләренең батырлыгы турында донесение алынгач, 25 нче укчы дивизия составына кергән 15 нче укчы корпусның политбүлек начальнигы урынбасары подполковник Рәхмәтуллин 6 нчы армия политбүлек начальнигы полковник Ненешкога болай дип хәбәр итә: «Лейтенант Широнин взводы сугышчылары, дошман атакаларын геройларча кире кайтардылар һәм гранаталары беткәч тә бер адым да артка чикмәделәр. 25 нче укчы дивизия политбүлеге начальнигы иптәш Гречкога лейтенант Широнин взводының бөтен составын хөкүмәт бүләгенә тәкъдим итү, ә корбан булганнарны үзләре үлгәннән соң бүләкләү турында минем тарафтан күрсәтмә бирелде. Бу фактка бәйле рәвештә дивизиядә киң политик-масса эшләре җәелдерелә».

Гитлерчылар, Билютин полкы гвардиячеләре оборонасын өзә алмагач, Тарановканы читләп узалар һәм Соколово авылы янында оборона тоткан чех батальоны позицияләренә һөҗүм итәләр. Соколовода батальонның надпоручик Отакар Ярош командалыгындагы беренче ротасы сугыша. Аның ротасына надпоручик Ярослав Ломның пулемет ротасы, надпоручик (хәзер генерал-лейтенант, ЧССРның Москвадагы илчелеге каршындагы хәрби атташе) Франтишек Седлачекның танкка каршы ата торган мылтыклар белән коралланган ротасы, подпоручик (хәзер генерал-майор, Чехословакия Халык армиясенең Баш политик идарәсе начальнигы) Франтишек Бедржихның миномет взводы булышлык күрсәтә. Аларга совет артиллериясе ярдәмгә килә. Чех сугышчылары үз-үзләрен аямыйча көрәшәләр. Соколово авылының үзендә өлкән лейтенант Петр Филатов һәм лейтенант Николай Мутле батареялары сугыш алып бара. Коммунист Мутле артиллеристлары батареяның иң соңгы орудиясе сафтан чыкканга кадәр атуларын туктатмыйлар. Николай Артурович Мутле Чехословакиянең сугышчан ордены белән бүләкләнгән беренче совет офицеры була.

1943 елның 8 мартында булып узган бу сугышта полковник Людвик Свобода батальоны сугышчылары дошманның 19 танкын юк итәләр.

Соколово янындагы бәрелештә өлкән лейтенант Василий Степанович Петров батареясы дан казана. В. С. Петров ул вакытта баш командование резервындагы танкка каршы ата торган 595 нче артиллерия полкының 4 нче батареясы командиры була. Бу батареяда комсомолец сержант Госман Мөхәммәт улы Тимершин, егерме яшьлек коммунист Заһидулла Ибраһим улы Сунаев һәм Татарстан комсомолы сафларында тәрбияләнгән унтугыз яшьлек Борис Ганчурин хезмәт итә. Әгәр алар хәзерге көндә исән булсалар, үзләренең легендар командирлары турында безгә бик күп нәрсәләр сөйли алырлар иде.

Соколово сугышында катнашучылар арасында татар халкының батыр улы гвардия кече лейтенанты Тәлгать Шәмсетдинов та була. Ул 25 нче гвардия укчы дивизиясенең 81 нче полкында хезмәт иткән. Тәлгать Шәмсетдинов Соколово авылы уртасындагы туганнар каберлегенә Отакар Ярош белән рәттән күмелгән.

Казан художество училищесы студенты Тәлгать Гаяз улы Шәмсетдинов Советлар Ватанын яклау өчен кулына корал алганда, аңа әле унтугыз яшь тә тулмаган була. 1942 елның январенда ул Дон ярына урнашкан Горшечное авылы тирәләрендә барган сугышларга катнаша. Кече лейтенант Тәлгать Шәмсетдинов хезмәт иткән дивизия Воронеж фронты составына керә, Донга һәм Иделгә ыргылган дошманга каршы аяусыз сугышлар алып бара. Тәлгатьнең полк командиры белорус халкының куркусыз улы гвардия полковнигы Павел Константинович Казакевич була. Аның командалыгында полк Доннан алып Белгородка кадәр сугышчан юл үтә, аннан Казак Лопаны, Дергачины ала һәм 1943 елның февралендә Ольшана елгасы аша Харьковка бәреп керә.

Тәлгать Шәмсетдинов үзенең гвардиячеләре белән башта Змиев шәһәренең төньяк өлешендә, тимер юлга якынрак урында хәрәкәт итә. Ләкин озакламый 81 нче полк

[illegible] тирәсенә күчерелә. Дивизия гвардиячеләренең чех сугышчылары белән бергә сугышачакларын Тәлгать Шәмсетдинов нәкъ әнә шул көннәрдә белә. 1943 елның 4 нче март иртәсендә гвардия кече лейтенанты Тәлгать Шәмсетдинов үзенең сугышчыларына түбәндәге приказны укый:

«25 нче гвардияче укчы дивизия частьлары командирларына.

1943 елның 3 мартыннан дивизиянең оператив буйсынуына Тимченко, Соколово һәм Артюховка янында оборона тотучы чех батальоны кертелде. Батальонның штабы — Миргород.

Дивизия командиры приказ бирә:

Партия һәм хөкүмәт карары нигезендә, Советлар Союзы территориясендә немец оккупантларына каршы чит ил частьлары көрәш алып баралар һәм алып барачаклар. Моның турында личный составка җиткерергә. Кием формасы: инглиз сукносыннан тегелгән шинель, погоннар, баш киемнәрендә туры почмаклы йолдыз. Бөтенесе дә безнең ил коралы белән коралланган.

Югарыда саналып кителгән районнардан барлык тыл частьларын һәм учреждениеләрне алырга, шулай ук барлык сугышчыларга чех батальоны белән яхшы мөгамәләдә булу турында кисәтергә.

Бу приказны 12.00 4.3.43 еннән дә соңга калмыйча һәрбер сугышчыга җиткерергә.

Үтәлеше турында язма рәвештә хәбәр итәргә.

25 нче гвардияче укчы дивизия штабы начальнигы гвардия подполковнигы Петренко».

8 мартта Соколово тирәсендә Тәлгать көчле атыш тавышлары ишетә. Ә бераздан аның күз алдында тирә-юньне чолгап алган көчле ялкын хасил була. Оборона тотучыларның каршылыгына үчләнгән гитлерчылар Соколовоны аяусыз төстә яндыралар. Янгын бары тик 9 март иртәсендә генә сүнә. Ниһаять, атышлар тына.

1943 елның 9 мартында 81 нче гвардия укчы полкы, Артюховкадан һөҗүм иткән чех батальонының 2 нче ротасы белән берлектә, Соколово авылына һөҗүм башлый. Тәлгать Шәмсетдинов, үзенең сугышчылары белән, көндезге сәгать 12 гә Диптана хуторы районына килеп чыга. Караңгы төшкәндә, полкның бер ротасы көньяк-көнчыгыш яктан авылга бәреп керә. Ләкин дошман көчле ут ача. Аның авылдагы 50 танкысы ялкын сибүче ут ноктасына әверелә. Гвардиячеләрнең һөҗүме туктатыла. Озак та үтми, немецларның 13 танкысы безнең ротаны авылны ташлап чыгарга мәҗбүр итә. Дошман танкларының, артиллерия һәм минометларының тоташ уты астында полк җиргә сыеныргга мәҗбүр була. Төн уртасында дошман танклары һәм пехотасы гвардиячеләргә каршы контрһөҗүмгә күтәреләләр һәм авылның көньяк-көнчыгышындагы биеклекне алалар. Икенче көнне иртән 81 нче полк 152 нче укчы дивизия пехотачылары белән алыштырыла һәм Змиево авылы тирәсенә туплана. Ләкин инде бу вакытта гвардиячеләр арасында Тәлгать булмый.

Шәмсетдиновның гомере ничек өзелгән, бу хакта әйтүе кыен. Безнең гвардиячеләрнең 9 март кичендә чех сугышчылары белән берлектә уздырылган һөҗүме вакытында үлгәнме ул, әллә дошман танклары контрһөҗүмгә күчкән чакта һәлак булганмы!..

Соколоводагы совет — чех дуслыгы музеенда ике рәсем бар. Аларның берсе — Отакар Ярош, икенчесе Тәлгать Шәмсетдинов рәсеме. Тәлгать белән бергә укыган һәм Соколово тирәләрендә барган сугышта катнашкан художник Г. Д. Мелентьевның «Мәңгелек туганнар» картинасы, А. М. Радионовның Тәлгать Шәмсетдинов рәсеме, башка әсәрләр белән бергә, Татарстан художниклары тарафыннан музейга совет һәм чех солдатлары бер рәттә торып сугышкан көннәргә 25 ел тулу уңае белән тапшырылган иде. Истәлек бүләкләрен кабул итү тантанасында Отакар Ярошның сугышчан дуслары — майор Данута Дрнкова, генерал-майорлардан Олдржих Квапил һәм Властислав Райхл, полковник Ян Бачковский, подполковник Франтишек Малина, полковник Ладислав Килиан, запастагы майор Йозеф Крно, запастагы полковниклар Борис Гибнер һәм Теодор Фиш катнашты.

«Свобода» батальоны үзенә бирелгән сугышчан приказны намус белән үтәде: Мжа елгасы аша дошманның бер генә танкысын да үткәрмәде. Немецлар Харьковка төньяктан бәреп кергәч, батальон сугыштан чыгарга приказ алды һәм хәзер Белгород

Советлар Союзы Герое исеме бирелүен тугандаш чех сугышчылары әнә шунда ишеттеләр. Ул чагында Людвик Свобода Ленин ордены белән бүләкләнде. Хәзер ул — ЧССР һәм Советлар Союзы Герое, Чехословакия Социалистик Республикасы президенты.

* * *

1943 елның май башларында чех батальоны Воронеж өлкәсендәге Новохоперск шәһәренә килде. Биредә Беренче аерым чех бригадасы төзелергә тиеш иде. Соколово сугышларында утлар кичкән, сынаулар үткән батальон базасында кыска гына вакыт эчендә 3 мең кешелек зур хәрби берләшмә төзелде. Ул танклар, артиллерия һәм һөҗүм сугышлары өчен кирәкле башка төр кораллар белән тәэмин ителде.

1943 елның апрелендә, Воронеж фронты штабында, фронт сызыгыннан ерак түгел урында чех бригадасы төзү турындагы мәсьәлә каралганда, полковник Людвик Свобода фронтның Хәрби советыннан һәм фронт командующие генерал Н. Ф. Ватутиннан бу бригадага совет Украинасының башкаласы Киевны азат итүгә катнашырга рөхсәт бирелүен сорады. Чех патриотларының сораулары канәгатьләндерелде.

1943 елның сентябрендә Кызыл Армия генеральный штабының махсус комиссиясе һәм Клемент Готвальд, Ян Шверма, Зденек Неедлы, Зденек Фирлингер катнашында, чех бригадасының хәрби өйрәнүләренә йомгаклау уздырылды. Бу өйрәнүләр бригада солдатларының һәм офицерларының югары сугышчан хәзерлеккә ирешүләрен күрсәтте. Генеральный штаб комиссиясе тарафыннан куелган «отлично» билгесе чех бригадасы коммунистлары эшчәнлегенә бирелгән лаеклы бәя иде.

Чех бригадасы алда торган яңа сугышларга әзерләнде. Бу — чех патриотларының үз Ватаннарын азат итү өчен көрәштәге зур җиңүен һәм Советлар Союзының миллиазатлык хәрәкәтен киң җәелдерүдә Чехословакия халыкларына туганнарча ярдәмен күрсәтүче фактор иде.

Чех бригадасының төзелеп бетүе турында хәбәр бөтен дөнья җәмәгатьчелегенә билгеле булды. Бригаданың Новохоперскида уздырылган йомгаклау өйрәнүләре хакында чит илләрнең бик күп хәбәрчеләре үзләренең репортажларын яздылар, ул репортажлар Англия, Канада, Америка Кушма Штатлары, Латин Америкасы һәм Австралия газеталарында басылып чыкты.

1943 елның октябрь ахырында чех бригадасы, алты эшелонга төялеп, Киев районына килде һәм Украина башкаласын азат итү сугышында хәлиткеч участокта булды.

Сугышка керер алдыннан чех бригадасы роталарында Днепрны кичкәндә күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелгән сугышчылар белән очрашулар уздырылды.

Һөҗүм 1943 елның 3 ноябрендә Киевтан төньяктарак урнашкан Лютежск плацдармыннан башланды. Бу вакытта 1 нче чех танк бригадасы икенче эшелонда иде һәм сугышның беренче көнендә, артиллерияне исәпләмәгәндә, аның подразделениеләре сугыш хәрәкәтләре алып бармадылар. Бригада сугышка 4 ноябрьдә керде. Балалар санаториясе тирәсендә дошман егерме танк һәм үзйөрешле орудиеләр белән көчәйтелгән ике полкын контрһөҗүмгә ташлады. 136 нчы укчы дивизиянең 269 нчы укчы полкына чех сугышчылары ярдәмгә килде. Бу сугышта шушы полк сугышчысы кызыләрмеец Әхмәтов үзенә ташланган биш гитлерчыны атып үтерде. Дошман пулясы тиеп берьюлы ике күзсез калгач, ул ярсып: «Сез кабахәтләрне күбрәк юк итә алмавым кызганыч»,— дип кычкырды.

Совет солдатлары белән бергә хәрәкәт итеп, Киевны азат итү сугышларында чех сугышчылары зур батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. Совет хөкүмәте аларның фидакарьлеген югары бәяләде. Бригаданың сугышчан батырлыгы Верховный Башкомандующий приказында билгеләп үтелде, ул II нче дәрәҗә Суворов ордены белән бүләкләнде, чех сугышчыларына рәхмәт котлаулары җибәрелде.

Шик юк ки, чех батальонының Харьков янында, аннан Киев янындагы сугышларда катнашуы Советлар Союзы һәм Чехословакия халыклары арасындагы дуслыкның тагын да ныгуына ярдәм итте.

һөҗүмгә күчтеләр. 29 декабрьда чехлар бригадасына Белая Церковь шәһәрен азат итәргә приказ бирелде. 30 декабрьда Суворов орденлы I нче аерым чех бригадасы, 74 нче һәм 163 нчы дивизияләрнең частьлары белән берлектә, Руда авылына һөҗүм башлады. Дошман аңа каршы ике тапкыр контратакага күтәрелде. Бу һөҗүмнәр вакытында 74 нче укчы дивизиядә хезмәт итүче Габит Гозәер улы Вахитов үзен кыю һәм куркусыз сугышчы итеп танытты. Лейтенант Габит Вахитов командалык иткән взвод дошманның бер танкысын, өч пулемет ноктасын, кырыклап солдат һәм офицерын юк итте.

Белая Церковь янындагы уңышлы операцияләре өчен чех бригадасына Верховный Башкомандующий икенче тапкыр рәхмәт белдерде. Бригада I нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий ордены белән бүләкләнде, аның күп кенә солдат һәм офицерларына совет хөкүмәте бүләкләре тапшырылды. Белая Церковь шәһәре өчен барган сугышта үз-үзен аямаган өчен лейтенант Габит Вахитов та хөкүмәт бүләгенә лаек булды.

Суворов һәм Богдан Хмельницкий орденнары белән бүләкләнгән аерым чех бригадасы 1944 елның январь — февраль айларында хәзерге Черкасск өлкәсендәге Жашков янындагы сугышта актив катнашты. 1944 елның апрелендә бригада 1 нче Чехословакия корпусы булып әверелде.

29 августта Словакиядә халык восстаниесе башланды. 1 нче Украина фронтының 38 нче армиясе һәм 4 нче Украина фронтының 1 нче гвардия армиясе гаскәрләре словак милли восстаниесенә ярдәм итү өчен һөҗүмгә күчтеләр. Карпатта озакка сузылган кан койгыч сугышлар башланып китте. Бу сугышларда генерал Людвик Свобода җитәкчелегендәге чех корпусы да катнашты.

1944 елның 6 октябрендә чех сугышчылары үзләренең туган җирләренә аяк бастылар. Ләкин Дукла тарлавыгындагы җиңү ифрат кыйммәткә төште: монда 85 мең совет сугышчысы, 6 мең чех солдаты һәм офицеры һәлак булды. 1968 елның 23 маенда Дукла тарлавыгыннан ерак түгел урнашкан Свидник шәһәрендә булып узган митингта ясаган чыгышында Людвик Свобода болай дип сөйләде: «Дукла — азатлык символы, чех дәүләтенең бердәмлеге өчен көрәшкән совет һәм чех халыкларының дуслык символы, Советлар Союзы белән безнең экзерсез һәм мәңгелек дуслыгыбыз символы булып тора һәм шулай булып калачак та... Карпатта һәм Ондава елгасы буенда искиткеч авыр һәм газаплы шартларда алып барылган сугышларда без 1938 елда азатлыкны ничек җиңел югалтуыбызны һәм аны нинди авырлык белән кайтарып алуыбызны аңладык. Словак һәм чех халыкларының азатлыгы өчен барган сугышларда 140 мең совет, һәм 12 мең чех сугышчысының каны коелды».

1944 елның ахырында Ондавада барган сугышларда Советлар Союзындагы күп санлы милләт вәкилләре онытылмаслык батырлыклар күрсәттеләр. Кызыл байраклы, Богдан Хмельницкий орденлы 271 нче Горловск укчы дивизия составындагы 867 нче укчы полкның 2 нче пулемет ротасы парторгы лейтенант Салуквадзе һөҗүмгә беренче булып күтәрелә һәм үзенең шәхси батырлыгы белән барлык сугышчыларны җиңүгә рухландыра. Дошманның контрһөҗүме вакытында бер станковый пулеметның расчеты сафтан чыгарыла. Пулемет янында бер үзе калган Салуквадзе каты яралана. Ләкин ул яу кырын ташлап китми. «Мин — коммунист һәм соңгы сулышыма кадәр сугышачакмын»,— ди ул.

Санитар — коммунист Арапитян, күкрәк тиңентен бозлы суга кереп, сугыш кырыннан яралы дүрт сугышчыны һәм ике офицерны алып чыга.

Шул ук дивизиядәге 865 нче укчы полкның автоматчылар ротасы парторгы татар егете өлкән сержант Җамалиев дошманның контратакасы вакытында сугышчыларга болай дип мөрәҗәгать итә: «Дусларым, бер карыш та артка чикмәскә! Соңгы сулышкача нәге постта калырга!» Шушы сугышта ул батырларча һәлак була.

Фронт көнбатышка тәгәри. 4 нче һәм 2 нче, соңрак 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре, Чехословакия территориясен азат итә-итә, илбасарларны үз өннәренә куалар. 1945 елның 9 маенда, Бөек Ватан сугышы тәмамланган көнне, Чехословакиянең башкаласы Прага азат ителде.

Немец-фашист гаскәрләренә каршы көрәштә совет һәм чех халыкларының сугышчан дуслыгы көннән-көн үсте һәм ныгыды. Бу дуслыкны үстерүдә татар халкының данлыклы уллары да үзләреннән зур өлеш керттеләр.

Фаяз Дунай

# БӘХЕТЛЕ СИН, БӘХЕТГӘРӘЙ

*ОЧЕРК*

Көзге аяз кич, бөтен әйләнә-тирәгә көмеш тузаны сипкәндәй нурланып торган айлы кич иде. Колхоз председателенең иртәсен дә, кичен дә кырыкмаса кырык төрле мәшәкате бар. Бу кичтә дә шулай булды. Механизаторлар белән киңәшеп аласың бар: колхозда быелгы кыр эшләре тәгәлләнеп бара, көннәр коры торганда егетләр үзләренә утын әзерләп калырга ниятлиләр икән. Син үзең дә аларның бу теләгенә каршы түгел. Кирәк чагында көнен-көнгә ялгап уңыш язмышын хәл иткән иптәшләрнең юллар такыр торганда утын мәшәкатеннән котылып куюлары хәерле. Тик менә икенче исәбең дә бар икән: кыр эшләреннән бераз бушанып торган арада техниканы ремонтлатып куярга ниятлисең. Чөнки хәзер авыл җирендә дә кышның мәшәкате җитәрлек, чана юлы төшкәндә тракторларың төзек булса, автомашиналарның юлга чыга алмый ятуыннан әллә ни интекмисең. Ә тракторлар күп сездә, 40 ка якын, эшләрнең яңасын кузгатканчы карап-төзәтеп кенә өлгер. Шуңа күрә дә механизаторларның үзләре белән киңәшеп хәл итәсең килә: егетләрнең дә хәтерләре калмасын, артель эшенә дә зыян килерлек булмасын. Кыскасы, акыллы уртаклык табасың килә.

Син елмаю катыш якынлык белән:

— Өйне таба алмыйча адашып йөрмә. Менә бу утны онытма,— дип багана башында елтырап утырган «эшләпәле» лампочкага күрсәттен дә такыр тыкрык буйлап правлениегә таба китеп бардың. Йөрешең һаман элеккечә табигый салмак, адымнарың нык. Соңгы дистә еллар синең буй-сыныңа, төс-кыяфәтеңә бөтенләй яңа бизәкләр өстәмәгән дияр идем — бераз гына тулыланып киткәнсең кебек. Әмма шомырт кара чәчең, түгәрәк йөзең, матур тембрлы йомшак тавышың, сүзне гомер гомергә авыл җирендә яшәгән картлар сыман сабыр гына, көттереп кенә һәм саф татарча итеп сөйләвең — гел элеккечә. Тышкы кыяфәтең түгел, рухи тирәнлеккә таба, күңел байлыгына таба үзгәргәнсең, ахры.

Синнән аерылгач та авылыгыз уртасыннан бормаланып-уралып аккан Бәрле елгасына карап шактый уйланып тордым. Ай нурлары түгелеп сибелгән елга өстендә, ак экрандагы сыман, синең үткәннәрең чагылып узгандай булды...

## Туган туфрак тарткан

Республикабызда Кавказ, Кырым якларына алыштыргысыз, үз бизәкләре белән тулы бик матур табигый почмакларыбыз бар. Мөслим әрәмәләре, Кама, Идел буйларындагы тугайлыклар, ярымутраулар,

«Бәреле» совхозы, Раифа заповедникы тирәләрендә булсаң — карап туймаслык, мактасаң — сүзләр җитмәс. Ләкин аның әлегә җырга кермәгән бер бик күркәм почмагы бар — сезнең Борындык авылы тирәләре.

Әлеге Бәрле елгасы өянке-тирәкләргә сыенып утырган авылыгыз аркылы уза да Зөягә барып кушыла. Зөясе дә авылыгызның борын төбендә генә, кыр капкасы аша чык та — болын буйлап йөгер, җәйләрендә суында коен, балыгын тот, яр буйларындагы әрәмәләреннән чиләк-савыт тутырып җиләк-җимешен җый яки, аргы ярга чыгып, тезмә тауларга сәяхәт кыл. Шунда ук, сезнең авыл чикләрендә үк — табигать юри юмартланып күргәзмәгә тезгән диярсең — эреле-ваклы күлләр. Һәм барысы да балыклы.

Табигатьнең шушы матур бишегендә синең ялан аяклы бала чагың, кырыкмыш тай сыман яшүсмер елларың йөгереп узган. Тәүге тапкыр зур кызылканат тоту, пионер галстугы тагу, җидееллык мәктәп бетерү, беренче тапкыр трактор сабанына «кунаклап» яңа буразналар сызу шатлыкларын да, әниеңнең, әтиеңнең вафат булуы хәсрәтләрен дә син шушы елгалар, күлләр тирәсендә, шул әрәмәлекләр, болын сукмакларында кичергәнсең. Шул ук өянке-тирәкләр, аналар, балалар, яшь киленнәр кебек үк кайгылы шаулашып, авылның ир-егетләрен Бөек Ватан сугышына озатып калганнар. Яу кырына китүчеләр арасында уналты яшьлек егет — син дә булгансың.

Хәрби курслар. Героик Ленинград оборонасы. Әллә никадәр соклангыч язмышлар һәм әрнүле фаҗигаләр белән тулы госпитальләр. Һәм дүрт-биш җирдән яраланган яшь солдат сызлану катыш сөенеч белән шул ук Зөя, шул ук Бәрле буйларына кайтып төшкән. Тик аларда элеккеге ямь юк, элеккеге бәйрәмнәрнең, уеннарның шау-шуы юк. Сугыш еллары кытлыгы су буйларындагы тал-тирәкләрне утын иткән, бөтен әйләнә-тирәдә моңсу тынлык, бушлык. Бала-чага күңелендә дә уен түгел, тамак кайгысы. Йорт аралаш тол аналар, ятим балалар. Ике күрше — Борындык, Шуширмә авылларыннан гына да 204 кеше фронт кырында мәңгелеккә ятып калган. Әнә шушы 204 гомер, 204 өмет хакы да сезнең, исән калганнарның җилкәсенә төшкән, Бәхетгәрәй. Алар әле дә авылыгыз уртасындагы һәйкәл ташыннан сезгә үзләре хакында искәртеп торалар төсле.

Син хисапчы булып эшли башлаганда, колхозыгыз бик кыен хәлдә булган. Ул еллардагы кыенлыкларны хәзер инде искә төшереп сөйләп тә торасы юк — илебезнең күпчелек почмакларында шундый хәл иде.

Табигать сиңа сабыр холык, хисле күңел биргән. Гел элеккечә әле хәзер дә җае, вакыты табылганда матур әдәбият укырга, җырлар, шигырьләр тыңларга яратасың, язучылар, композиторлар хакында сорашасың. Балаларга булган мәхәббәтең дә, мөгаен, шул хисле рухыңның ихтыяҗыдыр. Син педагог булырга җыенгансың. Еллары никадәр кыен, колхозның нужасы күп булса да, Казан педагогия училищесын тәмамлагансың, университетка да укырга кергән идең. Ләкин партиянең боерыгы сине башкарак юлдан алып китте. Әмма хәзер үзең дә үкенмисеңдер, эшчәнлегең педагогикадан читтә түгел. Хәтта киресенчә... Үз вазифасын дөрес аңлаган зур хуҗалык җитәкчесенә көн саен, сәгать саен диярлек тәрбияче-киңәшче бурычларын үтәргә туры килә. Әнә, авыл халкы да мактап телгә ала. Исеме Д. хәрефенә башлана торган бер иптәш элегрәк җинаятьле юлда азып-тузып йөргән. Хәзер менә колхоздагы мактаулы кешеләрнең берсе. Йорты-җире матур, ризыгы бәрәкәтле, семьясы тату. Бу иптәшне дөрес юлга бастырыр өчен шактый тырышырга туры килгән сиңа. Начар гадәтләрен ташлап авылның хөрмәтле кешеләре булып әверелгән колхозчылар сездә аз түгел. Кибет, клуб, колхоз идарәсе яки башка урыннарда булсын, колхозчыларның, кайбер башка авыллардагы кебек, үзара тәмсез тел белән гауга-лашып, ямьсез кылану яисә авыз ерып шәрә мәзәкләр сөйләү кебек гадәтләре күренми.

Авылда эшлекле тыныч атмосфера, үзара тату, ихтирамлы мөгамәлә сизелә. Яшьләр арасында да шулай.

Беренче карашка әллә ни әһәмияте дә юктыр кебек тоелган шушы этик бизәкләрдә синең дә педагогик тырышлыкларың, шәхси матур үрнәк күрсәтүләрең чагыла, Бәхетгәрәй. Чөнки авылның өлкәннәре үзләре синең мондый сыйфатларыңны зурлап сөйлиләр. Юкса бар бит әле шундыйлар, авылларда да шактый күренгәли: җитәкче иптәш дигәнебез тирә-юнендәге мәктәп балаларын, өлкәннәрне санга сукмый сүгенеп сөйли. «Гадилек гадәтенә сеңгән», янәсе. Әйтерсең, гадилекнең орлыгы сүгенүдә? Үзенең эштә генә түгел, сөйләм телендә дә культура, итагатьлелек үрнәге күрсәтергә тиешлеген оныта.

...Сиңа мәктәптә озак эшләргә туры килмәгән. Партиянең ул чактагы Кайбыч райкомы үз аппаратына чакырып алган. Районлагы артта калган хуҗалыкларны аякка бастыру мәсьәләсе кузгалгач исә шул ук партия райкомы сиңа үз авылыңа колхоз председателе булып кайтырга киңәш иткән. Дөресен язам, башта шүрләп-уфтанып йөрүләреңне, икеләнүләреңне мин дә беләм, ул вакытта районыгыз газетасы редакциясендә эшли идем. Борчылырлык сәбәпләре дә бар иде шул: колхозның иске акча белән нибары 33 мең сумлык запасы бар. Анысы да үз кассасында түгел, аны төрле оешмалардан даулап алырга кирәк. Ә бурычы — үз членнарына дигәндә генә 53 меңнән арта иде. Шуңа күрә дә колхозчыларның артель эшенә дәрте бик чамалы, шактый кеше тимер юлда, шәһәр тирәсе предприятиеләрендә эшләп көн итә. Ләкин, хәлләр никадәр мөшкел булмасын, коммунистлык бурычы һәм дымы, сулышы учларыңа, күңелеңә сеңгән туган туфрак сине үзенә кайтарды.

## Читлекләрне үгез җимергән...

Гомерләрне юкка гына агымсуга тиңләмиләр. Дөнья, тормыш мәшәкатьләре белән тулып, дистә еллар узып та киткән. Үзең белән очрашырга туры килмәсә дә, җай чыкканда таныш-белешләрдән хәлләреңне сораштырып тордым. Артель йөген кузгатып үргә таба сөйри башлавыңны җиткерәләр иде. Бер елны сезнең авылга: «Бар әле — урыннары бик ямьле. Ял да итәрсең, язарсың да»,— дип, хәзер инде мәрхүм язучы Мин Шабайны үгетләп җибәргән идек. Бик ошатып кайтты үзегезне, синең характерыңны яратып кайтты.

Беләм, җиңел түгел, бигрәк тә баштагы елларны кыен булган сиңа, колхозчыларны үз хезмәтләренең нәтиҗәсенә ышандыруы читен булган. Төзисе күп — ләкин артельнең кесәсе бик чамалы. Иген уңышы да киңәндерми. Өстәвенә, кай чакта кэйсы «ботакка» тотынырга белми аптырагансың. Авыл хуҗалыгында экономик, агрономик карашларның бик еш үзгәреп торган чагы. Әлбәттә, алар сезнең хуҗалык тормышында да чагылмыйча калмаган. Әле дә хәтердә...

Бер елны бөтен Татарстан буйлап «куян чире» таралды. Дәррәү кузгалдык та барлык хуҗалыкта йорт куяны үрчетергә керештек. Колхоз, совхозларны әйтәсе дә юк, хәтта биш-алты хезмәткәре булган бәләкәй учреждение җитәкчеләре дә читлек эзләп тыз-быз чабыша башладылар. Ул шаулы киңәшмәләр, йөкләмәләр дисеңме!.. Куян үрчетеп республиканың ит базасын баетабыз, янәсе. Шартларын, ул куян дигән җәнлекнең бик капризлы, нәзберек булуын, аны үрчетүнең үзенчәлекле хикмәтләре барлыгын шау-шу белән онытып та җибәргәнбез. Үзе доходлы, ите — файдалы, имеш. Шул «куян чире» сезне дә шактый интектергән. Әмма... нәсел үгезе кызык иткән үзегезне. Хәзер инде мәзәк итеп кенә сөйлисез.

...Көтү эзләп бара икән үгез. Сукмак куян читлекләре янынннан уза. Әлегә кадәр бу тирәләрдә йөргәне булмагандырмы, эчләрендә дыр-быр нәрсәдер сикерешкән бу читлекләр тәкәббер үгезгә бик сәер күренгән,

ахрысы. Маңгаен терәп беравык карап тора да теге — әйдә җимерергә. Читлекләрне мөгезенә элә дә чөя, элә дә чөя. Ярсыган үгезгә нәрсә: түгелгән хезмәтне белми ул, районга чакырып, «строгач та чәпәп» булмый аңа — икенче рәттәге читлекләрне дә чөеп-янчеп бетерә.

Син килеп җиткәндә, мескенем куанычы кыз, бу шаулы эшкә үзе теләп алынган кыз, тәгәрәп җылый: чыгам, күрше авылга кияүгә чыгам, Бәхетгәрәй абый,— ди.— Ичмасам, бу куян михнәтеннән котылырмын...

Икенче бер елны: «Сездә елгалар, күлләр күп — үрдәк үрчетегез»,— дип катгый боерык бирәләр. Авылда каз асраучы кеше күп, ләкин «үрдәк рәтен» белүчеләр юк. Аңа яраклы бинасын табарга, кешеләрне өйрәтергә кирәк — ләкин ашыктыралар.

Ашык-пошык 36 баш үрдәк алып кайтып, күлгә җибәрәсез. Атна уза, ун көн — вәт әкәмәт! — үрдәкләрне күлдән һич ашарга чыгарып булмый. Бу эшкә алынган колхозчылар көн саен хәлдән тайганчы күлдән үрдәк куу белән мәшгуль. Күлдә бака күп, тегеләр шуны тотып туенала да һаман суда «оҗмах кичерәләр» икән. Ниһаять, сулар туңгач, үзләрен яшь бәрәннәр абзарына кайтарып япкансыз.

Беркөнне район хәзерләүләр конторасыннан Әхмәтҗанов фамилияле вәкил килә. Үрдәкләре булгач, аларның продукциясе дә булачак бит инде, янәсе. Колхоз белән договор төзеп куярга кирәк.

Вәкил иптәш әлеге яшь бәрәннәр абзарына барып кайта да, башта көлми-сиздерми, акрын гына сорый:

— Бәхетгәрәй, бу көннәрдә үрдәкләр янына барганың бармы?

— Нәрсә, әллә берәр хәл булганмы?

— Үрдәкләрегез ул абзарда пәригә әйләнгәннәр, малай. Үзләре бакылдашмасалар, аларның үрдәк икәнен дә танырлык түгел...

Әллә мутлык белән, әллә алдан белештермичә, колхозчы агай әнә теге таныш күлгә бәке уя. Үрдәкләрне шул бәкегә «юынырга» куып төшерәләр. Менә тагын, аврткан башка тимер тарак: үрдәкләр шул бәкегә чумалар да — чыкмыйлар, чумалар да югалалар...

Керем чыганагын шуңа юнәлтеп, тиешле биналарын, техника-җиһазларын, белгечләрен булдырган — кыскасы, специаллашкан хуҗалыкларда, әлбәттә, куяны да, үрдәге дә табышлы. Ләкин ул елларда бездә һәр хуҗалыкны «куян модасы» белән «киендерерлек» шартларыбыз юк иде. Ярый әле, сабаклары гыйбрәтле булды, реаль чынбарлык үзебезгә хуҗалык-экономика өлкәсендә «модалар» белән мавыгырга ярамаганлыгын раслады. Сез дә «үз кыйблагызны табып», эре, нык адымнар белән яңа үрләргә атлагансыз.

## Шул ук җир—тик сые башка

Колхозыгыз хәзер дә зурлардан саналмый. Ике авылны берләштергән уртача хуҗалык ул үзе. Төп юнәлеше — иген игәсез, мал-туар асрыйсыз. Басулар, көтүлекләр шул ук. Ләкин җирнең хәзинә сандыгыннан алынган байлык ел саен ишәя бара. Әйтик, 1957 елны сездә игеннең һәр гектарыннан уртача 7,91 центнер уңыш чыккан иде. Ә менә ун елдан соң бу уңыш 18 центнерга күтәрелгән. Кайсы культураны алма — шундый ук үсеш. Чөнки җир-туфракның кадерен белеп, ашламасы белән аның күңелен күреп, хуҗаларча эшкәртә башлагансыз. Чөнки, әнә тракторчы Равил, Рәхимулла, Хәлилләрнең җиргә булган мәхәббәтләре, эшкә мөнәсәбәтләре, белем-осталыклары башка.

Шул ук су буйларыннан, аланлыклардан, көтүлекләрдән дә башкача файдаланып, күңел сөенерлек байлык аласыз хәзер. Киндерен чәчәсез, чөгендерен, кәбестәсен утыртасыз, печән запасы да муллан. Күрәсең, җир-ана сезне баеткан, абруйлы иткән. Хәзер Куйбышев исемендәге сезнең колхоз — Апас районында иң алдынгылардан санала. Үзенне орден белән бүләкләгәннәр. Бөтенсоюз күргәзмәсенә катнашасыз.

Дөрес, боларның берсе хакында да син сөйләмәдең. Гомумән, син үзең турында яки колхозның үсеше хакында сораша башлагач, сүзне, ничектер, җай гына читкә борып җибәрәсең. Без элегрәк район газетасының актив хәбәрчесе булган Равил Бикмуллин, партоешма секретаре Заһидулла абый Гарифуллин белән озак-озак сөйләшеп утырдык. Равилне экономист итеп үстергәнсез икән. Семья корып җибәргән, таштан йорт салып ята. Эштә бик уңган күренә, колхоз экономикасының кайсы ягы белән кызыксынма — җаваплары, саннары әзер.

Заһидулла абый колхозның алдынгы кешеләрен саный, гади колхозчыдан мастерской мөдире булып күтәрелгән Насретдин абый Гайфетдинов, өлкән ветеринар Габдрахман абый Сафиуллин, ферма мөдире Рәхимулла ага Габитов, бәрәңге үстерүче механизатор Рәхимулла Зиннуров һәм башка уннарча колхозчыларны мактап телгә ала.

— Колхоз баеган, мактаулы кешеләрегез күп. Ә менә хезмәткә түләү ничегрәк?

Равил, уннарча ведомость ачып, саннар, исемнәр атый башлый.

— Менә узган ай ведомостьлары. Карагыз, акчаны иң күп эшләүчеләр — механизаторлар. Менә, Җәмилов Салих узган айда 27 көн эшләгән. Төп түләү 128 сум 32 тиен. Өстәмә түләү буенча 77 сум 96 тиен алган. Барысы 206 сум да 28 тиен буламы? Бусы акчалата. Натура белән бушлай 16 центнер ашлык алган.

Менә тракторчы Равил Хәмидуллин. Айга 25 көн эшләгән. Төп түләү 124 сум 79 тиен. Өстәмә түләү буенча 65 сум да 32 тиен алган. Барысы 190 сум буламы? Артыгы белән.

— Терлекчеләр, төрле эшкә йөрүчеләр күпме ала?

— Көнгә уртача 3 сумнан 5 сумга кадәр.

— Өстәмә түләүнең шартлары ничегрәк?

— Беренче чиратта яхшы сыйфат өчен 25—40 процент артык түлибез. Аннары, классность өчен түләнә.

Әйе, хәзер игенченең сыйфат һәм осталык өчен тырышуы хезмәт хакы белән дә бәйле. Ай саен шулай, промышленностьтагы кебек. Еллар безнең авылларыбызга бик куанычлы иҗтимагый һәм экономик үзгәрешләр алып килә. Авыл кешесе хезмәте белән эшче хезмәте арасындагы аерымлыкларны бетерүгә юнәлтелгән этәргеч чара бу. Һәм хәзерге авыл кешесе укый, квалификациясен күтәрә. Сездә быел 25 ләп игенче курс тәмамлаган, терлекчеләрнең үз мәктәпләре бар. Башкалардан белем таләп иткәч, үзең дә укымый тора алмыйсың. Казанда колхоз житәкчеләре мәктәбен отличнога бетереп кайткансың. Соңгы вакытта укый торган китапларыңны караштырдым. Бәхетгәрәй. Тракторлар ремонтына, бригадаларда хуҗалык исәбе кертүгә, чөгендер, киндер игү технологиясенә кагылышлы китаплар, төрле журналлар, шигырь җыентыклары... Заман, тормыш таләбе бит бу.

— Колхозчыларга түләүнең башка формаларын да карыйк әле?

Экономист кабат дәлилләр китерә башлый:

— Һәр колхозчы, үз чираты житкәч, отпускасын ала. Теләмәсә — акчасын. Һәр пенсионерга акчасын да, ашлыгын да илтеп бирәбез. Өстәмә ярдәм фонды да бар — елына ике мең сумга якын. Менә, культуракөнкүрешкә 12—13 мең сум тотабыз. Бусы да аның — колхозчылар өчен бит.

— Ял йортларына путевкалар, ярыш алдынгыларына — премияләр,— дип, Заһидулла абый өстәп куя.— Бүген менә — правление утырышы. Килергә мөмкин.

Ярым җимерек правление өендә эшли башлаган беренче елларың искә төшеп куя. Тузан, пычрак, йомышы булганы, булмаганы шунда тулып ята. Стена буйларына чүгәләп утыралар да махорка көйрәтәләр, мәзәкләр, экиятләр сөйләнә. Кайбер агай-эне баш астына утын пүләне салып йокыга китә. Әйтерсең, өендә мендәре юк...

Хәзерге яңа бинагыз иркен, уңайлы. Ләкин аның тирәсендә беркем дә вакыт уздырыр өчен генә буталып йөрми. Килеп йомышын йомышлый да — үз юлына китеп бара. Кичләрен өендә радио тыңлый, телевизор карый, тели икән — кинога бара.

Җыелыш, утырышларны да нәкъ билгеләнгән сәгатендә башларга өйрәнгәнсез. Житәкче буларак синең хакта сүз чыккач, партоешма секретаре кешеләр белән киңәшеп, аларның инициативасын яклап эшли белүеңне яратып сөйләгән иде. Дөрес икән.

Правление утырышында комбайнчылар ярышына нәтиҗә ясап, алдынгыларны бүләкләү, ял йортларына путевкалар бирү мәсьәләсен карадыгыз. Һәр әйтелгән кандидатура турында биш-алты кеше чыгып сөйләде. Хезмәт күрсәткечләрен генә түгел, эшнең сыйфатын, үз-үзен тотышын, холкын-фигылен дә исәпкә алып бәя бирәләр. Бәхәс бар — тик артык сүз куерту юк. Чөнки вакыт исәпле. Күпчелек тавыш белән карар ителде: комбайнчылар ярышында Җәмилов Салихны, Нигъмәтуллин Фирдәвесне, Зарипов Фәргезатны җиңүчеләр дип санарга. Ярышта беренче урынны алучы Җәмилов Салихны 80 сумлык радиола, икенче урынны алучы Нигъмәтуллин Фирдәвесне 60 сумлык велосипед, өченче урынны алучы Зарипов Фәргезатны 30 сумлык кул сәгате белән бүләкләргә.

Мәскәү янындагы ял йортына путевкаларны механизаторлардан Хәбибуллин Равилгә, Җәмилов Салихка, терлекчеләрдән Хәйруллин Кашшафка, гади колхозчылардан Зиннурова Фәһимәгә, Садыйкова Бибинурга бирергә. Юл расходларын колхоз исәбеннән түләргә.

Юк, юк, бүләкләүләр моның белән генә бетмәгән, аларның күбесен Октябрь бәйрәме кичәсендә тапшыргансыз.

Дөрес, дустым Бәхетгәрәй: кырлар, көтүлекләр шул ук — тик сые башка икән шул. «Искитәрлек нәрсә юк — хәзер күпчелек хуҗалыкларда шулай» — дисеңме? Бик шөкер: ил белән булуы сөенеч аның.

* * *

Гадәттә, күп җирләр, шәһәрләр күреп, дистә еллардан соң туган авылына кайтып төшкән кешегә бу авылның үзе дә, аның йортлары да кечерәеп калган сыман тоела. Ләкин сездә киресенчә булып чыкты. Авылыгызның зурлыгына, урамнарның киңлегенә, йортларның матурлыгына сокланып йөрдем мин. Борындык гел яңарган икән, таш йортлар гына да иллеләп бардыр. Орнамент-бизәкләр белән матурлап салалар. Җәмәгать биналарын, мал-туар каралтыларын да өр-яңадан төзегәнсез. Яңа мастерской, яңа складлар...

...Сугыш вакытында утынга киселгән талларның тирәкләрнең яңалары үскән. Яңа җиләк-җимеш бакчалары утыртылган. Яу кырында өзелеп калган 204 гомергә алмашка яңа буыннар үскән. Тормыш иптәшең Самара ханым белән санап утырдык (ул авыл советы секретаре бит): соңгы 10 елда гына да сездә 670 бала туган, 181 яңа семья төзелгән. Үзеңнең дә берсеннән-берсе сөйкемлерәк өч улың үсеп килә. Олысы Илнур дүртенчедә укый, кечесе Ильяс: «Миң киләсе елга укырга яңа мәктәпкә барам»,— дип, хәрефләр ятлый. Чыннан да мәктәпнең яңасын төзисез икән. Таштан салдырасыз, зур итеп, барлык шартлары булырлык итеп. Бөтен авылга ямь биреп, шәһәрчеккә охшап торачак. Анда улларыгыз укыр, оныкларыгыз укыр һәм сезне, авылны бизәүчеләрне, рәхмәт белән телгә алырлар.

...Һәрбер ата-ана баласы дөньяга килгәч тә аның тәүфыйклы, бәхетле булуын тели. Синең әти-әниең дә шуны теләгәндер. Мөгаен, шуңа күрә дә Бәхетгәрәй дигән матур исем кушканнар сиңа. Нөзләр язмышы өчен үзеңне җаваплы санап, алар тормышын бизәү өчен тырышып йөрү, туфрагыңнан аерылмыйча муллык өчен көрәшеп яшәү — бу бәхет түгелмени. Хөрмәтең зур, семьяң тату, саулыгың бар, ризыгың — хәләл. Бәхетле син, Бәхетгәрәй Мөхәммәтҗанов, бик бәхетле!

**Әмир Нәҗип,**
филология фәннәре докторы

# «КОТАДГУ БЕЛЕГ» ӘСӘРЕНӘ 900 ЕЛ

Иң борынгы төрки телдәге язма истәлекләр, билгеле булганча, V—VIII йөзләргә карыйлар. Алар — Төньяк Себер һәм Алтай тирәләрендә яшәгән борынгы төрки халыклардан калган руник язмалар. Шушы дәверләрдән чак кына соңрак уйгурлар да согд хәрефләре нигезендә яңа милли әлифба төзиләр, һәм ул язу башка төрки кабиләләр, шулай ук төрки булмаган кайбер халыклар арасында да киң таралыш таба. Менә шул уйгур әлифбасы нигезендә язылган дини эчтәлекле әсәрләрнең (будда һәм манихей диннәре тәгълиматлары), шулай ук юридик документларның бер кадәре безнең көннәргә хәтле сакланып калганнар. Бу чуар эчтәлекле язмалар арасында нәфис әдәбият әсәрләренең фрагментлары да очраштыргалап куя. Кыскасы, төрки телләрдәге язма әдәбият тарихын V—VIII гасырлардан башларга кирәк. Ләкин, үкенечкә каршы, ул дәверләрдә иҗат ителгән әсәрләрнең зур өлеше сакланып кала алмаган.

Күрсәтелгән гасырларда Фәрганәдә һәм бөтен Урта Азиядә өзлексез талашлар, канлы сугышлар хөкем сөрә. Илдә тынычлык, юлда иминлек бетә. Көнбатышны ерак Кытай белән кушып, өлкәгә бәрәкәт биреп торган олы кәрван юлы ташландык хәлгә килә — бай хәзинәле сәүдәгәрләр, тулы янчыклы арымас сәяхәтчеләр илләрне төньяктанрак сузылган башка маршрут буенча гизә башлыйлар. Нәтиҗәдә Җидесу өлкәсендә[1] тормыш җанланып, экономик күтәрелеш пәйда була. Бигрәк тә игенчелек югары нәтиҗәләргә ирешә. Әлбәттә, экономик үсеш белән бергә, халыкның рухи мәдәниятендә дә яңа казанышлар барлыкка килә. Мәсәлән, Җидесуның үзәге булган Суяб шәһәренә барган сәяхәтчеләр (ул шәһәр Чү елгасы буенда торган) анда төрле эчтәлекле китаплар язылуын хәбәр итеп калдырганнар. Ә 766 елда менә шул Суяб шәһәрен яулап алган төрки телле карлук[2] кабиләләре илнең элекке хуҗалары булган икенче бер төрки кабиләләрне — төргәшләрне читкә кысрыклап, Җидесуда һәм Сыр-Дәрьяның көньяк өлешендә яңа мөстәкыйль дәүләт оештыралар. Килүче карлуклар тәэсирендә моңарчы хөкем сөргән уйгур язма теле үзгәреп, яңа җирлектә яңа карлук-уйгур әдәби теле формалаша башлый. Йосыф Хас Хаҗиб дигән олы әдипнең мәшһүр «Котадгу белег» исемле поэмасы — менә шул карлук-уйгур телендә иҗат ителгән әсәр.

Сүз уңаенда шул дәверда әдәби төрки тел кичергән кайбер этаплар мәсьәләсенә

---

[1] Җидесу дип хәзерге Казагыстанның көньяк-көнчыгышындагы зур территориягә әйткәннәр (Балхаш күленә койган җиде елганы күздә тотып). Җидесуга Җамбул, Алма-Ата, Талды-Курган һәм өлешчә Семипалатинск өлкәләре керә.

[2] Карлук кабиләләренең калдыклары хәзерге Таҗикстан җирендә яши.

дә кыска гына булса да тукталып китик. Җидесу өлкәсе бик борынгы дәверләрдән үк Урта Азия, бигрәк тә Фәргانә белән тыгыз мөнәсәбәттә булган. Аларның берсендә барлыкка килгән экономик һәм мәдәни үзгәрешләр икенчесендә дә үзләренең чагылышларын тапканнар. Мәсәлән, 636 елда башланган гарәп яулап алуы һәм ислам дине таралуы бер Урта Азиянең мәдәни тормышында гына түгел, бәлки Көнчыгыш Төркстан һәм Җидесудагы халыкларның рухи тормышларына да көчле тәэсир ясаган. Нәтиҗәдә элек шул территориядә туып формалаша башлаган, мәгәр ныгып җитә алмаган төрки язма теле кысрыкланып, дин теле булган гарәп теле өстенлеккә чыккан. Хәтта гасырлар буе эшкәртелгән бай традицияле фарсы теле дә икенче планга күчкән. Бу аңлашыла да: гарәп теле, дин теле булудан тыш, Үзәк Азиядән алып Испаниягә хәтле сузылган беек Гарәп халифәлегендә дәүләт-административ страция теле дә иде; өстәвенә берәр җирле телдә янсә диалектта язылган әсәр тар даирә белән генә чикләнсә, гарәп телендә иҗат ителгән әдәби һәм гыйльми хезмәтләр аларның авторларын бөтен шәрык дөньясына мәшһүр итеп, мактау-алкышлар китергәннәр.

Гарәп теленең нәфис әдәбият һәм фән өлкәләрендә менә шулай бер үзе хакимлек сөрүе X гасыргача дәвам итә. Ә X гасырдан башлап беренче планга яңадан фарсы теле чыга башлый. Әүвәл матур әдәбият өлкәсендә, аннары фән дөньясында да ул үзенә мәйдан яулый. Ләкин ул элекке төсендә генә калмый, бәлки бай лексикалы гарәп теленнән кергән хисапсыз күп алымнар исәбенә үзгәреп, баеп, мәйданга чыга. Хәтта гарәп сүзләрен күп куллану үзенә күрә бер алым, әдәби норма рәвешенә керә (гарәп-фарсы синоним сүзләрен парлап куллану бигрәк тә киң таралган күренеш була). Тора-бара менә шул фарсы теленә кергән гарәп алынмалары әзләпәзләп төрки язма әдәбиятка, хәтта халык сөйләшенә дә күчә башлый. 960 елны караханилар ислам кабул итеп, ә 999 елны оешкан кодрәтле Караханилар дәүләтенә Җидесу да кушылгач, яңа җирлектә формалаша башлаган төрки әдәби телгә гарәп теленең тәэсире тагы да көчәя.

Менә шул дәверләрдә ислам кабул иткән төрки халыклар арасында, элекке манихей һәм будда дине эчтәлекле әсәрләрдән башка буларак, ислам дине рухындагы әдәби китаплар иҗат итү омтылышы туа. Ләкин ул вакытларда язылган әйберләр безнең көннәргә хәтле сакланмаган яки әлегә табылмаган. Андый хезмәтләрнең безгә мәгълүм булган иң борынгысы булып югарыда аталган «Котадгу белег» — «Бәхетле итү гыйлеме» дигән зур поэма исәпләнә.

Дөрес, поэманың авторы үз әсәрен төркичә язылган иң тәүге китап дип тәкъдим итә. «Кереш»тә үк ул:

Гарәпчә, таҗикча китаплар укуш
Бизниң тилимизгә бурунгы укуш,—

ягъни: «Гарәпчә, таҗикча китаплар бик күп, ә безнең телебездә бу иң беренче уку китабы», ди.

Ләкин, безнең фикеребезчә, Йосыф Хас Хаҗиб биредә гомумән иң тәүге төркичә китап турында түгел, бәлки шундый бик зур күләмле беренче китап хакында сөйли булса кирәк. Чөнки әсәр теленең бик чарланган, әдәби җәһәттән нык эшкәртелгән булуы, авторның исә катлаулы гарәп-фарсы шигъри метрикасын (аб-бб-вб-дб...) дөрес һәм оста файдалана белүе, ниһаять, образлар системасындагы төгәллек, элеклелек шагыйрьнең билгеле бер мәктәп узуын, элгәрге тәҗрибәдән файдаланган булуын күрсәтә. Кыскасы, тел-әдәби җәһәттән мондый җитлеккән әсәрнең буш җирлектә, такыр мәйданда барлыкка килүе бик шөбһәле. Димәк, «Котадгу белег» поэмасы язылганчы ук ислам тәэсирендәге төрки әдәбият әзерлек һәм көчү дәверен уздырган булырга тиеш. Тик, югарыда әйтелгәнчә, бу элгәрге дәвернең язма истәлекләре сакланмаган.

Ә «Котадгу белег» әсәренә килсәк, ул Караханилар дәүләтенең көнчыгыштагы мәркәзе булган Баласагун шәһәрендә иҗат ителә башлап (бу шәһәр Казагыстандагы Чу елгасы буена урнашкан булган), Көнчыгыш Төркстандагы Кашгар шәһәрендә язылып беткән. Автор аны Караханилар дәүләтенең башлыгы булган Табгач Бугра Карахан Әбү Гали Хәсән бине Сөләйман Арслан Кара-ханга бүләк иткән һәм сарай тарафыннан үзенә мактаулы дәрәҗә булган «Хас Хаҗиб» дигән исемне алган.

---

[1] Караханилар дәүләте дип, X гасырның 20 елларында оешып, 1212 елга хәтле яшәгән һәм үз эченә Көнчыгыш Төркстан, Җидесу һәм башка күп кенә төрки һәм фарсы халыклар биләгән җирләрне алган зур территорияле феодаль төрки мәмләкәтне атыйлар.

Китапның язылып бетү тарихы турында автор болай хәбәр итә:

Йыл алтмыш икн ирди түрт йүз йыла...
Түгәл үн сикиз айда айдым бу сүз»,—

ягъни: «Дүрт йөз алтмыш икенче ел иде... бу сүзләрне мин нәкъ унсигез ай сөйләдем». [Милади буенча 1069—1070 елларга туры килә].

Бу дидактик поэма безнең көннәргә хәтле өч нөсхәдә килеп җиткән. Хәзер саклана торган урыннары буенча алар «Каһирә», «Вена» һәм «Ташкент» нөсхәләре дип аталалар. Соңгы нөсхә әдәбиятта табылу урыны буенча «Фәрганә» яки «Нәманган» нөсхәсе дип тә йөртелә[1]. Аларның беренче һәм өченчеләре гарәп хәрефләре белән, ә икенчесе, ягъни «Вена нөсхәсе» исә, уйгур хәрефләре белән язылган.

Вена нөсхәсенең азагында китерелгән язуга караганда, ул 849 елның 4 нче мөхәррәмендә Һират шәһәрендә күчерелгән булган. Бу — 1439 елның 18 нче июненә туры килә. Ә бу вакытларда Хорасан дәүләте башында Аксак Тимернең улы Шаһрух тора. Билгеле булганча, аның дәверендә күп кенә гарәп язулы әсәрләрне яңадан уйгур әлифбасы белән күчерү гадәте хөкем сөрә. Шулай булгач, «Котадгу белег» әсәре дә әүвәл гарәп әлифбасы нигезендә язылып, аннары уйгур язуына күчерелгән булырга кирәк.

Венада саклана торган нөсхәнең азагындагы язудан тагын шуны да беләбез: 879 елда [ягъни 1474—75 елларда] Тукат аркылы аны Стамбулда яшәгән уйгур каллиграфы Габдрахман-бахшига китерәләр. Соңыннан ул китап ориенталист Й. Хаммер кулына төшә һәм Венадагы Король китапханәсенә тапшырыла. Һәм 1870 елда 185 бит, 5971 бәеттән [икеюллыктан] торган бу әсәрнең кайбер фрагментлары ориенталист Вамбери тарафыннан бастырылып чыгарыла. Ләкин транскрипциядә, шулай ук немецча тәрҗемәдә дә, күп кенә хаталар, төгәлсезлекләр җибәрелә. Ә 1890 елда күренекле рус ориенталисты В. В. Радлов бу Вена нөсхәсен тулысынча бастырып чыгарып, 1900—1901 елда аның транскрипциясен һәм немец теленә тәрҗемәсен дә нәшер итә. Вена нөсхәсе белән әсәрнең Каһирәдәге вариантын беренче чагыштырып чыгучы да шул ук В. В. Радлов була. Дөрес, Радлов хезмәтләре басылып чыкканнан бирле шактый еллар үтте. Өстәвенә, тулырак булган яңа, Нәманган нөсхәсе дә табылды. Тюркология фәне дә шактый алга китте. Шуңа күрә Радлов хезмәтендә да кайбер төгәлсезлекләрнең, хәтта ялгышларның табылуы бер дә гаҗәп түгел. [Бу кимчелекләрне ачыклауда данияле галим В. Томсенның хезмәтләре аерата игътибарга лаек.]

Каһирәдә саклана торган 392 битле 5800 икеюллыктан гыйбарәтле гарәп әлифбасындагы нөсхәнең тарихы бик томанлы. Шулай да бу китап Мисырга анда кыпчак мәмлүкләре хөкем сөргән дәвердә китерелгән дип уйларга мөмкинлек бар.

Ташкенттагы нөсхә исә, югарыда әйтелгәнчә, иң тулысы. Ул 445 битле китап һәм анда барлыгы 6095 бәет — икеюллык бирелгән. Бу нөсхәнең фотокопиясе 1934 елда Икенче тюркология конгрессы вакытында Төркиядәге «Төрек теле җәмгыятенә» бүләк ителгән иде. Шуңа күрә дә төрекләр 1942—1943 елларда «Котадгу белег»нең өч нөсхәсенең фотокопияләрен өч том итеп бастырып чыгардылар. Ләкин исәлекнең төрек галиме мәрхүм Рәшит Әхмәт Арат тарафыннан башкарылган транскрипциясе, төрекчә тәрҗемәсе, сүзлеге һәм грамматикасы хәзергә хәтле дөнья күрә алмый.

Советлар Союзында исә поэманың академик басмасын, аның русча тәрҗемәсен матбугатка әзерләү өстендә тюрколог Айсылу Вәлитова эшләп килде. Кызганычка каршы, аның бу эше әлегә хәтле басмага әзерләнеп җитмәгән.

Шулай да югарыда аталган басмалар һәм кайбер күзәтүләр нигезендә бу өч нөсхәне чагыштырып, тел-лингвистик яктан җентекләп тикшерер өчен хәзер мөмкинлекләр бер кадәре бар дияргә мөмкин. Мәсәлән, бу өч нөсхәнең телен чагыштырганда, түбәндәге әһәмиятле фактлар ачыклана. Текстның фонетик үзенчәлекләренә карагандa Каһирә нөсхәсен күчерүче кеше төрки телләрнең «д-группа» диалекты вәкиле булса, Ташкенттагы нөсхә исә «з-группа» диалекты кешесе тарафыннан күчерелгән. Билгеле булганча, «з-группа» диалектларында Түбән Идел һәм Харәзмдә яшәгән төрки кабиләләр сөйләшкәннәр. Шулай булгач, Каһирә нөсхәсе китап авторының үз телен, ә Ташкент нөсхәсе исә күчерүченең телен күрсәтә дип уйларга мөмкин. Димәк, Чу елгасы буенда формалашкан карлук-

[1] Чөнки ул, беренче мәртәбә 1914 елда Нәманганда табылып, аның турында хәбәр дә басылгач, юкка чыга да, икенче мәртәбә 1924 елда Фәргана өлкәсендә яңадан табыла.

уйгур теле төрки телләрнең «д-группасына» керә икән. Мондый күзәтүләр нәтиҗәсендә тагын башка бик күп кенә әһәмиятле нәтиҗәләргә ирешеп булыр иде.

Китапның авторы турында тулы мәгълүмат сакланмаган, шулай да кайбер фактлар билгеле. Мәсәлән, Каһирә нөсхәсендә ике «кереш» бар, берсе — шигъри, икенчесе — проза белән язылган. Тикшерү нәтиҗәсендә боларның башка бер билгесез кешеләр тарафыннан язылган булуы ачыклана. Шулай да бу керешләр бик әһәмиятле, чөнки алар «Котадгу белег»не язган Йосыф турында беркадәре мәгълүмат бирәләр. Мәсәлән, «кереш»ләрнең берсендә бу китапның Чин хакимнәре хикмәтләре белән бизәлеп, Мачин хакимнәренең шигырьләре белән зиннәтләнеп язылуын әйткәч, бөтен Шәрыкта да, Төркстанда да Бугра-ха телендә моннан да гүзәл башка әсәр иҗат ителмәве хакында әйтелә. Шулай ук, билгесез авторның хәбәр итүенә караганда, бу китапны төрле илләрнең падишалары һәм галимнәре төрлечә атаганнар икән. Мәсәлән, Чин галимнәре аны «Әдәб-әл-мүлүк», ягъни «Падишалар әдәплелеге» дип, ә Мачин галимнәре исә «Әмин-әл-Мәмләкәт», ягъни «Мәмләкәт иминлеге» дип атаганнар. Шәрык илләрендә ул китап «Зинн әл-үмәрә» — «Әмирләр зиннәте» дигән исемдә, Иранда исә «Котадгу белег» дигән баш астында мәшһүр булган. Кайбер төшләрдә аны «Пәнд-намәи-мүлүк» — «Падишалар өчен нәсихәт» дип тә йөрткәннәр икән. Менә шул сүзләрдән китапның бик борынгы заманнарда ук күп кенә илләргә таралган һәм сөелеп укылган булуын беләбез. Китапның авторы Йосыф исә Баласагун шәһәрендә туып-үсеп, шунда бу әсәрне иҗат итә башлаган булган, һәм, югарыда әйткәнчә, аны Кашгар шәһәрендә тәмамлагач, Табгач Бугра-ханга бүләк итеп, «Олуг хаҗиб», ягъни «баш камердинер» дигән мактаулы дәрәҗә алган. Шуның өчен дә соңрак шагыйрьне Йосыф Хас Хаҗиб дип йөрткәннәр (фәнни әдәбиятта Йосыф Баласагуни дип тә атыйлар).

Моннан соң «керештә» бу китапта дүрт файдалы нәрсә булуы күрсәтелә: беренче — Гаделлек, икенче — Бәхет, өченче — Акыл, дүртенчесе — Канәгатьлек. Боларның һәрберсе төркичә сүзләр белән дә исемләнгән, һәм алар әсәрдә әдәби образ — геройлар рәвешендә тәкъдим ителгән. Мәсәлән, Гаделлек — Көн туг-ды Илиг («Патша Кояш туды»), һәм ул патша дәрәҗәсенә куелган; Бәхет — Ай тулды, ул вәзир урынында; Акыл — Үгдүлмеш («Макталган»), һәм ул вәзир улы дәрәҗәсендә бирелә. Канәгатьлек — Удгурмыш («Уянган») дип аталып, вәзирнең энесе сыйфатында тәкъдим ителгән. Китапта менә шул дүрт герой арасындагы сорау-җаваплардан торган хикмәтле әңгәмә бара.

Композицион яктан бу дидактик поэма 73 бүлектән гыйбарәт. Беренче өч бүлектә шул дәвердәге традиция буенча алла, пәйгамбәр һәм аның дүрт сахабасы мактала. Лирик чигенеш белән башланган дүртенче бүлектә яз фасылы тасвирлангач, Кашгар хакиме Бугра-ханны мактау бирелә. Моннан соңгы бүлекләрдә күктәге җисемнәр, белемнең әһәмияте, тел-сүзнең файда-зыяны хакында сөйләнелә. Аерым бер бүлектә автор үзе эшләгән хаталар өчен укучылардан кичерем сорап, картлыктан зарланып, яшьләргә үгет-нәсихәтләр бирә. Моннан соң үзәк бүлекләр башланып, аларда югарыда аталган геройларның әңгәмәләре бирелә. Әңгәмә үзәгендә исә белем, дәүләткә хезмәт, дәүләт һәм гаскәр башлыкларына зарури сыйфатлар, дәүләт башындагы түрәләр белән халык арасындагы мөнәсәбәтләр мәсьәләсе, шулай ук ил агалары, галимнәр, табиплар, мөнәҗҗим-күрәзәләр, шагыйрьләр, игенчеләр, сәүдәгәрләр, ярлылар һәм байларның бурычлары, хокуклары, үзара мөнәсәбәтләре тора. Болардан соң килгән бер бүлектә өйләнү, бала тәрбияләү, гаилә мөнәсәбәте, кунак әдәбе тикшерелә. Аннары әңгәмә яңадан ил-халык, мәмләкәткә җитәкчелек итү, кешелеклелек проблемаларын тикшерүгә күчә. Ниһаять, иң соңгы бүлектә автор, үзе турында сөйләп, картлыктан зарлана, ваемсыз үткән яшьлеген сагына; дусларның турылыксызлыгын, дөньяның фанилыгын искә төшергәч, укучылардан тагын бер кат гафу үтенеп, әсәрен тәмамлый.

Күрсәтелгән бүлекләрдән аерата бишенче бүлек игътибарга лаек: анда бик күп борынгы төрки астрономик атамалар бирелә. Мәсәлән, ул вакытта йолдызларның күбесе Кузы, Көчек, Арслан, Богдай башы, Чадан (Чаян), Балык, Углак (Кәҗә бәтие), Я (Җәя) кебек төрки исемнәр белән аталган икән.

Бу сөйләнгәннәрдән әсәрнең нигезендә үгет-нәсихәт, ягъни дидактик әсәр икәнлеге аңлашылса кирәк. Мондый әсәрләр, гадәттә, әдәби яктан кайтышрак сыйфатта язылган булалар. Ләкин шулай да Йосыф Хас Хаҗибның зур талантлы шагыйрь, чын ил-

һәм иясе булуын күрсәтә торган юллар поэмада аз түгелләр. Мәсәлән, язны тасвирлау, яшьлекне сагынып, картлыктан зарлану һәм башка лирик чигенеш моментлары бик зур осталык белән, гаҗәеп тәэсирле итеп язылганнар. Болар барсы авторның, югарыда әйткәнебезчә, беркадәре әдәби мәктәп узып, үзеннән элгәреләрнең бай тәҗрибәсенә таянган булуын күрсәтәләр.

Шагыйрь үзенең карт булуын әйтә. Димәк, бу аның соңгы әсәрләреннән берсе булса кирәк. Ә элеккеләре, шагыйрьнең яшьрәк чагында язылганнары кайда! Алар, һичшиксез, булганнар, тик югалганнар, яисә әлегә хәтле табылмаганнар. Алар киләчәктә, бәлки, табылырлар да. Мәсәлән, Синьцзяньдагы Өремче (Урумчи) шәһәрендә бихисап күп кульязмалар әлегә кадәр тикшерелмичә яталар, алар арасында 900 ел элек язылган кульязмаларның да очраштыргалавы мәгълүм. Бәлки, шулар арасында Йосыф Баласагунның да яңа әйберләре саклангандыр!!

Болай өметләнергә дәлилләр җитәрлек. Аларның берсе — «Котадгу белег»нең бик киң таралган, мәшһүр әсәр булуы. Югарыда әйтелгәннәрдән тыш (мәсәлән, әсәрнең төрле илдә төрлечә исемләнүен алыгыз) тагын бер мисал китерик. 1909 елны Алтын Урда дәүләтенең мәдәни мәркәзләреннән берсе булган Сарайчык каласының шәһәрлеген казыган вакытта табылган бер чүлмәктә түбәндәге язулар бар:

«Киши күрки йөз ул, бу йөз күрки күз,
Бу аууз күрки тил ул, бу тил күрки сүз».

Ә без сөйли торган «Котадгу белег» поэмасында исә шундый бәет бар:

Укуш күрки тил ул, бу тил күрки сүз,
Киши күрки йөз ул, бу йөз күрки күз.

Күренә ки, биредә мәгънә дә, шигырь дә бер, бары сүзләр генә алмашынган. Димәк, бу әсәр Алтын Урда туфрагында да киң таралган булырга кирәк. Гади бер чүлмәкче кулында «Котадгу белег»! Билгеле булганча, Нәваи, Сәгъди кебек бөек шагыйрьләрнең әсәрләре дә төрле вариантта, төрле эшкәртелештә таралган. Мондый үзгәрешләр авторлар исән чакта да булганнар. Хәтта «Котадгу белег»нең өч нөсхәсендә дә андый аермалар шактый күп табыла. Кыскасы, без тикшерә торган әсәрнең нөсхәләре заманында күп кенә булган булырга тиеш.

Йосыф Хас Хаҗибның әсәре мәдәни-тарихи җәһәттән дә бик зур әһәмияткә ия. «Котадгу белег»нең безгә килеп җиткән дөньяви эчтәлеге төрки телдәге иң борынгы әдәби әсәр булуы хакында югарыда беркадәре сөйләнде. Әйтелгәннәрдән бу истәлекнең уп иҗат ителгән дәвергә хәтле булган төрки язма әдәбият тарихын өйрәнү өчен дә мөһим икәнлеге аңлашылса кирәк. XI гасырдан соңгы төрки телдәге әдәбиятларны тикшереп белү өчен исә «Котадгу белег»нең кыйммәте тагы да зур. Югарыда китерелгән бер мисалдан тыш (чүлмәктәге язулар) «Котадгу белег» белән башка төрки әдәби әсәрләр арасында да көчле мөнәсәбәт булуын әйтергә кирәк. Мәсәлән, төрле төрки халыклар арасында киң таралган мәшһүр «Кыйсас Рабгузи» әсәрендәге шигъри текстлар белән (XIV гасыр истәлеге) без тикшерә торган әсәрдә аваздашлык шактый көчле. Мисалга яз фасылына багышланган шигырьләрне алып булыр иде. Шулай ук икенче бер әһәмиятле истәлек булган «Гатибәт әл-хакаик» исемле әсәр (XII—XIII гасырлар) турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Ә болар — төрки дөньяда бик киң таралып, бик күп төрки халыкларның язма әдәбиятларына тәэсир ясаган әсәрләр. Болардан тыш, тюрколог П. Мелиоранскийның хәбәр итүенә караганда, монгол империясендә «Котадгу белеги Чингиз-хани» дигән дидактик әсәрнең булуы да мәгълүм. Димәк, Йосыф Хас Хаҗибның әсәре Алтын Урда дәүләтендәге төрки әдәбиятларга да тәэсир ясаган булып чыга. Югарыда аталган Ташкент нөсхәсенең «з-группа» диалект вәкиле тарафыннан (ягъни Түбән Идел һәм Харәзм төркиләре вәкиле тарафыннан) күчерелгән булуы бу гипотезаны көчәйтә генә.

Кыскасы, әдәби-тарихи планда алганда, «Котадгу белег» әсәренең әһәмияте бер Караханилар дәүләтенең дәвере һәм даирәсе белән генә чикләнеп калмый. Икенчерәк итеп әйткәндә, бу әсәр борынгы язма әдәбиятлы халыкларның күбесе өчен уртак истәлек ул.

Йосыф Хас Хаҗибның поэмасы иҗтимагый-тарихи күзлектән караганда да бик зур байлык. Чөнки аны җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә XI гасырда хөкем сөргән идеология үзенчәлекләре, иҗтимагый фикер торышы, әдәп һәм педагогика мәсьәләләре, дәүләт һәм власть, хокук һәм бурыч

проблемалары турындагы тәгълиматлар, карашлар хакында да бай мәгълүмат алып булачак. Ә китапта теркәлгән социаль-иҗтимагый терминология өлкәсенә килсәк, бу инде тарихчылар өчен бетмәс-төкәнмәс хәзинә.

Бу мөнәсәбәт белән шуны да кабатлап әйтәсе килә: гарәп-фарсы алымнарының бу әсәрдә бик аз булуы, ягъни шул чордагы саф төрки язма телен төгәл гәүдәләндерүе белән дә «Котадгу белег» гаять әһәмиятле. Шуңа күрә дә бу әсәр бер карлук-уйгур әдәби теленең формалашуына гына түгел, бәлки чыгытай төркисе, Алтын Урда — Хорәзм, Алтын Урда — Мисыр, сәлҗүк-госманлы әдәби телләренең үсешенә дә зур йогынты ясаган. Аталган поэманың үзен тикшерү һәм соңрак дәверләрдә төрки телләрдә язылган әсәрләрне күзәтү бу фикернең дөреслеген раслый. Димәк, Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуниның «Котадгу белег»е күп кенә төрки халыклар әдәбиятларының башында торган уртак чыганак, кипмәс кизләү икән. Шулай булгач, борынгы төрки әдәбиятлардан кайсысының тарихын язганда да «Котадгу белег»тән читләтеп узарга мөмкин түгел.

Ләкин, кызганычка каршы, югарыда әйтелгәнчә, бу әсәр тиешлечә өйрәнелмәгән әле. Истәлек текстының академик басмасы да юк. Әсәрнең теленә күзәтү ясауда телчеләр кайбер адымны атлаган булсалар да, поэманың әдәби планда тикшерелүе бер дә канәгатьләнерлек түгел. Истәлекнең тарихи аспектта өйрәнелү дәрәҗәсе хакында да шундый ук фикерне әйтергә мәҗбүрбез. Шуңа күрә бу мәкаләне «Котадгу белег»не күп яклап өйрәнү дәвере озак көттермәсен иде, дигән өмет белән тәмамлыйсы килә.

# ПАРТИЗАН УКЛАРЫ

*Бөек Ватан сугышы елларында безнең Урал корычы Крупиныкы белән кара-каршы килеп рәхимсез якалашкан һәм бугазлашкан кебек ук, немец фашистларына каршы көрәштә совет халкы үзенең зирәк-тапкыр сүзен дә дошманны фронтта да, тылда да җиңәсе көчле корал итте. Үлемгә каршы сүзләр, яшәүне яклап, илбасар идеологиясе уйдырмаларына каршы торып, көрәшнең алгы сызыгында урын алдылар. Дошман йөрәгенә ук итеп юнәлтелгән әйтемнәр, мәкальләр, мәзәкләр һәм хикәятләр билгеле. Миңа, мәсәлән, ул чакта Белоруссиядәге заслоновчы партизаннарның берсе буларак, андыйларны үз җирләре вакытлыча басып алынган рус, белорус һәм украин дуслардан бик күп ишетергә туры килде. Күпләре истә калганнар, кайберләре язып куелган. Хәзер шул еллар фольклорының да матбугатка әледән-әле киңрәк урын алып керүе һәркемне куандыра. Мин чиксез бай бу иҗатның әлегә аз гына бер өлеше булса да безнең укучыларыбызга күңелле бер сәхифә булып җитүен бик телим.*

*ЗӘКИ НУРИ*

## Кияү

— Бу нинди процессия, Грэта? Кемне дә булса күмүме әллә?
— Юк, женаза түгел, туй бүген.
— Ә ни өчен барысы да елыйлар?
— Көнчыгыш фронтка алып китәләр.
— Кияүнеме?
— Юк, туйдагыларның барысын да.

## Борын чөя

— Син ни диярсең икән моңа: Ганс фронттан кайткан, ә үзе хәтта кул да бирми.
— Бәлки борын чөядер?
— Алай түгел шул! Кулын ул Витебск тирәсе урманнарында калдырган.

## Сәбәбе бүтән

— Рота командирын телефонга чакырыгыз әле, әйтәсе ашыгыч сүзем бар.
— Ә ул сөйләшә алмый бит, гер полковник әфәнде.
— Эше бармы әллә?
— Эше юк, ләкин сөйли алмый, чөнки башы калмады аның: бүген иртән советлар снарядны муен төбеннән алып ук өзеп узды ул башны...

## Блиндажда

Полковник фон Гоп-скок үзенең обер-лейтенанты итек киеп йоклап ятканын күрә.

— Сез нишләп болай аяк салмыйча йоклыйсыз, офицер әфәнде? Бу бит чисталыкка каршы нәрсә...

— Ләкин бу, полковник әфәнде, барыбер безнең файдага. Мин үземнең аякларыма үз батальоныма караганда күбрәк ышанам.

## Хәбәре бармы?

— Шульцтан хәбәр киләме?

— Хәбәре бар, әле күптән түгел генә бик тыныч ятуы турында хат килгән иде.

— Кем язган, Шульц үземе?

— Юк, үзе түгел, штаб начальнигы.

## Теш докторы янында

— Сезнең ике тешне тоташтырган күперчек сынган, комендант әфәнде. Тагын яңаны эшләргә туры килер.

— Кирәкмәстер дә бәлки,— ди комендант, тирән сулап.— Күперне барыбер партизаннар шартлатачак.

## Тамга

— Борыныңда нинди кара тап ул, синең, Яська?

— Шундый минем бар минем.

— Ә ник син аны кисмисең, я булмаса көйдермисең?

— Ярамый, чөнки немецлар аны паспортка яздылар. Аның өчен бик каты эләгүе мөмкин.

## Кызык нәрсә

— Бик тә кызык инде бу немецларның телеграф дигән нәрсәләре: бер очта нәрсәгәдер бармак белән басалар да, икенче башта менә дигән ялган сүз килеп чыга.

— Бу, туганым, нәкъ этләр белән эш иткәндәгечә була инде: аны да бит арттан торып койрыгыннан тартсаң, ул сиңа алдан торып өрә башлый.

## Күрмәсәм дә ишеттем

Немец судьясы бер шаһиттан сорый:

— Чын дөресен генә әйтергә тиеш сез безгә: полицай башына Иван ничек сукканын үз күзегез белән күрдегезме?

— Күрүен күрмәдем аны, әмма ләкин кемнеңдер ниндидер бер буш нәрсәгә сугуын бик ачык ишеттем...

## Дисциплиналылар

— Син нигә кулларыңны күтәрдең әле, юньсез баш. Иң соңгы солдат башын куйганчы сакланырга кирәк диелгән бит сезгә! — дип кычкыра фельдфебель Ганс исемле бер солдатка.

— Ә мин иң соңгысы булам бит, фельдфебель әфәнде,— дип җавап бирә солдат.— Бөтен рота моннан бер сәгать элек үк пленга бирелде инде.

## Күзләрем күрмәделәр

— Руслар сезне нинди көч белән шулай кырдылар соң?
— Әйтә алмыйм, генерал әфәнде, кыруын кырдылар, ә күзләрем күрмәде.

## Днепр ярында

— Ничек уйлыйсың, Фриц, бу елга тирәнме икән?
— Шулай булырга тиеш... Безнең батальон моннан өч көн элек шушы урыннан суга кереп киткән иде, әле һаман әйләнеп кайтканы юк.

## Яхшы исемле авыл

Безнекеләр фронтта бик каты кысрыклагач, фашистлар чигенәләр икән. Авыл саен диярлек туктап, мал талый-талый качалар.
Бер авылда аларга тәбәнәк кенә буйлы, чирләшкә кыяфәтле, колакка бераз катырак һәм күзләре дә чамалы гына шәйли торган карт очрый. Бүтәннәр немецлардан качып урманга кереп яшеренгән булалар.
— Авылыгыз нинди исемле? — дип бәйләнәләр картка.
— Нәрсә? Кемнең исеме?
— Бу нинди авыл, әйт тизрәк, юкса маңгаеңны пулядан чукытам!
— Ә, авыл дисез икән. Партизани исемле була ул.
— Партизани?! Партизани?! — дип пышылдаша башлый фашистлар һәм, машинаны бик кызу чаптырып, китеп тә баралар. Юлда тузан болыты гына күтәрелеп кала.
Авылның исеме яхшы булса, эшләр дә уңа икән.

## Ике ерткыч сөйләшә

Берсе Гитлер, берсе Муссолини исемле ике ерткыч очрашып сөйләшәләр:
— Хәлләрем шундыйдыр ки хәзер, фюререм, мин җир читенә, хәтта җәһәннәмнең үзенә китеп качарга әзермен.
— Дускаем-күгәрченем минем, әгәр шуларның берсенә юлны белсәң, миңа да берәр урын калдырчы анда.

## Һөҗүм алдыннан

— Фриц, бу юл кая илтер икән безне?
— Теге дөньяга.

## Бер көтү хайван

Гитлерчылар халыкның инде барлык терлеген диярлек талап бетерсәләр дә һаман мал житми үзләренә.
— Тагын күпме терлек табарбыз бу якларда?
— Җитәрлек әле,— дип җавап бирә авыл картлары,— әйтик әнә, безнең старостабыз бик яхшы нәселле үгез кебек, аннары тагын бер көтү полицай бар.

## Бер аңлашу

— Кызыллар үз елгаларын сихерләп-тылсымлыйлар дигән уй каян килде әле синең башыңа?
— Чөнки без алар иленә килгәндә Дон елгасы безгә тездән генә иде, ә менә хәзер бу яклардан табан ялтыратканда исә аның төбенә аяклар да көчкә тия.

# ФРОНТ МАТБУГАТЫННАН

*Татарстанның күп кенә язучылары Бөек Ватан сугышы фронтларында совет дәүләтен штык һәм каләм белән саклауда актив катнаштылар. Аларның бер группасы фронтларда татар телендә чыккан газеталарда эшләп, совет солдатларын-якташларыбызны рухландыручы мәкаләләр, очерклар, шигырьләр яздылар. Мәсәлән, «Ватан өчен сугышка» (Карелия фронты) газетасында Г. Әпсәләмов, «Кызыл Армия» газетасында (1 нче Белоруссия фронты) И. Гази, Г. Кутуй, «Ватан өчен» газетасында (Төньяк-Көнбатыш фронты) Ш. Мөдәррис, Г. Насрый, Х. Госман, «Алга, дошман өстенә» газетасында (Калинин фронты) Ш. Маннур, А. Шамов, А. Әхмәт иптәшләр эшләде. «Ватан намусы өчен» газетасында (1 нче Украина фронты) тупланган Р. Ишморатов, Г. Хуҗиев, М. Садри, Г. Бакиров, З. Шаһиморатов иптәшләр Берлинны алуда, Праганы азат итүдә катнаштылар.*

*Бу санда укучыларыбызга шагыйрь Мөхәммәт Садриның «Ватан намусы өчен» газетасында басылган берничә сатирик әсәрен һәм шул әсәрләргә газета художниклары ясаган иллюстрацияләрне тәкъдим итәбез.*

## ЯҢАДАН-ЯҢА „ТЕЛ“ЛӘР



Әй, сугышчы, батыр разведчикның
Эшләренә тагын бер кара;
Без «тел»ләрне күбрәк тоткан саен
Гиббельснең теле кыскара.

Эләктереп фашист ерткычларның
Ачу чәчкән явыз «тел»ләрен,
Тизләтәбез бөек илебезнең
Тантаналы җиңү көннәрен.

*В. БРИСКИН рәсеме.*

# ГВАРДЕЕЦЛАР ЯСАГАН «БӘЛЕШ»



Гитлерчылар хәзер белә инде
«Фюрер»нең дә шулай кабасын,
Ышанмаса, безнең гвардеецның
«Бәлешләрен» килеп карасын.

Тиздән-тиздән явыз Гитлерның да
Янына ук барып җитәрбез;
Фрицларны «бәлеш» иткән кебек,
Гитлерны да «коймак» итәрбез!

**1941 нче ЕЛДА** **1944 нче ЕЛДА**




Аннан талап, моннан урлап,
Яңа күлмәк текте ул,
«Бөтен дөнья бикәсе», дип
Үзен игълан итте ул.

Рус штыгы бу «бикә»нең
Тетмәсен тетеп салды,
Шуңа күрә элеккечә
Бер йолкыш булып калды.

*И. СЕМЕНОВ рәсеме.*

## Ильтани Илялова

# ИСЕМЕ—РИНАТ АНЫҢ



Ул Ринат исемле. Фамилиясе — Таҗетдинов. Яңа елның иң беренче көнендә — 1938 елның 1 гыйнварында дөньяга килә. Туган җире — Буа районындагы Кече Чынлы авылы. Үсә төшкәч, артист була. Урамнарда язның тәүге нурлары уйный башлаган көннәрдә — 1966 елның апрель аенда аңа Тукай премиясе лауреаты дигән мактаулы исем бирелә. Ике елдан бу исем янына тагын бер дәрәҗә өстәлә — Татар дәүләт академия театры афишаларында аның фамилиясе турысына «ТАССРның атказанган артисты» дигән сүзләр языла башлый.

Татар дәүләт академия театры артисты Ринат Таҗетдиновның телгә алып сөйләрлек бөтен биографиясе менә шул бугай. Туа, үсә, белем ала, эшли башлый. Бер карасаң, бик гади кебек. Әмма шушы кыска, нибары утыз еллык кына вакыт бөген бер зур гомергә тиңләшерлек. Шул еллар эчендә күпме сөенечләр һәм көенечләр күрмәгән дә, күпме шатлыклар кичермәгән ул.

Хәер, Ринатның борчулы көннәре бик аз булгандыр. (Күз генә тимәсен!) Аның турында «ул бәхетле йолдыз астында туган» дип шаярып сөйлиләр.

Әйе, яшь артистның уңышларына, чыннан да, көнләшерлек: күңеле теләгән уку йортына керү насыйп була, аны уңышлы тәмамлап, әйбәт кенә эшли башлый, матур гаилә тормышы корып җибәрә. Бәлки, артистның бу уңышларында гаҗәпләнерлек берни дә юктыр? Бәлки, «гаепле» кеше ул үзедер? Бу уңышларга ул табигый сәләте һәм искиткеч эш сөючәнлеге нәтиҗәсендә ирешкәндер? Карап карыйк: Ринат бу уңышларга ничек ирешә икән?

Ринатның биографиясе башка яшьтәшләренекеннән берни белән дә аерылмый диярлек. Малай чагында артист булу турында башына да китерми ул. Алай гына да түгел, чын артистларның бер генә спектаклен дә карарга туры килми аңа. Рәтле клубы да булмаган бәләкәй авылга нинди театр килеп йөрсен! Шулай да аның хыяллары кече яшьтән үк сәнгать дөньясына барып тоташа. Консерваториягә кереп, җырчы булу турында уйлый яшь егет. Һәм тикмәгә генә түгел. Музыкаль смотрлар вакытында аның ягымлы көр тавышы, моңлы җыры күпләрне әсир итә. Ләкин бәлә аяк астында гына йөргән икән. Бервакыт Ринат тавышын югалта. Аны өметсезлек биләп ала. Җырдан, музыкадан башка яшәү аңа ничектер буш һәм мәгънәсез булып күренә башлый. Бу рухи газаплардан аны аек акыллы, тәҗрибәле әтисе коткара. Күңелдә яңадан өмет кошы канат кагына, үз көченә ышанычы ныгый.

Урта мәктәпне тәмамлагач, Ринат зур хыяллар белән Казанга килә. Документларын консерваториягә тапшыра. Ләкин

Аннан да кире борылырга туры килә. Беткән баш беткән дигәндәй, документларын финанс-экономика институтына илтеп тапшыра. Экзаменнар бирә башлый. Ләкин үзеннән беринди финансист чыкмаячагын ачык сизә: математикадан экзамен бирергә дип алган билетын, укытучыдан гафу үтенеп кире тапшыра, имтиханнарны биреп тә бетермичә, яңадан туган авылына кайтып китә. Укый, әзерләнә. Исәбе — берәр институтка керү. Ләкин кайсына — үзе дә белми.

Шул елны аның тормыш агымын үзгәрткән бер вакыйга була. Авылга республика күчмә театры артистлары килә. Һәм Ринат театр белән «авырый» башлый. Шул ук елда икенче бер могҗиза була: 1956 елның язында газеталар Мәскәүдә татар актерлар студиясе ачылу турында хәбәр итәләр. Бу инде — болай да янып торган утка ялкын өстәгәндәй була. Әтисенең хәер-фатихасын алып, Ринат тагын Казанга юл тота. Кабул итү комиссиясендә исә Ринатка да һәм аның иптәшләренә дә фатиханы Академия театрының танылган артистлары, аерым алганда, олы сәхнә остасы Хәлил ага Әбҗәлилов бирә. Әле театрның нәрсә икәнен дә рәтләп белмәгән яшьләр «театр Мәккәсе» Мәскәүгә киләләр һәм даны бөтен дөньяга таралган Кече театрда белем алырга керешәләр.

Шулай һәртөрле мәшәкатьләр һәм маҗаралар белән тулы студент еллары башлана. Аларны Рига вокзалыннан ерак түгел урнашкан гомуми торакка — атаклы Трифоновкага урнаштыралар. Егетләргә еш кына вокзалда товар вагоннары бушатып ипилектозлык эшләргә дә туры килгәли. Ринат хәтта бер ара химия заводында да эшләп карый. Ләкин озакка түзми. «Кыякларга» туры килә.

Ә көннәр... киеренке уку эчендә үтәләр дә үтәләр. Мавыгулар, сөенечләр кайчагында күңел төшенкелеге белән дә алмашынгалый. Ринатка башта бик кыенга туры килә. Егетне һич кенә дә «кулга ияләштерә» алмыйлар: этюдлары барып чыкмый аның. Башкаларның бөтенесе дә шома бара. Р. Шәрәфиев, мәсәлән, сарык сую этюдын шулкадәр бирелеп башкара, хәтта педагогның теңкәсенә тиеп бетә. Укытучы хәтта аннан бу этюдны куеп тор дип ялварырга мәҗбүр була. Ринат исә актер осталыгы буенча этюдлар башкарганда аптырап бетә, ничектер үз эченә бикләнә, оялып кала иде.

Таҗетдиновны дәрестән соң алып кала һәм аның белән ачыктан-ачык сөйләшеп карый. Курыкмаска, үзеңне иркен тотарга кирәк, ди. Матур-матур киңәшләр бирә. Шуннан егет акрынлап эзгә керә, үзен иркенрәк сизә башлый, аңа кыюлык өстәлә.

Училищеда укучыларга еш кына, эшлиэшли үз-үзләрен онытып, студиядә караңгы төнгәчә калырга туры килгәли. Андый чакта М. Н. Гладков, берәрсен дежур гастрономга җибәреп, азык-төлек алып кайттыра, һәм, тамак ялгап алгач, эш яңа көч белән башланып китә. Андагы кайнар бәхәсләрнең иге-чиге булдымы икән? Әле берсе нәрсә булса да тәкъдим итә, икенчесе башка фикерне куәтли — актер профессиясенең нечкәлекләре, яшерен серләре шулай акрынлап ачыла бара. Щепкин исемендәге студиядә тәрбияләнүчеләр үзләренең педагогларын хәзер дә аеруча бер җылылык белән искә алалар. Чөнки ул үз вазифасын ничек кирәк алай башкаручы гади укытучы гына булмый, ә дөрес юл күрсәтүче акыллы киңәшче дә була. М. Н. Гладков үзе театр дөньясына керткән кешеләрнең язмышы белән турыдан-туры кызыксынып тора. Әле үткән кыш Казанга махсус килеп, Академия театрының күп кенә спектакльләрен карады, үзенең шәкертләренә эшлекле киңәшләр бирде.

Щепкинлылар студент елларында ук бөтен дөнья драматургиясенең иң яхшы үрнәкләрендә тәрбияләнәләр. «Отелло» трагедиясеннән Отелло һәм Яго, Отелло һәм Дездемона күренешләрен эченә алган өзекләр дә шул максатка юнәлтелгән иде. Ринат ул вакытта Отеллоны уйный. Әлбәттә, ул бу әсәрнең фәлсәфи тирәнлеген аңлаудан, образны үзенчә мөстәкыйль хәл итүдән ерак иде әле. Шулай да бу роль аны Шекспирны яратырга өйрәтә. Яшь артист хәзер дә Шекспир тудырган үлмәс образларның берсен, бигрәк тә Отеллоны уйнарга хыяллана.

Эштән буш кичләрдә Мәскәү театрларына йөрү чын-чыннан олы бәйрәмгә әверелә, шуның белән бергә яшь артистлар өчен осталык мәктәбе дә була. Ринат һәр буш кичен Кече театрда, МХАТта, Вахтангов исемендәге, Маяковский исемендәге һәм яңа гына ачылган «Современник» театрларында уздыра. Мәскәү, аның кайнап торган театраль тормышы, совет һәм чит ил коллективларының гастрольләре, Япониянең «Кабуки» театрыннан башлап бөтен дөньяга

ларының чыгышларына кадәр, һәртөрле күргәзмәләр, концертлар — берсе дә алар игътибарыннан читтә калмый. Матурлыкка, гүзәллеккә мәхәббәт аларның бик үк җиңел булмаган тормышын кызыклы һәм мәгънәле итә. Ринат ул елларны тирән сагыну, эчке бер шатлык белән искә төшерә.

Таҗетдиновка училищеда төрле амплуадагы рольләр өстендә эшләргә туры килә. Кайсы характерлы, кайсы комик, кайсы героик була ул рольләрнең. Шуңа күрә диплом эше итеп Маяковскийның «Мунча»сындагы Победоносиков ролен сайлавы да очраклы хәл түгел. Татар студиясе артистлары тарафыннан куелган «Мунча» спектакленә Мәскәүнең театр җәмәгатьчелеге югары бәя бирде. Уңышның сере, беренче чиратта, әлбәттә, төп рольне башкаручы Р. Таҗетдиновка бәйләнгән иде. Үзе әйткәнчә, образны Ринат беркадәр традицион рухта башкара. Шулай да яшь артист әсәрне үзенчә аңларга, кызыклы яңа детальләр табарга тырыша. Победоносиков һәм бухгалтер Ночкин күренешендә, К. Маркскың карта уйнавы турында сүз барганда, Победоносиков-Таҗетдинов бүлмәдәге К. Маркс бюстының ирексездән колакларын томалавы әнә шул уңышлы детальләрдән саналырга хаклы. Бу роль Таҗетдиновның төрле пландагы образларны уйнарга сәләтле, киң диапазонлы актер икәнен күрсәтте.

Победоносиков роленнән тыш, Ринат Ә. Фәйзинең «Тукай» драмасында Галиәсгар Камалны уйнады, аның образында фикер иясе, халыкка хезмәт итү өчен көеп-янып йөрүче кешене гәүдәләндерергә тырышты.

Әгәр без Р. Таҗетдиновның «бәхетле йолдыз астына туры килгән» уңышлар тулы язмышы турында сөйлибез икән, моңа бөтен нигезләр бар. Ул Щепкин исемендәге театр училищесын бары тик яхшы билгеләре белән генә тәмамлады. Яшь артисттагы талант чаткыларын бәяләргә өлгергән дәүләт комиссиясе членнары да аны Кече театрда калдыру турында чын-чынлап уйлаганнар иде. Ринатның рус телен әйбәт белмәве генә моңа комачаулады.

...Мәскәү белән Ринатның иң якты истәлекләре бәйләнгән. Бирелә ул үзенең гомерлек мәхәббәтен тапты. Ул чагында дүртенче курста укый иде Ринат. Башкалага гастрольләргә Илһам Шакиров килә. Булачак тормыш иптәше Рәисә белән алар менә шул концертта танышалар. Мәскәүдә туып-калдырып, дан-шәһәрәте дә, һәм хәтта торыр урыны да булмаган яшь ире белән Казанга кайтырга, аның язмышын уртаклашырга туры килә. Шулай итеп Илһам Шакиров, үзе дә сизмәстән, ике яшь йөрәкнең кавышуына сәбәпче була. Сәнгатькә, театрга турыдан-туры катнашы булмаса да, бу мөлаем хатын актер Ринатның чын дустына, булышчысына әйләнә. Еш кына ул ире катнашкан спектакльләрне кат-кат карый, Ринат белән бергә дулкынлана, шатлана, кайгыра. Гаиләдәге дусларча мөнәсәбәт, ярты сүздән аңлашу да актерның иҗатына уңай йогынты ясамый калмый, әлбәттә.

Мәскәүдә биш ел уку сизелмичә үтеп тә китә. Яшь артистлар Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының данлы коллективына кушылалар. Театр ветераннары Таҗетдиновның иҗади сәләтенә башта ук ышандылар. Ә бу — олы сәхнәгә аяк баскан яшь егет өчен бик мөһим иде. Әлбәттә, җиде ел эшләү чорында төрле дәрәҗәдәге, төрле югарылыктагы рольләр башкарырга туры килә. Ләкин ул беркайчан да тирән ялгышлар ясамый, алга баруын тигез дәвам итә. Шуңа күрә кыска гына вакыт эчендә аның Тукай премиясе лауреаты һәм ТАССРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәргә лаек булуы бер дә гаҗәп түгел.

1961 елдан бирле Ринат уннарча образлар тудырды. Аяз Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләрдә» драмасында Хәнҗәр роле аның Казандагы беренче эше иде. Аннан ул Мостай Кәримнең «Җырланмаган җыр» пьесасында хәйләкәр һәм мәкерле карьерачы Вәзирне уйнады. Хәй Вахит комедияләрендәге рольләрне башкарды.

ГИТИСның режиссерлык факультетын тәмамлап кайткан Марсель Сәлимҗановның 1962 елда «Котырган акчалар» спектаклен куюы һәм аны үзенчә хәл итүе сәнгать дөньясында зур кызыксыну уятты. Яшь режиссер, тапталган сукмактан бармастан, спектакльнең бөтен агышын әсәрнең исеменә илтеп ялгады. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр нииндидер нормаль булмаган, киеренке һәм чыннан да котырынган итеп күрсәтелде. Сентименталь борынгылыктан, беренче карашка зирәк һәм акыллы итеп сурәтләнгән Васильковны идеаллаштырудан качылды. Геройларның мөнәсәбәтләре икейөзлелек һәм мәрхәмәтсезлек белән тулы, һәркем үз мәнфәгате турында кайгырта.

Әсәрнең шулай оригиналь чишелешен-

деталь бар иде. Ул татар театры осталарының дан казанган ансамбленә килеп кушылды — Ф. Ильская, Х. Әбҗәлилов, Г. Шамуков, Ш. Әсфәндиярова, П. Исәнбәт кебек тәҗрибәле артистлар белән бергә уйнады. Шуңа күрә Таҗетдинов башкарган Глумов роле, гәрчә ул аның өчен актер осталыгының югары ноктасы булмаса да, бу юнәлештә алга бару өчен зур этәргеч иде.

Еллар буе уйналган зур һәм кечкенә рольләр Ринатның бөреләнгән талантына яңа сыйфатлар, яңа төсмерләр өсти торды. Ул бернинди эшкә дә чирканып карамады. Еш кына урта кул спектакльләрдә дә Р. Таҗетдинов башкарган рольләр башкалардан аерылып тордылар. «Ай тотылган төндә» постановкасындагы Дивана, «Яшь йөрәкләр»дәге Хәйретдин әнә шундыйлардан иде. Шуның нәтиҗәсе буларак, киеренке хезмәт үзенең матур җимешләрен дә бирә торды.

Р. Таҗетдиновның актерлык осталыгы турында сөйләгәндә, аның «Муса Җәлил» спектаклендә баш рольдә уйнавын әйтеп китмичә булмый. Артист биредә чын совет кешесе, патриот образы тудырды. Таҗетдиновның Мусасы «куркусыз һәм шелтәдән азат рыцарь» түгел. Ул барыннан да бигрәк үз илен чиксез сөюче, киң күңелле, миһербанлы кеше. Җир йөзендә игелек һәм гаделлек хакына көрәшә ул. Муса өендә хатыны һәм кызы янында аеруча ягымлы һәм игътибарлы. Мөлаем һәм йомшак күңелле бу кешенең корычтай чыдам, нык ихтыярлы булуына беренче карашка ышануы да кыен төсле.

Германиядә татар эмигранты йортында барган күренешләрдә дә Муса ягымлы, шат һәм ваемсыз итеп сурәтләнә. Аның бу халәте тышкы яктан гына шулай. Тамашачы геройның күзләрендә чит һәм дошман җиргә килеп эләккән кешенең әйтеп бетергесез сагышын укый.

Таҗетдинов Җәлилне хәрәкәттә, үсештә бирә. Шагыйрь образы күренештән күренешкә тышкы яктан да, эчке яктан да үзгәрә бара. Аның уйлары безгә дә килеп җитә сыман. Төрмә һәм тикшерүче бүлмәсендәге күренешләрдә ул кырыс һәм каршамас ихтыярлы, үзенең үтерүгә хөкем ителгәнен белгәч тә, ныклыгын һәм кыюлыгын югалтмаган кеше булып күз алдына килеп баса.

Батырлык һәм ныклык үзенчәлекләрен калку итеп күрсәтү белән берраттан, Таҗетдинов образның интеллигенция вәкиле, сым ясый, геройны безгә якын итеп күрсәтү өчен тәэсирле чаралар сайлый. Бу аңа эчке каршылыксыз тулы бер характер тудырырга ярдәм итә.

Үзбәкстан халык артисты Т. Ходжаев тарафыннан куелган «Гүзәлем Әсәл» спектакле Р. Таҗетдинов талантының тулырак ачылуы өчен уңдырышлы җирлек булды. Образларның эчке дөреслеге, эчке иркенлеге артистларны гади тел белән сөйләшергә этәрде. Татар театрының күп кенә спектакльләре өчен хас көйләп сөйләү алымы читкә кагылды.

Эссе көндә салкын чишмә суы эчсәң, үзең дә тел белән әйтеп бирә алмаслык ниндидер рәхәтлек хисе тоясың. «Гүзәлем Әсәл» спектаклен караганда да шундый ук хис кичерәсең. Әсәр башыннан ахырына кадәр тамашачыны тартып тора. Вакыйгалар, динамик үсештә бирелеп, ниндидер дәртлелек, ялкынлылык белән, төп фикердән бер урында да аерылмастан, кешеләргә олы мәхәббәт турында бертуктаусыз сөйлиләр.

Бөтен спектакльгә бары бер декорация — тауларга күтәрелүче юл гына (художник Э. Гельмс) ясалган. Ул — әсәрнең символик образы. Пьеса геройларының гомере шул юл тирәсендә үтә. Тормышларының төрле моментында алар я тауның түбәсенә күтәреләләр, я түбәнгә тәгәриләр. Менә шул детальләр әсәргә тирән фәлсәфи яңгыраш бирәләр дә инде.

Спектакльдәге геройларның һәркайсы үзенчәлекле, 'ләкин аларны берләштерә торган уртак яклар да бар. Бу — аларның эчкерсезлеге, вөҗданлылыгы, киң күңеллелеге. Автобаза диспетчеры Хәдичәгә гашыйк булып йөрүче тынгысыз шофер егет Ильяс та (Р. Таҗетдинов шул рольне башкара) шул сыйфатларга ия. «Ильяс тиз мавыгып китүчән, кызу канлы кеше, ишарәләр, күп очракта тотрыксыз хәрәкәтләре еш кына тәгәлләнми кала, сөйләү тоны җәһәт, кайчакта кисәктән үзгәрә, темпераменты чайпалырга тора. Бу актерга шелтә түгел. Киресенчә, ул образның мөһим төсмере»[1]. Менә ул Әсәл исемле кызны очрата һәм шунда чын бәхетнең нәрсә икәнен аңлый. Аның элекке елгырлыгының эзе дә калмый. Ул хәзер дулкынланулы, күзләреннән мәхәббәт нуры сирпелә. Аның хисләренең эчкерсезлегенә ышанмый мөмкин түгел. Ильяс һәм Әсәлнең (артистка Н. Га-

---

[1] «Театр» журналы. 9 сан. 1967 ел.

ләндә соклану уята.

...Таулар итәгендә, чәчәккә күмелгән агачлары белән хозурланып утырган йорт янында Ильясның машинасы ватылып калган. Су эзләп йөргәндә егет бер хатынкызга юлыга.

«Әбекәй!» дип эндәшүгә кисәк кенә көлә башлаган яшь кыз аны таңга калдыра. Шул минутта аларның икесен дә олы мәхәббәт хисе чолгап ала. Көтмәгәндә кабынып киткән бу хис бөтен әсәргә сафлык, яктылык өсти. Ике яшь йөрәкнең карашларында күпме пакьлек күрергә мөмкин. Әсәл, иркә һәм назлы роза чәчәгедәй, егеткә тартыла. Дуслары янында башкисәрдәй йөргән Ильясның кыюлыгы әллә кая югалган. Гашыйкларның күзендә чиксез бәхет чаткысы уйный. Ләкин Ильяс образының үсеше моның белән тәгәлләнми әле. Спектакльнең азагына кадәр Р. Таҗетдинов үз герое характерының төрле, көтелмәгән якларын ача бара. Безнең замандашыбыз булган Ильяс роле артистның иң яраткан образына әверелде.

Соңгы елларда, бигрәк тә бу спектакльдән соң, Ринатка бик күп хатлар килә башлады. Аларның кайберләре мәзәк, икенчеләре уйландыра, тәэсирләндерә торган. Бераүләр аңа гашыйк булулары турында язалар. Икенчеләрендә аннан киңәш алу максаты белән хат авторларының тормыш юллары сөйләнгән. Бу уңайдан ирексездән Гогольнең: «Театр ул — дөньяга бик күп игелекле сүзләр әйтердәй кафедра», дигән канатлы сүзләре искә төшә, әле яшь кенә артистның да тормыш дәресләре бирүче булып әверелүенә төшенә башлыйсың.

Бразилия драматургы Фигейредоның «Эзоп» пьесасындагы төп роль — Таҗетдиновның соңгы иң җитди эшләреннән берсе. Аны хәл итү бик авыр бурыч ул. Артистның өметсезлеккә бирелгән чаклары да була. Хәтта ул рольдән баш тарту турында да уйлый.

Артистның Эзоп образы өстендә мондый газаплы эзләнүләре аңлашыла — бу Таҗетдиновның трагик персонаж белән беренче очрашуы иде диярлек. Өстәвенә, ул моңарчы уйналган рольләрнең берсенә дә охшамаган. Ринат премьера алдыннан гына образның серенә төшенә башлый — «боз кузгала». Спектакль һәм Эзоп үзе тамашачылар тарафыннан хуплап каршылана.

Спектакльнең уңышына П. Исәнбәтнең әсәрне оригиналь чишүе дә зур булышлык итте. Театр сәхнәсендә геройлар борынгы лы, хисчән кешеләр булып гәүдәләнделәр. Эзопның эмоциональлеге, азатлык өчен янып-көеп, армый-талмый көрәшүе һәркемне тетрәтә. Биредә артистлар уйнарга күнеккән һәм тамашачылар күрергә гадәтләнгән көнкүреш күренешләре дә, сентиментальлек тә, җырлар да юк. Ул — барыннан да бигрәк кол кешенең язмышы һәм көрәше турында кырыс хикәя.

Шуңа күрә спектакльнең декорациясе дә гади һәм шартлы итеп эшләнгән. Сәхнәдә без ярымтүгәрәк станок, аның өстенә куелган өч шәмдәл, ә задникта зәңгәр күк йөзен генә күрәбез. Режиссер игътибар үзәгенә актерны куйган. Спектакльдә бөтен катнашучыларның диярлек башкару осталыгы тиешле художество югарылыгында булу факты гына да күп нәрсә турында сөйли. Беренче чиратта бу Р. Таҗетдиновка кагыла.

МХАТ постановкасында В. Топорков башкаруындагы Эзоп философ итеп, зур тәҗрибәле, кырыс тормыш мәктәбе үткән һәм дөньяның ачысын-төчесен татыган кеше итеп сурәтләнә. Аның шикләнүчәнлеге һәм ирониясе көлүе дә шуннан килеп чыга. Таҗетдинов башкаруындагы Эзоп исә үзенең азатлыкка омтылуында яшьләрчә тыелгысыз. Ул зынҗырларын өзүче мустангны хәтерләтә. Яшь актер шундый гаҗәеп көчле трагик образ тудырды. Әлбәттә, Ринат иҗат иткән Эзопка философик, тирән акыл, тәҗрибә җитеп бетми. Һәм актер аның ул сыйфатларына басым ясарга омтылмый да. Ләкин Эзоп үзенең газаплары, ирекка чиксез омтылышы белән таңга калдыра, өметсезлеккә бирелүләре һәм җәфалanулары белән тетрәндерә. Азатлык турында хыял әсәрнең буеннан буенча кызыл җеп булып сузыла. Ирек хакына Эзоп барлык мәсхәрәләрне, кимсетүләрне, кыйналуларны күтәрергә әзер. Таҗетдинов герое соры күлмәккә төренгән ябык, янтык гәүдәле, бөкрәйгән, ямьсез бер кеше булып күз алдына баса. Ләкин бу килбәтсезлек, шыксызлык Эзопның акыллы һәм үткен күзләрен томалый алмый. Тышкы яктан Эзоп-Таҗетдинов аз хәрәкәтчән, ишарәләргә саран, тавышы да акрын һәм тыныч. Әмма анда күпме кичереш, күпме омтылыш яшеренгән. Ул аерым моментларда гына үзенә ирек бирүләрен ялварып кычкыра. Менә аңа, әгәр күктә ике кукшә күрсәң, азат булырсың, дип вәгъдә иткәннәр. Эзопның күзләре күккә төбәлгән. Ниһаять, ул күткән кошлар. Ул, сөенеченнән ниш-

вын үтенә. Аның хуҗасы бу минутта хатыны белән үбешеп тора. Эзоп аңа тагын ялвара. Ксанф тагын хатыны белән мәшгуль. Кол кеше шашынып: «Кара!» дип кычкыра. Хуҗа, аңа илтифат итмәстән, кулын гына селти. Күкшәләр инде китеп югала. Эзоп әрнүләренең чиге-кырые юк сыман: ул, җиргә ятып, беренче тапкыр өметсезлеккә бирелеп кычкырып елый.

Бу килбәтсез кешенең чибәр Клея белән сөйләшү күренеше дә гаҗәеп оста эшләнгән. Кол бу хатынны ярата, ләкин ул үзенең хисләренә ирек бирми. Ш. Әсфәндиярова башкаруындагы Клея аңа мәхәббәте турында башта уйнап кына әйтә сыман. Ләкин максатына җиңел генә ирешә алмагач, ул я кырыслана, я хәсрәтле кыяфәткә керә. Безнең алда мәхәббәте кире кагылган, ачулы һәм горур патрицианка. Ә күзләреннән сагыш һәм мәхәббәт ташып торган Эзоп Клеяның аны кызгануын, яраларына тоз салмавын үтенеп ялвара. Менә ул Клеяның башын үтә саклык һәм наз белән иңбашысенда калдырырга теләгәндәй, бер мизгелгә тынып кала, аннан зур газаплар белән үз хисләренә катгый хөкем чыгара.

Эзоп-Таҗетдинов характерында без газап һәм әрнү, ачу һәм курку, ирония һәм зәһәрлелек, сарказм һәм горурлык күрәбез. Аның: «Ксанф, диңгезне чөмер!» дигән сүзләре нинди тирән мәгънәгә ия. Эзоп күпкырлы һәм төсмерләргә бай образ — ул я җәзалаулардан куркучы әзәрлекләнгән кол булып, я үлемгә каршы кыю баручы горур һәм азат кеше булып гәүдәләнә.

Эзоп образы өстендә эшләү яшь актерның гадәттән тыш сәләтен, зур мөмкинлекләрен ачып күрсәтте.

Яраткан артистыбыз ялкынланып яши, илһамланып иҗат итә. Бар тормышын сәнгатькә хезмәт итүгә, сәхнә осталарының иң матур традицияләрен дәвам итүгә багышлый ул. Шул мактаулы юлдан тайпылышсыз алга таба бара да бара.

Исеме — Ринат аның.

# КҮҢЕЛСЕЗ КИМЧЕЛЕКЛӘР

Галимнәребез борынгы әдәбиятның үлемсез үрнәкләрен эзләп табу, табылганнарын моңарчы билгеле вариантлары белән чагыштырып өйрәнү, аларны гыйльми эшкәртү һәм, бүгенге укучыга тәкъдим итәрлек дәрәҗәгә китереп, җыентыкларда, хрестоматияләрдә һәм аерым китаплар рәвешендә басып чыгару буенча соңгы елларда зур инициатива һәм активлык җәеп җибәрделәр. Бу, әлбәттә, шатлыклы күренеш. Борынгы әдәбиятыбызга караган әсәрләрнең байтагы «Татар поэзиясе антологиясе»ндә һәм «Борынгы татар әдәбияты» исемле китапта бирелгән булса, тагын күпмедер өлеше аерым китаплар рәвешендә басылып чыкты. Галимнәребез бу өлкәдә эшләүләрен дәвам иттерәләр һәм моның алда тагы да күбрәк һәм күркәмрәк нәтиҗәләр бирәчәгенә ышаныч зур.

Билгеле булганча, борынгы әсәрләрне гыйльми эшкәртү: танылмаган урыннарын тану, ачык булмаган җирен ачыклау, ул әсәрләрдә телгә алынган тарихи даталарны, вакыйгаларны, исемнәрне, образларны һәм кинаяләрне дөрес шәрехләү гаять зур көч куюны сорый. Аннан соң, бу әсәрләрдә хәзерге әдәби телебездә инде кулланылмый торган һәм бүгенге укучыга бөтенләй таныш булмаган сүзләр дә чиктән тыш күп очрый. Мондый хәл ул сүзләрнең һәркайсына тулы һәм төгәл аңлатма бирүне, аларны төгәл тәрҗемә итүне таләп итә. Бу яктан да галимнәребез зур фидакарьлык күрсәтәләр, аларның тырышлыклары, һичшиксез, тирән рәхмәт белән хуплауга лаек.

Ләкин шундый зур көч һәм тырышлык куеп эшләнгән әсәрләрдә, аерым очракларда, аерым урыннарда кайбер күңелсез күренешләр дә очрый. Ул әсәрләрне аерым-аерым алганда андый күренешләр чагыштырмача күп түгел. Әмма барысын бергә алып карый башласаң, мондый күңелсезлекләр шактый күп җыела. Сан сыйфатка әйләнә. Бер мичкә балга салынган бер кашык дегетне хәтерләтә башлый.

Нәрсәдән гыйбарәт соң ул күренешләр?

Алар борынгы әсәрләрдә очраган аерым даталарга һәм вакыйгаларга, исемнәргә һәм образларга, сүзләргә һәм кинаяләргә бирелгән аңлатмаларның тулы һәм төгәл булмавыннан яки бөтенләй аңлатма бирми үтүдән гыйбарәт.

Дөрес, бүген генә барлыкка килгән нәрсәләр түгел алар. Мондый күңелсез күренешләрнең кайбер мисалларын элеккерәк елларда да очрата идек. Алар хакында матбугатта да язылды. Мәсәлән, «Совет әдәбияты» журналының 1945 елгы 5 санында язучы Нәкый Исәнбәт Габдулла Тукайның Казан тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан әзерләнеп, 1943 елда чыгарылган академик басмасының беренче томына язган рецензиясендә шундый кимчелекләрнең бик күп үрнәкләрен дәлилле рәвештә күрсәтеп үткән иде. 1955—56 елларда чыгарылган дүрт томлыкта мәкалә авторы күрсәткән кимчелекләрнең байтагы төзәтелде. Шулай да шактый өлешенең шул килеш калганлыгын күрдек. Нәтиҗәдә, бер киткән кимчелек уннарча еллар буенча күренә килә. Чөнки андый басмаларны ел саен чыгарып булмый.

Сүзне янадан Габдулла Тукай томнарыннан башлыйк. Соңгы басманың беренче томында Тукайның «Дәрдемәнд дәгелмием?» исемле шигыре бар. Әлеге шигырьдәге «нәйләем» (ни эшлим) дигән сүз, элекке басмадагы кебек үк, «ниләем» рәвешендә калдырылган. Билгеле булганча, бер телдә дә «ниләем» дигән сүз юк. Бары тик төрекчә «нәйләем» (ни эшлим) генә бар. Төрек шагыйре Ибраһим Хәккыйның: «Мәүля нәйләр? Нәйләрсә, гүзәл әйләр» дигән юллары гына да моңа дәлил. Икенче яктан, «ни» иҗеге шигырьнең ритмын да боза. Чөнки бу урында, шигырь үлчәве буенча,

...» рәвешендәге озын иҗек килергә тиеш. Бу шигырьдәге «мөштәраем» сүзе дә дөрес аңлатылмаган.

Кәл, инан, ханым әфәндем, дәрдемәндем бәндәңез,
Һәп сәнең — кальбем, вә кәндем мөштәраем, нәйләем? —

диган юллар томлыкта түбәндәгечә тәрҗемә ителгән:

Кил, инан, ханым әфәндем, бәндәгез — дәрдемәнд,
Минем күңелем дә синеке, үзем дә сиңа сатылганмын, ни эшлим?

«Мөштәра» сүзе биредә сатып алынган нәрсә яки кол мәгънәсен аңлата. Шуңлыктан ул сүзне «үзем дә сиңа сатылганмын» дип аңлату бик тупас булып чыга. Беренче юлны да: «Миңа хуҗа булган ханым, мин сезнең гыйшкыгызга дучар колмын» мәгънәсендә аңлату төгәлрәк булыр иде. Шулай ук «кальб» (йөрәк) сүзенең дә «кәльб» (эт) рәвешендә язылуы бик күңелсез. «Кальб» сүзен күңелем дип алу да уңышлы түгел («күңелем дә синеке» дип әйтеп булмый, «йөрәгем дә синеке» — уңышлырак, төгәлрәк кебек).

Тукайның «Һазиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа» («Бу шигырь Мостафаны мактау турында») диган әсәрендә мондый юллар бар:

Төркиядә бер теләнче, сухта булган Мостафа;
Монда кайтып, ил казасы, фетнә булган Мостафа.

Юп-юаш муйнын бөгеп йөргән сарыклы бер сарык,—
Монда кайткачтын симергән, чучка булган Мостафа.

Шигырь, томлыкта әйтелгәнчә, Төркиядә укып кайтып, үз газеталарында прогрессив хәрәкәт вәкилләренә һөҗүмнәр ясаган һәм татар әдәби телен төрекләштерергә маташып йөргән Мостафа Ширванский диган бер пантюркист шарлатан турында язылган. Бу шигырьдәге «сухта» сүзенең «паразит» дип аңлатылуы урынсыз һәм ялгыш. Фарсыча «сухтә» (төрекчә «суфта») — шәкерт, ягъни мәдрәсәдә укучы. «Сарыклы бер сарык» сүзенә бөтенләй аңлатма бирелмәве укучыны аптырашта калдыра. Әгәр дә чалманың төрекчә «сарык» дип әйтелүе күрсәтелгән булса, Мостафаның «чалмалы сарык» икәнлеге аңлашылыр һәм укучы аптырашта калмаган булыр иде.

«Җәйге таң хатирәсе» исемле шигырь:

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата,—

диган юллар белән башлана. Биредәге «галибанә» сүзе җәйге таңның, үз яктысы белән караңгылыкны җиңеп, җир өстенә тантаналы рәвештә калкуын шигъри рәвештә күз алдына китерә. Ә инде «галибанә»не, томлыктагыча, «җиңгән сыман» дип аңлату сүзнең әдәби куәтен, образлылыгын югалта.

«Казан вә Кабан арты» шигырендә шагыйрь үз заманында Кабан күле артында булган искиткеч һәм коточкыч хәлләр турында сөйли:

Чыкканым юк тик әле иңктер бу күлнең артына,
Әллә мин ялкауланаммы? Әллә күңлем тартына?

Тик сөйли күргән кеше анда гараибләр күбен,—

ди шагыйрь һәм анда убырлы карчык яшәве, аның адашкан кыз балаларны, тотып алып, үз йортында хур һәм мәсхәрә итүе турында яза. Томлыкта «гараибләр» сүзенә бирелгән аңлатма укучыны гаҗәпкә калдыра. Чөнки шигырьдә «читтән килгән, бәхетсез кешеләр» турында берниндн сүз дә юк. Әгәр дә бу сүзгә «гаҗәп хәлләр» яки «искиткеч хәлләр» дип аңлатма бирелгән булса, мәсьәлә үзеннән-үзе аңлашылыр иде.

Дүрт томлыктагы күп кенә сүзләр һәм җөмләләр бөтенләй аңлатмасыз калдырылган. Мәсәлән, «Бер маңгы тәрәккыйгә» шигырендәге:

Хәзәр! «Әхҗары мин сиҗҗил»дә вардыр
Ходадан, вәсвәсә, тазлилгә каршы,—

һәм «вәсвәсә» сүзен котырту, «тазлил»не аздыру рәвешендә тәрҗемә итү белән чикләнелгән. Нәтиҗәдә, укучыда тәмуг утында кыздырылган ниндидер ташларда котырту һәм аздыруга каршы хода тарафыннан нәрсәдер күрсәтелгән икән дигән фикер генә туа, ә шагыйрьнең нәрсә әйтергә теләгәнлеге аңлашылмый кала. Биредә шагыйрь, бәлки, тәмугтагы «әхҗары мин сиҗҗил» дип аталган, ягъни балчыктан кыздырып ясалган һәм өстенә тәмуг әһелләренең исемнәре язылган ташны күздә тота торгандыр. Һәм «вәсвәсә» сүзен дә ике яктан өтер белән алмыйча, шулай ук «котырту» дип түгел, ә «куркыту, күңелгә курку салу» мәгънәсендә аңлату кирәк булгандыр. Ул вакыт укучыда, ходай шул таштагы исемнәр белән куркытып, азгынлыкка этәрүдән кисәтү ясый икән, дигән фикер калыр иде.

«Мөхәммәдиядән» исемле шигырьдә кулланылган (1 том. 154 бит) «Хиҗап каршысына» дигән сүзләргә түбәндәге аңлатма бирелгән: «Хатын-кызның качып (битенә пәрдә ябып) йөрүенә каршы». Нәтиҗәдә, бу шигырьдә Тукай телгә алган Әхмәтҗан Сәйдәшев дигән кеше хатын-кызларның биткә пәрдә ябып йөрүенә каршы ут ачкан булып чыга. Чынлыкта исә реакцион «Бәянелхак» газетасын чыгаручы бу кеше хатын-кызларның азатлыгына һәм йөзләрен ачып йөрүләренә каршы торуы белән билгеле. Биредә, бәлки, «хиҗап мәсьәләсенә», ягъни «хатын-кызларның битләрен ачып йөрүләре мәсьәләсенә каршы» дигән аңлатма кирәк булгандыр.

Дүрттомлыктагы аерым сүзләргә бирелгән аңлатмаларда мәгънәне боза торган бүтән төгәлсезлекләр дә шактый. «Хөҗҗаҗ» (шул исемдәге явыз вәзир) исеме ялгыш «Хәҗҗаҗ» (хаҗилар) рәвешендә алына. Төрекчә «анчак» (бары тик, фәкать) сүзе «шулай» дип; «гыйлаҗ» (дәва, дару) «ярдәм, котылу» дип; «шәһит» (дин юлында үлгән кеше) «гаепсез үтерелгән кеше» дип; «тәкъва» (динне нык тотучы) «изге» дип; «әз ин җаныйб» (бу яктан) «кайсы яктан» дип; «шәүкъ» (теләү) «якты истәлек» дип; «әкъва» (куәтле, көчле) сүзе «өстен» дип алына һ. б., һ. б.

«Өметсезлек» шигырендәге «Та кыямәт көнгә калды хаклар истирдат көне» («Хокукларның кире кайтарылуын таләп итү көне кыямәт көнгә калды») дигән юллар: «Тик кыямәт көнгә калды хаклар истирдат кире» рәвешендә бозып бирелгән. Бу юл Тукай әсәрләренең төрле басмаларында төрлечә (та кыямәт, тик кыямәт; истирдат көне, истирдат кире, хаклар эстәр дад көне һ. б.) бирелә һәм моны ачыкларга күптән вакыт иде инде.

Тукай мирасына һәм истәлегенә игътибарсыз карау шагыйрьнең тормыш һәм иҗатына багышланган фото-альбомда да урын алган. Альбомда Тукай укыган мәдрәсә дип, ниндидер ике тәрәзәле йортның рәсеме бирелгән. «Социалистик Татарстан» газетасының 1967 елгы 30 апрель санында Тукай укыган мәдрәсә бинасының дөреслеккә туры килә торган һәм шул мәдрәсәдә укыган кешеләрнең әйтүе буенча художник М. Рәхимов тарафыннан ясалган рәсеме урнаштырылган иде. Без бу мәдрәсәнең шул рәсеме тәкъдим ителүен кирәкле саныйбыз.

Шактый өлеше игътибарсызлык нәтиҗәсендә килеп чыккан мондый кимчелекләр Дәрдемәнднең 1959 елгы сайланма әсәрләр җыентыгында да очрый. «Яз чәчәге» шигырендәге «Ничөн бөкдең, умырзая, биленне» юлы «Ничек бөкдең умырзая җиленне» дип; «Кичә күр, иркәм»... шигырендәге «Күргәнең миннән җәфаларны оныт» дигән юл «Күргәнең миннән яфаларны оныт» дип, ялгыш бирелгән. «И мөхәррир» шигырендәге «бинаи рухыбыз» сүзе «бинан рухыбыз» рәвешендә язылган һәм бу сүзгә «телебезнең рухы» дигән аңлатма бирелгән (дөресе — рухыбызның бинасы буларга тиеш иде). Шул ук шигырьдә «кан энисемдер» сүзенә аңлатма бирелмәве аны «кандаш энием дер» дип аңларга юл калдыра (дөресе — кандаш дустым).

«Хикаяи гыйшык» шигырендәге:

Качан беркөнне Мәҗнүн диләфкарь
Ителде фәүте Ләйләдән хәбәрдар,—

юлларына бирелгән аңлатма тулы һәм дөрес түгел. «Мәҗнүн диләфкяр» сүзенә китапта «күңеле, уе белән саташкан бераү» дигән аңлатма бирелә. Беренчедән, Мәҗнүн биредә хас исем. Икенчедән, шигырьдә «диләфкяр» яки «диләфгяр» мәгънәсендәге, ягъни йөрәге яраланган, күңеле яраланган кеше турында сүз бара. Өченчедән, «Мәҗнүн диләфкяр» сүзендә, теркәвеч өчен кирәкле «е» хәрефен төшереп калдыру

аркасында, шигырь юлы бер иҗеккә кими һәм ритм бозыла. Ә бит шул ук шигырьдә «фәүте Ләйла», «кабре Ләйлә» (1928 елгы беренче басмада «Ләйла» дип дөрес бирелгән) сүзләре «е» теркәвече белән дөрес алынган. «Ни җирдә гыйшык вә сәүдәләр исе бар» дигән юлдагы «сәүдә» (дөресе — сәүда) сүзенә «гыйшык, мәхәббәт сәүдәсе» дип мәгънәсез һәм көлке аңлатма бирелгән. Аны «гыйшык һәм хәсрәт» дип аңлату дөресрәк булыр иде. Биредә (һәм күп кенә башка урыннарда) «гыйшк» дигән бер иҗекле сүзне, бүгенге орфографиябез буенча «гыйшык» рәвешендә ике иҗекле итеп язу да шигырьнең ритмын боза.

«Хәят» шигырендәге «Сәйр итеп күр, канча сангать сарф итеп дәсте әзәл» дигән юлдагы «сангать» (осталык) сүзе, ни өчендер, «сонгыят» (ясалмалык) рәвешендә бирелгән, ә бит астында «сонгыят» сүзе «осталык» дип аңлатылган. «Сәйр», «сарф» кебек бер иҗекле гарәп сүзләрен бүгенге татар орфографиясе буенча икешәр иҗекле итеп алу һәм ике иҗекле «сангать» сүзен өч иҗекле «сонгыять» рәвешендә алу аркасында, 15 иҗекле юл 18 иҗекле булып чыккан һәм шигырьнең ритмы тәмам бозылган.

«Кыйтга» шигыре «Чәчеп сүз дөрләрен, и килке мәгъмум» дигән юл белән башлана. (Мәгънәсе: чәчеп сүз энҗеләрен, и хәсрәтле каләм). Җыентыкта исә ул «Чәчеп сүз дөрләрен, и каләк мәгъмум» рәвешендә алынган һәм бит астында «Сүз дөрләрен — сүз җәүһәрләрен», «Каләк мәгъмум — җәберләнгән, кайгылы» дигән аңлатмалар бирелгән. Бу аңлатмалар буенча укыганда, «чәчеп сүз җәүһәрләрен, и җәберләнгән кайгылы» төсендәге иясез һәм мәгънәсез җөмлә килеп чыга. Чөнки «килк» (каләм) сүзенә аңлатма бирелми. «Килке мәгъмум» сүзенең «каләк мәгъмум» рәвешендә алынуы да дөрес түгел («килк» сүзе каләмне, ә «каләк» судагы салны аңлата).

Шул ук шигырьнең:

Агыз яшьләрне, кыл төшләрне ирва,
Бетеп, җир-җир буй атсын нәхле сәүда? —

дигән юлларындагы «нәхле сәүда» сүзе «гыйшык күбәләге», «ирва» — «сугару» дип аңлатылган. Мондый аңлатма буенча укыганда, «Агыз яшьләрне, төшләрне (ягъни җиргә күмелгән орлыкларның төшләрен) сугар, шул орлыклар бетеп, җир өстендә гыйшык күбәләге буй калкытсын» дигән мәгънә килеп чыга. Әгәр дә «нәхле сәүда» сүзенә «гыйшык агачы», «гыйшык пальмасы» һәм «бетеп» сүзенә «шытып» дигән аңлатма бирелгән булса, ул вакытта: «Яшьләренне агызып, орлык төшләрен сугар, шул орлыклар шытып, җир өстендә гыйшык пальмалары буй калкытсыннар» дигән шигъри юллар килеп чыккан булыр иде.

«Кыеп күкнең...» дип башланган шигырьдә автор «шонкар» (лачын) һәм «байгыш»ны (ябалакны) бер-берсе белән чагыштыра:

Кыеп күкнең йөзен очканда шонкар,
Сала күз авына таулардан аша,
Ничек юлдаш аңа байгыш, ничек яр,
Күзе нур очкыны күргәндә шаша.

Җыентыкта «байгыш» сүзенә «бернәрсәсе булмаган ялгыз, сукбай» дигән аңлатма бирелгән. Шагыйрь бит лачын белән сукбайны чагыштырмый!

Китапта «мәвада» (?) дигән сүзгә бөтенләй аңлатма бирелмәгән (1928 елгы басмасында бу сүз «мәбада» дип алынган һәм аңа «әгәр дә мәгәр» дигән аңлатма бирелгән). Дару, дәва мәгънәсендәге «тирьяк» сүзенә — «тарта, җәлеп итә торган көч» дигән аңлатма бирелгән. «Ганасирне (дөресе — ганасыйрне) әсир иткән табигать» дигән юлга «һәрнәрсәне үзенә кол иткән табигать» дигән аңлатма шигырьнең тәэсир көчен, һичшиксез, киметә. Чөнки, борынгы философларның уенча, «ганасыйр» сүзе табигатьнең төп нигезен тәшкил иткән җир, су, ут һәм һава кебек дүрт элементны аңлата.

Без биредә иң якын чордагы классик шагыйрьләребезнең басма әсәрләренә бирелгән аңлатмалардагы төп кимчелекләрне күрсәттек. Борынгы язма әдәбиятыбыз әсәрләренә бирелгән аңлатмаларда да шундый ук кимчелекләр шактый. Казан тел,

әдәбият һәм тарих институты тарафыннан әзерләнеп чыгарылган «Борынгы татар әдәбияты» җыентыгында да алар аз түгел.

Җыентыкның 78 битендә Колгалинең «Иосыф вә Зөләйха» поэмасының тәмам булу датасын күрсәткән бер строфа шигырь бар. Әлеге шигырьдәге «җәлали» сүзенә төзүчеләр «календаре» дигән аңлатма биргәннәр. Бу аңлатма берничек тә аңлашылмый. «Җәлали», ягъни бөек, зур мәгънәсендәге сүз ни өчен календарь дип алынган? Бәлки, ул «тарихе җәлали», ягъни бөек тарих дип йөртелә торган янача ел исәбе буенча, дигән мәгънәне аңлатадыр? Югыйсә, «Рәҗәп ае календаре утызыннан» дигән сүздән бернәрсә аңлатмый торган төшенчә килеп чыга. Бәлки, ул гарәп айларының һәрберсенә бирелгән эпитет кебек, (мәсәлән, рамазаны шәриф, шәүвале мөкәррәм), рәҗәп аеның эпитетыдыр? Моны, һичшиксез, ачыкларга кирәк. 101 нче биттә «Елан, чаян — җөмлә анда мәкам дотмыш» дигән юлдагы «мәкам» сүзенә «оя ясаган» дигән ирекле тәрҗемә бирелгән. «Урын алган» дигән тәрҗемә төгәл булыр иде. Шул ук биттәге «Шәйтан сүзенә гомраһ улып, аңа оемаң» дигән юлдагы «гомраһ улып» сүзенә бирелгән «ияреп» дигән аңлатма да ирекле тәрҗемә булып чыга. Аны «юлдан язып» яки «азып» дип тәрҗемә итү дөрес булыр иде. 105 биттә «Гыйбричә Иосыфә сүз сүзләделәр» дигән юлдагы «гыйбричә» дигән сүз дә «еврейчә» дип кенә түгел, бәлки «борынгы еврейчә» дип төгәл аңлатылган булса, әйбәтрәк буласы. 112 биттәге «Нәхас эчрә алтын көрси хазыйр кылды» дигән юлдагы «нәхас» сүзен «нәххас» дип язу дөрес. Юкса, «нәхас» сүзе кешенең холкын, табигатен, гадәтен, ә «нәххас» сүзе кол сату урынын (яки кол сатучыны) аңлата. 129 биттәге «шәриф» сүзе ни өчендер «мәшһүр» дип аңлатылган. 197 биттәге Хорәзминең «Мәхәббәт-нامә» поэмасындагы «Кара туфракдин сөнбел түрәтте» дигән юлларда «сөнбел» сүзен бу очракта «башак» дигәнче, «сөмбел чәчәге» яки «гиацент чәчәге» дип аңлату шигырьнең лирик рухына туры килер иде (гарәптә сөнбел һәм сөнбелә сүзләре һәр ике мәгънәне аңлатса да, көнчыгыш әдәбиятында сөнбел — гиацент, сөнбелә — башак мәгънәсендә кулланыла). 198 биттә авторның, үз сөеклесенә мөрәҗәгать итеп, «Пәри рөхсарәләренең күркә бае» дигән юлын «Йөзең гүзәл, матурлык фәрештәсе идең» дип тәрҗемә итү шигырьнең образлылыгын югалтуга һәм авторның әйтергә теләгән фикерен бозуга илтә. Аны «Пәри йөзлеләрнең күреккә бае» дип гади, ләкин образлы итеп тәрҗемә итәргә кирәк иде. Инде көнчыгыш поэзиясе өчен бик табигый булган «пәри» (ягъни җенниләрнең иң матур төре) образын бүгенге телебездәге «пәри» (ягъни җен кебек ямьсез) дигән образ белән бутаудан куркасың икән, «пәри» дигән сүзгә аңлату бирергә кирәк иде. Ә «фәрештә»нең бу очракта бөтенләй катнашы юк.

201 биттә шагыйрьнең үз сөйгәненә карата әйткән мондый юллары бар:

Әя гөлчәһрәләр малик-рикабы,
Камук галәм синең гамзең хәрабы.
Ләтафәт мөлкенең сахиб караны,
Муафикъ суратең берлә мәгани...
Синең хөснең камук галәмдә мәшһүр,
Йөзеңдә гизләнептер хөлд ара хур...

Җыентыкта бу юллар ирекле тәрҗемә сыйфатында түбәндәгечә бирелгән:

И син гөл йөзле гүзәлләрнең хуҗасы,
Бөтен галәмне синең серле күз кысып каравың хәрап итә.
Гүзәллекнең иң югары дәрәҗәдәге бәхет иясе,
Тышкы суратең белән эчке фикерең бер-берсенә муафикъ...
Синең матурлыгың бөтен дөньяда мәшһүр,
Йөзеңдә мәңгелек бизәк булган кояш яшеренгән...

Болай ярыйсы гына тәрҗемә ителгән кебек. Ләкин поэтик образлар төсләрен югалталар. Нәрсә ул «малик-рикаб»? Хуҗа гынамы, әллә үзенә кол итүче хуҗамы? Шулай ук нәрсә ул «сахиб-каран»? Гүзәллекнең иң югары дәрәҗәдәге бәхет иясеме, әллә Аксак Тимергә бирелгән «Сахибе-кыйран» дигән эпитетмы? Бу юллар бит шигъри образлар, шигъри тиңләүләр белән бәйләнгән төгәл аңлатмалар бирүне таләп итәләр. Аларны укучыга нәкъ шулай җиткерергә кирәк тә. «Йөзеңдә гизләнептер хөлд ара хур» дигән юл «йөзеңдә мәңгелек бизәк булган кояш яшеренгән» дигән мәгънәне бирәме, я булмаса, «йөзеңдә җәннәт эчендәге хурлар яшеренгән» дигән мәгънәне

аңлатамы? «Хур» сүзе каты «х» белән язылганда, бер үк вакытта без бүген кулланa торган «түбән», «хур» мәгънәсен дә, «кояш» мәгънәсен дә аңлата. Әгәр дә йомшак «х» белән язылса, җәннәттәге хур кызларын яки күз карасын аңлата. «Хөлд» сүзе исә мәңгелекле булу яки җәннәт мәгънәсен аңлата. Мәскәү Көнчыгыш әдәбияты нәшриятында А. М. Щербак чыгарган «Мәхәббәт-намә» әсәрендә бу юлның «Йөзеңдин гизләнептер хөлд ара хур» дигән варианты китерелгән һәм ул русчага: «От твоего лица скрылись гурии» дип тәрҗемә ителгән. «Хөлд ара хур» дигән сүз аны җәннәт эчендәге хур дип тәрҗемә итүнең дөреслеген күрсәтмиме? Ул сүзне «мәңгелекле булу эчендәге кояш» дип яки «мәңгелек бизәк булган кояш» дип аңлату дөресме?..

206 биттә «Колың күптер, вәли мин энҗе колмын» дигән юл бар. Җыентыкта бу юлга бернинди аңлатма бирелмәгән. Нәрсә ул «энҗе кол»? Биредә «инҗү» яки «инчу» сүзе шулай «энҗе» дип ялгыш язылмаганмы? Чыгтайча бу сүз үз ирег**е** белән хезмәткә кергән кешене аңлата. Әгәр дә шулай булса, шигырьнең образлылыгы бик нык көчәя: ниндидер «энҗе» кол урынына, «үз ирегe белән коллык итүче» образы килеп чыга.

208 биттә Хисам Кятипнең «Дастаны Җөмҗөмә» әсәрендә Иран шаһы Җөмшиднең «чәһербад» дигән эпитетына, Фәридун шаһның «гөзин» дигән эпитетына аңлатма бирелмәгән. «Шиддат ләгыйн» дигән хас исем (дөресе Шәддат булырга тиеш) кечкенә хәреф белән язылган һәм аңа да бернинди аңлатма бирелмәгән. 211 биттәге «гарип» сүзенә аңлатма бирелмәве дә ул сүзне бүгенге көндә безнең телдә кулланыла торган инвалид мәгънәсендә аңларга юл калдыра. Әсәрдә исә торган жиреннән китеп, чит-ят җирләрдә йөрүче кеше турында сүз бара. 212 биттә «Нагяһан бер хасса керде»... дигән юлдагы «хасса» сүзе кемне аңлата? Ул каты «х» белән языла торган «хассә», ягъни патшаның якын хезмәткәре түгелме? Бу сүзгә аңлату шулай ук бирелмәгән. 215 биттәге «кыйсмәте» (өлеше), «нәфсе кәрәм» (юмартлык иясе), 216 биттәге «мәстүр» (кием кигән, кием белән өртелгән) дигән сүзләргә дә аңлатма бирелмәгән.

254 биттә «Дастан Бабахан» поэмасында Зөһрәнең анасы, кызына мөрәҗәгать итеп: «Нә сәүда булды, и әрәм җаным» дип сорый. Биредә «сәүда» сүзенә «файда» дигән аңлатма бирелә. Нәтиҗәдә ана Зөһрәдән: «И әрәм җаным, нинди файда булды», дип сораган булып чыга. Дөреслектә ул «Нинди хәсрәт төште, и җаным рәхәте» булырга тиеш. («Сәүда» — гыйшык, мәхәббәт хәсрәте, «әрам җан» яки «әрамы җан» — җаным рәхәте).

Шагыйрь Мәүла Колый һәм Габдерәхим Утыз Имәни әсәреннән китерелгән үрнәкләрдә бик әһәмиятле һәм бүгенге укучыга аңлашылмый торган күп кенә сүзләргә шулай ук аңлатма бирелмәгән. (Мәсәлән, җет улып, юктыр сәбат, тагать кылып, нәфка итеп, голы-гыйштер, үшкәлдем, даныш улыр, мәдәт сорган, хемет иткән һ. б.).

Утыз Имәнинең хатыны Хәмидәгә багышланган мәрсиясендә (кайгы белдергән шигырь) «газизләрдән мәдәт сорган» дигән җөмләгә аңлатма бирелмәве укучыда, нинди «газиз»ләрдән ярдәм сораган икән, дигән сорау тудыра. Биредә «газизләрдән» сүзен «изгеләрдән» дип аңлату бик кирәк иде. «Мәрсияи Габденнасыйр вәләде Габдерәхим» (Габдерәхим улы Габденнасыйр мәрсиясе) дигән шигырьгә аңлатма бирмәү укучыны шулай ук саташтыруы мөмкин. Шуның өстенә, җыентыкта бу мәрсия дә Утыз Имәнинеке итеп күрсәтелә. Ә мәрсия баштан ахырынача ана кешегә багышланган юлларны эченә ала: «Кечелектә сөтен биргән шәфикамдин җөда булдым»; «Күзем нуры балам дигән миһерлемдин җөда булдым» һ. б. 540 биттә Утыз Имәнинең «Хәватин җенседер сурәткә мәгърур, хәрмәндләр (дөресе — хирәдмәндләр булырга тиеш) мәгани берлә мәсрүр», ягъни «хатыннар җенесе төс белән мактана, акыл ияләре мәгънә белән шатлана» дигән юллардагы «хәватин» сүзенә мәгънә бирелмәве, ә «хәрмәндләр» сүзенә «белгечләр» дигән аңлатма бирелүе аңлауны кыенлаштыра һәм мәгънәне боза. «Төрле вакыйгаларны сөйли торган бүлек»тәге: «Әгәр чәнди ки бән нә кабил ирдем» (әгәр беркадәр көчем җитмәс булса) дигән юлга «Кабул итәрлек, белерлек кеше идем» дигән аңлатма бирү дә бу юлның мәгънәсен киресенчә аңлата.

Мондый кимчелекләр шагыйрь Мөхәммәдъярның шул ук институт тарафыннан әзерләнеп, аерым китап итеп чыгарылган «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» әсәр-

ләрендә дә очрый. Бу әсәрләрдә бүгенге укучы аңламый торган күп кенә сүзләр шулай ук аңлатмасыз калдырылганнар. (Мәсәлән, әрбабы риваять — берәр вакыйганы, хәбәрне яки кемдер әйткән сүзне сөйләп бирүчеләр; тымтырак — ачу белән; мәрди вә зур — батырлык һәм куәт; үзенне кәмтәр бел — үзеңне түбән сана; ду галәм — ике дөнья; шәрм кыйлма — тартынма; зәбан — тел; дәват — кара савыты; раһ — юл; сүзенең мотыйгы — сүзен тыңлаучы; йа — җәя һ. б. кебек сүзләр укучыны сүзлекләр актарырга мәҗбүр итәләр. «Гайб», ягъни хәзерге телдәге «гаеп» сүзенең күп кенә урында «гаиб итәр» (юк итәр) яки «гаиб кыйлмаңыз» (юк итмәгез) рәвешендә алынуы да буталчыклык тудыра. Аны «гайб» рәвешендә алырга кирәк иде. Баш күтәрү, баш тарту, каршылык күрсәтү, чуалыш, фетнә, гөнаһ эшләү мәгънәләрендә йөри торган «гыйсъян» сүзен бар урында да «гөнаһ» дип алу дөрес түгел. Мәсәлән:

Басмагыл юлыга рәһбәрсез кадәм,
Башсыз юлы үзе булгай кәл-гадәм.
Бәхре гыйсъян эчрә булмаса кәми,
Мөшкел ул чыкгай сәламәт би кәми,—

дигән юлларда сүз ачыктан-ачык фетнә, чуалыш диңгезе (бәхре гыйсъян) турында бара. Автор биредә «Юлга рәһбәрсез, ягъни юл күрсәтүчесез аяк басма, чөнки башлыксыз юл үзе үк юк дәрәҗәсендәге нәрсә ул. Фетнә диңгезендә көймә булмаса, көймәсез аннан чыгу кыен булыр» дигән фикерне әйтә, юл күрсәтүче һәм көймә образын бергә бәйләп куя. Шунлыктан, биредә «бәхре гыйсъян» дигән сүзне «гөнаһ диңгезе» дип алу авторның фикеренә каршы килә. (Гөнаһ диңгезенә көймә белән керергә ярамый ич!)

118 биттә шагыйрь, үзенең гөнаһларын санап, түбәндәге юлларны яза:

Сәңа лаек кыйлмадым һәргиз гамәл,
Эшләрем камугы вә һәм дәгаль.
Дөньяда кыйлдым үкүш фосык-фәсад,
Рәхмәтеңгә кыйлдым, и хак, игътимад...

«Сиңа лаек бер генә эш тә эшләмәдем, эшләремнең барысы да ясалма, ялган булды; дөньяда бик күп бозыклык эшләдем, синең рәхмәтеңә каршылык күрсәттем (игътимад кыйлдым)»,— ди автор. Китапта исә «игътимад» сүзенә «ышаныч, таяныч, таяну» дигән аңлатма бирелгән. Ходаның рәхмәтенә таяну — гөнаһ эшләү булып чыга. (Биредә гарәпчә ноктaлы каты «г» белән языла торган һәм каршылык күрсәтү, каршысын эшләү мәгънәсен аңлата торган «игътимад» сүзе булырга тиеш).

Әгәр килсә эвенә мәрди миһман,
Тәңре биргән нигъмәтең кылгыл арзан (61 бит).
Диде: «Йигел, нигъмәт уш арзан сәңа,
Мән фида кыйлгам, якын бел, җан сәңа (65 бит),—

дигән юллардагы фарсыча «арзан» (лаеклы, яраклы, әзер) сүзенең аңлатмасыз калдырылуы укучыны бүгенге көндә без куллана торган «арзан бәяле» дигән мәгънә белән саташтырырга мөмкин. Соңгы ике юлдагы «якын бел» сүзен дә бәлки «йакыйн бел», ягъни «ачык бел» мәгънәсендә алырга кирәк булгандыр (чөнки «якын бел» дигән сүз сәер яңгырый).

Йомгак итеп, шуны әйтәсе килә: безнең әле тиешенчә гыйльми эшкәртелеп, укучы кулына тапшырылачак әдәби әсәрләребез шактый. Шулай ук Тукай һәм Дәрдемәнд кебек шагыйрьләребезнең кыйммәтле мирасын да кабат-кабат басып чыгарасыбыз бар. Аларны инде укучыда аңлашылмау тудырмаслык итеп, җентекле рәвештә тикшереп, кимчелекләрдән арындырып, аңлашылмаслык урыннарын мөмкин кадәр бетереп басып чыгарасы иде.

ӘХМӘТ ИСХАК,
ГАЯЗ ИШМӨХӘММӘТОВ.



## Лотфи Гадилов

# ДИПЛОМАТ

## Өлгергәнлек аттестаты



Күп җырларда җырланган, күңелләргә дәрт, көч бирә торган ямьле Дим елгасы буенда җыйнак кына бер авыл бар.

Авылның көнбатыш ягында таулар тезмәсе китә. Шул таулар буйлап килгән Чакмагыш елгасы, бәләкәй генә булуына карамастан, дөнья кыйраткандай булып, авылны аркылыга кисеп, Димгә барып кушыла. Тау тезмәләрен куе урманнар матурлап тора.

Җәйнең җылы, айлы кичләрендә әнә шул тауларга күтәрелеп, түбәнгә, көнчыгышка таба карасаң, күз алдына гаҗәп гүзәл бер күренеш килеп баса: тау битендә тын гына авыл җәелеп ята, аның артында зәңгәр тасма кебек сузылган, сокланып карап туймаслык Дим елгасы, яшел үләннәр, чәчәкләр, куаклар белән капланган болыннарны кисеп, серле итеп, ашыкмый гына ага да ага. Су буендагы кечкенә күлләр, күктәге йолдызлар кебек, күзләрне чагылдырып җемелдиләр, «Акмаржык» күле, тулган ай кебек, тирә-якка нурлар чәчә, ә башка күлләргә караганда калкурак җиргә урнашкан «Аккош» күле ай яктысында асылташ кебек ялтырап-балкып тора. Тирә-якта тынлык, сулап туймаслык шифалы, саф һава. Ямьле дә соң бу тирәдәге табигать!

Халкыбызның турылыклы улы, ялкынлы революционер һәм талантлы дипломат Кәрим Гәбдрәүф улы Хәкимов 1892 елның 28 ноябрендә менә шушы авылда ярлы крестьян семьясында дөньяга килә.

Ләкин табигате гүзәл, урман-суы мул, җире уңдырышлы булган Дусән авылында халыкның бик зур күпчелеге, тир түгеп, тырышып эшләсәләр дә, мохтаҗлыкта, авыр тормышта яшәгәннәр.

1906 ел. Бу елны бу тирәләрдә ачлык була, иген уңмый. Кышын авыл мәктәбендә укып, җәен кулакларда батрак булып эшләп йөргән Кәрим дә ул елны шәһәрдә бәхет эзләп карарга ниятли. Азрак акча туплап, яхшырак мәктәптә укып булмасмы, дип хыяллана. Август көннәренең берсендә, иртә үк, ике арыш икмәге салган капчыкны аркасына асып, Кәрим авылдан 220 чакрым ераклыктагы Оренбургка юлга чыга.

Күп өметләр белән шәһәргә килгән Кәрим озын көннәр буена ары сугылып, бире сугылып карый, ләкин эш таба алмый. Ахыр чиктә ул ит белән сәүдә итүчедә йомышка йөрүче малай булып урнаша, аннан дворник булып яллана. Бераздан тимер юлда ремонт эшчесе хезмәтен үти, ләкин монда да эш бетә. Эш эзләп Оренбург губернасының киң далаларын урап чыга. Эш таба алмагач, 1911 елның язында Төркстан ягына китә. Күп вакытлар каңгырып йөргәннән соң, Коканд өязендәге Канибадам күмер шахтасына кара эшче булып урнашу бәхетенә ирешә. Тиздән забойщик булып эшли башлый. Ул капиталистик эксплуатацияне, җәмгыятьтәге социаль гаделсезлекне үз җилкәсендә татый. Шахтада Кәрим патша хөкүмәте тарафыннан сөргенгә җибәрелгән Ковалевский дигән бер социалист белән таныша. Яшь Кәримгә ул капиталистик стройдагы эксплуатация, сыйныфлар һәм сыйнфый көрәш турында аңлата. Ковалевскийның шәкерте сәләтле булып чыга: алты айдан соң Кәрим Хәкимов, политик яктан ышанычсыз табылып, шахтадан сөрелә. Моннан соң ул бик зур кыенлык белән Батюшков күмер шахтасына урнаша ала. Бу яктагы шахталарда Кәрим өч елдан артыграк эшли.

Беренче бөтен дөнья империалистик сугышы аның дөньяга карашын тагын да ныграк үзгәртергә ярдәм итә. Кәрим Хәкимов, төрле юллар белән, армиядән котылып кайта һәм Оренбург губернасындагы Кувандык станциясенә тимер юл эшчесе булып урнаша. 1915 елның сентябрендә контора эшчеләргә эш хакы түләмәгәч, эшчеләрне эш ташларга өнди. Забастовканың өченче көнендә аны һәм берничә эшчене кулга алалар. Ул, моннан бик кыенлык белән котылып, Себергә юл тота һәм Томскида туктала.

Кәрим тормышының иң авыр минутларында да җаен эшли, кышын укый. Ул Оренбург өлкәсендәге Никольский мәктәбендә дә, Оренбург мәдрәсәсендә дә укып карый. Ләкин мәдрәсәдәге тәртип, схоластикага нигезләнгән, тормыштан, практикадан ерак торган «белем» аны канәгатьләндерми. Тормыш өчен кирәкле фәннәр, рус теле укыта торган мәктәп эзләп, ул 1910 елда Уфага Галия мәдрәсәсенә килә. Галия ул заманның алдынгы мәдрәсәсе булса да, Кәрим андагы тәртипләргә риза булмыйча китә.

Томскида университет та, күп кенә бүтән уку йортлары да, илдәге стройга каршы хәрәкәт итүдә гаепләнеп сөргенгә җибәрелгән кешеләр дә бар. Шәһәрнең югары уку йортларында укый торган мөселман студентлар җәмгыяте, мөселман яшьләрне югары мәктәпләргә керергә әзерләү максаты белән, кичке курслар ача. Анда түләүсез укытыла. Белемгә сусаган, моңа кадәр рус мәктәпләренә юл таба алмыйча интеккән Кәрим өчен зур бәхет ачыла. Ул анда да көндез эшли, кичен укый.

Шул вакытта Томск технология институтында укыган һәм моннан 51 ел элек Кәримне укыткан һәм аңа күп ярдәмнәр күрсәткән Әлимхан Ермәков (хәзер Казагыстанда, математика профессоры) Карагандада яши. Үзенең истәлегендә Кәрим Хәкимов турында ул болай яза:

«1916 елда мин Томскида Кәрим Хәкимов белән очраштым. Ул миңа үзенең кайдан килүе, укырга бик зур теләге булса да, мәктәпкә кереп, нормаль рәвештә укырга мөмкинлеге булмау, шуның өстенә яше дә үткән булуы (24 яшь), вакытында тиешле белем ала алмавы турында бик әченеп, әрнеп сөйләде. Ул үзенең табигате, үзен тотуы, мөлаемлеге, кыюлыгы һәм ургылып торган энергиясе белән миңа бик ошады. Мин аны үзем укытырга булдым. Ул үз алдына бик авыр бурыч — бер ел эчендә гимназиянең 4 классыннан экзамен бирү бурычын куйды һәм үз максатына ирешү өчен зур ихтыяр көче, тырышлык күрсәтте.

Без, студентлар, Кәримнең укуы өчен шартлар тудырырга тырыштык, әдәбият белән тәэмин иттек, аны алдынгы студентлар, прогрессив татар җәмәгатьчелеге, прогрессив оешмалар, түгәрәкләр белән таныштырдык».

Томскида Кәрим бик киеренке, ләкин шуның белән бергә бик кызыклы, эчтәлекле, вакыйгаларга бай тормыш белән яши, большевиклар белән аралаша. Ул февраль революциясен биредә каршылый һәм революцион вакыйгаларга большевикларча бәя бирә. Томск шәһәр үзидарәсенә сайлауларда актив катнаша, татар һәм башкорт хезмәт ияләре арасында аңлату эше алып бара, аларны большевиклар исемлеген яклап тавыш бирергә чакыра.

1917 елның язында, Томскиның икенче ирләр гимназиясендә экстерн юлы белән өлгергәнлек аттестатына экзамен биргәннән соң, Кәрим, революцион вакыйгаларга якыннан торып катнашу өчен, Оренбургка кайта.

## Октябрь көннәрендә



Ләкин Оренбургта эш таба алмый. Тагын Урта Азия ягына юл тота. Ташкент тимер юлындагы Анбулак станциясенә килеп, потребительләр җәмгыятенә счетовод булып эшкә урнаша, тимер юл эшчеләре белән бәйләнеш тота.

1917 елның октябрендә Оренбургка кайта. Бу вакытта шәһәрдә казаклар атаманы Дутов хакимлек итә.

Ноябрь аенда татар һәм башкорт буржуазиясе тарафыннан Караван сарайда зур митинг оештырыла.

Татар буржуазиясе вәкилләре, бер-бер артлы трибунага чыгып, мөселманнарны Совет властен танымаска чакыралар һәм большевикларга төрле яла ягалар. Митингтагы халыкның күпчелеге моның белән килешмәсә дә, беркем дә чыгып сөйләргә батырчылык итә алмый.

Шул вакыт урта буйлы, киң җилкәле, янып торган кара күзле бер егет кинәт трибунага сикереп менә дә: «Иптәшләр!» дип сүз башлый. Яңача яңгыраган бу сүзләрдән җыелыштагы байлар, муллалар, офицерлар, буржуаз интеллигенция аптырап кала. Трибунадагы билгесез егет көр тавыш белән большевиклар партиясенең империалистик сугышка каршы булуын, халыклар арасында тынычлык урнаштыру политикасы алып баруын, милли изүне бетерәчәген, җирне, фабрика-заводларны халыкка бирәчәген сөйли һәм Совет хөкүмәтен танырга чакыра. Оренбургта да, башка шәһәрләрдәге кебек үк, реакцияне корал көче белән җимереп, Совет власте урнаштырырга чакыра. Үзенең сүзен: «Дутовка бер генә дә мөселман солдаты бирмәскә, Совет властен танырга һәм аны яклау өчен көчне кызганмаска кирәк»,— дип тәмамлый. Залда шау-шу күтәрелә. Буржуазия вәкилләре трибунага таба ябырылалар. Шушы ыгы-зыгыдан файдаланып, егет юкка чыга. Шул чыгышыннан соң Кәрим Хәкимов, яшерен рәвештә, мөселман гаскәри частьларында Совет властен актив яклаучы Гариф Алпаров, М. Таһиров һ. б. белән эш алып бара. Бергәләшеп алар солдатларны Самара ягыннан һөҗүм итеп килә торган Кызыл Гвардия отрядларына каршы бармаска өндиләр.

1918 елның 31 гыйнварында Оренбург ак казаклардан азат ителә. Кәрим Хәкимов Хәрби-революцион комитет члены һәм мәгариф эше буенча губерна комиссары итеп билгеләнә. Ә бераздан Советларның беренче губерна съездында ул Оренбург губерна Башкарма Комитеты һәм партиянең губерна комитеты члены итеп сайлана.

1918 елның апрелендә Кәрим Хәкимов тормышында зур вакыйга була. Аны большевиклар партиясенә член итеп кабул итәләр. Бу турыда ул үзенең автобиографиясендә болай дип яза: «Партия оешмасы белән бәйләнгән социал-демократик түгәрәктә 1915 елдан бирле член булып торсам да, актив эшкә теоретик яктан да, практик яктан да хәзерләнсәм дә һәм февраль революциясе башланганнан бирле большевикларга теләктәш булсам да, мин РКП(б) сафына 1918 елның апрелендә генә керә алдым. Шушы моменттан алып мин үземне бөтенләй партиягә багышладым һәм партия эше минем туган эшем икәнен һәм партиягә хезмәт итүдән башка миндә бүтән максат юк икәнен сизә башладым».

Губерна мәгариф комиссары буларак, Кәрим Хәкимов зур эшләр башкара: мәгариф комиссариаты аппаратын төзи, аны кадрлар белән тәэмин итү, укытучылар хәзерләү өчен курслар оештыру, дәреслекләр булдыру һ. б. турында конкрет чаралар күрә, газеталарда, бигрәк тә «Мөхбир» дә, системалы рәвештә мәкаләләр белән чыга. Үзенең мәкаләләрендә ул татар һәм башкорт хезмәт ияләре белән рус хезмәт ияләре арасында дуслык мөнәсәбәтләрен ныгыту мәсьәләсенә зур әһәмият бирә.

Ләкин 1918 елда Оренбург идарәсендә гражданнар сугышы көчәеп китүе тыныч шартларда эшләүне дәвам иттерергә мөмкинлек бирми. Мәгариф комиссары үзенең күп вакытын төзелеп килә торган Кызыл Армиянең мөселман частьларында үткәрергә мәҗбүр була.

1918 елның июнь азагында ак чехословак фетнәчеләре, Дутовның казачий полклары Оренбургка якынлашалар. Дошман гаскәрләренең чагыштыргысыз күп санлы

булуын истә тотып, большевиклар Оренбургны вакытлыча калдыралар, Актүбә ягына чигенәләр.

Яңа гына барлыкка килгән Актүбә фронтында көчле сугышлар башланып китә. Татар-башкорт батальоны белән венгрлар батальоныннан Интернациональ полк төзелгәч, Кәрим Хәкимов бу полк составында Мартук, Каратугай һәм Яйсан станцияләре янында булган сугышларда катнаша. Интернациональ полкның татар-башкорт батальоны командиры Карип Хәйруллин икенче эшкә күчерелгәч, сугышларда күрсәткән батырлыкларын игътибарга алып, Кәрим Хәкимовны татар-башкорт батальоны командиры итеп билгелиләр.

1919 елның 22 январенда Кызыл Армия частьлары, Дутов бандаларын тар-мар итеп, Оренбургны кабат азат итәләр.

Татар-башкорт батальоны командиры Кәрим Хәкимов белән батальон комиссары Шамил Усманов, икесе дә ат өстендә, үзләренең батальоны башында, азат шәһәр урамнарына керәләр. Шәһәрдә Совет власте урнаша, Кәрим Хәкимов яңадан элекке урынында, мәгариф өлкәсендә, эшләвен дәвам итә.

1919 елның апрель башында Көнчыгыш фронтының Көньяк группасы Хәрбиреволюцион советы заданиесе буенча Кәрим Хәкимов Казанга җибәрелә. Ул анда Беренче Идел буе укчы татар бригадасын оештыручыларның берсе була. Кәрим Хәкимов бу бригаданың политбүлек начальнигы итеп билгеләнә.

Бу бригаданы төзешүдә катнашуы турында Кәрим Хәкимов үзенең автобиографиясендә болай дип яза: «12 апрельдә Казанга киттем. Анда Шамил Усманов иптәш белән бергә аерым Идел буе татар укчы бригадасын оештырырга тотындык. Июньдә бу бригаданың частьлары инде фронтта сугыштылар».

1919 ел ноябрь аенда Көнчыгыш халыклары Коммунистлар партияләренең II съезды җыелды. Кәрим Хәкимов — бу съездны җыюның инициаторларыннан берсе һәм аны чакыру комиссиясе члены.

Съезд ачылу алдыннан, 21 ноябрьда, партиянең Үзәк Комитеты, В. И. Ленин җитәкчелегендә, делегатлар белән киңәшмә үткәрә. Киңәшмәдә Кәрим Хәкимов В. И. Ленин алдында ике мәртәбә чыгыш ясый [1].

В. И. Ленин съездның беренче көнендә үк агымдагы хәлләр турында доклад белән чыга. Делегатлар юлбашчының докладын зур игътибар һәм дикъкать белән тыңлыйлар.

Кәрим Хәкимов съездда ясаган чыгышында Үзәк бюроның эшен бик каты тәнкыйтьли, солтангалиевчеләрнең астыртын эшләрен фаш итә.

Кәрим Хәкимов бу съездда Үзәк бюро члены һәм аның оештыру бүлеге мөдире итеп сайлана.

## Төркстанда

Төркстан фронты командующие М. В. Фрунзе 1920 елның февралендә, Төркстанга барышлый Оренбургка тукталып, Урта Азия халыкларының телләрен, гореф-гадәтләрен белгән, аларның тормыш шартлары белән таныш булган берничә кешене үзе белән алып китә. Шуларның берсе — Кәрим Хәкимов.


Ташкентка килгәч, Кәрим Хәкимовны Төркстан фронты Политуправлениесенең агитация һәм пропаганда бүлеге начальнигы һәм бер үк вакытта Политуправление начальнигы В. В. Куйбышевның урынбасары итеп билгелиләр.

Ул чакта, В. И. Ленин күрсәткәнчә, җирле халык, хезмәт иясе мөселманнар белән үзара дөрес мөнәсәбәт булдыру бик әһәмиятле мәсьәлә, политик эшнең төп мәсьәләләреннән берсе иде.

М. В. Фрунзе һәм В. В. Куйбышевның эшчәнлеге В. И. Ленин күрсәтмәләрен тормышка үткәрүдә үрнәк булып тора. Урыннарда ничек эшләргә кирәклекне Кәрим Хәкимов алардан өйрәнә: еш кына халык арасында була, ленинчыл милли политиканы аңлата, төрле милләт хезмәт ияләре арасындагы дошманлыкның байлар өчен генә файдалы икәнен, хезмәт ияләренең изүчеләргә каршы көрәшләренә зарар гына китерүен төшендерә.

---

[1] Ленинский сборник, XXIV, Партиздат, М., 1933, 194 бит.



В.К.

Тов. Хакимова знаю по 19–20 гг. в Туркестане. Из работников мусульман он был наиболее коммунистически выдержан и чужд националистич. уклонов. Работал сначала в политотделе фронта, потом был секретарем ЦК КПТ, затем моим замест. в Бухаре, как полн.предст. РСФСР. Считаю т. Хакимова добросовестным членом партии. По происхождению он пролетарий.

15.II. В.Куйбышев

Копия

ЦЕНТРАЛЬНАЯ КОНТРОЛЬНАЯ КОМИССИЯ РКП(большевиков)

№ 7548/к. Москва, 18.II. 1928 года

Тов.КУЙБЫШЕВУ

ЦКК просит сообщить знаете ли вы тов.ХАКИМОВА Карима по работе в 1919 году по 1921г. в гор.Самаре и Туркестане. В своей автобиографии при чистке тов.Хакимов ссылается на Вас и указывает, что Вы можете дать о нем отзыв.

СЕКРЕТАРЬ ЦКК: (подпись)

1.1.
14.II.60г.

*К. Хәкимовка В. В. Куйбышев биргән характеристика*

1920 елның июнендә Төркстан фронты политработникларының беренче съезды үткәрелә. Бу съездны әзерләүдә һәм аны үткәрүдә Кәрим Хәкимов актив катнашты. Съездга М. В. Фрунзе белән В. В. Куйбышев җитәкчелек итәләр. М. В. Фрунзе агымдагы хәлләр, В. В. Куйбышев партия һәм совет төзелеше турында доклад ясыйлар. Кәрим Хәкимов мөселман кызылармеецлары арасында ничек эшләргә дигән доклад белән чыга.

1920 елның 8 июнендә РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы утырышында Татарстан республикасында партия һәм совет төзелешенә бәйләнешле булган күп кенә мәсьәләләр каралды. Политбюроның шул ук утырышында ТАССРның Вакытлы Рево-

люцион Комитеты составы тикшерелә. Комитет составы 1920 елның 10 июнендә Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан раслана. Комитет составына Кәрим Хәкимов та кертелә.

Ләкин Төркстан фронты Политуправлениесендә җаваплы постта булуы сәбәпле Кәрим Хәкимовка Совет Татарстаны Вакытлы Революцион Комитетында эшләргә туры килми.

1920 елның июлендә, В. В. Куйбышев тәкъдиме буенча, Кәрим Хәкимов Төркстан Коммунистлар партиясенең Вакытлы Үзәк Комитеты секретаре итеп билгеләнә. Үзәк Комитет бу чорда Кәрим Хәкимов җитәкчелегендә политик-массовый эшне җанландыру, партия оешмаларын шовинистлардан һәм урындагы милләтчеләрдән тазарту, коммунистларның җаваплылыгын күтәрү, партия съездын һәм Советлар съездын чакыру һ. б. буенча күп кенә эш башкара.

1920 елның сентябрендә ачылган Төркстан коммунистлар партиясенең V Край съездында Совет республикасының эчке һәм халыкара хәле, Төркстанда партия һәм совет төзелеше, авылда эшләү кебек бик мөһим мәсьәләләр тикшерелә.

Съезд Вакытлы Үзәк Комитетның политик линиясен һәм практик эшен яхшы дип таба. Үзәк Комитетның 17 кешедән торган яңа составына Хәкимов та сайлана.

Партиянең V съезды ябылуның икенче көнендә Төркстан Советларының IX съезды ачыла. Биредә Хәкимов Сәмәрканд делегаты буларак катнаша һәм Советларның Төркстан Үзәк Башкарма Комитеты члены итеп сайлана.

Төркстанда Совет властен ныгытуда, урындагы буржуаз милләтчеләргә каршы көрәштә, халык массаларын илнең политик тормышына катнашуга җәлеп итүдә бу ике съезд зур роль уйный.

Ул чакта Бохара формаль яктан бәйсез дәүләт булып саналса да, гамәлдә Бохара әмире Америка — Англия империалистлары һәм рус акгвардеецлары кушуы буенча, Совет Төркстанына һөҗүм итәргә әзерлек алып бара иде. Бохара хезмәт ияләре Төркстан фронты Хәрби-революцион советына мөрәҗәгать итеп, әмиргә каршы коралды ярдәм күрсәтүне сорадылар.

1920 елның август азакларында Төркстан фронты гаскәрләре, алар составында Беренче Идел буе татар укчы бригадасы да, үзләренең интернациональ бурычын үтәү йөзеннән, Бохара әмирлегенең баш күтәргән хезмәт ияләренә ярдәмгә килделәр. 2 сентябрьдә иске Бохара алынды, анда халык власте урнашты.

Кәрим Хәкимов бу сугышларда турыдан-туры катнаша һәм күрсәткән батырлыклары өчен Бохара Халык Республикасы медале белән бүләкләнә.

В. В. Куйбышев РСФСРның Бохарадагы тулы хокуклы вәкиле итеп билгеләнә.

Бохара халыклары тарихында яңа тормышка юл ачылды. 1920 елның 14 сентябрендә Беренче Бөтен Бохара съезды Бәйсез Бохара Халык Совет Республикасы төзелүен игълан итте. Республиканың җитәкче органнарын сайлады.

Съездда Кәрим Хәкимов РСФСР хөкүмәте исеменнән котлау рече белән чыгыш ясый: «Съездны РСФСР хөкүмәте исеменнән котлыйм,— ди ул үзенең речендә.— Барыннан да элек шуны әйтергә кирәк: элек, царизм вакытында, рус хезмәт ияләре белән бергә, башка халыклар да изелеп килделәр. Хәзер һәрбер халык үз язмышын үзе хәл итә. Татар, башкорт, кыргыз халыкларының, төркстанлыларның үз республикалары бар. Хәзер менә Бохара халкы да, Совет Россиясенең эчкерсез ярдәм күрсәтүе аркасында, үз халык республикасын төзергә мөмкинлек алды...

Бохара хезмәт ияләре дә, үзләренең сыйнфый дошманнары белән эшне бетереп, тыныч төзелеш юлына чыгарлар дип ышанам» [1].

Бохарада Совет властеның позицияләрен ныгыту эшләре белән турыдан-туры В. В. Куйбышев шөгыльләнде. Кәрим Хәкимов та бу эшне юлга салуда актив катнаша.

13 октябрьда Бохара Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты составы төзелде. Үзәк Комитетның секретаре итеп Кәрим Хәкимов билгеләнә.

Бохара Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты кыска гына вакыт эчендә партия сафларын милләтчеләрдән, яраксыз кешеләрдән тазарту, партия дисциплинасын ны-

---

[1] «Бохара әхбары» газетасы (Бохараның революцион вакытлы хөкүмәте органы), № 5, 1920 ел, 11 октябрь.

...тиу, массалар белән бәйләнешне көчәйтү өлкәсендә шактый эш эшләде. Бохара Коммунистлар партиясенең 1920 елның декабренда үткәрелгән конференциясендә бу бик ачык күренде.

Кәрим Хәкимов конференциядә, Коммунистик Интернационал вәкиле сыйфатында, котлау речь белән чыгыш ясый.

Тиздән Кәрим Хәкимовны РСФСРның Бохарадагы полпредствосына эшкә күчерәләр. «Ноябрьда (1920 ел) РСФСРның Бохарадагы тулы хокуклы вәкиле иптәш Куйбышев Мәскәүгә китте,— дип яза ул бу хакта үзенең автобиографиясендә,— һәм мин полпредствога аның урынбасары итеп җибәрелдем. Бу эш мине Бохара Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты җитәкчесе роленнән бушатмады гына түгел, бәлки миңа тагын да җаваплырак бурычны — үзебезнең линияне дипломатик адымнар белән үткәрүне дә йөкләде».

Хәкимов хәл итә торган эшләрнең төре һәм күләме тагын да зурая. Аңа хәзер партия, совет, хуҗалык эшләре белән дә шөгыльләнергә кирәк. Еш кына күп мәсьәләләрне, җитмәсә тагын беренче мәртәбә генә куела торган мәсьәләләрне, бер үзенә генә хәл итәргә туры килә.

1921 елның гыйнвареннан Кәрим Хәкимов — РСФСРның Бохарадагы тулы хокуклы вәкиле.

Бөек социалистик илнең тулы хокуклы вәкиле халык белән дөрес мөнәсәбәт урнаштыруга, җирле халыкның милли үзенчәлекләрен исәпкә алып, аның һәрьяклап үсүенә булышлык итүгә аеруча игътибар юнәлтә. Бу турыда күп приказлар чыгарыла. Менә шундый приказларның берсе:

**«РСФСРның БОХАРА СОВЕТ РЕСПУБЛИКАСЫНДАГЫ ТУЛЫ ХОКУКЛЫ ВӘКИЛЕНЕҢ ҺӘМ ТӨРКСТАН ФРОНТЫ РЕВОЛЮЦИОН СОВЕТЫ УПОЛНОМОЧЕННЫЕНЫҢ 42 НОМЕРЛЫ ПРИКАЗЫ**

*1921 ел, 11 апрель. Иске Бохара шәһәре.*

*Төркстан фронтының Бохара территориясендәге барлык махсус бүлекләренә Бохара Халык Совет Республикасының гражданлык эшләренә һич тә тыгылмаска боерам.*

*Бохара Халык Республикасының бәйсезлек хокукларын һәртөрле бозу һәм аның эчке гражданлык эшләренә тыгылу минем тарафтан РСФСР нигезләрен усал ният белән бозу дип каралачак һәм гаепләләр революцион вакытның законы буенча аяусыз рәвештә җәзага тартылачак.*

*РСФСРның Бохарадагы Тулы хокуклы Вәкиле һәм Төркстан фронты Революцион Советының Уполномоченные — Хәкимов»*[1].

1921 елның җәе Хәкимов тормышына ике мөһим вакыйга алып килә: ул, Төркстаннан делегат буларак, РКП(б)ның май конференциясендә һәм Коминтернның өченче конгрессында катнаша.

Биредә Хәкимов тагын В. И. Ленинны күрү бәхетенә ирешә. Сөекле юлбашчының чыгышларын ул зур дикъкать белән тыңлый.

1921 елның сентябрендә Кәрим Хәкимовны Мәскәүгә чакырып кәгазь килә. Аны чит ил эшләре комиссариатына эшкә билгелиләр.

## Чит илдә дипломатик эштә

Яшь Совет дәүләте, ниһаять, тыныч хуҗалык һәм культура төзелеше юлына чыкты. Социалистик дәүләтнең үсешендә, халыкара хәлендә яңа этап башланды.

Илебездә социализм төзүне уңышлы алып бару өчен тышкы шартларның уңайлы булуы кирәк иде. Совет хөкүмәтенең тышкы политикасы искиткеч авырлыклар белән яулап алынган тынычлыкны ныгытудан, илне тышкы политик изоляциядән һәм экономик блокададан чыгарудан, чит илләр белән киң сәүдә бәйләнешләре һәм дипломатик мөнәсәбәтләр булдырудан тора иде.

Совет дәүләте Көнчыгыш илләрнең халыкларына һәм хөкүмәтләренә мөрәҗәгать итеп, аларны тиң хокуклы һәм дуслык мөнәсәбәтләре булдыруга чакырды. Бөтен

[1] «Бохара Республикасы Үзәк Революцион Комитеты, Бохара Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты хәбәрләре» газетасы. № 9, 1921 ел, 25 апрель.

доньа тарихында беренче мәртәбә бөек ил артта калган илләр белән аларның тиң хокуклылыгын һәм суверенитетын тануга нигезләнгән бәйләнешләр урнаштыруга тәкъдим ясады.

Көнчыгыш илләренең колонизаторларга каршы көрәшкә күтәрелеп килүче халыклары йөрәгендә бу тәкъдим кайнар теләктәшлек хисләре тудырды. 1921 елның 26 февралендә Мәскәүдә Совет — Иран договорына кул куелды. Совет хөкүмәте патша хөкүмәте белән Персия арасында төзелгән, тиң булмаган барлык договорлардан баш тартуы турында тантаналы рәвештә белдерү ясады. Иранның Россиягә булган бурычлары һ. б. юкка чыгарылды.

Дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырылгач, көн тәртибенә Иранның зур шәһәрләрендә совет генераль консуллыклары оештыру мәсьәләсе килеп туды. Совет властена чын күңелдән бирелгән, аның мәнфәгатьләрен якларга сәләтле һәм көнчыгыш халыкларының тормышын, гореф-гадәтләрен, телләрен белгән кешеләр табарга кирәк иде.

1921 елның август азакларында Кәрим Хәкимовны Иранга генеральный консул итеп җибәрәләр. Иранга барышлый, үзенең бертуган энесе Халик Хәкимовка (хәзер ул Мәскәүнең гыйльми-тикшеренү институтларының берсендә эшли, техник фәннәре докторы, профессор, 1918 елдан партия члены) Ашхабадтан ул болай дип хат яза: *«Безне бергә бәйләгән, һичбер вакытта да үзгәрми торган ике нокта бар: берсе — минем белән синең арада яшь вакыттан ук урнашып килгән туганлык мөнәсәбәте, икенчесе — һәм иң мөһиме — икебезнең дә бер идеягә, бер максатка булган хезмәтебез — пролетариат диктатурасы өчен булган көрәшнең бер сафында булуыбыз. Иранга киткән вакытта мин шул ике ноктаның тулы көенчә сакланып калачагына гына түгел, бәлки тагын да ныгыячагына тамам ышанам.*

*Абыең — Кәрим ХӘКИМОВ».*

1921 елның октябрендә Хәкимов Иранның Мәшһәд шәһәренә килеп җитә һәм үз вазифаларын үти башлый. 1924 елның башында аны тагын Мәскәүгә чакыртып алалар.

...1924 елда СССР белән Хиҗаз корольлеге арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнашты. Хиҗазга беренче агент һәм генеральный консул булып Кәрим Хәкимов билгеләнә. Мәскәүгә аны менә шуның өчен чакырып алалар. 1924 елның августында ул үзенең ышаныч грамотасын Хиҗаз королена тапшыра.

М. И. Калинин тарафыннан кул куелган бу грамотада болай дип язылган:

*1924 ел, 24 апрель.*

*Совет Социалистик Республикалар Союзының Үзәк Башкарма Комитеты председателе*

*Гарәп Һашимилар Корольлеге Короле Хөсәен ибне Гали Галиҗәнапләренә*

*Галиҗәнапләре, бөек һәм яхшы дус, Совет Социалистик Республикалар Союзы белән Гарәп Һашимилар Корольлеге арасында урнашкан дуслык мөнәсәбәтләренең өзлексез дәвам итүен тәэмин итүне теләп, Совет Социалистик Республикалары Союзы Үзәк Башкарма Комитеты гражданин Кәрим Гәбдрәүф улы Хәкимовны агент һәм генеральный консул итеп билгеләүне яхшы эш дип исәпләде.*

*Гражданин Хәкимовны бу грамота белән вәкил итеп билгеләп, Сез Галиҗәнапләреннән аны ягымлылык белән кабул итүегезне һәм аның Сез Галиҗәнапләренә Совет Социалистик Республикалар Союзы хөкүмәте исеменнән сөйләячәк барлык сүзенә ышануыгызны үтенәм.*

*Бу уңай белән Сез Галиҗәнапләренә һәм дус гарәп халкына тынычлык һәм зур уңышлар теләвемне белдерәм.*

*М. КАЛИНИН.*

*Расладым: Чит ил*
*эшләре комиссары*
*Г. ЧИЧЕРИН*[1]

Совет консуллыгы һашимилар белән сәгудиләр арасындагы хәрби конфликт аеруча кискен төс алган чорда Хиҗазга килеп җитә. Бу хәл совет вәкиленең эшен

[1] СССР һәм гарәп илләре. 1917—1960 еллар. Госполитиздат, Мәскәү, 1961. 60 нчы бит.

шактый кыенлаштыра. Кәрим Хәкимовка Хиҗазда тиз алмашынып торган шартларда дөрес юнәлеш ала белү белән бергә, һашимилар дәүләте булган Хиҗазга якынлашып килә торган һәлакәтне дә исәпкә алып, зур дипломатик осталык һәм такт күрсәтергә туры килә.

1924 елның декабренда сәгудиләрнең гаскәрләре Мәккә шәһәрен алалар һәм совет консуллыгы урнашкан Җиддә шәһәрен камыйлар. Камап тору бер ел дәвам итә. 1925 елның декабренда Җиддә бирелергә мәҗбүр була.

Сәгудиләр башлыгы Ибне Сәгуднең Хиҗазга дошман булган чагында килгән Кәрим Хәкимов шактый авыр хәлдә кала. Советлар Союзы белән гарәп халыклары арасындагы бәйләнешне өзәргә тырышкан империалистик державалар бу конфликттан файдаланырга омтылалар.

Мондый шартларда совет вәкиле бу хәлдән чыгуның бердәнбер дөрес юлы Ибне Сәгуд белән турыдан-туры бәйләнеш тоту дип исәпли һәм бу хакта Совет хөкүмәтенең рөхсәтен сорый. Советлар Союзы яңа гарәп дәүләтен — Сәгуд Гарәбстанын танырга карар бирә.

1926 ел февраленең бер төнендә Хәкимов консуллыкның бер секретаре белән, җиңел автомашинага утырып, Җиддәдән чыгып китә. Машинаны Хәкимов үзе йөртә. Бу вакытта инде сугыш хәрәкәтләре тукталган булса да, аерым бәрелешләр булгалап тора әле. Машинада йөрү шактый ук хәвефле. Күптән түгел генә фронт сызыгы булган урынны үткәч, сәгудиләр армиясенең бер офицеры аны Ибне Сәгуд чатырына алып килә. Ибне Сәгуд совет вәкилен шатланып каршы ала. Хәкимов Совет хөкүмәтенең яңа дәүләтне танырга карар бирүен һәм аның белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруга әзер икәнен Ибне Сәгудка белдерә һәм үзенең хатын тапшыра.


*К. Хәкимов гарәпләрнең милли киемендә.*

Хатта болай диелә:

**«ХИҖАЗ КОРОЛЕНӘ, НӘҖД ҺӘМ БЕРЛӘШКӘН ӨЛКӘЛӘР СОЛТАНЫНА**

*1926 ел, 16 февраль, № 22*

*Хөкүмәтемнең кушуы буенча мин Сезгә, Галиҗәнапләре, шуны хәбәр итәм: Совет Социалистик Республикалар Союзы хөкүмәте, халыкларның үз-үзләрен билгеләү принцибы нигезендә эш итеп һәм Хиҗаз халкының Сезне үзенең короле итеп сайлавында гәүдәләнгән ихтыярына зур хөрмәт күрсәтеп, Сез Галиҗәнапләрен Хиҗаз короле, Нәҗд һәм берләшкән өлкәләр солтаны итеп таный.*

*Шул сәбәпле, Совет хөкүмәте үзен Сез Галиҗәнапләре хөкүмәте белән нормаль дипломатик мөнәсәбәтләр хәлендә дип исәпли.*

*Хатымның ахырында Сез Галиҗәнапләренә үземнең чын күңелдән ихтирамымны белдерергә рөхсәт итегез.*

*СССРның агенты һәм генеральный консулы ХӘКИМОВ»*[1]

[1] СССР һәм гарәп илләре. 61 нче бит.

Бу яңа дәүләт белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру Совет хөкүмәтенең уңышлы адымы булды. Ул империалистик дәүләтләрнең яңа гарәп дәүләтен танырга әле ашыкмаган бер чакта эшләнде. Алар бу адымны Гарәбстан ярым утравында аерым өстенлекләр һәм хокуклар тәэмин итәрлек күп кенә шартлар белән бәйләргә телиләр иде. Советлар Союзы, бу дәүләтне беренче булып танып, колонизаторларның мәкерле ниятләрен җимерде. Соңыннан алар да бу дәүләтне танырга мәҗбүр булдылар.

Кәрим Хәкимов бу илдә дүрт ел эшли.



*Кәрим Хәкимов — Хиҗазда СССРның вәкаләтле илчесе*

## Ямәндә

Бу елларда СССР белән Ямән корольлеге арасында да дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырылды. 1929 елның азагында бу илгә Кәрим Хәкимовны тулы хокуклы вәкил итеп билгелиләр.

Тиздән король Имам Яхъя илнең вәкиле Хәкимовны кабул итә. Алар, корольнең Макам аш-Шәриф дигән сараенда икәү генә калып, көнчыгыш халыклары гадәтенчә паласка утырып, халыкара хәл, СССР белән Ямән арасындагы мөнәсәбәтләр турында озак сөйләшәләр. Кәрим Хәкимов корольгә М. И. Калининның хатын тапшыра, шулай ук Имам Яхъя хатларында кузгатылган күп кенә сорауларга җаваплар бирә.

Имам Яхъя М. И. Калининга болай дип җавап бирә: «...*Кәрим Хәкимов... әфәнденең безгә килүе турында Сезгә белдерәбез. Бу җитди, саф күңелле, ягымлы кешене яхшы кабул иттек. Хәкимов әфәнде йөзендә без хөрмәткә лаеклы кешене каршыладык һәм аны безнең илгә җибәргәнегез өчен Сезгә рәхмәт белдерәбез...*»[1]

Кәрим Хәкимовның инде дипломатик эш өлкәсендә шактый зур тәҗрибәсе бар, ул Ямәннең экономик һәм политик хәле белән Җиддәдә эшләгәндә үк таныш, гарәп халкының тарихын, гореф-гадәтләрен, алар-

[1] СССР һәм гарәп илләре. 72—73 битләр.

ның телләрен яхшы белә. Гарәп теле белән бергә ул төрек, фарсы телләрендә дә французча да иркен сөйләшә.

Ямәндә Кәрим Хәкимов белән бергә эшләгән, 1919 елдан КПСС члены Алексей Тимофеевич Спирин (ул хәзер Мәскәүдә яши) болай яза: *«Октябрь бәйрәме көннәрендә полпредствода үткәрелә торган мәҗлесләрдә 700—800 ләп кунак — хөкүмәт вәкилләре, министрлар, губернаторлар, гарәп интеллигенциясе, чит ил кешеләре була иде. Кәрим Хәкимов биредә кешесенә, милләтенә карап бер телдән икенчесенә бик җиңел күчеп, гарәп, төрек, француз телләрендә мөрәҗәгать итә иде. Аның күп телләр белүенә, гарәп илләренең тарихы, экономикасы һәм культурасы белән нык таныш булуына гаҗәпләнеп карыйлар иде».*

Ямән дәүләте ул вакытта авыр хәл кичерә иде: Англия империалистлары, Ямәнгә протекторат көчләп тагу юлында күп кенә уңышсыз омтылышларыннан соң, турыдан-туры сугыш хәрәкәтләре башладылар, Ямән шәһәрләрен һәм авылларын бомбага тоттылар. Бу сугыш хәрәкәтләре 1928—1929 елларда аеруча көчәйде. Бу көннәрдә Ямәннең суверенитетын тик Советлар Союзы гына яклап чыкты.

«...Безнең ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерү эшендә без Сезгә тәмам ышануыбызны һәм, Сезнең безгә карата булган дуслыгыгызга бөтенләй ышанган хәлдә, үзебезнең игътибарыбызны Сезгә юнәлдерүебезне Хәкимов әфәнде Сезнең Гали хөкүмәтегезгә өстәмә рәвештә хәбәр итәр», дип язды Ямән короле СССРның Чит ил эшләре халык комиссариатына.

СССР белән гарәп илләре арасында дипломатик һәм сәүдә мөнәсәбәтләре башлануын Көнбатыш Европа дәүләтләре, бигрәк тә Англия, куркып каршыладылар. Бу вакытта инде Гарәбстанда танылган дипломат булып әверелгән һәм зур авторитет казанган Кәрим Хәкимов шәхесенә күбрәк игътибар итә башладылар.

Чит ил газетасы «Шәрык эл Адна» (1929 ел, 16 январь) болай дип язды: «Большевиклар үзләренең игътибарын Ямән ягына юнәлдерделәр. Ямәнгә үзләренең сәүдә-политик вәкилләре белән бергә товарларын да җибәрделәр, ул вәкилләр арасында элекке совет агенты Хәкимов Хан да[1] бар... Большевиклар Хиҗазда биш ел буена ирешә алмаган нәрсәгә — «Бәхетле Ямәнгә» бик тиз ирештеләр... Большевиклар договор төзү өчен уңайлы момент сайлый белде»[2].

Англия газетасы «Нир-Ист»ның Җиддәдәге хәбәрчесе исә: «Элекке совет генеральный консулы Кәрим Хан Хәкимовның күптән түгел Ямәндә ачылган бер рус сәүдә предприятиесе (Совторгфлот филиалы) җитәкчесе постын биләү өчен Җиддә аркылы Ямәнгә үтүе соңгы вакытта биредәге әһәмиятле вакыйгаларның берсе булып тора»[3], дип язды.

Ул вакытта Англия газетасы «Таймс» хәтта «Гарәбстанда кызыллар интригалары» дигән зур бер мәкалә басып чыгарды: «...Генеральный консул Кәрим Хәкимов аеруча житез булып чыкты. Ул күп кенә мөселман илләрендәге тормыштан риза булмаган элементлар белән бәйләнеш тотты һәм аның эше Кызыл диңгез бассейнына гына түгел, бәлки Голландия Һиндстанына да тарала»[4].

«Таймс»ның бу мәкаләсендә шул нәрсә дөрес: сәүдә һәм дуслык мөнәсәбәтләрен ныгыту һәм киңәйтү юлында Кәрим Хәкимов чыннан да зур эш җәеп җибәрә. Ә мәкаләдә әйтелгән башка моментлар җәмәгатьчелек фикерен алдауга исәп тотылган буржуаз пропаганда гына. Гарәп илләренең Советлар Союзы белән сәүдә турында килешүләр төзүе алар өчен файдалы иде. Шул ук «Таймс» газетасы үзе үк: «Гарәп халкы большевикларны үзләренең табигый дуслары һәм союздашлары итеп күрәләр...», дип язарга мәҗбүр булды.

Күп еллар буена чит илләрдә СССРның тулы хокуклы вәкиле вазифасын башкару кебек аеруча җаваплы һәм киеренке хезмәт, шулай ук үтә эссе климат Кәрим Хәкимовның саулыгын шактый какшата, һәм ул үзен туган иленә чакыртып алуны

---

[1] Чит ил газеталары Кәрим Хәкимов турында язганда еш кына «Хан» дигән сүзне кулланалар. Төркиядә рус акгвардеецлары тарафыннан чыгарыла торган бер газета хәтта: «Хәкимов ярлы крестьян улы түгел, бәлки Чыңгыз хан токымы», дип язган.

[2] Үзәк дәүләт Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш архивы. Фонд 6857, опись 1, дело 210, 161 нче бит.

[3] Шунда ук, 216 нчы бит.

[4] Шунда ук, 190 нчы бит.

сорап СССР чит ил эшләре комиссариатына язарга мәҗбүр булды. Аның үтенече кабул ителде. 1931 елның азагында илебезнең Чит ил эшләре халык комиссариаты Ямән короле Имам Яхъяга болай дип хәбәр итте: «...Гражданин Кәрим Хәкимов үзенең ике арадагы мөнәсәбәтне үстерүгә һәм киңәйтүгә юнәлдерелгән эшенә Сез Галиҗәнаплары тарафыннан һәртөрле ярдәм күрсәтелүе һәм шуның аркасында бу эшнең уңышлы баруы турында миңа хәбәр итте. Кызганычка каршы, гражданин Хәкимов нык авырып китте һәм безгә аның бик нык какшаган сәламәтлеген яхшырту өчен СССРга кайтару турындагы соравын канәгатьләндерергә туры килә...»[1]

1932 елның февралендә Кәрим Хәкимов Мәскәүгә кайтты. Аның бик күптәнге теләге тормышка ашты. Аңа укырга рөхсәт иттеләр. һәм, бераз ял иткәннән соң, ул Кызыл профессура институтының дөнья хуҗалыгы һәм дөнья политикасы бүлегендә укый башлады.

Ләкин ул институтны тәмамлый алмады. 1935 елның язында аны яңадан, икенче мәртәбә, Сәгуд Гарәбстанына СССРның тулы хокуклы вәкиле итеп җибәрделәр. Ул анда 1937 елның октябренә кадәр эшләде.

* * *

Бөек Октябрь улы Кәрим Хәкимов Совет властеның беренче, авыр елларыннан башлап, гомеренең соңгы көннәренә кадәр Бохарада, Иранда, Сәгуд Гарәбстанында, Ямәндә Совет дәүләтенең тулы хокуклы вәкиле сыйфатында Советлар Союзының тынычлык сөюче тышкы политикасын тормышка үткәреп килде. Ул Совет Россиясе халыклары арасында, шулай ук аның чит илләр белән дуслык мөнәсәбәтләрен ныгытукиңәйтү эшенә барлык көчен салды. Советлар Союзының барлык халыкларның азатлыгы, бәйсезлеге, дуслыгы өчен көрәшүче, авыр вакытларда ярдәм итәргә әзер торган бердәнбер ил икәнен көнчыгыш халыкларына гамәлдә күрсәтте.

Кәрим Хәкимовның бу хезмәтләре нәтиҗәсез калмады, дуслык мөнәсәбәтләре хәзерге көндә тагын да үсте һәм киңәйде.

Кәрим Хәкимов Советлар иле дипломаты дигән исемне югары тотты, аңа тап төшермәде.

Туган ил халык бәхете өчен көрәшкән һәм шул юлда корбан булган турылыклы улларын һәм кызларын бервакытта да онытмый, аларны зур хөрмәт белән искә ала. Кәрим Хәкимовның туган авылында, Дүсәндә, колхозчылар ике гектар чамасы мәйданда җиләк-җимеш бакчасы утырттылар һәм шунда, махсус бина салып, авылдашларының революцион һәм дипломатик эшенә багышланган мемориаль музей оештырдылар. Бохарада, Оренбургта һәм Уфада аның исеме белән аталган урамнар бар. Уфа, Оренбург, Ташкент, Бохара музейларында аның фотолары илебезнең кадерле кешеләре фотолары белән берраттән тора.

---

[1] СССР һәм гәрәп илләре, 76 нчы бит.


# БЕЗНЕҢ САФКА



Туфан Миннуллин исеме әдәбиятыбыз мәйданында әле соңгы ун ел эчендә генә күренә башлады. Язучы буларак аның ныклап формалашып та җиткәне юк. Ул әле бер пәрдәлек пьесалар язып үзенең көчен сынап карый, әле күп пәрдәлек пьесалар язып профессиональ сәхнә яулап алырга исәпли. Я булмаса, кечкенә хикәяләр язып, проза өлкәсендә үзенең уй һәм хисләрен халыкка җиткезү өчен иҗат мәйданы эзли. Шунысы әһәмиятле: аның һәр әсәреннән тормышны яхшы белүе, әдәби теленең яхшы ук бай һәм җанлы булуы, сәхнә, театр таләпләрен, драматургия таләпләрен яхшы белүе сизелеп тора. Т. Миннуллинның инде матбугатта басылып чыккан уннан артык хикәя һәм пьесалары, китаплары бар. Бер пәрдәлек пьесаларының күбесе үзешчән сәнгать театрларында әледән-әле уңышлы гына куелып торалар.

Күп кенә уңышлы образлары булган, яхшы ук кискен һәм тормышчан конфликтлы «Очканда һәм кагынганда» пьесасы Әлмәт театры сәхнәсендә куелды. «Азат» исемле, әкият стилендә язылган пьесасы Татар дәүләт академия театрында барды. Яшь тамашачыларның мәхәббәтен казанды. Китап булып басылып чыкты. Бүгенге көндәге әһәмиятле темаларның берсен — яшьләр арасында мораль-әхлак проблемаларын чагылдырган «Миләүшәнең туган көне» дигән яңа пьесасы Татар дәүләт академия театрында бик уңышлы барды. Кыскасы, Туфан Миннуллин яңадан-яңа әсәрләр яза, иҗатын һаман активлаштыра бара.

РИЗА ИШМОРАТ



Мин Роберт Батуллинны өч әсәре буенча беләм: «Минем исемем Дүрткүз», «Каникуллар дәвам итә», «Әбүгалисина». Боларның икесе балалар өчен язылган повестьлар, соңгысы шулай ук балалар өчен язылган пьеса. Бу өлкәдә эшләүче әйбәт язучы килә дип уйлыйм. Чөнки Роберт геройларының характерын белә. Балалар өчен язылган әсәрләрнең үзенчәлеген яхшы төшенә. Кызыклы итеп яза ала. Барыннан да бигрәк миңа Робертның киң карашлы, белемле булуы һәм күпне белергә тырышуы ошый. Балалар өчен язучылар арасында үзе бик күпне белә торган, яки белергә омтылган кешеләр җитми безгә. Батуллинның шул ягын хуплыйм һәм киләчәктә дә бу омтылышын киметмәвен телим.

**ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА**

●



Яшь шагыйрь Гәрәй Рәхим (Григорий Родионов) поэзиябезгә соңгы елларда гына килеп керде. Аның әле калын китаплары да юк. «Вәгъдә» исемле шигырьләр җыентыгы һәм балалар өчен хикәяләр («Чәчәк сатучы малай») җыентыгы гына бар.

Кайбер шагыйрьләр унар-егермешәр китап чыгаралар, әмма аларның поэтик йөзен танып булмый. Мин Гәрәй Рәхимне юка гына шигырь җыентыгы белән («Вәгъдә») шагыйрь итеп таныйм. Аның шигырьләрендә яңа поэтик фикер үзенчәлекле форма аша ачыла. Табигый ритмикасы татар шигыре традициясеннән, халык җырларыннан килә һәм аларга яңалык өсти. Гәрәй Рәхим шигъри холкы белән тыйнак, сабыр, салмак, уйчан, әмма поэзиядә кыю сүз әйтергә сәләтле шагыйрь. Аның поэтик офыгы якты, ачык, үзенчә...

Гәрәй Рәхим прозаик буларак та үзенең көчен сынап карый һәм өмет уята.

**ИЛДАР ЮЗЕЕВ**

◇ П ◇

# ХАЛЫК МӘХӘББӘТЕ— ИҢ ЗУР БУЛӘК

*«Моабит дәфтәре» фильмында*
*Муса Җәлил ролен башкаручы,*
*РСФСРның халык артисты,*
*Дәүләт премиясе лауреаты*
*Петр Черное сөйли.*

Экранда герой шагыйрь Муса Җәлил образын сурәтләргә тәкъдим ясалгач, мин дулкынландым, каушадым, хәтта бу җаваплы эштән куркып калдым.

Картинаны төшерү дәвамында без үз эшебез белән бергә, сценарийны эшкәртү, төзәтү белән дә бик күп шөгыльләндек. Ләкин бит сәнгатьтә, һәр эштәге кебек, һәркем үз эше белән шөгыльләнергә тиеш. Автор әсәрнең идеясен тасвирлый, актер аны образ аша сурәтли, режиссер аның синтезын бирә. Сәнгатьтә иң мөһиме — үз эшеңне намус белән, зур җаваплылык белән башкару. Ләкин сценарийның баштагы вариантын үз эшеңә җаваплылык белән карап башкарылган эш дип әйтеп булмый иде.

Менә, ниһаять, сценарий кабул ителде, группа тупланды. Иң башта мин шагыйрь тормышының иң җылы почмагына һәм аңа иң якын кешеләргә: хатыны Әминә ханым белән кызы Чулпанга мөрәҗәгать иттем. Мусаның яки турыдан-туры, яки читләтеп бу ике якын кешесенә мөрәҗәгать итмәгән бер генә шигыре дә юк диярлек бит.

Мине гаять тә җылы каршы алдылар. Муса турында истәлекләрне алар бик кадерләп саклыйлар. Мусага карата мәхәббәт, ягымлы хисләр алардан якты, гүзәл нурлар агышы булып бөркелә. Миңа Муса әйберләрен: утызынчы еллардагы имән өстәлен, кара савытын, ручкасын, дәфтәрләрен, блокнотларын, мандолинасын — кыскасы, аның белән бәйле булган барлык нәрсәне күрсәттеләр.

Гаҗәп нәрсә алар — әйберләр! Әйтик менә, синең алда гади кара савыты тора һәм аның янында әллә кайчангы каурый каләм ята, ди. Алар әле синдә берниндн хис тә тудырмыйлар: кара савыты — кара савыты булып, каләм — каләм булып кала бирә. Әгәр дә инде бу кара савытының Муса Җәлилнеке булуын, каләм белән Пушкин язганын әйтсәләр, синең уеңда фантазия ташкыны күтәрелә, зур тойгылар туа, кинәт үзең дә үзгәреп китәсең һәм бу әйберләрдәге һәр вак нәрсәне, һәр үзенчәлекне гаять зур игътибар белән карарга керешәсең. Аларны гадәттәгечә дорфа итеп түгел, зур саклык белән, бик йомшак тотып кулыңа аласың һәм, гаҗәп хәл, бу телсез, салкын шаһитлар күп нәрсәләр турында сөйли башлый, кулыңда аларның җылысын тоясың.

Мин алар торган квартирадан канатланып чыктым, һәм минем алда ниндидер өмет яктысы җемелдәде. Ләкин сценарий буенча эшли башлагач, шактый кыенлыкларга юлыктык.

Режиссер белән бер атнага фильмны төшерү эшләрен туктаттык та, мин Казанга китеп бардым. Партиянең Татарстан өлкә комитеты һәм Культура министрлыгы безнең шикләнүләрне бетерергә ярдәмгә ашыктылар. Шагыйрьнең дуслары, аның иҗатын өйрәнүчеләр белән очрашулар оештырдылар. Миңа Җәлилнең кульязмалары, документлары һәм башка кыйммәтле әйберләре саклана торган хәзинә белән танышырга мөмкинлек бирделәр. Мин төрле кәгазь кисәкләреннән тегелгән, битләренә гарәп хәрефләре белән шигырьләр язылган атаклы дәфтәрчекләрне — кечкенә блокнотларны гомеремдә беренче кабат кулыма алдым. Бу моментта бик дулкынландым мин — бу җансыз, телсез шаһитлар гына түгел бит, монда — бу дәфтәрчекләрдә — аның фикерләре, хисләре, аның йөрәге, каны, ышанычы саклана,



*Петр Чернов Казанда. «Моабит дәфтәре» фильмы афишасы янында.*

Мин Ленинградка кайттым, һәм Ленфильм директоры бүлмәсендә киңәшмәгә җыелдык. Бу киңәшмәгә безнең баш консультант Гази Кашшаф та килде. Киңәшмәдә сценарийны бик тиз яхшырту чаралары турында сөйләштек. Эшләр шактый яхшырды, шулай да, бу бик ашыгыч башкарылганлыктан, кимчелекләрдән без бөтенләй үк котыла алмадык.

Сәнгатьтә нәрсә дә булса иҗат итү өчен әсәрнең идеясе, герое белән мавыгырга, аны чын күңелдән яратырга кирәк. Режиссер, оператор һәм мин, актер,— без героебызны тирән дулкынланып иҗат иттек һәм Җәлилнең югары партиялелеге, гражданлыгы алдында тулы җаваплылык тоеп эшләргә тырыштык.

Хәзер шагыйрьнең тормышы турында мин шактый тулы беләм инде һәм шуңа күрә бик ышанып әйтәм: аның турында ике, өч (әйтергә кирәк, сценарий авторлары өч кеше) мавыктыргыч сценарий язарга мөмкин иде. Ләкин шунысы шарт: геройны чын күңелдән яратырга кирәк. Дөрес, бу билгеле хакыйкать, шулай да ул мәҗбүри.

Менә, ниһаять, фильм эшләнеп тәмамланды, һәм 1968 елның 12 октябрендә аны төшерү группасы премьерага дип Казанга чакырылды.

Поездданн төшкәч тә, без фильмның бик киң рекламалануын күрдек. Шәһәр афишалар белән тулган иде. Безне матбугат, радио, телевидение вәкилләре каршы алды. Һәр җирдә — листовкалар. Алар татар һәм рус телләрендә күрсәтеләчәк фильмны карарга чакыралар. Бу бер Казанда гына түгел, республиканың барлык шәһәрләрендә, районнарында шулай иде. Җәлилнең үлеменә чирек гасыр үтүгә карамастан, бөтен Татарстан, барлык татар халкы өчен геройның истәлеге изге һәм кыйммәт булуына без тагын бер кабат ышандык.

Минем Казанда кышын да, җәен дә, көзен дә булганым бар. Идел буендагы бу есыл шәһәр елның һәр вакытында үзенчә матур тәэсир калдыра. Җәй көне ул үзенең яшеллеге, шәһәрнең эчендә дип әйтерлек җәелеп киткән пляжлары белән гаҗәпкә калдырды, ә кышын мин аның борынгы истәлекләрен, яңа төзелешләренең киң колачын күрдем. Минем Казанда яз көне булганым юк, ләкин премьера көннәрендә кешеләрнең күзләрендә, күңелләрендә язгы хисләр, язгы нурлар шул кадәр мул иде ки, минем өчен көз дә язга әверелгәндәй булды.

Актер буларак, мине Казанның театрлары кызыксындырды, һәм мин кабат-кабат театрларга йөрдем. Татар академия театры спектакльләрен карадым һәм башкаручылар арасында фильм буенча таныш иптәшләрне күреп куандым. Спектакльләр миндә әйбәт тәэсир калдырды. Рус драма театрында чын осталарча башкарылган «Качу» спектаклен күрдем. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында «Дон Кихот»

балетын карап, труппаның яшь составы башкаруында беркелеп торган хискә һәм дәрткә сокландым.

Казанда хәзерге заманча итеп җиһазландырылган кино-театрларның аз булуы кызганыч. Озакламый алар да барлыкка килер дип ышанасы килә.

Казаннан башка без Бөгелмә, Түбән Кама, Әлмәт, Чаллы шәһәрләрендә дә булдык. Бу сәяхәт — шундый төгәл һәм эшлекле итеп оештырылган иде, без үз вакытыбызның һәр сәгатен файдалы итеп үткәрдек. Бу шәһәрләрдә киң масштабта алып барыла торган төзелешләр безне чын-чынлап гаҗәпләндерде. Биш ел эчендә җитмеш биш мең кешелек шәһәр салу — бу гаҗәпләнерлек түгелмени!! Шунысы шәп: бу шәһәрләр хәзергечә көнкүреш шартларына туры китереп салыналар.

Кара алтын, газ запасы, бу байлыкларны эшкәртү перспективалары — әкияттәгечә. Без «Дуслык» нефть үткәргеченең «нуль» билгесе белән билгеләнгән урынында да булдык. Ул меңнәрчә километрларга куәтле тормыш агымы озата торган ниндидер бер үзенчәлекле гиперболик артерияне хәтерләтә.

Ашкынып ага торган Каманы авызлыклаучы тәвәккәл, батыр кешеләрне дә күрдек без.

Авыл хуҗалыгы районнарында да ирешелгән уңышлар белән сокландык. Шунысы күңелле: татар авылларына сәнгать һәм культура торган саен тирәнрәк үтеп керә. Бөгелмәдәге культура сарае, андагы менә дигән тамаша залы, төрле түгәрәкләр өчен бүлмәләр — барысы да хәзерге заманча итеп җиһазландырылган. Бүлмәләрнең берсендә без нәни кызларның балет биюләренә өйрәнүен күрдек.

Иң мөһиме, әлбәттә, бу байлыкларны тудыручы кешеләр. Шунысы игътибарга лаеклы: республикада дәүләт, партия һәм административ эшләргә җаваплы җитәкчеләр итеп яшь кадрлар билгеләнә. Ә бу кешеләргә белем, югары культура хас.

Без шундый бер бик үзенчәлекле хәлнең шаһиты булдык: ике райком секретаре сөйләшә иде. Берсе аларның пенсиядәге секретарь, олы яшьтәге кеше, колхозлашу чорында, Ватан сугышы елларында авыл хуҗалыгы белән җитәкчелек итүнең бөтен авырлыкларын, сугыштан соңгы еллардагы сынауларны үз җилкәсендә татыган кеше. Ә икенчесе — яшь, күптән түгел генә сайланган, югары белемле кеше. Һәр икесе дә бер-берсенә гаять тә ихтирамлы. Бу мөнәсәбәт ата һәм аның улы арасындагы эчкерсез мөнәсәбәтне хәтерләтә. Ата кешенең үз карамагындагы зур хуҗалыкны улына, аның эшлекле кулларына тапшыруы белән горурлануы сизелеп тора иде. Ә улы, әтисенең фидакарьлеген аңлаганы хәлендә, үз эшенә намус белән, партия һәм халык кушканча карый. Бик тормышчан мирас үрнәген күрдек без. Шунысын да әйтергә кирәк: аларның берсе татар, икенчесе рус иде.

Безнең сөйләшүләр вакытында аларның олысы мина һәрвакыт: «Иптәш Давыдов»,— дип мөрәҗәгать итә торган иде. Мин: «Мөгаен, «Күтәрелгән чирәм» фильмындагы мин уйнаган рольне истә тотып, чын фамилиямне белмичә шулай эндәшә торгандыр инде ул»,—дип уйладым. Аңарга тагын бер кабат текәлеп карадым да күңелемнән шулай фикер йөрттем: «Әй абзый, син үзең Давыдов бит. Әлбәттә, син хәзер әзрәк картайган, әмма ләкин заманында сине, мөгаен, хатын-кызлар җыелышып «өшкергәннәрдер». Синең Варюха-Горюхаң да булгандыр. Булгандыр, һичшиксез, булгандыр. Син нәкъ менә шул тоқым кешесе, факт!»

Без Татарстан республикасында Җәлил исеме белән йөрдек, бу исемнең йөрәкләрне, күзләрне, кочакларны, һәр йортның ишеген ачарга сәләтле изге бер исем икәнлеген күрдек. Бу исем белән без һәр йортта кадерле кунак идек. Җәлил хәзер дә кешеләргә зур хезмәт күрсәтә, аларны тәрбияли, үзара берләштерә, алар күңелендәге гүзәл хисләрне үстерә.

Кешеләр герой истәлеген үз йөрәкләрендә саклап кына калмыйча, аны килəчәк буыннарга да тапшырырга омтылалар. Без булган һәр шәһәрдә Җәлил урамы бар, һәр районда Җәлил колхозы бар.

Бу сәяхәт безнең күңелләрдә мәңге сакланыр. Безгә карата шундый җылы караш, кунакчыллык өчен бик зур рәхмәт сезгә, дуслар!

Безнең картина Җәлил тормышын һәм аның образын сурәтләүче беренче омтылыш кына. Бу тема мәңгелек, аны сурәтләүнең мөмкинлекләре чиксез...

Җәлил! Халкың синең җиңеп чыкты, син аның йөрәгендә һәм кочагында яшисең!

# МИНЕМ ЕЛМАЮ

Фәнис Яруллинның шигырьләре үзләренең ихласлыгы, уйчан лиризмы, үзләренә генә хас экерсезлеге белән аерылып тора. Әле соңгы айларда гына аның балалар өчен язылган тагын бер китабы дөньяга чыкты. Ул китап «Минем елмаю»[1] дип атала.

Балалар өчен язылган кайбер китаплар бәхетсез булалар. Алар укылмый. Чөнки язылган шигырьләр, балаларның нарасый беркатлылыгына зурларча өстән карап елмаеп, зурларга сөйләү генә булып чыга. Мондый шигырьләрне тыңлап зурларның елмаюы бик мөмкин, әлбәттә. Алар өчен балачак гаять кызык әйбер бит... Ә бала андый шигырьләрне укып чыкканнан соң елмаерга уйлап та карамаячак, чөнки бу шигырьдә сөйләнгән «көлке» вакыйга — аның өчен табигый бер хәл генә...

Тукайның «Су анасы»н гына искә төшерик. Аны зурлар да, кечкенәләр дә ярата. Чөнки Тукай бу шигырьне язган чакта балаларның нарасыйлыгыннан көлүне максат итеп куймаган. Бу минутта ул үзе дә бала шикелле — малайның алтын таракны күреп алган минутын гына хәтерлик!

Тукайлар, Алишлар бала белән сөйләшкәндә аны үз тиңдәше итеп, дусты итеп сөйләшә белгәннәр.

Ф. Яруллин да шушы ягы белән безне куандыра. Китап «Бушлык» дигән шигырь белән башланып китә. Өй эче яп-ялангач... Буш... күңелсез... Юкса бөтен нәрсә урынында кебек... Ә, менә хикмәт нәрсәдә — әни өйдә юк бит!

Бала өчен ана — үзе бер дөнья, иң кадерле кеше. Ул оҗмахында да, әнисез булса, яшәмәячәк. Сигез генә юллы бу шигырьдә бала күңеленең якты бер нюансы чагылган.

Гомумән, бу китапка кергән шигырьләрнең һәрберсе әнә шул нюансларны, якты моментларны күрсәтеп бирүгә, сабый күңеленә ниндидер уйландыргыч нур чаткысы, рәхәт елмаю дулкыны салуга юнәлтелгән.

Табигать күренешләрен балаларга бик якын булган, аларның зиһене рәхәтләнеп кабул итә торган чагыштырулар белән сөйләп бирә белүгә мисал итеп, авторның «Март кояшы», «Апрель», «Май», «Кыш башы», «Суык төсе», «Йолдызлы кич», «Язгы парчалар», «Ак болытлар» дигән шигырьләрен китерергә була. Кояш «болыт белән төренеп, ялкау баладай йоклый. Юрганын ачмый торып, болыт астыннан чыкмый». «Апрель батыр, җиң сызганып, елгада бозлар вата». «Үләннәр борын төртәләр, бөреләр тунын сала». «Болытлар, иске толыптай, асылынган-салынган. Күк бүген алама тунын катлый-катлый ябынган».

Әнә шундый җиңел тел белән әйтелгән гади генә чагыштырулар, билгеле, балаларның күңелен яулап алачак. Алар бит үзләре дә тузгыган күңелсез болытларны күреп йөриләр. Ә шигырьне укып карагannан соң, шагыйрь абыйларының әнә шундый болытларны иске толыпка охшатуы аларны гаҗәпләндереп һәм бер үк вакытта сокландырып куячак. Шигырь эчендә сиздерми генә яңгырап куйган «толып» сүзе белән «болыт» сүзе арасындагы эчке яңгыраш аларны сискәндерәчәк.

Фәнис Яруллин балалардан зурларча өстән карап көлми. Ул шигыренең беренче юлында ук кызыклы гына бер тон ала: әйтерсең лә бу кызның яки малайның беркатлылыгы турында аның яшьтәше — шаян гына бер бала сөйли кебек:

Кичәге карлыгач килгән,
Күрче, күрче, әтием,
Әнә ничек борыны белән
Чукып тора тәпиен.
— Бәлки башка карлыгачтыр,
Каян беләсең, кызым?

[1] Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1968 ел.

— Әнә ич койрыгы ярык,
Шуннан таныдым үзен...

— Иң чиста дәфтәр кемдә?
Назада түгел — миндә!
Карасалар дәфтәрен,
Чынлап та дәфтәр чиста.
Чөнки Мөнип аңарга
Язмаган бер хәреф та».

Балаларны «Том Сойер маҗаралары», «Тимур һәм аның командасы» кебек әсәрләр, билгеле, ныграк кызыктыра. Бер шигырь китабын укыганчы, алар югарыда әйтелгән калын-калын проза әсәрләрен берничә кат укып чыгарга әзер. Шуңа күрә балалар өчен шигырь китабы бирү — шагыйрьнең иҗнәренә бик күп эш йөкли. Балаларга, хисле шигырьләргә караганда, сюжетлы, эчтәлекле шигырьләр ошыйрак төшә. «Минем елмаюм»га кергән кечкенә генә күләмле шигырьләрнең дә үзләренә күрә бик мавыктыргыч сюжетлары бар. Ә инде «Гаделша командасы», «Көч чишмәсе» (әкият), «Ике кыз һәм бер көчек» кебек озын шигырьләр исә сюжет мәсьәләсендә тагын да отышлырак килеп чыккан.

Кыскасы, Фәнис Яруллинның бу җыентыкта басылган шигырьләре җиңел тел белән, хәтергә бик тиз сеңеп калырдай сурәтләүләр кулланып язылган. Фәнис Яруллинның елмаюы балаларның гына түгел, зурларның да күңелендә җылы дулкын кузгатыр дип уйлыйм.

ЗӨЛФӘТ.

# «ИКЕ АККОШ» ТУРЫНДА

Шагыйрь Ә. Баяновның шигырьләре хискә ярыйсы бай, теле матур. Әнә шул гадилеге белән ул күп кенә укучыларны куандыра ала. Шагыйрьнең «Ике аккош» исемле яңа җыентыгын укыганнан соң күңелдә шундый фикер туа.

Җыентык авторның «Тыйнак кеше турында баллада»сы белән башлана.

Сүзсез генә киткән ул Себергә,
Җырларын да сүзсез җырлаган.
Аның өчен буран килгән телгә,
Аның өчен богау чыңлаган:
— Яшәсен революция!

Әнә шундый кеше турында җыйнак кына язылган баллада бу. Балладада революция солдаты образы саран гына буяулар белән, әмма тулы ачылган.

Шул ук нәрсә «Уйладым да кабат кайтасымны...» исемле шигырендә дә күренә:

Уйладым да кабат кайтасымны,
Бикләмәдем басу капкасын.
Төнем китсә, синдә җаным кала,
Өшетмичә, авылым, сакларсың.

Күрәсез, бу юллар шигърияткә, образлы. Шигырьнең калган өлеше дә шулай дәвам итә. Шулай итеп, шагыйрь туган авылыннан аерылган кешенең теләк-хисләрен истә калырлык, хис уятырлык итеп тасвирлый.

Шагыйрьнең «...Агып бара чәчәк бәйләме...» һәм «Уянсалар» исемле шигырьләре дә шактый тирән фикерле. «Уянсалар» шигырендә автор күп нәрсә әйтә. Кешелеккә бәхет яулаган Мусаларның онытылмаслыгы да, аналарның сөенеч яшьләре кыйммәтле икәнлеген дә искәртә. Шул ук вакытта шигырьдә: «Сугыш булмасын иде!» дигән фикерне дә үткәрә:

Аналар күз яшен җыйсалар,
Ясалыр бер океан, әр-яңа!
Шауласын ул сөенеч яшьләре,
Ургылсын ул океан елларга,
Чыксыннар майданга Мусалар!—

ди ул. Шулай итеп, укучыда фикер уята, аны уйланырга мәҗбүр итә.

Җыентыкта «Ике аккош» исемле җырпоэма да урнаштырылган. Анда бер мәхәббәтнең бәхетсез азагы турында сөйләнә. Әмма әсәрне җыр-поэма дип атау дөресме икән? Җыр-поэмада кояш, җылылык күп булырга тиеш түгелме соң? Ф. Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармунның җыр-поэма дип атарга мөмкиндер. Ә моны...

«Ике аккош» — гыйбрәтле вакыйга турында сөйли. Яшь кыз Гөлүсәне фән биеклекләре кызыксындыра. Ләкин тормыш кызны алдый: ул сөйгән егете Нәҗипкә хыянәт итә. Моның сәбәбе — Гөлүсәнең тәҗ-

[1] Ә. Баянов. «Ике аккош». Шигырьләр, поэма. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1968 ел.

рибасезлеге, фән белән мавыгудан суккы- раюы. Сүз юк, яшьләр өчен кирәкле әсәр бу. Геройларның эчке кичерешләре дә шактый тулы бирелгән. Әмма поэмага зур әдәбият күзлегеннән чыгып карaганда, әсәрне тулаем бик үк уңышлы дип булмый. Поэманың конфликты түбәндәге юлларда ачыла:

Ул ишетте:
Еллар буе язганнарын аның
Укып берәү юкка чыгарган.
Күңеле кинәт сынды Гөлүсәнең,
Шатлыклары сүнде,
Шатлыклары сүнде шуңардан.

Кешенең еллар буе түккән хезмәтен берәү генә юкка чыгара аламы? Фәндә 99 % тырышлык кирәк бит. Ә бу сыйфат, поэмадан күренгәнчә, Гөлүсәдә бар. Димәк, бу юллар тиешенчә нигезләнеп җитмәгәннәр. Ә боларны алып ташласаң, поэманың сюжеты һәм конфликты җимереләчәк. Кызганычка каршы, әсәргә әнә шундый кирәк булган өчен генә кертелгән очраклылык бездә шактый әсәрләрне харап итә. Җансыз, билгесез затларны гаепләп сюжет кору — поэманың укучыны ышандыру көчен киметә.

Ә. Баянов поэманы болай тәмамлый:

Идел өсте янып сүнгән инде,
Пар күләгә күптән йөреми,
Әллә Идел үзе гыйбрәт сөйли,
Әллә аны моңсу җыр иңли...
Пар аккошлар анда күренми.

Бу юллардан аңлашылганча, инде бар да беткән, мәхәббәтнең киләчәге караңгы. Әмма чын мәхәббәткә бернинди киртә дә юк бит, ул барысын да кичерергә, онытырга сәләтле. Шуңа күрә поэманы болай тәмамлау белән килешәсе килми, чөнки әсәр гыйбрәтле вакыйга сөйләүгә генә кайтып кала.

Бүгенге поэзиябездә «урта кул» шигырьләр күп. Аларны укыйсың да «ярый инде» дип куясың. Шагыйрь яшь вакытта ничектер кайнарлыгы, омтылышы белән җәлеп итә. Әмма нигәдер кайберәүләр бер-ике китап чыгарганнан соң, басынкыланып, сүрелеп калалар. Дөрес, тонналаган алтын комында алтын бөртекләре бик аз була. Әмма поэзиядә мондый чагыштырма урынлы була алмый кебек. Укучының кыска гына гомерендә укырга болай да әйбер җитәрлек. Аңа хәзер әдәбиятта тагын да югарырак дәрәҗәдә эшләнгән, җитлеккән әсәрләр кирәк. Ә Баяновка да бу хакта күбрәк уйлану зыян итмәс иде. Безнең бу шагыйрьдән күбрәк көтәргә хакыбыз бар һәм ул бу ышанычны аклар дип өмет итәбез.

С. ХӘКИМҖАНОВ.

## Шәүкәт Галиев

### Аптырагач...

1

Шигырьләрен укыйлар да
Киңәш бирәләр аңа:
— Син, энекәш, ни инде...
Хикәя язып кара.

2

Хикәясен дә укыйлар,
Киңәшчеләре яңа:
— Син, иптәшкәй, ни инде...
Пьеса язып кара.

3

Драмасын укып карыйлар,
Юк тагын бүтән чара:
— Син, абзыкай, ни инде...
Тәнкыйть тә язып кара.

* * *

Әйтте теге дулкынланып
(Күзендә аның яшьләр):
— Минем хәлләр, алайса,
Ничава бит, иптәшләр!

### Үзең нинди...

Бигрәк сай бит, бик беркатлы,
Бик төссез геройлары —
Ташка үлчим генә инде
Хисләре дә уйлары!

Үзеннән-үзе нәтиҗә
Чыгадыр, ахры, моннан —
Акыллырак булалмый шул
Геройлар... авторыннан.

## Зәки Нури

### «Үзтәнкыйтьче»

— Тәнкыйть язсаң мактау сүзең һаман
Елга булып шаулап агыла.
Нәрсәдән бу? — Үзтәнкыйтьне сөям!
Шул сыйфатым эштә чагыла.

### Уң кул белән сул аяк

Зур эштә ул уң кул булып эшли.
Сукса — саклан: чөнки таза кул.
Шуңа да бит бөтен бастырганын
Сул аягы белән яза ул.

### Кино сөюче сүзе

«Карарсың,— дип,— уналтыга житкәч»,—
Бик күп әйтте кино миңа да.
Инде әйтәм: — Уналтыдан узгач,
Карар нәрсә тапмыйм кинода.

## Ш. Мадриш

### Эзе бар...

Шагыйрь илһам көтте,
Илһам килми йөрде.
Җәй үтте, көз житте,
Кыш агартты жирне.
Шагыйрь: «Булды! — диде.—
Пеләшем — ак алан.
Менә ходай бирде!
Мин хәзер язалам.
Шыгырдаган карда
Шыгыр-шигырь бардыр:
Шыгырдатып карыйм
Шыгырдаган карны».
Шыгыр-шыгыр йөрде,
Үзенең эзен күрде.
«Эзләр... эздә — фикер!» —
Атылып өйгә керде.
Кар бик сай булса да,
Фикер тирән иде.
Таңкәле-таңкәле
Илһам килгән иде.

«Эзләр — энже карда...» —
Шагыйрь тәмам кызды.
Шытырдатып язды,
Шытырдатып бозды.
«Ел да кышлар килсен,
Карлар яусын»,— диде.
«Дөньяда яшәсән,
Эзең калсын»,— диде.
«Эз калдыру,— диде,—
Бу — бөтен якта бер.
Декабрь — кыш булса,
Көз була — октябрь».
Әйләнсен тәнкәгә
Тәнкә-тәнкә карлар,
Шагыйрь кесәсендә
Шыгырдар гонорар.
Тәрәзәдән күзәтә:
Эзләр күмелмиме?
Эзе бар... Эз булгач,
Шагыйрь түгелмени?!

◇ II ◇

Үткән елның 19 декабрендә Татарстан журналистларының IV съезды булды. Татарстан журналистлар союзы идарәсенең отчет чорындагы эше турындагы докладны Союз идарәсе председателе Ш. Х. Хамматов ясады. Ул ике съезд арасында журналистларыбыз башкарган эшләр, ирешкән уңышлар турында сөйләде. В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССР төзелүгә 50 ел тулуга әзерлек унае белән журналистлар алдында торган бурычларга тукталды.

Аннары Ш. Х. Хамматов доклады буенча фикер алышу булды. Буа районы газетасы редакторы Н. Гобәйдуллин авторлар активы белән эшләү һәм КПСС Үзәк Комитетының Октябрь пленумы карарын тормышка ашыру унае белән авыл хуҗалыгы мәсьәләләрен яктырту турында сөйләде. Күп тиражлы «Строитель» («Төзүче») газетасы редакторы А. Андреев яңа кеше тәрбияләүдә газетаның роле турында сүз алып барды. Радиотапшырулар һәм телевидение комитеты председателе Ф. Надыйров радио һәм телевидение аша В. И. Ленинга багышланган тапшырулар турында сөйләде. «Чаян» журналының баш редакторы А. Яхин журналистларны матбугатта басылган материалларның нәтиҗәлелеге өчен активрак тырышырга чакырды. Казан дәүләт университетының кафедра мөдире Л. Юдкевич журналист кадрлар әзерләү мәсьәләсенә тукталды.

Фикер алышуда Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе Ибраһим Гази да катнашты һәм журналистларны иҗатларын тагын да активлаштырырга, каләмнәрен үткенәйтергә, шаблон буенча язу алымнарыннан котылырга тырышырга һәм һәрвакыт партия бурычларын истә тотып эш итәргә чакырды.

Съездда катнашучылар СССР журналистлар союзы идарәсе члены, «Международная жизнь» журналының баш редакторы урынбасары профессор Ш. П. Санакоевның чыгышын зур кызыксыну белән тыңладылар.

КПСС өлкә комитеты секретаре иптәш М. Ф. Вәлиев съездда зур речь белән чыкты.

Соңыннан Татарстан журналистлар союзының җитәкче органнары сайланды.

Татарстан журналистлар союзының яңа сайланган идарәсенең пленумы булды. Ул оештыру мәсьәләләрен карады. Татарстан журналистлар союзы идарәсе председателе итеп Ш. Х. Хамматов, аның урынбасарлары итеп Г. К. Камалиев, Ф. Г. Надыйров, җаваплы секретарь итеп В. Н. Михайлов иптәшләр сайланды.

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕНӘ КОНКУРС

Профсоюзларның Татарстан өлкә советы, Язучылар союзы, Культура министрлыгы, Халык иҗаты йорты, Бөтенсоюз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге, В. И. Ленинның тууына 100 ел, Совет Татарстанының төзелүенә 50 ел тулуга багышлап, иң яхшы драма әсәрләренә конкурс игълан иттеләр.

Конкурсның максаты бөек Ленин турында, ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру, халкыбызның гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары елларында, илне индустрияләштерү һәм авыл хуҗалыгын коллективлаштыру чорында күрсәткән батырлыклары турында, замандашларыбыз — эшчеләр, кыр һәм ферма хезмәтчеләре, совет интеллигенциясе вәкилләре турында яңа әсәрләр язуга драматургларны һәм яшь авторларны тартудан гыйбарәт.

Конкурска стационар һәм күчмә театрлар, халык театрлары һәм үзешчән сәнгать коллективлары өчен язылган күп пәрдәле сәхнә әсәрләре: драмалар, героик драмалар, трагедияләр, комедияләр кабул ителә.

Конкурска дигән әсәрләр язу машинкасында ике интервал аша бастырылган (ике экземплярда) булырга тиеш. Аерым конвертта авторның девизы, фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм адресы күрсәтелә. Ул конвертлар жюри карар кабул иткәннән соң гына ачыла.

Конкурсның срогы 1968 елның 15 декабреннән 1970 елның 1 гыйнварена кадәр билгеләнә.

Конкурста иң яхшы дип табылган драма әсәрләренә түбәндәге бүләкләр бирелачәк:

Беренче бер премия — 1.000 сум.
Икенче ике премия — 600 әр сум.
Өченче өч премия — 400 әр сум.

Әсәрләрне түбәндәге адрес белән конкурс жюриена җибәрергә: КАЗАН, КРЕМЛЬ, ТАТАРСТАН КУЛЬТУРА МИНИСТРЛЫГЫ, «ИҢ ЯХШЫ ДРАМА ӘСӘРЕНӘ» КОНКУРСКА.

## ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫГЫ

Декабрь аенда Кама Тамагы районында әдәбият атналыгы үткәрелде. Атналык ике олы бәйрәмгә — Ленинның тууына 100 ел, Татарстанның 50 еллык юбилеена багышланып үткәрелде. Анда язучылардан Фатих Хөсни, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Мөдәррис Әгъләмовлар катнашты. Олы Кариле, Олы Карамалы, Келәнче, Яңа Сала, Кырташ авылларында әдәби кичәләр үткәрелеп, аларда Тукай исемендәге, XXII парт-

съезд исемендәге, «Большевик», «Яңа юл», «Уңыш» колхозы членнары, мәктәп укучылары катнаштылар. Әдәбиятыбыз турында, аның бүгенге торышы турында сөйләшү булды. Язучылар һәм шагыйрьләр кичәләргә килгән халыкны үзләренең иҗатлары белән таныштырдылар, яңа әсәрләрен укыдылар.

Атналык дәвамында китап сәүдәсе дә оештырылды. Язучыларның автографлары белән күп кенә китаплар сатылды. Очрашуларда укучыларның әдәби зәвыклары шактый үскәнлеге, матур әдәбиятка ихтыяҗның һаман арта баруы бик ачык күренде.

## КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ

Үткән елның апреленнән декабрена кадәр район газеталарын иң яхшы итеп чыгаруга һәм полиграфия ягыннан оста эшләүгә республика конкурсы үткәрелде. Аны Татарстан АССР Министрлар Советы янындагы Матбугат идарәсе, Татарстан журналистлар союзы, культура работникларының профсоюзы өлкә комитеты, полиграфиянең һәм нәшриятларның фән-техника җәмгыяте республика идарәсе игълан иткән иде.

Күптән түгел жюри конкурска йомгак ясады һәм лауреат газеталарны билгеләде. Беренче премия һәм беренче дәрәҗә диплом, үткән елгы кебек үк, Биектау районының «Путь Ильича» газетасына бирелде (редакторы М. Петров).

Икенче премия һәм икенче дәрәҗә диплом Чистайның «Ленинский путь» газетасына бирелде (редакторы Е. Полосухин).

Өченче премияләр һәм өченче дәрәҗә дипломнар «Зеленодольская правда» (редакторы Н. Цимбалов) һәм Алабуга районының «Новая Кама» газеталарына бирелде (редакторы А. Анисимов).

Газетаны чыгару культурасын күтәрүләре, шулай ук конкурста актив катнашулары өчен, Бөгелмә, Мөслим, Кама Тамагы, Түбән Кама, Югары Ослан, Әлмәт, Буа, Актаныш, Чаллы, Куйбышев һәм Кукмара районнары газеталарына кызыксындыру дипломнары бирелде.

Газеталарны полиграфия ягыннан матур башкарган өчен Түбән Кама, Әлмәт, Актаныш, Чаллы һәм Кукмара типографияләре коллективларына кызыксындыру дипломнары тапшырылды.

Республика конкурсында җиңеп чыккан «Путь Ильича», «Ленинский путь», «Зеленодольская правда» һәм «Новая Кама» газеталары икенче турда катнашу өчен Бөтенроссия смотр-конкурсына тәкъдим ителделәр.

## ХАЛЫК ТЕАТРЛАРЫ АРТА

Кукмара хезмәт ияләре тантаналы вакыйга кичерделәр. Ул көнне 400 урынлы район культура йорты тамашачылар белән шыгрым тулы булды. Район культура бүлеге мөдире Д. Петров тантаналы кичәне ачып, районда халык театры ачылу уңае белән барлык тамашачыларны һәм үзешчән театр артистларын котлады һәм аларга зур иҗади уңышлар теләде.

Халык театры сәхнәсе алдындагы тасманы кисү драмколлективның иң өлкән үзешчәне пенсионер Гали Галиевич Галиевка тапшырылды. Шулай итеп, Кукмара районында да үзешчән халык театры эшли башлады. Бу — республика районнарында унберенче халык театры. Ул үзенең беренче спектакле итеп Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт» әсәрен сәхнәгә куйды. Спектакльдә уйнаучы үзешчән артистлар Г. Галиев, И. Низамиев, Х. Гарипов, Р. Сабиров, С. Исрафилова, Х. Хөсәенова үзләренең рольләрен оста, матур башкарулары белән тамашачыларда бик җылы тәэсир калдырдылар. Халык театры коллективы озакламый район авыллары тамашачыларына — колхозчыларга, совхоз эшчеләренә дә спектакльләр күрсәтәчәк.

## Ш. УСМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Күренекле татар совет язучысы, гражданнар сугышы каһарманы Шамил Усмановның туууына 70 ел тулу уңае белән, 1968 елның 23 декабренда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында юбилей кичәсе үткәрелде. Әдипнең тормышы һәм иҗат юлы турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Альберт Яхин ясады. Аннары Шамил Усмановны күреп белгән кешеләрдән профессор Гыйлем Камай, язучы Гази Кашшаф, Казагыстаннан килгән академик С. Кенесбаев һәм скульптор, Тукай премиясе лауреаты Бакый Урманче иптәшләр кичәгә җыелган күп санлы тамашачыларга әдип белән бәйләнешле истәлекләр сөйләделәр.

Соңыннан Татар дәүләт академия театры артистлары һәм Татар дәүләт филармониясе артистлары көче белән бик әйбәт концерт бирелде.

## Ә. ДАВЫДОВНЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ ТУЛА

Татарстан язучылар союзы идарәсе Президиумының чираттагы утырышында Ә. Давыдовның туууына шушы елның 25 мартында 50 ел тулу юбилеен үздыру мәсьәләсе каралды. Союз идарәсе председателе Ибраһим Гази чыгышын тыңлаганнан соң Президиум түбәндәге карарга килде:

1) Ә. Давыдовның 50 еллыгын билгеләп үтү өчен, С. Хәким, Р. Мингалимов, Г. Рәхим һәм Ш. Маннапов иптәшләр составында юбилей комиссиясе төзергә;

2) Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Ә. Давыдов иҗатына багышланган тантаналы кичә үткәрергә;

3) Ә. Давыдовның сайланма әсәрләрен туплап, «Советский писатель» нәшриятына тәкъдим итәргә.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

ТАССР Верховный Советы Президиумының 1968 елның 19 декабренда игълан ителгән Указы нигезендә, Татарстан

ССРның атказанган артистлары Шәү-
(әт Хәсән улы Биктимировка, 'абделгазиз Габдрахман улы ыятдиновка, Вера Егоровна Һиникинага (барысы да Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры ртистлары), Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры солистлары, ТАССР-ның атказанган артистлары Идеал Дәүләт улы Ишбуләковка һәм Салих Зарифулла улы Хәйруллинга, овет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, Татарстан АССРның халык ртисты дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының шул ук көнне игълан ителгән Указы нигезендә, совет культурасын үстерүдәге һәм хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдәге хезмәтләре өчен, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры директоры урынбасары Низаметдин Фәхретдин улы Камаловка һәм В. И. Качалов исемендәге Казан Зур драма театрының әдәби бүлек мөдире Игорь Германович Ингвар-Линсцерга Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.

## МӘСКӘҮДӘ ЧЫГАЧАК

Бу ел Мәскәүдәге Үзәк нәшриятларда байтак кына татар авторларының китаплары рус телендә чыгарырга әзерләнә. «Советская Россия» нәшриятында Гариф Ахуновның «Человек ищет сокровище» («Кеше хәзинә эзли») исемле повесть һәм хикәяләр җыентыгы, профессор Гыйлем Камайның «Мечте навстречу» («Хыялны каршылап») исемле истәлекләр китабы, Зәки Нуриның «Улыбка» («Елмаю») исемле шигырьләр җыентыгы, «Детгиз» нәшриятында Гариф Гобәйнең «Дочь бакенщика» («Маякчы кызы») исемле повесте, «Гослитиздат» нәшриятында Муса Җәлилнең «Моабитская тетрадь» («Моабит дәфтәре»), «Советский писатель» нәшриятында Роберт Бикмөхәммәтовның «Дорога остается» исемле очерклар җыентыгы басылып чыгачак.

## КАРАБАШТА ОЧРАШУ

Инде берничә ел Лениногорскида чыга торган «Ильич васыятьләре» газетасы редакциясе каршында әдәби-иҗат берләшмәсе эшләп килә. Анда ике дистәгә якын яшь һәм башлап язучы катнаша. Язучы Шамил Бикчурин җитәкчелегендәге бу берләшмәнең утырышлары даими үткәрелә. Утырышларда әдәби кануннар, жанрлар һәм әдәбият теориясенә кагылышлы башка мәсьәләләр белән бергә, яшь язучыларның яңа шигырьләре, хикәяләре, очерклары тикшерелә, яхшы дип табылганнары шәһәр һәм республика матбугатларына тәкъдим ителә.

Берләшмә членнары әдәбиятны пропагандалау белән дә шөгыльләнәләр. Әледән-әле нефтьчеләр, колхозчылар алдында чыгыш ясыйлар. Бүгенге татар әдәбияты турында сөйлиләр, үзләренең әсәрләрен укыйлар. Шундый очрашу әле күптән түгел генә Карабаш эшчеләр поселогында да үткәрелде. Анда язучы Ш. Бикчурин, яшь язучылардан Ж. Рәхимов, А. Хәсәнов, К. Әмиров, Ә. Исхаков, М. Газизов һәм башкалар катнашты. Алар тамашачыларга үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

Кичәнең икенче бүлегендә Лениногорскидагы музыка-художество укытучылары һәм укучылары концерт бирде.

## «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» ГАРӘП ТЕЛЕНДӘ

Татар әдипләренең башка телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләре байтак. Әмма шулар арасында иң күп һәм иң зур тираж белән басылып чыкканы — Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» исемле повесте дисәк, һич тә ялгыш булмас. «Тапшырылмаган хатлар» СССР халыклары телләренә тәрҗемә ителеп тә, чит ил телләрендә дә күп мәртәбәләр басылып чыкты һәм басылып тора. Әле күптән түгел генә бу әсәр Мәскәүдә «Прогресс» нәшриятында «Мәхәббәт хатлары» («Рәсаиле ган-элхәбби») исеме белән гарәп телендә аерым китап булып басылды. Повестьне гарәпчәгә элек Казан дәүләт университетында студентларга гарәп теле укыткан, ә хәзер пенсионер Гаяз ага Ишмөхәммәтов тәрҗемә иткән.

Ул китапның тышлыгы менә шундый.



## СИМПОЗИУМ БУЛДЫ

Күптән түгел СССР Фәннәр Академиясе тел институтының төрки телләр бүлегендә «Көнбатыш һәм көнчыгыш славян телләрендә төрки сүзләр» исемле симпозиум булып узды. Анда илебезнең төрле почмакларыннан һәм чит илләрдән килгән төрки тел белгечләре, академиклар, докторлар катнашты. Симпозиумда житәкчелек итү бурычын төрки телләр галиме — профессор Н. А. Баскаков үтәде. Симпозиумда 25 кә якын доклад һәм чыгышлар тыңланды. Докладларда сүз, нигездә, славян телләренә килеп кергән төрки сүзләр һәм төрки телләр аркылы кергән гарәп-фарсы сүзләре турында барды.

Казан галимнәреннән профессор Ә. Ахунжанов үзенең чыгышында рус телендә очраган татар сүзләренә тукталды. Кызыклы мисаллар китерде. Профессор Г. Әмировның рус әдибе Аксаков әсәрләрендәге төрки сүзләргә багышланган чыгышы, Уфадан килгән иптәш Гарипов, Чувашиядән килгән иптәш Сергеев докладлары да зур кызыксыну белән тыңланды.

Симпозиумда элекке Татарстан китап палатасы директоры (хәзер пенсиядә) Әхмәт ага Булатов та катнашты һәм чыгыш ясады.

Симпозиум бик жанлы үтте. Тыңланган докладлар буенча фикер алышулар, сораулар, чыгышлар булды. Бу мәсьәләне өйрәнү — халыкларның үзара аралашу тарихын, аларның бик күптәннән экономик һәм культуралы бәйләнештә булганлыгын күрсәтте.

Соңыннан профессор Н. А. Баскаков йомгаклау сүзе белән чыкты. Ул славян һәм төрки тел белгечләре алдында зур бурычлар торуы хакында сөйләде, якын киләчәктә «Славян телләрендә төрки сүзләр» исемле сүзлек бастырып чыгарырга кирәклеген әйтте.

## СПЕКТАКЛЬ УҢЫШЛЫ ҮТТЕ

Әлмәт Техника йортында Республика күчмә театры драматург Рәисә Ишморатованың «Шамил» драмасын күрсәтте. Бүгенге яшьләребезнең тормышын чагылдырган бу спектакльне Әлмәт тамашачылары яратып карадылар. Соңыннан тамашачылар шул әсәр буенча конференция үткәрделәр һәм авторга үзләренең фикерләрен, тәкъдимнәрен әйттеләр. Шулай ук әсәрдәге кайбер житешсезлекләрне, артистлар уенындагы кайбер кимчелекләрне дә күрсәттеләр. Конференциягә Рәисә Ишморатова да катнашты.


## КОМПОЗИТОРЛАРЫБЫЗ КОНЦЕРТЛАРЫ

СССР композиторлары союзының IV съездына әзерлек барган көннәрдә (1966 елның 7 декабреннан 12 декабрена кадәр) Татарстан композиторлары союзы идарәсе татар композиторларының яңа әсәрләреннән төзелгән концертлар үткәрде. Консерваториянең актлар залында һәм Казандагы махсус музыка мәктәбендә үткәрелгән ул концертларга Алмаз Монасыпов, Анатолий Луппов, Илдус Якупов, Бату Мулюков, Борис Трубин һәм Нәжип Жиһановларның симфоник музыка әсәрләре; Рөстәм Яхин, Аллаһияр Вәлиуллин, Әнвәр Бакиров, Алмаз Монасыпов, Брам Юсфин, Альберт Леман, Александр Ключарев, Фасиль Әхмәтов, Жәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Хөснул Вәлиуллин, Мансур Мозаффаровларның вокал-инструменталь әсәрләре тыңланды. Соңыннан концертларда тыңланган әсәрләр буенча иҗади дискуссия үткәрелде.

# СОЛДАТ ТУРЫНДА ҖЫР

З. ХӘБИБУЛЛИН музыкасы

КАВИ ЛАТЫЙП сүзләре




Җиз йөгәнле кашка атың
Булды синең канатың.
Атың белән үттең, егет,
Мәскәү — Берлин арасын.

Күз алдыма син киләсең,
Күрсәм кашка атларны.
Искә төшә яшь тай сыман
Уйнап йөргән чакларың.

Син кулыңда кылычыңны
Яшен төсле уйнаттың.
Ут-сулардан алып чыкты
Сине сөекле атың.

Җыр шинелле яңгырады
Исемең җиңү юлында.
Атың кайтты, үзең калдың
Ятып сугыш кырында...

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210